КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Булат ИБРАҺИМ. Кем чоры бу... *Шигырьләр.* 3
Рифә РАХМАН. Татар кызы. *Роман.* 8
Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН. Үткән еллар кайтавазы. *Шигырьләр.* 56
Вакыйф НУРИЕВ. Казаннан – мияу. *Хикәя.* 60
Рифат ҖАМАЛ. Чәчәктә булсам да күзләрен... *Шигырьләр.* 66

ЯҢА ИСЕМНӘР

Илшат БИЛАЛОВ. Мәдинә тавы. *Повесть.* 70

«КАЗАН УТЛАРЫ»НЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП

Ренат ХАРИС. Әдәби хәрәкәт үзәгендә. 122
«Казан утлары – минем язмышымда: Факил САФИН. Юнәлеш бирүче басма. 127

«АҺ, ТУГАН КАУМЕМ ГАЗИЗ!» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Сәмига СӘҮБАНОВА. Әткәм чыбыркысы. *Хикәя.* 129

ЮБИЛЕЙЛАР

Вахит ИМАМОВ. Чатыр таудан дөнья шәп күренә. *(Марсель Галиевкә 75 яшь).* 145
Фотоархив: Марсель Галиевнең тормыш мизгелләре. 152
Гөлфия ГАЙНУЛЛИНА. Үзгә дөнья сурәте *(Нәбирә Гыйматдиновага 65 яшь).* 154
Юбилейга барышлый: фотоархив. 158
Якутлар табыладыр вакыт белән: «Мәхәббәттә кайчак ялгызлар без...». *Хатларны Гөлнур САФИУЛЛИНА укыды.* 160
Кардәш халыклар әдәбияты: Әкбәр ГОШАЛЫ. Һәр авоздан да сүз ясап булмас. *Шигырьләр. (азәрбайҗан теленнән Рифат СӘЛАХ тәрҗемәләре).* 176

ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР

Туган якка уза кош юллары... *(Саҗидә Сөләйманованың тууына 95 ел).* 179
Тузга язган сүзләр генә калды *(Мөдәррис Әгъләмовның тууына 75 ел). Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара.* 180
Җанисәп – 2021: Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. 1917 елгы инкыйлабка кадәр җанисәпләр: йомгак урынына. 181
Шаян сәхифә: Зимфира ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА. Уены-чыны бергә. 188
«Казан утлары» архивыннан. 159
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. 190

КАЗАН УТЛАРЫ
№ 10 (1188) 2021

БАШ МӨХӘРРИР –
Рөстәм Госман улы ГАЛИУЛЛИН

ИДАРӘ:
Ирада Әюпова
Разил Вәлиев
Рәдиф Гаташ
Искәндәр Гыйләҗев
Айрат Зарипов
Дания Заһидуллина
Ркаил Зәйдулла
Илгиз Зәйниев
Илфак Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Газинур Морат
Рүзәл Мөхәммәтшин
Айдар Сәлимгәрәев
Равил Фәйзуллин
Илсур Һадиуллин
Данис Шакиров
Ленар Шәех

Баш мөхәррир урынбасары: **Вакыйф Нуриев.**
Җаваплы сәркатип: **Ландыш Әбүдәрова.**
Бүлек мөхәррирләре: **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан, Рамил Ханнанов.**
Мөхәррирләр: **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Илгизә Сабирова.**
Сайт мөхәррире: **Ләйсән Зарипова.**
Исәп-хисап бүлеге: **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
Машина йөртүче: **Наил Кадыйров.**

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1617).
Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).
Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).
Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266), касса – 222-09-84 (өст.1874).
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмахананең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.09.2021, график буенча 29.09.2021, басылып чыгу вакыты 04.10.2021.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^1/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Е-3915. Тираж 8986.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2021 ел

Булат
Ибраһим

КЕМ ЧОРЫ БУ...

Утырып сөйләшик әле бер...

Бу заман шулкадәр тизләнде,
Үзгәрде яшәүнең мәгънәсе.
Әйдәле шушында тукталыйк,
Тукталыйк һәм бераз көч алыйк.
Каядыр ашыгу, ашкыну,
Нигә соң? Кайда соң? Белгән юк.
Беләсең, без инде күптәннән,
Ихластан шатланып көлгән юк.
Югыйсә дөньясы бер көлке,
Көлеп ят мәгънәсез сүзләрдән.
Күрешәбез дә кебек үзебез,
Сөйләшкән генә юк күптәннән.
Югыйсә сөйләшер әйберләр
Бихисап бу салкын шәһәрдә.
Тик нигә? Нигә соң әле дә:
«Иртәгә, әйдәле иртәгә»...
Әйдәле, барысын ташлыйк та
Сикерик туктамас арбадан.
Нилеккә бу синең шөһрәтең?
Нилеккә бу сиңа ялган дан?
Нигә бу якалы күлмәкләр,
Нигә бу ялт(ы)равык савытлар?
Шул арба көпчәге астында
Тузанга күмелеп җан бирә
Кабатлап булмаслык вакытлар.
Утырып сөйләшик әле бер,
Утырып сөйләшик...

Булат ИБРАҺИМ (1990) – *шагыйрь, Муса Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты; «Балык теле», «Шагыйрь/Поэт», «Утырып сөйләшик әле бер» исемле китаплар авторы. Казанда яши.*

Казаннан Тукай китә!

(Була язып калган хәл)

Шар ярып, Печән базарын гәҗит сатучы малай
Гөжләтте бүген иртәдән, әйтерсең лә сипте май.

«Тукаев китә Казаннан!» – «Әл-ислах»тан укыгыз!
Казанны ташлап, Кырлайга китә шагыйрь улыбыз.

Казанны ташлап, Кырлайга? Ялгандыр бу, сафсата!
Кеше Казан диеп шаша, бу – Казаннан баш тарта?

Сәгъди абзый янынадыр, кунакка кайтуыдыр.
Туйгандыр инде Казаннан, ял итеп алуыдыр.

Шулай вакыт-вакыт кайчак газиз туган көннәрен
Читкә чыгып уздырырга, беләм, гадәт кергәнен.

Үз теләге белән түгел, кушканнар, ди, түрәләр.
Тукаев артыгын язган, шуңа аны сөрәләр.

Юк ла, үзе теләп китә. «Тарайды Казан», – дигән.
«Эттән күбәйде дошманым, акылдан язам», – дигән.

Барып кына кайта икән, күрешәсе кешегә.
Төштән соң пар атлар җигеп, кайтам дигән кире дә.

«Монда безнең бабайларның түре, почмагы», – дигән,
«Монда дәртле күңелемнең хуры, оҗмахы», – дигән...

Сату көне сүнеп бара, кояш сүрелә күктә.
Колакта һаман шул тавыш: «Казаннан Тукай китә!»

Әйт, телем...

«Син безгә нигә, әйт әле?» диючеләргә җавап,
Әйт шуларга, туган телем, сорамасыннар кабат.

Әйт шуларга, тыйнакланма, тыелып беттең инде,
Кеше көен көйли-көйли кыелып беттең инде.

Әйт, телем, шартлатып сөйлә, йоклаганнар сискәнсен.
Алай иртә күммәсеннәр, гайрәтең бар, исән син.

Син сәүдәләр йөрткән тел бит, тарих, ярлыклар язган.
Теленнән ваз кичүчегә надан дигән сүз таман.

Син догалар кылучы тел – Аллаһны зурлаган тел.
Син, яуларда җиңү яулап, тынычлык сораган тел.

Башларын чайкап утырсын телсезләр, томаналар.
Телләрен җуйган халыклар бер заман югалалар.

Бер заман югалалар шул, ә югалгач, табылмас.
Менә инде ул чакларда тешләргә тел дә булмас.

Шул тел белән үз ипиен табып, баеп беткәчтен,
«Нигә миңа бу тел» диеп, оран салып йөргәчтен,

Ана телен ят иткәннәр ят итмәсме анасын?
Мин шикләнәм, бик шикләнәм, Раббым үзе сакласын.

«Син безгә нигә, әйт әле?!» диючеләргә җавап:
Телең барында телеңне кадерлә, кардәш, ярат.

***

Кем чоры бу,
Кемнең көен суза гавам?
Катлы-катлы битлек киеп,
Йөзен җуйды хәзер адәм.
Нәрсә кыйммәт:
Җанмы, малмы?
Хәерчене күрә алмый ярлы,
Җене сөйми аның байны.
Айный алмый ята заман,
Еллар буе эчеп ялган.
Кем арбасы – шуның җыры,
Акчаң булса – көнең җылы.
Матур сүзләр үсә шаулап,
Мәйданнарда ирек даулап
Йөргән буын бара көзгә,
Көн авыша хәзер төнгә.
Арттан гына пычак кайрап,
Дус дигәнең, мизгел сайлап,
Упкыннарга этәр сине.
«Иң якын дус» дияр сине,
Амин тотып җеназаңда.
Исемлеккә куеп тамга,
Салып куяр битлекләрен,
Читкә куеп этлекләрен,
Киеп ап-ак күлмәкләрен,
Өмет баглап якты язга...
Кем чоры бу,
Кемнең көен суза гавам?
Катлы-катлы битлек киеп,
Йөзен җуйды хәзер адәм.

Акча сөйләгәндә, хаклык дәшми

Акча сөйләгәндә хаклык дәшми,
Халык һаман күзен йомып яши.
Тешен кысып йөри бирә һаулап,
Көнне төнгә, очны очка ялгап.
Төп башына утырып гомер итә,
Җае чыккан чакта шөкер итә.
Куәт булган чакта алдый, үзе,
Вакыт җиткәч, сөйли «намус» сүзе.
Акча сөйләгәндә хаклык дәшми,
Көч булганда җирдә яшьлек яшьни.
Картаелгач килеп куна үпкә,
Күңел тула вак-төяккә, чүпкә.
Хаклык шулай китеп бара бер көн,
Учак сүнә, күкне каплый төтен.
Ә тәртәгә килеп керә балаң,
Һәм башлана бу җыр өр-яңадан.

***

Ел саен Казан урамнарын су баса

Нух пәйгамбәр хәстәрләнеп йөргән алдан,
Фәлән елда шундый яңгыр яуган.
Ә югыйсә, һәр ел саен шундый ук хәл:
Безнең өскә ишеп ява ялган.

Вакыт узган бераз, заманасы башка:
Пәйгамбәрләр саны чиктән ашкан.
Оран салып йөрүче юк батабыз дип,
Эт койрыкка сылтый, муен – башка.

«Заманадан калмаска» дип ашыгалар,
Беренчелек өчен ярышалар.
Кичә яңгыр явып узды башкалада,
Җәйрәп ята суда машиналар.

Кошчык

М.Җәлил һәм аның көрәштәшләренә багышлап

Өмет өзми язлар, җәйләр буе,
Килеп кунып шушы коймага,
Өзелепләр сайрый моңлы кошчык,
Җанын белми кая куярга.

Чәнечкеле тимер чыбык тузган,
Таралышкан кургаш болытлар.
Ач бүреләр, исерек майорлар юк –
Гүя барысын да җир йоткан.

Кайда шагыйрь, нигә чыкмый инде?
«Сугыш бетте» диләр үзләре.
Эх, күрәсе килә тагын бер кат
«Илем» диеп янган күзләрен.

Ишегендә һаман йозак микән?
Богаудамы аяк-куллары?
Минем җырлаганны тыңларга дип,
Шагыйрь бүген тагын чыкмады.

Мин аңардан отып калган идем
Шушы моңлы көйне, сагышны.
Йөрәгемдә һаман яши шул җыр,
Кайтавазы булып сугышның.

Көн сүрелә, сайравыннан туктап,
Кошчык очты өзми өметен.
Ул гасырлар буе сагынып сайрар
Халкыбызның батыр егетен.

Өшегән алмалар

Алмагачлар ышанмыйлар кыш киләсенә,
Алданганнар мескенкәйләр көз иртәсенә.
Көз иртәсе нурлар белән сыйпап назлаган,
Карлар быел яумас диеп, явыз алдаган.

Эх, самими алмагачлар, шулай ышанып,
Йә туңып үләсең җирдә, йә инде янып.

Дәшти-кыпчак кайтавазы

(Җыр[1])

Бу җил нигә улый,
Нигә елый, яңгыр булып,
Гавам моңы?
Күңелләргә үтә
Тамчы белән
Тарих угы.

Кушымта:
Дәшти-кыпчак кайтавазы,
Дала исе килә.
Эх, яшисе килә минем,
Минем өстә минем күгем,
Эх, яшисе килә бүген,
Эх, яшисе килә...

[1] Радик Сәлимов музыкасы.

Җир-анабыз күпер сузган яктылыкка,
Бу һаваны минем өчен, минем өчен сула.

Шаулы диңгез дулкыннары
Ярга бәрә,
Үткәннәрне алып килә.
Киләчәкне кемнәр белә?
Акчарлаклар гүя бүген
Миннән көлә...

Ярда калган яраларны кысып бәйлә әйдә.
Мин теләмим әрнүләрнең
Ычкынуын бәйдән.

Болытларны ярып,
Кояш чыга күккә,
Үз илемдә кояш туа.
Минем күңел туган җирдә,
Тугач җиргә,
Күңел шунда кала.
Чиксез төрки дала...

Татар, алга!

(Җыр[2])

Караңгы төсләрне тарата,
Офыкта кызарып таң ата.
Йоклама, татарым, сагына Ватаның.
Без монда чит түгел, бу җирдә.
Торып чык йокыңнан, тор, әйдә.
Чакыра безне таң,
Татарым, тор, әйдә!

Кушымта:
Ярсу йөрәк безнең тәндә,
Чиксез куәт безнең җанда.
Тарих ага безнең канда
Татар, алга, алга, алга!

Кояшның батырлык нурлары –
Татарның тарихи юллары!
Без суда һәм җилдә, без исән бу җирдә!
Без монда чит түгел, бу җирдә,
Әләмең тибрәлсен күкләрдә.
Чакыра киләчәк,
Татарым, тор, әйдә!

[2] Артур Исламов музыкасы.

Рифә
Рахман

ТАТАР КЫЗЫ

РОМАН*

Өченче бүлек

**Син – тирәктер, ә мин – тал,
Сөя алсаң, сөеп кал.**

1

Зәмниханың ябь-яшь килеш яңа төшкән йортында солдат хатыны булып яшәп калачагы уена да кереп чыкмаган иде: ире сугышка башыннан ук эләкте.

Китәргә хәзерләнеп йөргән көннәренең берендә Әхмәтгалимнең үзе белән солдат хезмәтенә алынасы яшьтәше аларда иде. Сүз исән кайту, сугышта яраланулар тирәсендә бөтерелә башлагач, ул, Зәмниха белән Җиһан апасының күңелләрен күтәрмәкче булып, сүзне уенга борып маташты:

– Тапкансыз кайгырыр нәрсә, плингә төшәрбез дә мимеч[1] ризыгы ашап, бүксә симертеп ятарбыз.

Әллә никрутның[2] шаяртып әйткәннәре фәрештәләрнең амин дигәненә туры килде, төньяк-көнбатыш фронтка эләккән Әхмәтгалим сугышның башында, иң кызган чагында әсирлеккә төште. Ул килеп эләккән җир төрле бараклардан торган Вюнсдорф лагере иде. Татарның күплеген, динилеген күрепме, лагерьда, озак та үтмәстән, зур гөмбәзле, биек манаралы мәчет төзеп куйдылар. Театр, китапханә инде бар иде. Боларга Галим шаккатты.

Тоткынлыкта вакытта Әхмәтгалим, сугышның ниндиенә ялгыз баштан керсә дә, урыслар җиңеләчәк икән әле, дип уйлады. Бергәләп сугышса да, башка илләрдән хәле хөртирәк иде аның. Армиядә һәр нигә кысынкылык, тәртип юк, солдатка хөрмәт юк. Көмеш кашык белән яхшы тәлинкәләрдән ашаган, шикәр салып, чәй-каһвә эчкән алман сугышчысының ризыгы рус солдатының ике ятып бер төшенә керми. Әгәр рус армиясе мондый зур сугышларга әзер булса, кеп-кечкенә Германиянең һөҗүменә каршы тора алмас, миллионлап солдатын тере килеш аның кулына тоттырыр идемени? Ел дигәндә, никадәр җирен югалтты Рәсәй. Туган якларында да шул турыда, илнең киләчәге хакында сөйләшәләрме-юкмы – белми, боларны ачыктан-

[1] Мимеч – немец.
[2] Никрут – рекрут.

* Журнал варианты.

Дәвамы. Башы узган санда.

ачык язарга шүрли, әмма дә ләкин, минем өчен борчылып ятмагыз, монда барысы да яхшы, тамак тук, өс бөтен дип, хат салган һәм шуңа җавап көтә иде Әхмәтгалим.

Көткәндә, һәр сәгатең, минутың озыная. Көтәр түземлеге калмаганда, Зәмнихадан хәрефләре битләренә җем-җем тезелгән җавап килеп ирешә. Әсирлектәге Шүләнгер кешесенең, ашарына җитмәүгә түзә алмыйча, киптергән җиләк белән чикләвек булса да салыгыз, посылкага рөхсәт бар, дигән хаты килгәнлекне язган иде ул. Артыннан ук, тамагың туярлык ашаталармы, авырткан, гарипләнгән җирең юкмы, бик сагынмыйсыңмы дип, иренең сорауларына җавап бирүдән битәр, үзе сорау яудырган булып чыкты. Әхмәтгалимгә немец ягы ризыкка кыенлык кичерә башлаган, әсирләргә туганнарыннан ризык соратырга ярый, әмма ач икәнлекләрен язу тыела, дигән сүзләр ишетелгән иде. Гарәп язуын кем укып торган, татарчаны кайсы юньләп аңлаган, тикшергән, ач мин, дип язса да язгандыр, дип уйлады.

Алманча яхшы гына пупалаганын[3] күргәч, Әхмәтгалимне баракта озак тотмадылар – зур җир биләүчегә анда ук яшәү шарты белән хезмәткә җибәрделәр. Ул яңарак кына лагерь лавкаларының берсендә агачтан ясаган әйберләрен, күлмәк эштән алып кайткан ризыкларын саттыра башлаган иде, монысына бөтенләй сөенде. Болай да алдынгы илләр тормышын барып күрәсе, алманнардан эшкә өйрәнәсе, техникалары белән танышасы килгән иде аның.

Урнашкан йортының китапханәсе бай иде, авыр кыр эшеннән бушаганда, агротехникага кагылышлы китаплар укыды, үзе өчен яңа игү алымнарын кырда сынап карады Әхмәтгалим. Хуҗалар урыс саналган татар тоткынының тел белүенә дә, эшкә кулы ятуына да, әдәбенә дә, динилегенә дә таң калды. Солыхка кул куелып, сугыш тәмамлангач, Әхмәтгалим белән елый-елый хушлаштылар, монда кал, яшь хатын алырсың, теләсәң, үзебездә торырсың дип үгетләделәр – каласы итмәде, Зәмнихасын, балаларын сагынганын әйтте. Берничек җаен таба алмагач, аларны да үзеңә алдыра аласың, дип тә карадылар.

– Туган җирне монда алып килеп булмый шул, – диде.

Әхмәтгалимне хуҗалары шыплап әйбер тутырган ике зур чемодан белән озатты. Монда барометр да, яшелчә орлыклары да, эш кораллары да, тукыма-сабын ише нәрсәләр дә, үзе укыган кайбер китаплар да бар иде. Әхмәтгалим, шуларны күтәреп, ноябрьнең егермеләренә Өскебашка кайтып та төште.

Зәмниха шәп киемнәрдә – өстенә сукно пальто, фетр эшләпә, аягына кара күн ботинка кигән, муенына шарф ураган иренә тартым адәмне тәрәзә пәрдәләрен тартып торганда күреп алды. Үз-үзенә ышанмыйча, тагын да ныклабрак карады. Пар нарат яныннан узып, өйләренә якынлашучы ир-атның кемлеген чын-чынлап аңлау белән җаны табан астына төшеп киткәндәй булды. Үзен кулга алырга тырышты. Киң итеп сулады да:

– Әхмәтгалим! Исән! – дип кычкырып, җан-фәрманга каршы алырга йөгерде. – Әнкәй! Балалар! Әхмәтгалимем кайткан!

Зәмниханың чәрилгән тавышын йорттагы бар кеше ишеткән һәм артыннан ук урамга сибелгән иде. Сөенәсе, көлешәсе урынга,

[3] Пупалаганын – сөйләштергәләгәнен.

Шәмгыйҗиһан карчык еларга тотынды, аңа, берни аңламастан, балалар да кушылды. Зәмниха гына, Әхмәтгалимне беренче күргәндәге шикелле, каршысында җемәеп көлеп, кочакка алганнарын көткәндәй басып тора иде.

Барысы белән кочаклашып-күрешеп чыккач та, Әхмәтгалим тиз генә өенә кермәде. Йорт белән капка арасындагы утыргычка утырды да Ямьбикә белән Әхмәтгалиен ике ягына алды:

– Их, үскәнегезне дә күрми калдым, сез инде нинди дәү икән!

– Мин ападан да дәүрәк! – дип, Әхмәтгали кулларын югары күтәреп күрсәтте.

– Дәү инде, дәү! – дигән булды Ямьбикә. – Миңа – җиде, сиңа – дүрт.

Әхмәтгалим кызына юри генә әйткәнен аңлатып күз кысып алды да:

– Улым, яшең генә кечкенә синең, үзең бөтен малайлардан да дәү! – диде. Аннан кесәсеннән чыгарып, икесенә дә этәч кәнфит тоттырды.

– Мин моның кәгазен үземдә калдырам, – диде Ямьбикә. – Чәчүргечләр тартмасына салып куям.

– Мин эти бирәсе кәнфит кәгазьләрен кесәгә җыям, – диде малай, уйлап тапканына үзе дә канәгатьләнеп. Балаларының нык үзгәргәнен, сүзгә остара барганнарын, аны бөтенләй ятсынмаганнарын күрү Әхмәтгалимгә күңелле иде. Икесен дә үзенә тартып, җилкәләреннән кысып алды.

– Әтәй, авырттырасың бит! – дигән булды кызчык.

– Минеке бер дә авыртмый! Мин дәү инде! – дип кабатлады малай.

Икесенә дә нәрсә белән дә булса мактанырга кирәк иде.

– Мин күп итеп җиләк җыя беләм! – дип куйды Ямьбикә. – Савыт-саба юам. Синең чабатаңны да әйбәтләп бәйләп бирә алам.

Әхмәтгалимнәр өенә гомер чабата кергәне юк иде. Балаларның аягына игътибар да итмәгән икән – икесе дә чабатадан утыра! Авыр булып китте. Алай да Туган ягың туган ягың инде. Хәерчеләр, ялангачлар иле булса да, үзеңнеке, дип уйлады әсирлектән котылуына, зур бүләкләр алып кайтып, барысын да шатландырасына, балалары исәнлеккә, урталарында утырганына сөенгән ир.

Ул да булмады, Шәмгыйҗиһан карчык, алъяпкыч почмакларына яшьләрен сөртә-сөртә, өстәл хәзерләргә кереп китте. Энесе әйберләрен күтәреп алды да баскыч төбенә илтте. Зәмниха, Галименең кайтканлыгыннан хәбәр салырга дип, туганнарына йөгерде. Ул да булмады, җизнәсе белән Ләмига апасының, Җәмигаттиләренең, Хөсәен балаларының, тагын әллә кемнәрнең Түбән урамга йөгергәне күренде. Айбану апасы гына һаман юк иде.

– Теге көнге кебек тагын солдатлар куып йөри мәллә? – дип көлде Әхмәткәрим. – Аннан булыр.

– Нәрсә булыр? – дип сорады Әхмәтгалим.

– Авыл аша солдатлар тезелеп уза икән. Алгай ягыннан килеп, бездән соңгы тыкрыкка җиткәч, урманга борылган болар. Айбану апа соңгы солдатның арт ягын авылны чыкканчы көянтә белән каезлаган. Әле аннан соң да артларыннан китмәкче икән дә, берсе иптәшен кызганган, куркытыр өченме, тоткан да төбәми-нитми генә, апа ягына аткан. Тиюен тимәгән.

– Вәт шәп иткән! – дип көлде Әхмәтгалим.

– Апа кайтыр якка борылган да артын каплый-каплый йөгерә, ди.

– Монда һаман төрле-мөрле хәлләр җитәрлек икән. Авыл кешесе шуның

белән үз күңелен күреп, кәефен күтәреп яшидер инде, – дигән булды Әхмәтгалим. Сүзне шулай йомгаклаганда гына, ухылдап-пухылдап, Айбану апасы килеп җитте:

– Әллә мин генә юк инде монда?

Аны бөтенләй ишетмәгән кебек:

– Апа, көянтәң атамы әле? – дип шаяртты Әхмәткәрим. – Өйгә тагын бер солдат кайткан, киеме генә кешенеке төсле – мимычныкы.

– Кемнәр иде соң ул? – дип сорады Әхмәтгалим Айбану апасыннан. – Кызылларммы, акларммы?

– Аны каян беләсең: әле берсе керә, әле икенчесе. Бала-чага куркытып, авыл аша йөриләр. Мин куып җибәргәч, бер дә узганнары юк.

– Шәп иткәнсең алайса.

– Шәбен шәп... Юарга салгач, күлмәк итәген карасам, арт турысы тишек. Тидергәннәр икән бит миңа тәки. Әле дә ярый исән калганмын.

Айбану борылды. Чыннан да, күлмәгендә зур гына ямау тора. Әллә ату белән атмауны аермаслык беркатлы инде апалары, әллә кызык ясап сөйли. Шулайдыр. Әхмәтгалим әсирлектә, әрсезрәк, тотнаксызрак санаса да, укымышлылыклары аркасында үзенекеләрдән алгарак куйган алман кызларын исенә төшерде. Аларга биргесез бит кыюлыкта Айбану апасы!

Көннең үткәне сизелмәде дә. Туганнар таралышты. Урыннар җәелде. Әхмәтгалим ак келәтнең киң сәкесендәге мамык ястыкларга, хатыны кочагына чумды. Ул Зәмнихасына төне буе чит җирләрдә күргәннәрен сөйләп чыкты. Боларны, бүгенге хәлләрне һич кенә дә башы аша уздыра алмаган хатын, ире сөйләгәндә, синме соң бу дигәндәй, әле теге төшен, әле бу төшен тотып-тотып карады. Аннан үз ире икәнлегенә шиге калмагандай, кочагына ныклап ук елышты.

Әкренләп көннәр, эшләр элекке агымына керде. Зәмнихага алда гомер гел шулай узар кебек иде. Гражданнар сугышы да тәмамланып, Әхмәтхәсән балалары, яңадан тәмам аякка бастык кына дигәндә, Әхмәтгалим тагын хәсрәтле уйлар белән кайтып керде. Гадәтенчә, күрешеп бераз тын алуга, дөнья хәлләрен сөйләргә тотынды.

– Тормышның кайларга таба китәсен беркем белми хәзер, – дип башлады ул сүзен.– Шунысы хак: байларга көн тәмам бетәчәк. Андый вакытта баймы син – юкмы, исләре китеп тормас. Барысының кеше хисабына юнәнеп каласы, ачының ашыйсы килер.

– Сугыштан соң хәерче азды шул авылда, – дип кушылды аңа Зәмниха.

– Әйе. Аларның ашарына да югында ике катлы пулатларың белән байлар исемлегенә керәсең дә керәсең...

Әхмәтгалим кайчандыр патша кадәр патшаны төшерәселәренә, крестьянга көн киләсен сөйләгәндә, бер дә ышанмаган, әмма каршы да төшмәгән иде Зәмниха. Бары да ире әйткәнчә булды. Хәзер ышанды. Әхмәтгалименең урыс-урагай арасында да, Казан байлары-муллалары эчендә дә белешләре күп иде, сөйләшкәннәрдер, кисәтеп куйганнардыр, дип уйлады.

– Зәмнихакаем, көч түгеп җыйган байлыкларыбызның берсе дә калмаячак. Тиз арада сүтеп, кайсын кисеп, кайсын болай гына су буендагы мунча янына төшереп өяргә кирәк,– дип дәвам итте Әхмәтгалим.

– Балалар үсеп килә. Кызларга аерым бүлмә кирәк, – дигән булды үзе ияләшкән тормыштан аерыласы килмәгән Зәмниха.

– Сыярбыз! – диде Галим. – Башкалар мунча кадәр йортта да ничәшәрләп яши. Безнең бер каты да алты почмаклы. Җәйгә ак келәте, чиннеге бар.

Әхмәтгалимнең ныклы карарга килгәнлеге, барысын да уйлап, аңа әйткәнче үк хәл иткәнлеге әллә кайдан күренеп тора иде. Күптән түгел әнисен югалткан, шуның хәсрәтеннән дә әле айнып бетмәгән ирен борчыйсы килмәде, кайвакыттагыча фикерен үзгәртергә маташмады Зәмниха.

– Их, әтәй-әнәй исән булса, – дип кенә куйды. – Менә кайда кирәк аларның киңәше.

– Инде үзебез – әти-әни, кече туганнарга киңәш бирерлек яшьтә.

– Әхмәткәримне шуннан йорт салып башка чыгарсак була. Абыйларның йорт-җире безнекедәй шәп түгел. Бер өлешен аларга бирик.

– Башкаларныкы янында абыйларныкы да, апаларныкы да зур ул, карчык. Ярлы-ябагай алга таба уртакка көн итмәкче. Үзләренеке булмагач, хәллерәк тормышлыларның барысыннан нидер каерырга тырышачаклар.

– Бар көчеңне куеп, тырышлыгың белән тырмашып яшә дә... Нинди бай инде без?! – диде Зәмниха, ә бит кияүгә чыкканда, каенаталарының мул тормышына шаккаткан иде.

...Инде менә Әхмәтхәсән абзыйның тырышлык куеп салган бөтен каралтысы бер катлыга әйләнде дә куйды. Түбәсенең яңа гына буялган кызыл калайларын – абзар түбәләреннән төшерелгән тактага, абзарныкыларны имән кайрыларыныкына алмаштырдылар. Матур күрекле өйнең кыяфәте китте.

– Кешене бөтенләй пошаманга төшердек, – диде Зәмниха. Әхмәтхәсән эткәйләренә килен булып төшкән көннәрдә яшь наратлар төбенә ясап куелган ике кешелек утыргычта күбрәк ятлар ял итә, Әхмәтгалимен дөньяны башкача көтү уе баскан иде, чөнки әле бу, әле теге хәбәрләр Өскебашка көн саен булмаса, ай саен килә иде. Аларның чынга ашуын озак көтәсе булмады – авыл хәллеләренең соңгы байлыгын тартып алырга керештеләр.

Иң элек Ямьбикә кызының каенаталарын урамга чыгарып ташладылар. Авылдашлары, абзар-келәтләрендәге ашлык, сыер-сарык кебек байлыкны гына түгел, кием ише әйберләрен дә, дәррәүләп килеп, сәгать эчендә йолкып-ташып бетерделәр. Ата кеше кызы бусагасына килеп егылыр, шул мәхшәрдә тора алмас дип көткән иде, ялгышты: түзде. Аннан, ире белән бер булып, төп йорттан чыгып, караучысыз күршеләренең чаршау белән бүлеп алынган аш-су почмагында аһ-зарсыз гына яшәп киттеләр. Ә бит бирергә теләмәгән иде Зәмниха Ямьбикәсен Габделкасыймга, бирергә теләмәгән иде. Галимне:

– Ничек туганнар арасында гаилә кору ул? – дип аптыратып бетерде.

– Туганлыкның никахка дин рөхсәт итә торганы, итмәгәне бар, шәригать барысын тыймый, – диде Әхмәтгалим. Алаен алай да ул, эченнән үзе дә кызын совет власте кыйный башлаган Гаделшаныкыларга бирергә кызгана иде. Инде яучы булып, үз туганы килеп кергәч, бөтенләй ачуы чыкты.

– Ярар, ризалашмасаң, барыбер тартып алачак ул синең кызыңны, – диде Айбану, ана белән ата күңеленә шом салып. Бу сүздән соң бирмәде дә бирмәде Әхмәтгалим. Кызына кызыкканнарның күплеген белә, күз тиярлек, башкалар күзе төшәрлек Ямьбикәсен артыгын урамга чыгарып та йөртми, суга киткәндә дә артыннан:

– Алдыңны-артыңны карап атла! – дип әйтеп кала иде.

Ямьбикә әтисенең сүзен тыңлады, капка төбенә килеп сызгырып торганнар янына чыкмады, егетләр күп җирләрдә озак сөйләшеп утырмады, әмма дә ләкин Габделкасыйм ниндидер эш белән килгәч, лапасыгызның урта тирәсендәге такталар арасындагы ярыкны бер кара әле, дигән иде, карады. Карады да шаккатты: шул ярыкка хат кыстырып киткән. Аны урамда соңыннан да күрмәмешкә салышып үтә иде ул, тик ярыктагы хатларга җавап язды. Ел буе вәгъдә биреп килгәннән соң, әтиләр каршы дип, сабый күңелле Касыймның сүзен аяк астына сала, күңелен рәнҗетә алмый иде. Шул кичне үк абзар артын саклаган Айбану апасына ияреп, бакча буйлап инешкә таба йөгерде. Анда Касыйм үзе көтеп тора иде.

Ямьбикәнең аягында күн чүәкләр күреп, күзне әйле-шәйле иткән ай яктысында агымсу аркылысына сирәк куелган ташлардан таймыйча-егылмыйча үтә алыр микән дип шикләнде ул:

– Күтәреп алып чыгыйм мәллә, үзеңнән генә буламы?

Ямьбикә бу сүзләрдән уңайсызланды. Ул җиңел йөрешле, кыр кәҗәсе кебек җитез кыз иде – инешне, таштан-ташка сикереп, бер-ике генә атлады.

– Буең билемнән генә, ярышсак, җиңәсең икән син мине.

Кыз көлде. Яратканы Касыйм белән җитәкләшеп, Сәрбиҗамал туталарына йөгерде. Таң беленер-беленмәстә Әхмәтгалимгә, кызың Гаделшаларда кунды, дигән хәбәр килеп иреште.

– Нинди егет ул, кәлҗемә! – диде Әхмәтгалим. – Кызны кеше шикелле сорап ала да белмәгән!

– Әллә юньләп сораучыга үзең бирергә күнекмәгәнме? – дип каршы төште Айбану. – Барыбер аңа чыга ул, дип әйттем бит югыйсә. Җитмәсә, Галимулла белән бәхәсләшкән булган Касыйм. Ямьбикәне кайсы үзенә ала алмаса, шул авылдан чыгып китәргә тиеш дип килешкәннәр. Сиңа, кызыңны бер күрер өчен, капка төбендә таңгача йоклап утырган җиңел уйлы Галимулла кирәкме, эштән башканы белмәгән Касыйммы?

Әхмәтгалим тегермәннәре булган, тире иләгән, кибет тоткан Йосыф малайларын, бигрәк тә Гаделшаны, улы Касыймны бик ярата, әмма киләчәкләрен уйлап, кызы өчен кайгыра иде.

– Заманның Касыйм кебекләргә якты чырай күрсәтмәгән чагы булмаса! Анысы – бер... Зәмниха да, нигә һаман туган белән алышасыз-барышасыз, ди... Икенче-өченче буыннар гына бит...

– Авыл туганнардан таралган инде ул! – диде дә Айбану чыгып та йөгерде.

Әхмәтхәсән Гаделшаларга баргач, Габделкасыймга Ямьбикәне никах укытып бирергә, шуннан соң язылыштырып та чыгарга дип килешкәннәр иде. Ямьбикә, әйберләрен хәзерләргә дип, әтисенә ияреп, туган йортына кайтып китте. Бирнәсен тәртипкә салып, җитмәгәнен җиткереп, өстәп, шактый вакыт узды. Бу Ямьбикәгә ике өйдәге тормышның нык аерылганлыгын аңларга бик җитте.

Берчакны өшәнчек сандыгын караштырганда:

– Әнәй, шундый байлар иде бит алар, бернәрсәләре калмаган! – дип елады да елады ул. – Байлыкка кызыгып әйтүем дә түгел, авылда иң тырыш кешеләрнең бернәрсәсез диярлек калулары кызганыч.

Ямьбикә шулай дисә дә, аякларында нык тора иде әле Йосыфныкылар. Кыз ягындагы никахка гына канәгатьләнмәделәр, кызыл туен да уздырдылар, мәһәрен дә кызганмадылар. Чын-чынлап кияүләп йөрүләр генә булмады диярлек. Габделкасыйм белән Ямьбикә Гаделшаларга җәяүләп кенә, кыз әйберләреннән кулларына күтәрерлеген генә алып төшеп киттеләр. Сандык, савыт-саба, комган-чиләк ише нәрсәләрне, инде монысына да кызыкмасыннар дигән кебек, караңгыда Әхмәтгалим ат белән илтте.

Өйләнеп кайткач, кызларыннан аерылудан моңсуланган иренә карап:

– Син мине шәп атларда барып алган идең, Галимем! – диде Зәмниха. – Үзгәрсә дә үзгәрә икән тормыш. Бездән дә хәллерәк, бар кеше нәрсәдер өмет итеп карап торган Гаделша иде.

– Баш исәнлеге кирәк, малы табылыр...

– Мәһәрен кире кайтарасы, бирнәсен тагын да арттырасы калган.

– Миннән тормас, – диде Әхмәтгалим, этисенең дә кайчандыр үзенә шулайрак әйткәнен искә төшереп. – Кирәк-яраклары чыкканда бирербез.

Туйдан соң эшле көннәр башлана, алай итәм, болай итәм дип корган планнарың да үзгәреп куя. Яшь килен белән кияүгә авыл советына барырга вакыт тимәде дә тимәде. Ниһаять, ул көн дә килде.

Ямьбикә, өйдән алдарак чыгып, әле һаман хәзерләнеп өлгермәгән, эшнең тегесен бетерүгә, икенчесенә тотынган, язылышырга чыгып китә алмаган Касыймын бераз ашыктырыр өчен, һава сулап, ишегалдында көтәргә булды. Тышта кояшлы, әллә нинди серле яктылык иде. Ишегалдында бөтенләй каралмаган, кичә яуганы ныклап тапталмаган кар ята, түбәләр ак та ак инде.

Койма аркылы урам яктан бөртек яфраксыз калган каен күренеп тора. Төнен җиллерәк булды. Алдагы көндә калын гына итеп сырып алган кардан арынган ботакларына берничә кош килеп кунган. Салкын узмасын дигән кебек бөрешеп утырганнар да, тамчы да кымшанмыйча, аны күзәтәләр сыман.

Нигә күренми соң Касыйм? Эшкә бирелеп, онытып җибәрмәгәндер инде? Туйлардан соң:

– Җаен табып, хәзер үк кереп чыгарбыз, авыл сәвите якында гына, – дигән иде дә ул, һич бушый алмады, гел сузды, дип уйлады. Ташулар туктагач, Өске ярларына ныклап кайткач, никах укытканнар иде алар. Инде кышка да керделәр... Дөрес, Ямьбикә моңа кәефен артык төшермәде. Кайчан булса да Касыйм белән язылышу үзенә күрә бер сөенеч иде аңа.

Ямьбикә яңа яуган кар бөртекләрен тотып уйнагандай итте. Эриләр дә юкка чыгалар, салкын рәхәтлеге барыбер кала. Гомер дә шулай икән ул, һәр көне үтә дә китә, матур истәлекләре күңелдә яши бирә, дип уйлады моңарчы артык зур хәсрәтләр кичермәгән яшь килен. Ул бераз көтте дә, ишегалдында тик кенә торасы килмичә, урамга чыкты. Бакча артыннан авыл советы ягына таба сукмак та бар иде. Карга бата-бата, аннан бармыйм әле, дип уйлады. Кышкы күренешкә хозурланып, ялгызы әкрен генә атлый торырга булды. Иренең кайнарлыгын, чыккач, кулыннан әләктереп, шатыр чабасын белә иде.

Ямьбикә кияүгә киткәндә, иске әйберләрен бөтенләй алмады.

– Безнең дәрәҗәне кодалар янында төшермә, – диде әнисе. – Шаламага калыр. Андый әйбер дә бик кирәк.

Шулай итеп, әз генә киелгән күлмәкләре дә келәт кашагасында эленеп калды Ямьбикәнең. Бүген өстендә – шәл якалы шәп драп пәлтә, аягында –

матур калыпка басылган көяз кызлар итеге, кулында – кәҗә мамыгыннан перчатка. Кәнсәләрдә озак торырга туры килсә, эчтә эссе булып, пәлтәмне салсам дип, әтисе Казаннан алып кайткан өсле-аслы костюм киде.

Берзаман Ямьбикәгә артыннан Касыймның кызу-кызу атлаганы ишетелгәндәй булды. Борылып караса – язгы көн, эсселәгән диярсең, эшкә ярый әле дип ташланмаган иске бишмәтен җилкәсенә салган да тузып беткән киемнәрендә, егетләрчә шәбәеп, күзләрен мут уйнатып, ике атлыйсын бер атлап килә. Башындагы бүреген яшьләрчә кырын салган. Аягына карады – олтанлы, арттан кунычын бераз ярган киез итеген генә эләктергән.

Бай да бай дип, һаман теңкәләрен корыталар, байлар алар кебек буламыни, дип аптырады Ямьбикә. Элек Касыймның болай хәерче кыяфәттә йөргәнен бер дә күргәне юк иде.

– Нигә бу кадәр начар киендең? – дип сорады ул аннан, янына килеп җитәрәк.

– Яхшысы кешедә бит, – диде ире.– Әнигә охшап йомшак мин, әйберләрне алып китәргә килүчеләрдән яшереп тә калдырырга булгандыр.

– Әткәй әнә бер дә йомшак түгел, ул булып ул биреп җибәргән.

– Рәешкә киярлек кием табар идем әле, салдырып калулары бар.

Мондый уй Ямьбикәнең башына да килмәгән. Шәп кыяфәттә күрсәләр, алырлыклары калган икән әле боларның дип, иртәгә үк килеп җитәчәкләр. Ире, өстендәгесен дә салып, кулларына үзе үк тоттырыр. Ялгышмаган Ямьбикә. Озак та үтмәде, Касыйм, бер кешегә әз генә акча бирәсе урынга, кесәсендәге бар булганын калдырган.

– Бик арыган идем. Ул әйтмәде. Мин санап тормаганмын. Кире сорарга кыен инде, син генә барып алырсың, – диде ул, башын кашып.– Ашыгычлыгым галәмәте.

Барып алырсың... Әйтүе җиңел дә бит, кеше биргәнне кемнәндер икенче берәүнең сорап алуы бер дә җиңел булмас... Алай да Ямьбикә карышмады, шул акчаны сорап барырга дип киенгәндә, иренә моның ише хәлләргә сәерсенгәнен дә әйтми калдыра алмады:

– Йосыфныкылар дип, дер куркып торучылар бар тагын.

– Алар бит – бабай, әтәй, абыйлары...

– Йөрәксез дип әйтсәм, мәңге кеше ышанмас.

– Башкасына гайрәт җитәрлек миндә. Әйбер сорарга кыенсынам. Үземнекен дә. Шуңа калган шикелле...

Ямьбикә боларның барысын да, әнисенә хәл белеп баргач, ире алдында ук түкми-чәчми сөйләгән, кызыкка алып, бер көлешкәннәр дә онытканнар иде. Себергә сөрелүчеләрне озатырга дип, капка төбенә чыккан Зәмниханың хәтереннән анысы да, башкалары да бер-бер артлы тезелеп үтә торды. Ул һаман да кереп китмәгән, аптырашып, борчылып, урамда торганнарга тагын бер кат күз йөртеп чыкты – болар барысы да туганнар бит, араларында ярлыраклары да бар, дип уйлады. Андыйларының туганлыгы әллә кайда – борынгыда калган инде. Хәзер менә үз кызының-киявенең маллары белән көн итеп ятучылары да юк түгел... Шулай ямансулап, бер фикерен икенчесенә ялгап утырганда, Югары урамнан, кулларын болгый-болгый атлап, кабаланып-сөртенеп, кияве төшеп килгәнне күрде. Кызу канлы, гаделлекне сөйгән Касыйм ярлыларның бу эшләренә гарьләнгән:

– Әби, кара син боларны! Балаларына кайчак тиенсез дә язу өйрәткәндер, ата-аналарына дога кылгандыр хәлфә. Үзе дә ярымач иде. Хет шуңа кагылмасалар соң! Ичмаса, безнекеләрнең яманны көнләштерерлек маллары бар иде. Менә мин... Төп йорттан сыңар кашык алмадым! Башка чыккач, этәй хәл белергә менде, күреп алды да, безнең итек, дип, аягымнан салдырды. Имеш, булдыклы малай буш урында булдыра. Әни еламсырап сорагач та, берни бирмәде ул. Әле дә ярый Ямьбикә әйберләре безнең белән китте. Читтлардан да берни кызганмаган, бозылып китмәсеннәр дип, үз балаларына кирәктә дә кысмырланган этәйнең бар эшләп җыйганы җыен ачавызга калды!

Әйе, аларның токымнарын тегеләйгә, болайга сүтеп тә күрсәтте замана. Туган-тумачаларының берише таралды. Кайсыларыдыр киттеләр дә, озак та үтмәде, үзләре күздән югалгач, бар нәрсәләре таланган йортларына әйләнеп тә кайттылар. Кайткач, бик үкенделәр, тик яңадан кузгалырлык хәлләре калмаган иде. Үзләре китмәгәннәрне, зар елатып, кире кайтмаслык сөрделәр. Алар менә, безгә язганны кеше күрмәс, дип, туган җирләрендә яшәп калды.

Яше дүрт дистәдән артып киткән Зәмниха Түбән Өскебашка тәмам ияләшкән, авылның үз кешесе булып беткән иде. Дан-дәрәҗәсе көн арты көн артты аның. Кем күрсә, сәламләми үтми, олы юлга чыгучылар да, ераклардан кайтучылар да, сөннәт әбием, кендек әбием, дәва әбием, дип, йә хушлашып, йә нәрсәгә дә булса хәер-фатыйхасын алырга, йә хәл белергә килә иде. Үз балаларына да ул әби дә, әни дә иде. Авырга узган саен, Өскебашны Шүләнгернекеләргә тагын да үрчетәм мин дип, күрше хатыннарына шаярып сөйләргә ярата иде Зәмниха. Бервакыт теленнән Галим янында да ычкынды.

– Алла кушсаңны әйт, – дигән иде аңа җанкисәге шул вакыт. – Әле исән-сау тапкач та, баланың алдагы гомере өчен кайгырасың. Чирләмәсен, бер-бер хәл ясамасын үзенә дип, ут йотасың.

Болай әйтерлегенең сәбәбе дә юк түгел иде. Ул әсирлектән кайтканның икенче елында Хәлимәбикә исемле кызы туды. Шатлыгы эченә сыймады. Бераздан Зәмниханың яңадан көмәнле икәнлеге беленде, тик күрер күзгә сау-сәламәт кыяфәттә дөньяга килгән Рәхимгәрәе бер дә озын гомерле булып чыкмады... Әнисенең яше тамудан туктамаган бишектә абыйсы артыннан ук Маһисорур аваз салды, аның яшәренә дә бераздан өмет сүрелде. Тиз арада тәпиләп киткән, җәен чирәмлектә туп кебек тәгәрәгән, ай йөзле, зур күзле кызчык көтмәгәндә хәле китеп егылды, уйнамаска әйләнде, кызышты-янды. Кызамыкның котырынган чагы иде, Маһисорур да йоктырган булып чыкты. Им-томның кайсы да файда китермәде. Көннәрнең берендә гәүдәсенең эссесенә чыдый алмаган сабый акылын югалтты. Караватында күктән күбәләк тотам дип, кулларын изәп, саташып ятты-ятты да Әхмәтгалимнең бөтен эчләрен айкап ташлады – тынып калды... Шуннан алда гына:

– Хәзер күбәләк тотмый инде ул: ниндидер Гөлсирә, Айсирә әбиләрне күктән үзенә чакыра, – дигән иде, Әхмәтгалимне аптырашта калдырып, сеңлесен ничек юатырга, ни белән алдап тынычландырырга белмәгән Ямьбикә.

Бу исемнәр таныш та, таныш та түгел тоелды Әхмәтгалимгә. Ата кеше кемнәр икәнлеген тәгаен генә хәтеренә төшерә алмады. Әллә соң ике иңендәге фәрештәләрне күрәме кызчыгым, дип куркып та калган иде ул шул чагында.

Инде менә... Шул фәрештәләр белән күккә ашкан...

– Башына бәргән аның, – диде елап шешенеп беткән Зәмниха бу хәлдән югалып калган иренә. – Миендәге кан тамырлары кисәк шартлаганга охшаган.

Әхмәтгалим өлкән кешеләрнең башына гына кан сава дип уйлый иде. Күпне күргән, күпләрне дәвалаган Зәмниха әйткәнгә ышанды. Янына килеп, кызның, эсселектән бераз арынсын дип, әнисе өстеннән япмасын алып ташлаган, җиңсез эчке киемендә газаптан корышкан кебек гәүдәсенә карады: бер ягы – ак, икенче ягы шәмәхәләнеп тора...

Юлы гына бер ачылсын, диләр. Анысы да хак. Маһисорур ташлап китсә дә, йортта бала тавышы тынмады. Егерме тугызда кызы, тагын ике елдан улы туды. Аларга тагын да, элеккедән килгән гадәт буенча, яраткан туганнарының исемен – Рәгыйдә белән Галинур дип куштылар. Галинур – нәселләрендә борынгыдан ук килгән исем булса, Әхмәтгалинекенә ятышса, Рәгыйдәне Айбану апасы иң башта үз кызына биргән иде. Зәмниха, гел кабатламыйк инде дип, килешмәскә тырышып та караган иде, ахыр чиктә ир сүзен сүз итте.

Сугышчан холкы, бераз усаллыгы, булдыклылыгы белән аерылып торган Шүләнгер халкын Әхмәтгалим ярата иде. Үз илләрен, үз йортларын аяк терәп саклый алырлык аларның кайсы да. Кайберәүләр, явызлар алар дип, бик үк өнәп бетерми үзләрен. Явыз дип бәйләнүләренең тарихы ерактан килә. Әле элеккерәк, дин үтә көчле еллардан бер риваять калган. Әллә чын, әллә уйлап чыгарылган, әллә шул як кешесен сөймәүчеләр тараткан. Сөйләүләренә ышансаң, авылның азгын бер ире әллә ничә хатын ала, барыбер нәфсесе басылмый. Көннәрнең берендә авылның яшь, үтә чибәр кызына күзе төшә моның. Кемлеген ныклап сораштыра. Кызның күз атып йөргән егете барлыгын, качып кына очрашуларын белеп ала, алай да муллага бара:

– Фәлән-фәлән кешегә өйләнәм мин, фәтваң[4] нинди?

Хәзрәт:

– Дин дүрттән артыкны тыя, – дип, ризалыгын бирми. Мәчеттән тешен кысып чыгып китә теге. Берсен аерсам, дүртенче генә була, алай ярамасмы, әллә соң мулланы шуңа ризалатыйммы, дип уйласа да, янына кабат барырга базмый. Аптырагач, кызны яучы аша соратып карый, тик ул да, ата-анасы да ризалык бирми, дип кайта. Бу хәл кияү булырга хыялланган ирнең гарьлегенә тия. Үзенекен итә алмагач, тота да кыз турында гайбәт тарата: имеш, тимерче алачыгы янында караңгыда егете белән кочаклашып басып торган.

Кешедән кешегә сүз тарала, ахыр чутта муллага да ирешә. Яшьләрнең дин тыйган әхлаксызлыгы аңа ошамый. Картларны мәчеткә киңәшкә җыя. Боларны нишләтергә, калганнарга ничек гыйбрәт бирергә дип, бергәләп уйлашкач, егет белән кызны алачык янына китертә. Кыз, эшнең ничек бетәсен сизенгәндәй, үксеп елый, олылардан, Аллаһтан кичерү сорый. Егет тешен кысып тик тора. Халыкка кызганыч та кебек, әмма теге явыз адәм шаһитләрне тапкан, мулла җәзага фәтва биргән, мондый бозыкларны яшәтергә ярамый дип, сүзендә нык тора. Бераздан күбесе:

– Дин шулай кушкач... Мулла абзый белми эшләмәс... – ди башлый.

Егеткә тимерче сарае янында кабер казыталар да кыз белән шунда

[4] Фәтва – дини китапларга таянып чыгарылган карар.

төшеп, кочаклашып ятарга кушалар. Кыз ята, егет – юк. Кабер кырында аягын асылындырып утыра.

– Төш-төш, әнә, кочакла, төнлә кочаклашкансыз бит әле, – диюләренә кым-кырыч карыша. Елавына чик-чама юк. Кыз инде өнсез генә дерелди, беркемнән ярдәм булмавын күреп, язмышына буйсынырга уйлый.

Кызына, үзенә кабер казыткан мулла егетне үлемгә мәҗбүрили алмый: еламсырап, һаман чокыр кырында утыра. Аңа эти-әнисе булса да ярдәм итәр кебек тоела. Тегеләй карый, болай, алар күренми. Бу хәлдән куркып калучылар, һаман да ризасызлар табылса да, беркем егет белән кызны ачыктан-ачык якламый, котырган, шашынган төркемне тынычландырмый. Бәлки, егет төшмәгәч, куркыту белән генә беткән дә булыр иде бу эш... Әлеге дә баягы адәм актыгы аның арт ягыннан килә дә таш белән башына бәрә. Бичаракай, аңсызланып, кызы янына килеп төшә.

– Чык! Мин үзем генә! – дип кычкыра кыз. Сөйгәне аны ишетерлек, аңларлык хәлдә булмый. Икесен бергә тере килеш күмәләр...

Бу гыйбрәтле хәл турында дусты Гарәфетдиннән дә ишеткәч, тагын имәнеп киткән, барыбер ышанырга теләмәгән иде Әхмәтгалим:

– Безнең тирәдә мондый нәрсәләр булмас, кара халык эше ул, Урта Шүләнгер – белемле як, борынгы аксөяк токым корган авыл.

– Әллә бөтенләй булган эш тә түгелдер, – диде дусты.– Гыйбрәт өчен генә сөйләнәдер. Башка җирләрдә дә очрыйдыр моның ише хәлләр, кеше җанын алырга әзер юньсезләр, әмма аларның табылмавы яхшы.

– Чын икән, үткәндә калса да, авыл өстендә кара тап ул. Җитмәсә, яман эшеңне дингә сылтау. Зыян салмаган бөҗәкне сытарга да кулым бармый...

Үзе эченнән, хәзер соң кешеләрне ачлы-туклы тормышка калдыру, иленнән куу шул ук тереләй үтерү белән бер түгелмени, дип уйлады, гаепсез юкка чыгарылганнарның инде саны да юктыр.

– Яманлык таралучан, үрчүчән, – дигән иде Зәмниха, еллар узгач бу турыда ничектер сүз яңадан кузгалганда. – Кайчак бик иманлылар да явызлана.

– Авыл ул – бер токым, – диде Әхмәтгалиме, элекке уеннан баш тартмаганлыгын күрсәтеп. – Вәхшилеге дә, яхшылыгы да бер гаиләнеке...

– Анадан ала да туа, кола да. Без менә ничә бала – бер-беребезгә, төс-кыяфәтне искә алмаганда, артыгын охшамаганбыз, – дип сүзен дәвам итте Зәмниха. – Син мине, Зәлиха шундый, Гөлшикәр шундый, дип, аларның тегеләр яки бу гадәтләре өчен битәрли алмыйсың бит. Шүләнгердә дә кешенең төрлесе бар. Галиулласы да, Сәмигулласы да. Мулласы – килгән кеше. Ул фәтва чыгармаса, кем күрәләтә берәүнең газиз баласын тереләй җир астына тыга?

– Бер яман хәл әнә шулай авылга гомерлек кара ягар өчен җиткән, – дип тагын кабатлады Әхмәтгалим.

Зәмниханың болай сөйләнүе юкка түгел. Пырдымсыз, текә Зәлиханың Өскебашында килен булуын баштан ук теләмәгән иде ул. Сеңлесенә Хәмәтдиннең күзе төшкән икән, дигән сүзләр ишетелгәч үк, ахырын уйлап, кәефе кырылды. Бөтен өмете Зәлиханың егетне ошатмавында иде.

Хәмәтдин атна саен Шүләнгергә юл тотса да, бер дәшүдән үзенеке итәр кебек кыланса да, кызны карата алмады. Зәлихага да инеш буенда очраган егет шунда ук ошады, тик сер бирә торганнардан түгел иде. Кыз егетнең

җитез генә эләктергән көянтәсен кире тартып алды да, борын җыерып караганнан соң, кызу-кызу атлап, ябык чишмәгә су алырга кереп китте. Хәмәтдиннең моңа кәефе тәмам төште. Дөпелдәгән йөрәген көчкә тыеп, җәяүләп, Өскебашка кай арада кайтып җиткәнен дә сизмәде.

Зәлиха Хәмәтдин үзсүзлерәк булыр, артыннан туктаусыз йөрер, башкалар кебек сорап йөдәтеп бетерер дип көтте. Алай булып чыкмады. Атасы ягыннан туган тиешле берәү, минеке бул дип, яучы арты яучы җибәреп, тәмам җелеген корыткан иде, үзен атасыннан бер сорау белән чикләнгән Хәмәтдингә үч итеп, шуңа китте дә барды. Ел дигәндә, ике айлык баласын ирендә калдырып, ата-ана йортына кире кайтып та утырды. Нихан карчыкның Габделбасыйр югында әкрен генә:

– Ни булды? Кияү бик әйбәт кеше бит, – диюенә каршы:

– Яратмыйм! – диде дә бетерде.

– Яратмагач, ничә ел кире каккач, пычагыма чыктыңмыни?! – диде ишектән көтмәгәндә килеп кергән, Зәлиханы ишетеп алган Басыйр. – Чыбыркы белән ярсаң да, аз сине. Беренче сораучыга ук көчләп бирәм!

Зәлиха атасының корыланып китүеннән курыкты, каршы дәшмәде, тиз генә ак келәткә чыгып китте дә, сүксәләр, өйдән монда кадәр ишетелеп торыр дип, башаяк төренеп ятты. Тавышланмадылар бугай, берни ишетелмәде. Каенана йортында эштән бик арыган, баладан соң әллә ни рәтләнеп тә җитә алмаган Зәлиха тынычлап йокыга китте дә тәүлек буе келәтеннән чыкмады.

Бу хәлләрне ишеткән Хәмәтдин, озак та үтмәде, яучыга шул ук Бибимәрфуганы юллады. Габделбасыйр агай монысында Зәлихадан сорапнитеп тормады, шунда ук ризалыгын бирде. Кыз моңа эченнән сөенде, әмма кияү куенына кергән көнне, башкача әйтсә, горурлыгы тапталганга санап:

– Әтәй мәҗбүриләмәсә, чыкмый идем мин сиңа, – дип, Хәмәтдингә арты белән борылып ятты.

Хәмәтдин Зәлиханың холкын чамалый башлаган, кешеләрдән дә сораштырган иде, сүзенә карап-нитеп тормады, каерып алды да кызны гәүдәсенә кочты. Иреннән аерылып кайтса, әти-әни каршы төшсә дә, алам мин аны дип, ничәмә-ничә ант эчкән иде ул. Ниһаять, үзенекен итте, әле кайчан гына аккошныкы кебек ак муеннарын суза-суза өстән карарга тырышкан Зәлиха аның кочагына керде. Баласын да янына алдырмакчы иде Хәмәтдин, вакытсыз ана имчәгеннән аерылган кыз тиз арада вафат булган иде.

Бер-берсен дөньядан артык сөйгән кебек кияү белән кәләшнең туйдан соң әле күгәрченнеке, әле этнеке-мәченеке кебек көннәре башланып китте. Каенанасы Мәгъруфә үзләре янында ым да чыгармаган Зәлиха белән Хәмәтдиннең мунча саен ызгышып, бүртенеп кайтуларыннан тәмам туйды, аңламасلармы дип, карты белән үзләре керенгәннән соң, казандагы кайнар суны тамчысына кадәр түкте дә, коедан алып, сап-салкын су тутырды. Аннан туганнарына – Җиһан карчыкларга төшеп китте:

– Әйт әле, җаныкачкаем, килеңне бик мактап сөйлиләр бит, миңа кайлардан гына эләкте бу аждаһа? – диде.

– Аждаһа булса да, үзегезне дә уздырып эшли торганы, – дип көлгән булды Җиһан карчык. – Бар ягы килгән инде синең килеңнең дә, тик менә холкы... Ахырга кадәр торып бетәрләр микән?..

– Әле бездә яшәгән көннәрен бармак белән санарлык, мунча саен пырылдашканнары өйгә кадәр ишетелә.

– Малаең ни ди соң?

– Холкы өчен ярата, имеш, басынкы хатын белән яшәве кызык түгел.

– Кызык эзләп өйләнәләрмени?! – дип аптырады Җиһан карчык. – Өлкәннәр исән чагында булышыр кешең барына сөенеп, гөрләтеп яшисе бит.

– Балалары тугач, сабырланыр әле, – дигән иде Мәгърүфә, үзен дә ышандырырга тырышып. Бер-бер артлы ике бала алып кайтты, кыз чагындагы холкы барыбер үтмәде Зәлиханың. Карты Хөҗҗәт ахырдан:

– Кешенекеннән дә уздырган яратышуларына чыдаша алмый болар! Ярату зур булган башта акылга урын калмый,– дип, балаларының кыланышына кул селтәде.

Зәмниха кода-кодагыйларының хәлен аңласа да, Зәлиха өчен бик борчыла, кеше, ире каршысында алар өчен ояла иде. Әхмәтгалимнең генә бер дә исе китмәде. Байларның бар нәрсәсе тартып алынган заманда моңа кайгырырлыгы юк, аның өчен барыннан да бигрәк Мәгърүфәләр кырына башка чыккан Ямьбикәнең хәле хәл иде. Аталарыннан баш тартканга салынып, төп йорттан чыгып киткәннәренә генә тынычланмадылар, инде үзләре көч-хәл белән җитештерелгәненнән дә куып җибәрделәр. Әйбере яраган колхоздан, әйберсез калгач, үзе дә артыкка калган Габделкасыйм көнен дә, төнен дә, колхозга алсыннар әле, минем бер дә гаебем юк дип, район белән авыл арасын таптарга тотынды.

Берләшүгә үзе каршы иде Әхмәтгалим. Авылда күмәк хуҗалыклар төзелү турында сүз чыккач, беренче әйткәне шул булды:

– Немецлар, күмхуҗлары булмаса да, бик шәп яшиләр әле.

Халык арасында таралган бу сүзе өчен шәп кенә эләгергә дә мөмкин булгандыр, әле дә ярый эшне зурга җибәрмәделәр, чакыртып сораштырдылар да башка алай сөйләнмәскә куштылар.

– Пленнан төрле әйберләр белән кайткансың икән, – диде районнан килгән уполномоченный. – Шуларга карап, һава торышын да әйтә алгач, симәнә орлыкларын да яхшырта алам, дигәнсең, әйдә, колхозга кер дә кыр эшләренә җаваплылыкны үз өстеңә ал.

– Башка бер кеше дә юкмыни соң?

– Юк. Кайдан булсын? Сәвиткә агрономнарның бик кирәк чагы.

– ...

– Әле чүлмәк ясау артеле дә ачарга йөрибез. Анысына да күз-колак булырсың.

Әхмәтгалим теләсә-теләмәсә дә килеште – агротехник булып китте. Килешмәүнең ни белән бетәсен чамалый иде. Шунда ук ашлык сортларын яхшыртыйм дип, тәҗрибәләр дә уздыра башлады. Кыш буе агач тартмаларга орлык чәчеп, шытым тикшерде, чыгышын санарга гадәтләнде. Аларның барысын да чәй кәгазьләре артына елныкын елга Зәмниха язып бара, аннан пөхтәләп, тигезләп сыпырып, тәрәзәләре укалы шкафка иске бер китап эченә тыгып куя иде. Әлеге шкафта Әхмәтгалименең нәсел тамырларын чагылдырган шәҗәрә дәфтәре, Зәмниханың сөннәт исемлеге дә бар. Уртанчы кызының көндәлекләре дә, Гыйлембай белән алышкан хатлары да шунда.

Уналты яшендә, гашыйклыгына чыдый алмыйча, иләсләнеп, авылның иң чибәр егетенә кияүгә барган Хәлимәбикә, Гыйлембайның кайбер гадәтләренә үпкәләп, ай дигәндә, атасы йортына кайтып төште. Эч серен бушаткач, кире дә китмәкче иде, Әхмәтгалим ишекне бикләп үк куйды:

– Беркая бармыйсың! Кемгәдер мыскылларга дип үстергән кызым юк.

Кызының зарыннан гына мондый сүз әйтмәс иде Әхмәтгалим. Бер керүендә каенанасының яшь килен юган савытларның чисталыгын тикшереп торганын күргәч:

– Алар чынаяк кына юа беләләр! – дип, җилтерәтеп алып кайтып та китмәкче иде, Хәлимәбикә тыңламады – ирен бик ярата иде.

– Бу юлы нәрсә булды соң? – дип сорады ул әнисе янында еламсырап торган кызыннан.

– Гыйлем белән кичләтеп, капка төбенә ял итәргә чыккан идек. Миңа бер сүз әйтмичә, кире кереп китте. Яңадан чыгып дәшмәсме дип көттем-көттем дә, чыкмагач, сәбәбен аңламагач, ялгызым керергә кыенсындым, сезгә килдем.

Зәмниха кызының әлеге эшенә ни дияргә белмәде. Ишек катыннан түргә узарга кыенсынып, еламсырап торган Хәлимәбикәгә:

– Бар кер, уналты яшьтә уналты тиенлек акылың булмаса, әнә шул ул, кайтып ата йортына егыласың! – дип кенә әйтте дә абзарга маллар арасына чыгып китте.

Ипи табагына йомырка җыеп йөргән Зәмниха сарыклар аша узганда, итәген чәйнәп калган бәкәйгә:

– Апаңның синеке кадәр дә мие юк икән, мин аны яратам, ул – мине, дип аңгыраеп чыккан иде, иренең яратуы айлык кына булган, ахрысы, – диде. – Атасы чүлмәк артеленә илтеп тыгар әле башын.

Зәмниха ачу беләнрәк шулай дисә дә, Әхмәтгалимнең йомшаклыгын, шулай эшләтмәсен белә. Юкка гына укыттымыни ул Хәлимәбикәсен?! Кукуруз утырту өчен, тирес белән черемәдән чүлмәк ясаргамыни?! Әхмәтгалим шәһәр кызлары кебек иркә, елмаеп кына, кеше сүзен җөпләп кенә торган Хәлимәбикәне бик ярата, җитмәсә, каенанасының бызгылыгын, бар эшен тикшереп, гаебен табарга тырышып торганын күп күргән иде. Чүлмәк артеленә дә тыкмады, үзең дә гаепледер, дип авыр сүз белән дә битәрләмәде, белемле кешеләрнең кирәк чагы дип, яңа ачылган курсларга җибәрде.

Матур тормыш яраткан Хәлимәбикә авылдан китәр дә кире әйләнеп кайтмас дип уйлый иде Зәмниха, ялгышкан. Кайтты. Аннан яңа ачылган детсадта дусты Дөррия белән бергәләп тәрбияче булып урнашты. Озак вакытлар узмады, хатынының кичермәсен аңлаган Гыйлембайның, бәхет эзләп, чит якларга юл тотканы ишетелде. Ул аннан Хәлимәбикәгә, һаман яратуын аңлатып, хатлар язарга, бүләкләр салырга кереште. Кыз җавап бирмәде, бүләкләрен, мыскыл итүемә алыр дип, кире дә җибәрмәде.

Хәлимәбикә кичләрен тик утырмас өчен минем янга кил дип, вакыт-вакыт Гыйлембае салган акчаларга тукымалар, берсеннән-берсе матур чигү җепләре алып кайтты да атасы кабат сатып алган сандыкларга бирнә әйберләре хәзерли башлады. Ирен аерылдым дип кенә онытып бетермәгән, әмма үпкәсе зур иде, яңадан кушылыйк, дигәненә каршы, ни ярар, ни юк дип җавап кайтара алмады. Ашъяулыкларга бизәкләр төшергәндә дә, кулъяулыклар чиккәндә дә, әледән-әле бергә торган көннәре, дус вакытлары

хәтеренә килеп моңаеп куя, әмма бу хисләргә яңарырга, киңәеп китәргә ирек бирми, башкасы – ыграк та яратканы, әтием кебек хатынын кадерли торганы чыгар әле дип өметләнә иде.

Кызының эшеннән, шөгыльдән ямь табуы Зәмниха күңелендәге аңа бәйле борчуларын юкка чыгарды. Үзеңне халык арасында кеше итеп тою өчен булдырган эшең кирәк, күршеләргә, агай-энегә файдалы булуы яхшы дип саный иде ул. Менә аның шифалы куллары никадәр кешене саклап калгандыр, чиста пәкесе йогышлы чирләр котырынган заманда малайларның исәнлеген какшатмауга сәбәп булгандыр.

Зәмниха үзен гел кирәкле кеше итеп тойды. Бала, сугышмы-тынычлыкмы, үстерергә хәлеңнән киләме, юкмы – сорап тормый, туса туа. Ике-өч ел дигәндә, сөннәт исемлегендәге малайларның саны туксан тугызга җитте дә дәфтәрнең ул бите, култамга салынып, бөкләп куелды. Алай да күкрәгендә сөннәтче, шифачы әби йөрәге тибә иде әле Зәмниханың...

Диндарлыгыннан ырым-шырымнарга артык игътибар бирмәгән Зәмниха, сөннәт дигәндә, әллә нәрсә эшләде. Бабасыннан, йөзенче баланы сөннәткә утыртырга ярамый, үлә, дип ишеткәне бар иде, акылы белән шул сүзне кире какса да, күңеле тыңламады, ниндидер зур бер көч аннан сөннәт пәкесен еракка – келәттәге кием-салым салынган сандыкның инде кесәсенә түгел, төбенә үк яшертте.

2

Әле кайчан гына тормышы бик нык булган Әхмәтгалимнең тора-бара хәлләре начарая башлады, маллары кимеде, үзе сызганнан-сызды. Бер гаепсезгә ире төрмәгә утыртылган Ямьбикәне дә, туган-тумачасын да терәшәсе бар иде аның. Оныклары – гел алар өендә, бары – бергә, югы – уртак, әле дә ярый башка балалары ярдәменә мохтаҗ түгел, инде үзе аларга таяна иде.

Әхмәтгалим бервакытта да улларыннан, кызларыннан зарланырлык як тапмады. Һәркайсы бик тырыш булып, кул арасына тиз кереп китте. Сәвит чорында балаларны укыту бигрәк тә кирәк дип саный иде ул, җидене бетерүгә, Әхмәтгалиен Лубян техникумына җибәрде. Артыннан «яхшы укый»дан башка сүз килмәде. Сабакташларыннан аерылып торуына аеруча Зәмниха сөенде. Татарда, баланың яхшысы – атадан, начары – анадан, дигән сүз булганга, өйдән беренчесе чыгып киткәндә, иренең, тәрбияң җитмәде, дип әйтүеннән бик куркып калган иде – тынычланды.

Укып та бетерде, үз якларындагы урманнарның берсенә лесник булып та урнашты Әхмәтгали. Җиләк җыярга, үлән ташырга җай килүенә шатланды соң Зәмниха. Әхмәтгалимнең башында сөенечле уй янында борчулысы да күп иде. Утызынчы елларның ачлыгына, кыерсытылуларга түзә алмаган туганнары бер көнне, алар турысында җыелып, тегесен – сулга, монысын уңга сала торгач, Балхашкамы, шуның тирәсенәме китәргә, дигән карарга килделәр. Андагы тормышны белешеп кайту өчен берәүне, акча җыеп, шул якка җибәрделәр.

Озак та үтмәде, агай-эне тагын киңәшкә тупланды. Балхаштан бер дә яхшы хәбәрләр белән кайтмаган иде Мөхәммәтша.

– Кояшының эссесенә чыдар хәл юк, җире – тозлык, ашы беткән, ашаганнары – балык, – диде.

– Бер дә безнең ризык түгел икән, – диештеләр калганнар. – Сугышта

да, урыс тамагын гына кайгырткандай, лычкылдаган кәбестә ашы белән интектерделәр, туярлык ипи дә бирмәделәр, башка юньле ашны әйткән дә юк.

Татарның яхшы тормышлысы калҗалы иткә, бодай-арыш икмәгенә күнеккән. Заһирныкылар арасында, байларча тормасалар да, сугыш елларында да ачлыкка чын-чынлап тилмергән кеше булмады. Уйлаша торгач, Балхашка бармаска, башка җиргә китәргә дип хәл иттеләр. Үз начарыңнан тагын да яманракка качарсыңмыни, кебегрәк фикер йөрттеләр. Соңгы җыенга алар токымыннан сөйләшергә килүче төп йорт хуҗаларының саны гына да ике дистәдән арткан иде. Балалар-оныклар, киленнәр дә калмаган булып чыкты. Түбән урам Сабантуй урынына әверелде, умарта күчедәй гөжләде.

Иң элек якындагы пуҗымнардан Сәлимҗан абзыйлары, энесе Әхмәткәримнәр кузгалды. Кешеләр күпләп китәсе булгач, каралтыларга бәяләр төште. Сәлимҗаннар яңадан, шәптән төзедек, дип тормый, йортын юк-бар бәягә булса да сатарга риза иде. Йә, үзебез урнашырбыз, йә әйләнеп кайтырсыз әле дип, бер туганнары аңа ашыкмаска кушты. Кешеләр сорап килсә дә, килешкән буенча, өен озак кына бирмичә торды Әхмәтгалим. Инде ул да сатылды, яңа хуҗа табылмаганнарны ятлар урнашудан саклау Зәмниха өстенә төште. Үзенең Ямьбикәсе, әнә, бушка гына кеше өендә яшәп китәргә кыенсынды, яңасын салганчы торып торырга ярар дип, Бурят-Монголиягә китүче берәүнең кечкенә, какшау гына йортын сатып алды да зур көч түгеп рәтләде.

– Авыл бер бетә башласа, тәмам бетә икән, – дип сөйләнгәләп йөри башлады Әхмәтгалим. Яшь чагында ул еракларга китәргә, дөнья күрергә хыяллана иде. Хәзер менә аңа үз иле, үз авылы якын. Якын дип... көннән-көн кысыла авыл кешесе. Җир яратканы да китәргә мәҗбүр аның. Зәмниха белән алар да китәр микәнни?..

– Патшаныкы да яхшы ук булмагандыр. Анысында хет эшләгән кешенең, тырышның тамагы тук иде. Монысы ризыкның авызыңа керергә торганын да тартып ала, – ди иде Әхмәтгалим, хатынына эчен бушатып. – Менә мин колхозда яшелчә үстерүне башлап җибәрдем. Инде Алгайга кадәр – Аю елгасынача – кыяр, кәбестә түтәлләре тезелешкән. Ничек калдырып китәсең?

Элек тегермәнгә дә, елгага да Аюлар килә иде, дип сөйли иде әтисе. Шунда тирәкләр артына качып, кайчак кешеләрне күзәтәләр, имеш. Тегермәннән агып төшкән суда юынганнарын күрүчеләр дә булган. Бигрәк тә балалары коенырга, куышырга ярата икән, тик чумарга гына куркалар, ди.

Сугыш елларында аюлар кабат бераз булса да, үрчеде микән?.. Тегермәнгә килгәннәре дә, урман юлларына чыкканнары да күренми. Әллә беттеләр, әллә киттеләр... Әллә сәвитнекеләр юкка чыгарды. Гаиләсен алар хәленә калдырасы килми Әхмәтгалимнең. Булышчым булыр дип, Ямьбикәсен яшелчә үстерү эшенә билгеләтте ул. Балаларын бикләп калдырып, иртәнге өчкә үк төшеп җитә кызы. Суны инештән алып, кояш чыкканчыга кадәр сибәргә кирәк. Аннан чүп утау, туфрак йомшарту башлана. Яхшы карагач, нәрсә утыртсалар да, мул була, иртә өлгерә, колхозчыларга өеп-өеп китерәләр.

Авыл кешесен яшелчәчелеккә күнектерәсе килә Әхмәтгалимнең. Монда калырлык түгел, без барыбыз китәбез, алмагачлар утыртсак – җитә, әйләнеп кайтуыбызны үсеп көтеп торырлар, колхоз барыбер кирәгеннән дә артыгын тарата бит, диләр. Ипи юк заманда яшелчәнең артыгы буламыни?!

– Алмагачлар үсеп көтәр, диләр икән, кайтырга китүләре алайса. Зимагурлыкка киткән шикелле, – ди Зәмниха. Шулай гына булса икән ул.

Түбән урам тулысынча диярлек китте. Авыл белән озатып, елашып калдылар. Сигез хуҗалык иде анда. Тар-тар җирләрдә яшәгән, нигез пуҗымны бүлә-бүлә таралган туганнарныкы иде алар. Берсеннән берсе аерылып чыга торгач, ян бакча бәрәңгеләре үзләренә җитсә дә, кышын малга иркенләп бирерлек булмый башлады.

Колхоз синең күз алдыннан юкка чыгуыңны гына көтеп тора икән. Кеше китә, йорты кала, дип сөенгән кебек иде кайберәүләр. Туганнарының каядыр барып урнашу хәбәре килү белән, утыз тугызынчы елны ук, җитәкчеләр берсенең хуҗалыгын тимерчелек итте, икенчесеннән җәен тавык асрау йорты ясады. Өченчесен тегесен-монысын чәчәргә, үсентеләрне зуррак савытларда төпләтергә дип, Әхмәтгалимгә бирделәр. Зәмниха, үзенә бик ышанып, авыл советына да төште, колхоз рәисенә дә сүз катып карады:

– Алар кайтасыларын әйтеп, сакларга кушып киттеләр бит миңа, – диде.

– Колхоз җирендәге бар милек – колхозныкы, үзләренеке булса, күтәреп алып китәрләр иде, – дип кырт кына кисте Әмирхан.

Кайтышларына калырмы, дип уйлады Әхмәтгалим, үзе эшләгән йортны бик тәртиптә тотарга тырышса да. Анда һәрвакыт дымлы, тавыклар торганында мүкләре йолкынып беткән инде. Тавыкларга бирелгән каралтыдагы келәтләргә көрпә оны, әрбә кертеп тутырдылар. Тегермәндә коелган кабыктан – кибәктән иләгәндә калган бар нәрсә шунда иде хәзер. Әрбәсенең бер өлешен кош-корт асраучыларга хезмәт көне хисабыннан бүлеп бирәселәр, ди. Бала-чага җәй буе машинадан чистартканнан соң калган ашлыкны җыярга йөрде. Алары да – келәтләрдә. Калдык-постык бөртекләрне соңыннан йортында тавык тотканнарга бүлмәкчеләр.

– Элек көрпәне малга да алмый идек, хәзер менә ике кат тарттырып, ипигә кушабыз. Шуңа да сөенә халык, – дип гаҗәпләнде Әхмәтгалим дөньяларның шулкадәр артка китешенә.

Тормышның начараюыннан битәр, Әхмәтгалим күңеленә гомер бакый бергәләп яшәгән авылда агай-энесез калу авыр килде. Ян туганнары да каралтыларын Зәлиха аркылы кодалашасы берәүләргә – Өшен ягы кешеләренә – юнь генә бәягә җибәрде. Әлегә Әхмәткәримнәрнеке тора иде. Әхмәтгалим үзе йорт-җирен сатарга дип, берәү белән килешсә дә, уйлана торгач, күз-күрмәгән кай якка да чыгып китмәскә булды.

– Инде без нишлибез соң? – дип сораган карчыгына:

– Үзеңнән качып буламыни? – диде. – Балалар урнашып бетмәгән. Әле анда нәрсә көткәне билгесез. Бар җирдә шул сәвит власте.

Өйне сөйләшкән кешенең Әхмәтгалимнең йортын сатмаска булганлыгын белгәч, хәтере калды. Шәплегенә, бүрәнәләренең ныклыгына кызыгып кайткан, өйдәгеләрен сөендергән иде ул. Әхмәтгалим өзелеп ялынуына түзмәде, келәт-мазарын, мунчасын яшәп торырга дип калдырды, башкасын, сүтеп, шул кешегә биреп җибәрде. Әхмәтгалиенең өйгә урман[5] юнәтәсенә бик ышанган иде. Җитәрлек материал кайтарып җиткерергә дә өлгермәде улы, сугыш та башланды.

[5] Урман – агач, материал.

– Борчылма, башкасына үзем тырышырмын, – диде ата кеше. – Менә хатының Сәрвәр нишләр?

– Бер дә мине күтәргә охшамаган... – диде Әхмәтгали.

Ире китү белән, Сәрвәр килен анасы янына Аксыбыга элдертте. Каенанага-каенатага хезмәт итүдән курыкмады, сугышның башында ук алынгач, Әхмәтгалием үлеп калыр да, тол яшәрмен, яшь арткан булыр, чыгарга кеше тапмам, дип уйлады бугай ул. Әле авылда ир-атлар бар иде... Әхмәтгалим үзләре белән бер көн дә тормаган, улыннан бала күтәреп калмаган Сәрвәрнең бу эшен гаепләмәде. Улыннан шул чакта уңайсызланып булса да:

– Сарафаз кайда? – дип тә сораган иде ул.

– Анысы, этәй, яраттык та оныттык, дигән шикелле бер нәрсә генә булды аның. Урман эченә кызык эзләп килгәннәрне дә хатынга санасаң. Йөргән кешесе бар иде. Шуңа чыгып тора.

Бервакыт Сибгатулла абзыйсының алты хатынга өйләнүен гаепләп сөйләшкәннәрен тыңлап торгач, Әхмәтгали:

– Мин әле аннан да уздырам, – дигән иде. Шулай булып чыкмагае.

– Әстәгъфирулла! – диде аның сүзеннән бөтенләй куркып калган Зәмниха. – Авызыңнан җил алсын! Менә безнең кебек чөкердәшеп, бер-береңнең кадерен белеп яшәүләргә ни җитә?!

– Хәзер дөнья үзгәрде: кызлар башка, мин дә башка. Бар нәрсәгә ирек.

– Хәзер дә, элек тә кеше кеше инде ул. Яратып өйләнешкәннәрнең иртәгесен үк аерылганы да, димләп кушылганнарның гомер буе яшәгәне дә бар. Ирек ул кешенең җанында, канында.

– Булмаганы үз коллыгына да ризамы?

– Хатын-кыз да – безнең кебек үк кавемнән, тик аларны инсаф, гыйффәт бизи, иргә хезмәт дәрәҗәсен күтәрә, – дип, сүзгә кушылды Әхмәтгалим.

– Илгә хезмәт белән иргә хезмәт – бер үк нәрсә түгел, этәй. Кайберәүләр, әйтик, миргә хезмәт итә. Һәркем бәхеткә юлны үзе сайлый.

– Булмаган сүзне сөйләп утырма! – диде аңа Зәмниха, тавышын күтәребрәк. – Атаңнан оялмыйча. Ирләр үзен ничек тотса, хатын-кыз шундый була. Кабартсаң-иркәләсәң, мендәрдәй йомшак, каезласаң, таласаң, үзе дә пычкыга әйләнә. Бозыклык юлына тартып кертсәң, бозыладыр да.

Шаяртканга салынып, үз киресен тукыды Әхмәтгали:

– Миңа ниндие дә ярый. Кызларның бөтенесен дә яратам. Сибгатулла абый кебек...

– Ул менә барыбер Хәнифәсенә, сабыр холыклысына, эшкә булганына, үзен гафу иткәненә, ата-анасын бакканына кайтып егылды.

– Мин әле аның яшенә җитмәгән, – дип көлде Әхмәтгали.

Аның болай әрсез сөйләшүе берсенә дә ошамады. Әтисе:

– Әйдә, буш сүзне шушында бетерик! – диде дә урыннан торды. – Шунысын истә тот: кеше кызлары белән нидер эшләгәнче, башта үз сеңел-апаларыңны уйла.

Әхмәтгали дә, Сибгатулла да күргән берсе кызыгырлык ир-ат иде. Буйлы, булган, акчалы. Андыйларга яшь, әле берни аңламаган кызлар, башкалар белән тормышын көйли алмаган хатыннар ябышырга гына тора. Аңа ошыйммы-юкмы дип уйламыйлар, алдын-артын белештермиләр.

Бер күрде дә шунда ук гашыйк булып өйләнде Зәмнихага Әхмәтгалим.

Бер белән торды – аңа ышанычы ныклы иде. Дөнья үзен кай якка тәгәрәтсә дә, хатынының артыннан йөгерәсен белә иде ул. Шахтага барган саен, яңа хатын белән яшәп кайткан Сибгатулланың ахыр чиктә, барыбер аны гына яратам, дип, Хәнифәсенә кайтып егылганын аңлый алмады. Ә бит берни булмаган кебек шул хәлләрне онытып, менә дигән яшәп яталар...

– Ятмаска, – ди күрше Әмирхан. – Хәнифә, Сибгатулла киткәч, үзе дә бер дә кимен куймады.

Әмирхан белми әйтмәс. Кем-кем, ул белми әйтмәс... Улына Хәнифәне, ирен гафу итүен аңламаса да, авыз суларын корытып мактап утырган булды... Әхмәтгалим тормышның Әмирхан белгән якларыннан бөтенләй хәбәрсез икән. Әхмәтгалиен әйтерлекме: эшне башлаганчы ахырын уйламаучан Сибгатулла артыннан кумакчы булып кылана. Башка нәрсәгә акылы алдан йөри торган ир-ат үзе. Шаярып утырганың шар ярып килсә!..

Әхмәтгали, сугыш якынлашканын сизеп, мобилизация игълан ителүгә үк китәчәген әйтергә дип авылга кайткан иде. Бөтенләй башка нәрсәләрне сөйләшергә. Шаяртуым гел урынсыз булды дип кыенсынды. Урамга чыкты. Яшьлегендә әтисе утырткан наратларга карап тора башлады. Зурайганнар. Алар да кешеләр кебек гел үзгәрештә. Бер төстә генә тора дисәләр дә, язларын яшәреп-яшелләнебрәк китәләр. Ел арты ел күркә чыгаралар, коялар, күзгә күренеп үсәләр, күккә, кояшка үрлиләр. Үсүдән барыбер туктарлар, аста йөзгән болытларга да җитмәсләр, картаерлар... Кеше алар гомерен дә яшәми...

Наратларның өске якта киңәеп киткән ботакларында ник бер оя булсын! Наратка авыл эчендә кош оямый, әллә кунмый да микән ул? Шулай булса яхшы. Ябалдашлары инде утыргычка түбә сыман. Хәзер яннарына барсаң, чәер исенә чыдарлык түгелдер.

Бала чагында әтисеннән, наратка нинди кошлар оя кора, дип сораган да кебек ул. Наратны тиеннәр ярата, кошлар башка агачлар булмаганда гына оялый, анда да күбрәк каргалар, чәүкәләр, саесканнар, дигәне исендә калган. Кошлар үз итсен өчен, наратның биеклеге дә, астында җим таптырырлык үлән, яшь үсентеләр дә кирәк, имеш. Күркәләрендә орлыклар булгач, ул да җим бит инде. Әллә башка кеше сөйләде микән? Хәтерендә, бертөслерәк, тавышлы, мин яратмый торган кошлар икән, дип уйлаган шикелле тора.

Наратлыкта, чыршылыкта яшәгән кошларны күп күрде Әхмәтгали урманда эшли башлагач. Куе ылыслы урманнарда апрельдән август башларына кадәр җыры, тавышы тынмый аларның. Җәйнең төрле вакытында бала чыгаручылары бар дигән сүз бу. Баласын кышларын күркә орлыгы белән туендырган чукырларга әнә нарат, чыршы арасында көн итүдән дә яхшысы юк.

Кичләрен урманны тикшереп йөргәндә тукталып, хушисле, күкрәкне ача торган һава сулап, әйләнә-тирәне күзәтүдән тәм таба торган урыннары бар Әхмәтгалинең. Бигрәк тә чукырлар үз иткән чыршылыкларны, шулар тирәсендәге аланлыкларны ярата ул. «Кеп-кеп-кеп» дип кычкырып, төркемнәре белән дулкын ясап очкан әлеге кошларның тизлегенә, хәрәкәтчәнлегенә таң кала ул.

Оя корган, гаилә төзегән кошлар кешеләргә бик тарта икән. Ата чукыр чыршының иң биеккә үрләгән ботагына утыра да сызгырырга-көйләргә, башка сәер тавышлар чыгарырга тотына. Артына ут капкан кебек йөгерә,

бөтерелә, ана кошның игътибарын яуларга тырыша. Күзе төшкән кызның тәрәзә төбенә килеп сызгырынган, өйләре турыннан җырлап үткән, сөйгәненең чыкканын көтеп, якын-тирәдә әйләнеп йөргән авыл егетләренә охшата аны Әхмәтгали, әмма үзенә түгел. Аңа кызларны каратырга тырышырга кирәкми, ягымлырак итеп бер сүз катуы да җитә.

Әхмәтгали кечкенә вакытыннан дустына әйләнгән наратлар янына барып утырды. Әтисе ясап куйган эскәмия һаман да нык иде. Чирек гасырдан артык ничек чыдаган ул?! Сынмаган, черемәгән. Юка иске такталардан гына ясалмаган шул. Гомерлеккә җитсен, оныкларыбызга ук калсын дип эшләнгән. Сугыштан исән кайтмаса, аннан менә беркем дә, хәтта берни дә калмый. Ничек тә исән кайтырга кирәк. Кайтуга ук, утыргычның яңасын, үзенекен ясарга!

– Батырлык күрсәтергә хыялланып, эштән күңелең суына башлаган синең, малай, – дип, канәгатьсезрәк кыяфәттә әйтеп куйган иде әтисе бер көнне, Әхмәтгали:

– Вәт, шәп булды фин сугышына киткәннәргә, нинди батырлыклар күрсәтеп өлгерделәр, зерә мине җибәрмәделәр, – диде.

– Иртән чәйгә утырган саен шул сүз.

– Иртәнге чәйне туктатыйммы, сүзнеме? – дип шаяртуга борып маташты Әхмәтгали, гадәтенчә.

– Әтиең белән кеше шикелле сөйләш! – диде әнисе. – Холкымны беләсең. Аңа сүз әйттереп тормам.

– Кан коелган җирдә күбрәк башсызлар батыр була, синнән нидер килеп чыкмый калмас, уйламыйча, утка-суга керергә генә торасың, – диде атасы. – Хезмәттә тырышлар алдынгылыкны бирми. Хезмәт батыры да була алыр идең, нигәдер сугышка атлыгасың.

– Әнисенең йөрәге янып озатып каласын белмәгәнгә, – диде Зәмниха.

Әхмәтгалинең әледән-әле:

– Немецның безгә бәреп керәсенә шигем юк, Алла кушса, беренче көнне үк үзем барып язылам! – дигән сүзләре, иртәгә сугышка чыгып китәсе булмаса да, бу өйдә әкренләп, сугыш көтү рухын арттырды. Зәмниха моны күреп тора, шуңа күрә малаеның алай сөйләшеп утыруын өнәп бетерми иде.

– Әниең турында уйла, – диде Әхмәтгалим дә бервакыт, ул тагын сугыш башланачагы турында сүзгә керешкәч. – Немецларның бер бәреп керәсен мин аңламый дисең мәллә?!

Әхмәтгали тын калды. Әнисенә карады. Йөзеннән үзе белмәгән нәрсәләрнедер чиксез борчылып, хәвефләнеп диярлек көткәнлеге күренеп тора. Аны кызганудан йөрәгенә авыр булып китте.

– Бала-чага уенымыни ул? – дип дәвам итте Әхмәтгалим. – Агач мылтык күтәреп, тавык куып йөргән малайга охшый башладың. Сугышма, үзеңне батыр тотма, димим. Әле син берни күрмәгән. Баргач сөйләрсең бу сүзләреңне! Инде ниндидер борчырлык хәлләр килеп чыкса, әниеңне утка салып, алар турында хатка язма. Йөрәген яраламаслык сүзләр тап.

– Ярар, әтәй. Гафу ит. Алдан ук борчылма әле, әнәй, син дә.

Әхмәтгали, чәен эчеп бетереп, догасын кылгач, рәхмәтен әйтеп кузгалды. Ул җиңелчә генә киенеп, тагын урамга чыкты. Матур бер көн иде. Түбән як буйлап апрель гөрләвеге ага. Язның көчле җылы яңгырыннан соң эрер-эремәс яткан карлар кояшка шактый биреште, юкка ук чыга башлады,

челтерәп кенә яткан сулар киңәеп, әле кайчан гына галош белән узып булмаслык гөрләвеккә әверелде. Ямьбикә апасы кызларын аларга төшереп җибәргән икән. Икесе дә – капка төбендәге утыргычта. Әниләренең эше күптер, аяк астында буталмасыннар, дигәндер. Китеп баргач, апаларына ярдәм итеп тә булмаячак.

Әхмәтгали, кызларны кысрыклап, урталарына кереп утырды.

– Менә урын да табылды.

– Безне кыстың бит! – диде Газизәбану.

– Миңа хәзер нишләсәм дә килешә, – дип көлде абыйлары. – Яннарым, җәй көне сугышка китәм бит!

– Орден алып кайт! – диде Газизәбану.

– Немецлар да кызганыч, аны кеше үтерсәң генә бирәләр! – диде Миңлебану.

– Сез менә батырмы соң? – дип сорады абыйлары.

Иң элек Миңлебану сикереп торды:

– Мин – юк!

– Батыр! – диде, авызын ерып, кечерәге Газизәбану.

– Алайса кайсыгызның батыррак икәнен тикшерәбез: кем дә кем менә шушы гөрләвеккә кереп ята?

Газизәбану сикереп торды да өр-яңа кышкы сукно пәлтәсе белән Түбән урам буена агып яткан гөрләвеккә кереп тә ятты.

– Мин батыр түгел, – диде бичара Миңлебану. – Пәлтәне чылатсаң, әшәкеләнә, әнигә эш була.

– Алайса барыгыз, ул күргәнче, әбиегезгә кереп киптерегез.

Пәлтәсеннән шыбырдап су агып торган Газизәбануны күргәч, Зәмниха аңлады: бу шул Әхмәтгалинең генә эше. Иртәгә сугышка китәргә хыялланган ир-ат инде, һаман да бала-чага котыртуын, шаяртуын куймый.

Кыз туңар, салкын тидерер, дип бик курыкканнар иде, чәйли-чәйли кичне көтә торгач, тимер мич янындагы аркалы урындыкка эленгән пәлтә кипте, тик, якаларының шәлперәйгәнен күреп, әниләре барыбер аңлады. Түзмәде, әнисе йортына төшеп, Әхмәтгалинең кергән бирде:

– Балаларым чирләсен дип, шулай эшлисең мәллә? Үзең дә гел яланөс йөрисең. Салкын тияр, үпкәм кабарыр дип тә курыкмыйсың.

– Миңа тияр зәхмәт юк ул, апа! Кызларыңны алай да башка котыртмам.

...Җәй тиз житте. Эссе һәм матур килде. Инде сугыш башланмас та кебек иде, көтмәгәндә колхоз радиосы, бөтен урамга ишетелерлек авыр хәбәр җиткерде.

Әле кайчан гына сугышка китеп, батырлык казанырга хыялланган, чакыру тотып кайткач, Әхмәтгалине моңсулык басты. Аны этиләренең вак балалар белән ялгыз калуы, апасының бер ярдәмчесез икәнлеге тынычсызлый иде. Газизәбану белән Миңлебану кирәк чагында әле дә ярый бабаларына килеп сыена, алар өендә ризык таба. Бүген иртә таңнан Әхмәтгалине күреп калырга төшкәннәр үзләре. Бөтен кызык аның янында кебек инде аларга.

Сугышның беренче көненнән мин барам дип язылган Әхмәтгалинең бүген шаяртырга җае юк. Эченнән һәркемне озатырга килгән сабыйларны бигрәк тә кызгана, әйтеп китәргә матур сүзләр тапмый азаплана иде ул. Ничек күңелләрен күрергә белмәгәндә, кесәсендәге кәнфитләре исенә

төште. Шул чакта бөтенләй көтелмәгән хәл килеп чыкты: Зәмниха, балалар кулындагы абыйлары биргән кәнфитләрне алып, кире Әхмәтгалигә кайтарды. Шкафтагы савытта башкалары бар иде, шуларын кулларына тоттырды.

– Биреп калдырсаң, әйләнеп кайтмассың, алып китсәң, ризыгың тартып кайтарыр, – диде ул, ашъяулыкка төреп куелган икмәктән кибән башын кисеп алып, Әхмәтгалиенең куен кесәсенә тыкканда.

– Син нәрсә, әнәй, гомер бакый ырымга ышанмаганны.

– Ышанмыйм. Чыннан да шулай булса дип кенә куркыта.

Әхмәтгали телемем урынындамы дигән кебек күкрәк турысын капшады:

– Исән-имин әйләнеп кайтырга булышсын, әнәй.

Газизәбану белән Миңлебану абыйларының әйберен җыйнап, тынычландырып, аерым-аерым хушлашып йөргән чагына туры килгәннәренә үкенделәр. Тагын да иртәрәк төшәселәре калган икән. Кәнфит эләккәч, бу үкенеч онытылды – сәке кырына утырып, шуны суырырга тотындылар.

Менә бераздан Әхмәтгалимнәр йорты каршысына җигүле ат килеп туктады. Солдатның башка иптәшләре – Гаффар да, Заһир да, Әхмәтгазиф та, үзләре белән кытүмкәләрен[6] алып, арбага менеп кунаклаганнар иде.

– Хәерле юл, улым, исән-сау йөреп кайт, – диде аерылу сагышыннан йөрәге тагын авырта башлаган Әхмәтгалим агай.

– Үзеңне берүк саклый күр, утка акаеп-бакаеп килеп кермә, Ходай сакланганны саклар! – диде Зәмниха түтәй.

– Әхмәтгали абый, безгә кәнфитне күп итеп алып кайт! – диде Газизәбану. Сугышка озату шундый күңелле, Сабантуй кебек була икән, дип уйлады ул, китүчеләр янына тирә-яктан агылган халыкка таң калып. Миңлебану дәшмәде. Ул кешедән әйбер сорарга, көтәргә уңайсызлана иде.

– Киттеләр... – дип куйды алар күздән югалганнан соң Зәмниха. – Аллага тапшырдык. Исән-сау гына йөрсеннәр инде.

Сәрвәр озатырга кайтып тормаган иде...

Урамны, күңелләрне авырайтып, шомлы тынлык баскандай булды. Сөйләшми-нитми генә таралыштылар.

3

Әхмәтгалиләрнең сугышка алынуына озак та узмады, Зәмниханың йөрәген умырып алгандай итеп, улының хәбәрсез югалганлыгы турында хат килеп төште.

– Уен кебек кенә сөйләшкәннәр иде киткәндә, – диде Әхмәтгалим. – Уеннан уймак чыга. Плен-мазарга эләккән булмагае.

– Син менә анда да бер дигән яшәп яткансың бит, – диде Зәмниха.

– Заманы башка, карчык. Бүген безнең илгә бөтен дөньяның котырынган чагы. Йә бетерәбез, бетермәсәк, үзебез беткәнче сугышабыз, дип тырышачаклар.

– Ай Аллам...

– Сугыш озаккарак сузылса, явызлана барырлар инде ул.

– Әле башы гына.

[6] Күтүмкә – аркага асып йөри торган капчык.

– Безгә – башы, чынлыкта әллә кайчаннан бара. Авылдан фин сугышына эләккәннәрнең бөтенесе турында югалганлыкларыннан хәбәр килде. Туганнары плиндәдер дип көтә. Шулайдыр дип уйлыйсыңмыни син? Үлгән инде алар. Өстәгеләр фронттагы бар хәлнең дөресен сөйләтми.

– Нигә?

– Ватан өчен үлгәннәргә ата-анасы пенсия ала. Болай... Ничектер...

– Плиндә түгел, чуртта булсын, Әхмәтгалием исән генә калсын.

– Кайсының яхшы икәнлеген дә белгән юк...

Зур бәйрәмгә кебек җыелышып, шаулашып-гөрләшеп, хәзер кирәкләрен бирәбез аларның, дип мактанышып, әллә нинди батырлыкларга әзер булып хушлашулар күршеләре Гази аягын өздереп кайткач, кайгы хатлары килә башлагач тукталды. Сугыш хәсрәте бар өйгә, Әхмәтгалимнәргә дә бик тиз узды. Баласының чын язмышыннан хәбәрсез ата, йөрәген тотып, өй түрендәге караватка барып ятты.

Зәмнихалар яңа йортның бер ягын оештырып киләләр, түбәләре генә эшләнеп бетмәгән иде. Төзүчеләрдән бик арыды, ашарларына булмагач, эшне сузалар, торалар да, баганаларга утырып, тәмәке кабызалар, әледән-әле аннан чәй чыгарталар. Әтиләре төрмәдә булган Газизәбану белән Миңлебану да кызганыч, аларга да ризык элекке кебек үк – теләгәнчә тәтеми. Кеше өстендә торулары җитмәгән, әле бер җирдән йортлары җимерелә, әле мичләре... Барысын Ямьбикә төзәтә, барысына әйберне ул юнәтә. Беркөнне:

– Кеше хәерчесен рәтләп тәмам туйдым, үзем өй салам, – дип килгән.

– Төзүчеләрең минеке кебек кыланса, белмим... Берүзең ерып чыгарсыңмы? – дип сорады әтисе. Ямьбикә уйга калды. Нишләр...

Бу хәлләр сугыш чоры авырлыкларының башы гына иде әле. Әхмәтгалим карт уртада бура чолан белән бүленәсе йортларының бер ягын ныклап эшләп чыккач, икенче якны келәт кенә итәргә уйлады. Абзарлардан башка көн итеп – мал тотмыйча яшәп булмый иде. Төп көчен шуларга куйды.

– Нинди ир идем бит әле генә, колхоз эше өстенә балалар хәсрәте, авыр чакта өй салулар белән беттем.

Зәмниха иренә, гомер булмаганча, бик текәлеп карады. Чыннан да, элекке Әхмәтгалим юк иде инде...

– Борчылма әле, картым, – диде ул, бик йомшак булырга тырышып. – Барысы да рәтләнер. Сугышлар бетеп, Әхмәтгалием әйләнеп кайтыр да, элеккечә үк яшәп китәрбез.

– Әхмәтгалидә генәме хәсрәтем? Галинурның, буе зур дип, алтынчы класстан укуын ташлаттылар. Мәктәбендә аннан башлы бала юк иде. Борын астына мыек та төртмәгән баланы колхозның иң авыр эшләренә китереп тыктылар, аннан хәрби заводка олактырдылар.

– Ни хәлләр итик, сабырлык кирәк.

– Галинур хатындагы сүзләр йөрәгемне талый. Мондагы эш колхоздагы күтәрү-төшерүләр генә түгел икән. Ашау җитми, бик ябыктым, дигән. Гөрнәдир кебек малай бит ул. Ике метрдан артык буен анда нәрсә белән туендырып бетерсен?

– Шулай инде. Кияү төрмәсеннән котылды дигәндә, яңадан тотылды...

– Анысы да түзмәгән, үзе сорап, сугышка киткән.

– Төрмәдә сугыштагыдан да яманрак булгандыр.

– Ябылуда ачтан үлгәнче, мылтык тотып, тук килеш үлүең дә яхшырак.

Шуларны сөйләшеп, әйдә тынычланыйк дигәндә, Хәлимәбикә кайтып керде. Чиләбегә ФЗӨгә димләп маташалар, имеш. Зәмниханың йөрәге, күкрәк читлекләрен ватардай булып, китереп-китереп сугарга тотынды:

– Хәбәрләрегездән хет егыл да үл икән, кызым. Ризалашма бер үк, Галинурны да шулай дип алдап алып киткәннәрен беләсең.

– Ризалашма, кызым. Алай да эш – сугыш түгел, – диде Әхмәтгалим.

– Әй, этисе! Шуңамыни Галинурым, сугышка китсәм, батырларча үләр идем, монда ачлыктан үтермәгәйләре, дип язган. Әле генә сөйләштек бит.

– Син алай булыр дип торсаң, шулай булып чыга да ул.

– Әхмәтгалим, бу хәлләргә әллә бер дә кайгырмыйсыңмы син? – дип сорады аптырап калган Зәмниха.

Кайгыра иде Әхмәтгалим, ничек кайгырмасын, кайгыра иде. Авылның ничә кызын ФЗӨгә җибәрәбез дип, Себергә олактырганнар. Ул Хәлимәбикәнең дә хәлләре яхшы түгеллеген, мәҗбүриләсәләр, сазлыкка, салкынга урман кисәргә китәчәген аңлады. Сине дә шулай итмәгәйләре, дип, алдан ук куркытып куйсынмыни?! Зәмниханың болай да ярылырга җиткән йөрәгенә таш өстенә таш ыргытсынмыни?!

Кызының эчендә утлар уйныйдыр, тыштан гына тыныч күренергә тырышадыр. Әтисе белән әнисе сөйләгәннәрне бүген дә, гадәтенчә:

– Ә-эе, әтәй, ә-е, әнәй... – дип җөпләп тора, әнә. – Ә-əәәә...

Хәлимәбикәнең йомшак, күркәм холкын Әхмәтгалим бик ярата иде. Йомшаклыгын белгәнгә, ир-атлар гына түзә алган эшләргә чыдамас, чирләр, бетерешер дип курыкты. Егетләрдәй нык, абый-энеләре белән урманнарга йөреп, бергә уйнап үскән, Сабантуйларда көрәшсә, батыр калырдай Рәгыйдәсе өчен ул моңарчы бөтенләй кайгырмады. Җиденчене тәмамлауга, колхозның иң зур бригадасын җитәкләргә куйдылар аны. Сугыштан имгәнеп кайткан ирләр хәттин иде югыйсә. Инде анысы гына җитмәгән, ферманы да Рәгыйдәгә тапшырганнар. Хәзер шундагы хатын-кызлар санга бар, чынында юк ир-ат белән абзар матчасына сыер күтәрә, ат кадәр атларны арканда тарттыра! Бала китерәсе бар, димиләр, эчләре төшәр, димиләр. Мәктәп бетергән малайлары да булгандыр, сабый бер кызны шундый авыр, җаваплы эшкә куймасалар!

Рәгыйдә кыюлыгы, туры сүзлелеге белән Шүләнгерләргә – Зәмниханың үзенә, йөз кыяфәте белән – бигрәк тә туры карашлы, чем-кара чәчле ир-туганнарына охшаган. Бала вакытында анысын, энеләремне дә сөям, дип сөя торган иде әнисе.

– Рәгыйдә – безнең сыңар инде, – диде аңа бервакыт Әхмәтгалим, нәрсә җавап бирер микән дип тикшереп кенә. – Буйга да яшьтәшләреннән ныграк, көчкә дә һичберсенә бирешмәслек.

– Телгә дә кирәгеннән артык үткенме? – дип сорады Зәмниха.

– Юк, карчык, ул ягы синә тарткан.

Көлделәр дә бетерделәр.

Гел ир-ат арасында эшләп тә, егетләрне янына якын җибәрмәде Рәгыйдә. Әхмәтгалим үзе юкта шуның өчен кызын мактап-мактап куйгалый иде.

– Син нәрсә, мине якын җибәрдең, димәкчеме? – дип сорады берсендә Зәмниха. – Су буенда көянтәмне тоттыруымны әйтәсеңме? Шулай кирәк

булган ул. Мин каптырмасам, үткен сеңелләремнең берәрсе барыбер эләктерер иде үзеңне.

Мич башында борчак чөеп уйный, ялкау, дип, теге егетне кире какты, кыяфәте ошамый, дип, монысын, мәлҗерәгән, кәлҗемә, дип, өченчесен Рәгыйдә. Соңгы вакытта гына Түбән очтан Хафиз исемле берәү белән дуслашып йөри икән, дигән сүзләр китте. Булса булыр, Хафизның әти-әнисе начар кеше түгел, дип уйлады Зәмниха. Хәзер дуслашып йөрсәләр дә, бала вакытында Рәгыйдәнең аның белән серкәсе килешмәде. Юллары каршы килсә, юл бирешмәделәр, бәхәс чыкса, икесе ике якта булдылар алар.

Рәгыйдәнең Хафизның кыланышларына исе китмәде, теләсә, ул аны акылга утырта аласын белә иде. Теләмәде... Шуңа күрә кагылмады, сукмады, әмма чәкәләшкәндә юл куярга да ашыкмады. Күрше малайлары урманга Рәгыйдәгә ияреп барды, хатыннар, эшкә чакырсалар җимертә генә дип, үсмер вакытында ук аның янәшәсенә басарга тырышты. Янында үзен әллә кем кебек тотса да, Хафиз да аңа тагылып йөрде.

Зәмниханың киткәннәр өчен генә түгел, калганнар өчен дә эче поша иде шул. Бервакыт Хәлимәсе Югары оч Шәпи малае белән очраша башлаган. Рашит исемлесеме шунда. Ул мәхлук, сугышка алынмас өчен, авылдан чыгып качкан. Шул хәзер каршы Тау як урманда дезертирлар белән бергәләп яшәп ята, дип сөйләнәләр. Бу хакта белеп торса да, Зәмниха ачуын чыгаруым бар дип уйлап, иренә сөйләмәде. Ул барыбер сизде. Тәкәнеш райсобесында эшли башлаган Хәлимәбикә, ялга кайткан саен, кичләтеп төенчек тотып каядыр йөгерә дип бик аптыраган икән. Җитмәсә, Рашит хакында кайсыдыр ишеттергән булырга охшаган. Бернидән дә тыюын тыймады Әхмәтгалим. Кич чыгарга җыена башлаган Хәлимәбикәне:

– Кая хәзерләнәсең?! Өеңдә генә утыр! – дип туктатты. Кыз алдарга күнекмәгән иде, дөресен әйтергә курыкты.

– Рашит белән синең хакта төрле сүзләр йөри. Шуның янына чапмыйсың микән син, кызый?

– Ә-эээ...

– Күрергә вәгъдәң булса, вәгъдәңне бозма, әмма дә ләкин, барсаң да, анаңны үзең белән ал!

– Анда кадәр...

– Синең кичкә каршы шунда киткәнеңне белсә, өйдә тыныч утырыр, дип уйлыйсың мәллә?

– Ә-эээ...

– Качкын ирләрнең урмандагы бүре белән бер булуы да бар, – диде. – Аларның тамагы ач. Икмәккә дә, хатын-кызга да нәпселе чаклары...

– Ә-эме, әтәй? Ә-эээ... Алайса хәзер. Әнәйгә әйтим.

Хәлимәбикә килеште, урман кырына Зәмниханы ияртеп китте.

– Соң, кызым, үз анасы юкмыни соң аның?! – диде юлда барганда эче пошкан Зәмниха.

– Сугыш вакытында ирләр кадерлегә әйләнә, дисең бит.

– Әйләнмәгәе! Ирсез калсам калам, Шәпи малае белән сөйләшеп тә тормыйм түлке! – диде Зәмниха. – Аннан юньле кеше чыкмаячагы алдан ук күренеп тора, ди атаң да.

– Ярар ату, – дигән булды соңгы менгәннәрендә Хәлимә. – Яратуын

да яратмыйм. Әнисе, ашарына мин алып барсам, шунда ук тотарлар да утыртып куярлар, дигәч кенә...

– Аны утырталар, безне юк икән!

– Үтенечемне аяк астына салма, күземә карап торган бер малаем, дигәч...

– Димәгәе! Синә да насыйбы бетмәс әле.

Хәлимәбикә әнисе белән әтисе сөйләгәннәрнең үз файдасына икәнлеген белә иде. Рашиткә артык исе китми, тышкы кыяфәтенә генә күзе төшкән, ни холкын, ни гадәтләрен өнәп бетерми иде. Шуннан соң урманга ризык ташудан туктады. Халык арасында, Рашит дуслары белән караклык юлында икән, дигән сүзләр таралгач, үзенең беркатлылыгына, олы кешеләрнең тормышны ничек аңлауларына шаккатты. Әниләре тамагына ризык илтсә, кеше басып йөрми бит инде ул, мин дезертир ашатып, илгә хыянәт иткәнне рәхәттә яшәткәнмен, аныкылар, әнә, үзләре турында кайгырта, дип уйлады.

Сугыш башлангач, Хәлимәбикә, балалар бакчасын ташлап, Казанга китеп барган, аяк киеме җитештерүгә урнашкан иде. Мәскәүнекеләр фабрикаларын тиз арада хәрби заводка әйләндергән. Эш сәгатьләрен арттырганнар. Шундагы авырлыкка чыдый алмыйча, Хәлимәбикә качып кайтты.

Иртән вакыт булмас дип, Зәмниханың мич төбенә ипи салып, бәрәңге тәгәрәтеп йөргән чагы иде. Кызының бу рәвешчә кайтып егылуы ананың тез буыннарына кадәр калтыратты. Өнсез калды Зәмниха. Буылды, тыны җитмәс булды. Иреннән су соратып алды да мич янындагы эскәмиягә көчхәл белән барып утырды.

– Кичке уй иртәнгә ярамый, – диде Әхмәтгалим. – Әйдә, чәеңне куеп эчерт. Арыганлыгы күренеп тора.

– Ә-э, – диде Хәлимә, куркып кына.

– Ни белән кайттың, кызым?

– Поезд өстендә. Аннан соң җәяү инде. Караңгы төшкәнне кукуруз арасында качып көтеп тордым да авылга кердем.

Зәмниха карчык бераздан айнып киткәндәй булды. Еламады, артыгын сорашмады, ни әйтерләр дигән кебек болай да куркып карап торган кызын борчыйсы килмәде. Гадәттәгечә, яулык почмагын тешләп, уйга калып утырды да өстәл хәстәрләргә тотынды.

Исеме генә – десятник, кул астында әллә никадәр кеше эшли. Бәйрәмнәрдә артель ризык бирә. Күңелләрен күтәрү өчен кемдә дә булса пешеренеп-төшеренеп, бәйрәм ясыйлар. Табын көйләүне, нәрсәне дә тәмле хәзерли дип, Зәмнихага кушалар. Аталарының төп йортына янәшәдәге Сәлимҗан абыйларының өе буш булгач, бу бәйрәмне шунда гына уздырырга булдылар. Иртәгә үк җыеласылар дип тормады, шуның абзарындагы тирес астына борынын гына чыгарып күмеп куярга планлаштырды Зәмниха. Каралтыларына алардан башка беркем дә керми иде. Мондый вакытта Хәлимә шунда качкандыр дип шикләнмәсләр, дип фаразлады.

Ихата эчендә, абзар тәрәзәсенә якын гына, тышка ыргытырга дип өеп куелган, соңыннан түтәлгә әйләнәсе тирес өеменә ашыкмый гына зур уем ясады, төбенә киртәгә кибәргә эленгән паласларны алып кереп җәйде, аннан баш селкеп кенә, кызына кереп ятарга кушты, борын турысын кечкенә генә

ачып, чит-читләрен чүпрәк белән нығытканнан соң, өстенә тагын бер кат күтәртмәгә ябышкан кизәкне кубарып ыргытты.

Хәлимәне качыру эшенә башта батыр гына тотынган Зәмниха тора-бара, артель бәйрәмендә берәрсе көтмәгән хәл китереп чыгармаса гына ярый, дип курка ук башлады. Тапсалар, Хәлимәнең яше аз түгел, үсмерлектән чыккан, төрмәгә үк тыгып куюлары бар, дип уйлады. Юраучы юрап китерә, диләр, уйсыз – уйлап... Шулай килеп чыкты да.

Йортка кунаклар җыелган вакытта көлеп кенә торучан, булганы белән сыйланыгыз дип кыстап, барысын да йөдәтеп бетерүчән хуҗабикәнең тынып калганлыгы, йөзеннән ни сәбәпледер төс качканлык кемгә дә күренерлек иде. Ашарга пешергәндә дә, болай ук бетерешмәгән иде әле ул. Кеше киткәч, өенә керде дә егылды. Кунаклар янында сыйланган күршесе дә сизде моны, шуннан соң йорттагы хәлләрне ныклап күзәтергә тырышты. Көн димәде, төн димәде, Әмирхан Зәмниханы каравыллады. Каравыллады да аның Сәлимҗаннар йортында нишләп йөргәнлеген аңлады. Бу вакытка авыл советына кызны эзләткән язу килеп төшкән иде инде.

– Иптәш Гарифуллин, – диде ул, кантурга керә-керешкә. – Туганнар дип яклап калдырырга маташма. Әхмәтгалимнәрнең Хәлимәбикәсе Сәлимҗаннар каралтысында качып ятканга охшаган. Бүген үк Тәкәнешкә хәбәр бир.

Зыя ни дип җавап кайтарырга белмәде. Яшерсә, башта – Тәкәнешкә, аннан ары – Себергә олау белән үзе китәчәк иде. Әмирханның кемлеген белә. Хәбәр итәргә булды. Күңеле дөрес сизгән: район үзәгеннән шул арада килеп тә җиттеләр, нәрсә карап ятасыз, дип пырлатып чыгып та киттеләр. Ул да булмады, бичара Хәлимәбикәне, Сәлимҗан абзыйларының абзарыннан тотып алып, Тәкәнешкә озатканнар. Чыдаса чыдап калыр...

Дүрт ай яткырып, көн саен сорау алып йөдәткәннән соң, кире Өскебашка кайтарып җибәрделәр Хәлимәбикәне. Ул тегесе-монысы белән үзегенә үткән авылда калырга теләмәде, Тәкәнешкә барып, райсобеска эшкә урнашты.

Начарга китсә дә, яхшыга борылса да, тиз генә юлын үзгәртми икән тормыш. Бер кайгыдан йөрәгең басылган кебек кенә була, икенчесе килеп ирешә, өченчесе... Бар хәсрәтне мин генә күреп бетерәм икән, дисең, бер-бер артлы шатлыклы көннәрең, айларың тезелеп китә. Сөендергәненнән кайгысы күбрәк еллар башланды бугай алай да. Хәлимәбикә өчен тынычландылар гына, яраланып, имгәнеп, шулай да исән калып, ике баласын ялгызы үстергән Ямьбикәсе янына гимнастёрка кесәсенә ак билетын тыккан Габделкасыйм кайтып керде. Монысына артык хәсрәтләнмәделәр: аның мәңге бетмәс кебек сугыштан әйләнеп кайтуы мөһим иде.

Кырык дүртнең кышкы кырык градуслык зәмхәрир суыгында нәҗескә каткан күлмәк-ыштанында пленнан качкан, үпкәләре нык чирләп, госпитальдә яткан Әхмәтгалидән дә хат килеп төште. «Үпкә ничек тә рәтләнер, аяк-куллары эшләми башлады. Аңсыз хәлемдә яткан җирдән – рубеждан табып алганнар», дигән.

Бәдрәфтә ничә көн өстенә йомышлатып утырганнан соң, үзен эзләүләр туктатылгач, бpraктагылар үлем йокысы белән йоклаганда, качуның җаен тапкан икән бичаракай. Әхмәтгалим малаеның тапкырлыгына шаккатты, батырлыгына, кыюлыгына сөенде. Фашистның бик явызланган чагы, ничек булдырган ул моны, дип гаҗәпләнде. Әйе, немецның – котырган,

үзебезнекеләрнең әсиргә эләккәннәргә аннан да яманрак чаклары... Качуын исәпкә алсалар гына инде...

– Чирләсә чирләр, анын каравы исән, – диде Зәмниха, сөенеч яшьләрен тыеп тора алмыйча.

Дошман ягында рәхәтләнеп көн итеп кайтса да, берни булмаган иде Әхмәтгалимгә, фаразы рас килде: улына рәхмәт әйтмәделәр. Шул арада җыелган хәрби судта, ун ел туган ягына кайтмаска, моннан ары анда яшәмәскә, дип карар җиткергәннәр дә, госпитальдә бераз дәвалангач, ныклап терелүен дә көтмичә, Донбасска – шахтага эшкә җибәргәннәр.

– Ярты сәламәтлеген югалткан ир-аттан да куркып тора бу сәвит влачты, – диде Зәмниха.

– Анысына гына түзәрбез, исән кайтса, барысына да риза идең. Менә бит кайтты, – диде Әхмәтгалим, хатынының күңелен күтәрергә тырышып.

Шундый уңай хәбәрләр белән сөенешеп яши генә башлаганнар иде, хәлләр кирегә үзгәреп китмәсенме? Тагын бер төн уртасында, апасы кебек агарынып, хәлдән таеп, Галинур кайтып төште. Эшкә алынганда, аңа әле ундүрт кенә иде. Озак та узмады югыйсә, шул арада йончыган, олыгайган бер кыяфәт кергән.

Әхмәтгалимнең хәле начарланып киткән көннәр иде.

– Улым, әллә соң... Качтыңмы? – диде Зәмниха. – Атаң чир белән булышып ята. Һаман сезне сөйләшә. Дәшимме?

Әхмәтгалим, йөрәген тотып, урыныннан торып килә иде инде:

– Тәки түзә алмадыңмыни соң, улым?

– Түзәр кадәренә түзелде.

– Кай яктан кайтып кердең?

– Каршысыннан.

– Берәр кеше күрдеме?

– Бүре!

– Ишкәнсез икән ишәк чумарын. Кияүнең башына да авыл сәвитендәгеләр җитте. Әмирханның кемлеген беләсең. Нишләтер?.. Ул хәзер колхозны җитәкли.

– Ай алла, улым икәнсең, бәгырь кисәгем, – дип, сүзгә кушылды Зәмниха. – Ниләр генә эшләрбез? Озак көттермәсләр, эзләп тә килерләр. Хәлимәбикә апаң көннәренә генә калдырмаса ярар иде.

– Кыз башы белән никадәр утырып чыкты, – диде ата кеше. – Сугыштан качканнар урманда ял итте. Беркем барып әләкләмәде. Зыян салуларыннан курыктылармы? Үзләре кебек имансызларның исән калуын теләделәрме?..

– Сугыш бетте бит инде. Хөкем дә итмәделәрмени соң?

– Алар кемгә кирәк?! Рәхәтләнеп яшиләр, ди. Рашит абыең әнисенә качмый-нитми кайтып киткән. Исән калган бит! Караклыгы түгел, дезертирлыгы өчен дә утырмаган.

Галинурны, бәлки, яшь дип кызганырлар. Ашатып-эчерде дә, мунчага да кертеп чыгаргач, өстенә абыйсыннан калган чиста киемнәр кидергәч, идән астына мендәр-ястык ыргытып, улын шунда төшереп җибәрде Зәмниха. Таң беленер-беленмәстә ишегалдына караса, күзенә күренә мәллә дип тора: Әмирхан абзар ягыннанмы, лапастанмы чыгып килә. Актарынып йөрүне бу юлы үзебезнең абзар артыннан башлаган, дип уйлады Зәмниха. Теге

чактагы кебек тирестә ятадыр, дигәнме... Башка бер-бер мәкере булганмы, бармы?..

Зәмниха, күршесе өйгә кермәсен дип, каршысына чыкты:

– Ни булды, Әмирхан?

– Зәмнихатти, артыгын әйтеп тормыйм, эшнең нәрсәдә икәнлеген беләсең. Кеше-кара күргәнче хәл ит, бүген үк эзләп килмәгәйләре, – диде Әмирхан. – Мин әле өч көн түзәм. Аннан да алда хәбәр итмәүләре дә бар, дип уйлыйм. Качканлыгы тиешле урынына килеп кермәгәч кенә беленер.

– Галинурны үзебезнең дә күргән юк, – дип каршы төшә башлаган иде дә Зәмниха, председатель бик тиз туктатты:

– Аңгырага салынып маташма! Син түгел, мин дә беләм!

«Ничек аның кадәр күп вакыт бирәсең әле син, бар, йөгер, хәзер үк күршеңне төшеп әләклә. Без монда кичләрен бал чөмереп ятканда, ул станок артыннан да кайтып кермәгән, мәктәп баласы гына булгач, эшнең авырлыгына, ачлыкка түзмәгән, ә аны җәһәннәмгә мин җибәргән идем, дип әйт!» – дип кычкырасы, лачкылдатып, битенә төкерәсе бик килгән иде, Зәмниха түзде, малаеның язмышын начар якка хәл итәр иде ул сүзләр.

Колхоз рәисе, күршеләрен кызганудан битәр, үзе өчен кайгыра, качкыннарны тапсалар, аңа да гаеп ташлаячакларын белә иде. Болай – кереп куркытып – Галинурны яңадан элекке эш урынына җибәрәсенә өметләнде. Чыннан да, районнан эзләп килүче мылтыклы адәмнәр озак көттермәде. Дүртенче көннең төш вакытында алар Әхмәтгалимнәрдә иде инде. Зәмниханың өстәлгә таба күтәреп килгән самавыры чак кулыннан төшеп китмәде: ишекне сак кына, күңелгә шик йөгертерлек итеп кенә шакыдылар. Шакулары йомшак булса да, сөйләшүләре каты иде. Өй пыран-заран китерелде, чормалар актарылды, абзардан мал чыгарылды... Түрдә авырып яткан Әхмәтгалим дә кузгатылды. Галинурны эзләп-эзләп тә таба алмагач, өркеп беткән Зәмниханы тагын да ныграк куркытырга тотындылар.

Әмирхан:

– Бүген үк кире китә алмаса, инде дә эзләүчеләрдән тегендә-монда качып котыла алса, сезгә өч көн бирәм, – дигән иде, бигрәк тизләгәннәр болар, ни кадәр ара үтеп, безнең янда өч көн дә яшәп кала алмагае Галинур, дип уйлады Зәмниха. Өйдә калдырып, ялгышты бугай. Урманга җибәрергә йөрәге җитмәде. Нинди хәл булмас, ничек тамагын туйдырыр, дип уйлады. Әтисе, әнә, иптәшләре белән бүреләргә юлыкты. Ак бүреләр икән. Ябыклар, ачлар.

Бүреләрне авыл тирәсендә күрүчеләр дә бар. Әхмәтгалиме, ак бүре башка – салкын якларда яши, болары картайганга, хәлсезләнгәнгә агарган; тук булсалар, котырык белән чирләмәсәләр, авылга килмиләр алар, ди. Ач вакытта үз туганнарын да ашый икән алар. Хәлсезләнгән, яраланган иптәшләрен өзгәләп кенә ташлыйлар, ди. Авылдашларына көн күрсәтмәгән Әмирханны юкка гына Бүре димиләрдер. Еракта кыштырдаганыңны да ишетә ул бүре. Ояларына балаңны ничек чыгарып җибәрәсең?

Зәмниха, тыныч калырга тырышып, килүчеләрне өстәл янына чакырды. Булдыра алганының барын табынга чыгарды. Өйасты капкачы турысына палас җәеп, өстәлне шуның өстенә утырткан иде. Берсе шуны сизде. Зәмниха күреп торды: өстәл урынында түгел кебек тоелды аңа. Рәхәтләнеп ашап утырган җиреннән тукталды да аягы белән паласны капшарга кереште,

аннан карчыкның кулларына карап тора башлады. Болай да куркуы җитәрлек Зәмниханың бармаклары туктаусыз дерелдәргә тотынды.

Тамаклары туйган, күңелләре булган иде инде. Тикшерүчеләр, табында бер кабарлык ризык калдырмаганнан соң, өстәлне күчереп, идән астына төштеләр. Зәмниха аңы китеп егылды. Йөрәгенә түзә алмаган Әхмәтгалимнең качкынны эзләүчеләр әйләндереп ташлаган әйберләрне җыйнап, тәртипкә салып, абзар-лапас тирәсендә йөргән чагы иде. Бу хәлне белми калды.

Мылтыклы адәмнәр төштеләр дә шунда ук кире дә менделәр. Идәндә тәгәрәп яткан карчыкны күрделәр. Мәрхәмәтләре килеп, битләренә суккалап, аңына китерделәр дә ишеккә юнәлделәр. Беркемне тапмаганнарына ачулары алай да нык чыккан, өстәлгә рәхмәт тә әйтмичә, котырынып китеп барулары иде. Конвоирларның соңгысы, ишекне япканда, кулындагы наганын имән бармагында әйләндергән булып маташты. Кисәтүе, янәсе.

Зәмниха буп-буш өй астыннан Галинурны тапмауларына бик аптырады. Өй асты тишегеннән башын тыгып карады: караңгы почмакта, чыннан да, беркем юк. Мендәр-ястык та күренми. Идән терәткән баганаларга бау белән аскан аларны Галинур! Ничек шикләнмәгәннәр?! Зәмниха баскычны турылады да, әле генә ничә иргә чыдаган аркылы такталарының сынып китүеннән сакланып, аска төште. Нигезгә ясалган җилләткеч киергесенең алынганын, ташларның урыныннан купканын күрде – малайның төн буе, бер-бер хәл килеп чыкса дип, үзенә качарга юл киңәйтеп ятканлыгын аңлады.

Ул арада Галинур да кайтып керде – тау як басуында качып яткан.

– Болай булгач, иртәгә үк кеше-кара күргәнче, абый янына чыгып китәм. Монда яшәп, тормышыгызны җиңеләйтәсе идем дә, булмады, – диде ул.

Рәгыйдә бу көннәрдә колхоз эшеннән кайтып керми, кичен-төнен фермада ята, урманга йөри, тегесен эшләтә, монысын оештыра, юньләп күрешкәннәре дә юк иде. Бераздан кичке аш җиткәч, шәлләре җилкәсенә төшкән Рәгыйдә дә күренде.

Өстәл тирәсенә утырышып, чәй эчәргә керештеләр.

– Энем, бер дә түзәрлек булмадымыни соң? – дип сорады Рәгыйдә апасы да.

– Агач барагыбыз төннәрен салкын, тузып беткән диярлек, тәртип яраткан кеше аз. Ашау ягы такыр – моңа кадәр бирелгән икмәк телемнәре нәзекләнгәннән нәзекләнә, сыйфатсызлана, башкасы бөтенләй юк.

– Шулай... Сәвит алырга гына белә, – диде ачуы килгән ата.

– Инде сугыш та беткәч, укырга китү дә барып чыкмагач, урман кисәргә ерак Себергә үк җибәрәләр, дигән сүзләр дә йөри башлагач...

– Качып дөрес эшләгәнсең. Ат кебек гәүдәң белән син дә чыдамагач!

– Егылып үлүчеләр дә булды. Кайсы – чирдән, кайсы – хәлсезлектән. Тамагы сау, эшне яхшы эшләгән кешегә бик читен. Ялкаулар анда да әкренгә йөрүен белә.

– Мәҗбүриләп, мәктәпне ташлатмасалар, укып йөрер идең әле, энем.

– Тегендә дә, үзең сәламәт, буең да бар дип, олылар гел аны йөгертәләр икән. Кешедән әллә никадәр артык эшләгән, каршы төшәргә уңайсызланган, – дип, үз сүзен кыстырып алды Зәмниха.

– Менә шул инде ул – олы сүзен сүз ит, дип үстерүләребезнең бәласе, – диде, артыгын катнашмыйча, читтән тыңлап торган Әхмәтгалим.

– Ничекләр исән калган инде?! Әнә, Фәхрибануттәеңнең Кенҗәбикәсен яңа алып кайтып күмделәр, – диде Зәмниха.

– Нәрсә булган?

Әхмәтгалим кул гына селтәде. Моны аңлата алырлык хәлдә түгел иде. Зәмниха урын җәяргә кереште. Рәгыйдәгә сөйләп бирергә туры килде:

– Ул да поезд өстендә ялга кайтырга булган. Күп эшләтәләр, аз ашаталар, ичмасам, ял көнне тамагымны ялгап китәрмен, ди икән.

– Кара инде, әнисе үзе дә Сәрбиҗамал кодагыйның биргәне белән генә яши.

– Шулай да бит, энем. Анасы кеше биргәнне үз тамагыннан өзеп ашата инде. Хәзер беркемнең дә артыгы, башкаларга таратырлыгы юк.

– Мәктәптәге укуларны туктаттылар. Җеназада булганнар һаман шуның турында сөйләшә. Йөзләре, тимер чыбыкка киселеп, кайтарылып ук чыккан иде. Үлгәч, түбәдән кайдадыр егылган. Эзләп алып кайттылар, – диде Зәмниха.

Рәгыйдәнең ачуы бигрәк тә авыл советы тирәсендә эшләгәннәргә килгән иде:

– Фәхрибануттәй кәнсәләр идәнен югач, шунда көн иткәч, аңа миһербанлырак булырлар дип уйлый идем, аның да бердәнбер кызын адәм заты чыдамаслык эшләргә җибәрделәр.

– Кайда ие соң ул?

– Якын тирәдәрәк. Синең кебек хәрби заводта түгел бугай, тимер юлда эшләгән, шпаллар алмаштырган шикелле. Шуңа күрә атна саен авылга чапкандыр да инде.

– Атаңнар, кәнсәләр дип тормады, мулланы шунда чакырттылар. Мин дә төн сакларга бардым, бар белгәнемне укып утырдым, – диде Зәмниха.

Сөйләшеп сүз бетмәслек кебек иде, тик барысының да хәсрәтне көчәйткәнен күргәнгә, башка борчуларын яңартмадылар.

– Әле дә исән калгансың, – дип куйды сәке кырында мендәр кабартып торган Зәмниха. – Әтиегезнең намазга баскан саен кылган догалары булышкандыр инде. Мин дә суга барганда да теләдем, судан кайтканда да. Су юлындагы теләкләр кабул дигәннәре хак икән.

Күптән шаяртмаган Әхмәтгалим күңеленә җылы өстәп елмайды:

– Әйтәм җирле, сине су буенда күргәннән соң өйләндем.

Зәмниха каршы төшмәде, иренең кайчандыр җырлаганына тартым җыруы белән җавап бирде:

Су буенда агачлык.
Син – тирәктер, ә мин – тал.
Алсаң, шуны белеп ал,
Сөя алсаң, сөеп кал.

Әле дә ярый сиңа чыкканмын, әле дә ярый син исән, Әхмәтгалимем.

– Балаларныкы менә ничек булыр...

Һәр шатлыкта моңсулык төсмерләре бар, нинди еллар соң бу, дип уфтанды эченнән Зәмниха. Инде ул Әхмәтгалиеннән дә тагын бер, алдагысыннан юньлерәк хәбәр көтә, Алла кушса, иртәгә төпчеге аның янына сәфәргә чыгачак.

Яман холыклы, явыз ниятле булса да, авылда күрше белән яшисең. Араңны бозмаска тырышасың. Күпвакыт үпкә-фәләнеңне эчеңә йотып, ачык йөз белән каршы аласың, чәеңне куясың.

– Явызлыкларыннан туеп, башкалар кебек, артында, канечкеч, Бүре, ди идем Әмирханга, бу яхшылыгын онытмам, бер тапкыр да кушаматы белән әйтмәм, күршекәем, дип ягымлы итеп эндәшермен, – дигән иде өч көн эчендә беркая хәбәр итми торган күршесенә күңеле булган Зәмниха. Сүзендә торды, әмма барыбер аны юньлегә саный алмады.

Колхоз рәисе үзенекеләргә дә начар иде. Әледән-әле өендә тавыш куптара. Бичара Камәрия, иреннән ычкына алса, рәттән торган күршесенә түгел, өч өй аркылы яшәгән ахириенә йөгерә. Андый чакта араларына керә, йомшак холыклы хатынны ире кыеныннан сакларга күнеккән иде Зәмниха. Теге хәлләрдән соң берничә көн үтүгә, кычкырышып, урамга чыкканнарын күрде дә Әмирхан каршысына йодрыгын селкеп килде:

– Синең рәислегеңә карап, Зәмниха башым белән Камәрияңне кыйнатып, талатып тораммы соң?!

Йодрык селкүе бер нәрсә, урта бармагын очлатып, Әмирханның маңгай уртасына шәп кенә төртте.

– Күгәртәсең бит, кеше арасына чыгарлыгын калдыр, – дип мышкылдый башлады Камәрия.

Ирләрнең йодрык белән китереп тондыруыннан да яманрак иде бу. Көч тә икән Зәмнихаттидә дип уйлап, күзләрен акайтты Әмирхан, каршы суксам, икенче җавабында аяктан ук егачак. Әмирхан болай да түрәләр каршысына бил бөгеп бармаган, авылда дәрәҗәсе зур сөннәтче карчыктан шүрли иде. Үз балаларының да кендек әбисе иде ул. Хатынын дөмбәсләү уеннан кире кайтты – өенә китте. Кара син гайрәтләнүен, дип сукрана-сукрана, Камәриясе артыннан кермәсен өчен капка аратасын этте. Әнә, бик булдырса, койма аша сикерсен йә күршеләрендә генә яшәсен.

Зәмниха карчык куркуыннан дерелдәп торган Камәрияне кызганды.

– Әйдә, безгә керәбез. Синең ялкау, явыз Әмирханың ашарга таба белмәсә дә, кеше куркытырга, өйрәтергә булдыра. Тимер мичне генә кабызырбыз да өстендә коймак пешереп ашарбыз. Дучмакларым да бар иде дә бит, балаларга менгездем.

Камәрия сүзсез генә аның артыннан иярде.

– Күршекәем, ишетелмәдеме, кем дә булса мунча якмаганмы? – дип сорады аннан Зәмниха. Ул, әнисе Нихан кебек, бер мунчадан чыга, шул арада икенчесенә керә иде. Ләүкәдән төшмичә юынуына аның янәшәсендә һичкем чыдамый. Шуның өстенә, туктаусыз эссе сала, чабына. Моны белмичә, бергә керәбез, дип ияреп баручылар, ул юынып чыкканчы, өйалдында утыра, кыш көне кире өенә кайтып китә торган иде. Камәрия юаш кына, оялып кына:

– Иртәгә үзебез ягарга уйлап торабыз, – диде.

– Явыз Әмирхан мунчасына керәмме соң?! Берәр сүз әйтсә, йә ул исән кала, йә мин.

Күршесенә Зәмниханың электән дә үпкәләре җитәрлек иде. Сугыштан иртәрәк, имгәнеп кайткан Әмирхан Әхмәтхәсән балаларының авыр елларда да яхшы торуларыннан көнләште, ачуына буылырдай яшәде. Ничек боларга зыян салырга дип, төннәр буе йокламый ята иде. Ахырда уйлап тапты: югары белемең юк дип, Әхмәтгалимне эштән алырга кирәк! Колхоз рәисенең авызыннан шундый сүз чыкканга барысы да аптырады.

Авылда зурга укыганнарны чыра яндырып эзләсәң дә, таба алмыйсың, агрономлыкка һич югы техникум бетергәннәр хакында әйтеп тә тормаслык иде.

Үз эшен бер дигән башкаручы, кул астында эшләүчеләргә таләпчән, агрономлыкны белгән Әхмәтгалимне алдылар, тик урынына кемне куярга белмәделәр. Хәзерге заман институтын түгел, мәдрәсә дә бетермәгән иратлар аннан бушаган урынга килергә ашыкмады.

Ә бит Әмирхан җиңелчәрәк гарипләнеп кайтканчы, сугыш вакытында ирсез яшәгән Камәрияне бер дә ярдәменнән ташламаган иде Әхмәтгалим. Сөннәтче, дәвачы Зәмнихасының да яхшылыгы күп тигәндер. Аның өчен генә, сөннәт пәкесен кулга бер дә тотмаячакмын дип әйтеп, икенче кат яшергән җиреннән алып, эшкә керешкән иде ул. Йөзенчесе үлә, дигән сүзне дә әйтеп карады, тегесе тыңларга да теләмәде. Баласы исән-сау булсын, дип, дога кылып, йөз дә бер, дип санап китте Зәмниха... Барысы да онытыла икән, дип үпкәләде Әхмәтгалим. Күршесенең яманлыкларыннан йөрәк хасталыгы тагын да көчәеп, кан басымы бик күтәрелә торганга әйләнде.

Әхмәтгалимгә әле алтмыш тирәсе генә, кул кушырып ята алмый иде. Хәлимәбикә качып кайтыр алдыннан гына тотты да урман артеленә керде. Акчасын да ала, агачын да бирәләр, ризыгын да өләшәләр иде. Яраткан эшеннән чыгаруларына, артельгә юлның ераклыгына йөрәге әрнесә дә:

– Колхозга бушка эшләп тә ярамадым, монда ичмаса акчасын да алам, кадерне дә беләләр, – дип, үз-үзен юатты. Хезмәт көненә генә яшәүнең мәгънәсезлеген, авыл кешесенең чарасызлыгын аңлаган, инде нишләргә белми аптыраган чагы иде.

Бер-бер артлы килгән төрле хәсрәтләргә батып, Зәмниха бик озак әниләренә бара алмый торды. Соңыннан моңа үкенде. Сиксән өче тулган Нихан карчык көннәрнең берендә, аңа җиткерәсе васыятьләрен энекәшләренә генә әйтеп, якты дөньядан китеп барган иде. Шуның аркасында Хәлимә белән Галинур борчулары чигенде, кысыраеп китте. Хәсрәтле хәбәрне алуга ук, кирәк-яракларны җыеп, Зәмниха белән Зәлиха туры юлдан урман аша гына Шүләнгергә чыгып чапты.

Башка бер чакта кунакка барганда, кошлар сайравына сокланып, юл буендагы чокырлардан сулар эчә-эчә, җиләкләр капкалый-капкалый, агачлар белән сөйләшә-сөйләшә барган булыр иде Зәмниха. Аның йөрәге бүген әнисенә җитәрлек хөрмәт күрсәтә алмавы өчен сыкрады. Юл аңа артык озын тоелды. Тизрәк барып җитәсе килде.

Зәмниха, әле җиңел генә, әле сөртенгәләп атлый-атлый, ничә еллар ирсез тормыш алып барган Нихан карчык, аны иртә ташлап киткән әтисе турында уйлады, ахыргы көннәрендә әнисен караган энеләренә рәхмәт укыды. Уйлары күп, хәсрәтләре күтәрмәслек булса да, җеназаны тоткарламыйк дип, яңгырдан соң тигезсезләнеп кипкән урман юлыннан ашыга-ашыга бардылар.

Әхмәтгалиме ат белән дә илтеп куя алмады шул дип, үз туганнарыннан, күрше-күләннән кыенсынды Зәмниха. Нихан – сезнең әниегез түгел дип, ирләрен дә, балаларын да ни артель, ни колхоз эшеннән калдыртмаганнар. Кечкенә Газизәбану белән Миңлебануны, җәяүле юл ерак, мәет күрү ныгымаган йөрәкләренә ярамас дип, үзе дә алмаган иде ул.

Дүртенче бүлек

Ындырында чары[7] бар, күзе ачның бары бар.

1

Кыр эшләренә чыгар алдыннан Дәррә бәйрәме узды. Елның-елына бакча башларында дәррә боткасын Зәмниха карчык пешерә. Ул тирәдәге калкулык өсләре тигез, чишмә якын – көн буена сузылган бәйрәм өчен чәйгә суны шуннан гына ташыйлар.

– И-и-и, ботканың тәмлелеге, Зәмниха, – дип, тәлинкә тотып, олылар да килә. Әллә күпме кешегә, читтән килеп чыкканнарга да җитәрлек итеп, ике казан пешерә ботканы Зәмниха. Ярмасы – халыктан җыелган, сөте-мае – үз сыерларыныкы. Ярмасы югы бәрәңге булса да китерә, анысын учакка да ыргыталар, боткага да кушып җибәрәләр. Төтен исләрен, май тәмнәрен сеңдерә-сеңдерә пешкән ботканы туйганчы ашаганнан соң, калганын бүлешеп, өйләренә алып китәләр. Тәлинкәдә кайтканы – Дәррәгә килә алмаучыларга, кемдер тавыгына да сорый. Имеш, бу ботканы ашаган тавыклар көн дә йомырка сала, хаста кеше мәңге китмәс кебек чиреннән дә терелә.

Зәмниха карчык җыелган йомыркаларны да су буена кичке уенга төшәсе яшьләргә үзе пешереп калдыра. Югары оч Дәррәсенең даны Аксыбы, Алгайларга кадәр таралган. Шул ук ярма, шул ук сөт, шул ук май, ди аннан авыз иткән кеше, тәме бөтенләй башка, әллә соң мең үләннең серен белгән Зәмниха карчык шуларны да саламы? Зәмниха үзеннән сораучыларга серле генә елмая да:

– Тәме сыер сауган кулларымда, боткага ярма чистарткан бармак очларымда, май язган гөбе чиләгендә, – ди.

Дәррәнең икенче көнендә Әхмәтгалим кыр җиренә йомырка тәгәрәтә торган иде. Аларын да соңыннан җыеп ашыйлар аның. Ул йомыркалар – сабанчыларга, игенчеләргә. Әхмәтгалим бу ел Дәррәгә чыга алмады, кырның өлгергәнлеген тикшермәде, барометрының эшләү тәртибен аңлатып-күрсәтеп, шуны сорап төшкән малайга бөтенләйгә тоттырып җибәрде. Зәмниха моңсуланды. Кияүгә чыкканнан соң, Галименнән башка уздырган беренче бәйрәме иде бу.

Дәррә ризыкларының Әхмәтгалимгә дә шифа бирәсенә өметләнгәч, картым урында ята, мин монда ботка пешереп йөрим, дип борчылмады Зәмниха. Башкаларга булган дәва аңа ник ирешмәде соң, дип сыкранды ул соңыннан. Догасын укыган, шифасы тисен дип, тәлинкә тутырып салган боткасын, йомыркасын өшкергән, теләкләрен елый-елый теләгән иде югыйсә.

Ире авыргалап торса да, шушы яшендә үк урынга калыр дип уйламады да уйламады Зәмниха. Бөтен нәрсә дә син дигәнчә генә булмый: гел көтмәгәндә нык чирләгән Әхмәтгалим, күңеленә менә терелә, менә терелә дигән өмет чынлап узгач, кырык җиденең апрелен чыкканда, ялгызын калдырып китеп тә барды. Дөньяның гаделсезлекләреннән бик тузган, балалары өчен борчылган йөрәге озакка чыдамагандай булды.

Үләренә ун көн кала Әхмәтгалим Зәмниханы эшеннән бүлеп, караваты янына дәшеп алды да кулларын сак кына учларына салды:

[7] Чар – кибәк.

– Тормыш мәшәкатьләре белән, туйганчы сөйләшкән дә булмагандыр.

– Менә бит сөйләшәбез.

– Юк, мондый гәпләшүләрне генә әйтмим мин. Өйләнгәндә, сиңа иртәсен дә, кичләрен дә гел ярату турында сөйләрмен кебек иде...

– Егет уенда башка ни булсын?!

– Анысы кемдә ничектер.

– Өйләнгәч, егетлек артта кала.

– Эш анда түгел, Зәмниха. Ул чакта әле мин сиңа матур сүзләрне көненә бер булса да әйткәнмендер.

– Әйттең.

– Әкренләп, аларны борчулар, хәсрәт-кайгы хәбәрләре алмаштырган икән бит... Тормыш нинди чакта да күбрәк табарга кирәк булган ул матур сүзләрне, мактау-сыйпауларга вакытны күбрәк табарга кирәк булган.

– Мин синнән болай да бик канәгать.

– Яхшы булырга тырыштым да тырышуын, тик җитәрлек кадерләдем микән, дип кайгырам.

– Башка борчуларың булмаса... Тапкансың, – дигән булды иренең бу уйларына аптыраган Зәмниха.

– Инде менә әнине, кызларымны да кадерли алдым микән, дип кайгырам.

– Алдың, алдың. Син дә шулай дигәч.

Зәмниха Әхмәтгалимнең бармаклары дерелдәгәнне тойды. Күзләренә карады: керфек төпләре яшьләнгән. Моны күргәнен сиздермәскә тырышты.

– Андый гына уйлар кемгә дә килә ул, картым. Мин дә үземне үстергән әти-әнигә җитәрлек ярдәм иттемме, дип уйга калгалыйм. Каенанам белән каенатамның күңелләренә тиярлек сүзләрем чыкмадымы дип борчылам.

– Хәлләрне ныклап белешеп утырырга вакыты да табылмаган аның.

– Картайгач, вакыт бар нәрсәгә җитә. Тормышны гына элекке кебек алып бара алмыйсың.

– Мәңге яшәр кебек... – дип өстәде Әхмәтгалим. – Бер җыру җырлап бирим әле үзеңә:

Аккош күрсәң, атып ал,
Былбыл күрсәң, сатып ал.
Сагынганда бер җырларсың,
Бу җырымны отып ал.

Алай ятсам, сызланам,
Болай ятсам, сызланам,
Өчегезнең арагызда
Галинурны кызганам.

Зәмниха сәерсенде. Аның исән биш баласы бар иде. Карале, кечкенәдән вафат булмаганнары һаман да исән-сау бит, дип сөенде. Бер уч икән бит алар. Кайсы бармагыңны тешләсәң дә, авырта... Галинурны кызганам, ди карты. Нидән икән бу сүзләр? Менә ул Галинурны да үстерешкән, хәзер бөтен тормышларын җигеп барган, колхозның эш атына әверелгән Рәгыйдәне кызгана. Бер эштән кайтып керә, икенчесенә чыгып китә. Бөтен күргән кызыгы, ялы – җәйге уенлыктан артык түгел. Анысы да йокы хисабына аның. Таң атканчы, фермасына китәсе, аннан – нәрәденә[8], ул арада бригадасын йөреп чыгасы.

Галинур да кызганыч анысы. Төпчеген әтисенең аерып куюына гына гаҗәпләнде Зәмниха. Миннән башка каласың, сине бигрәкләр дә җәллим,

[8] Нәрәд – колхозда көндәлек эшләрне билгели торган иртәнге җыелыш.

димәде карты. Рәгыйдәнең үз тормышы юк әле, дип тә әйтмәде. Галинур үсмерлектән чыкмаганга, кайбер олы кеше дә күрмәгәнне күргәнгә, аны аерып алып кызгана микән әллә?

Зәмнихага ташлама, кара, булыш улыма дип, нәзер әйтүеме бәгырь кисәгенең?.. Әллә нинди, соңгы сагышлы сүз кебек ишетелде аңа бу җыру. Кинәт имәнеп китте. Әхмәтгалим йөзеннән күзләрен алмый утыра иде. Керфекләрен йокы баскандай, хәле киткәндәй төшергәнен күрде. Тын алганы да беленми. Гәүдәсен капшады. Уф, исән...

Чынлыкта да, Галинурыма тормыш барысыннан да авырга килде дип, еш уйлады соңыннан Зәмниха. Ничек кенә сынамады аны михнәт арты килгән михнәт? Башта да, атасы вафатыннан соң да. Әхмәтгалим юкка кына кызганам дип әйтмәгәндер, алдагысын да күңеле белән тойган булыр.

Элегрәк Зәмниха күбрәк Әхмәтгалине уйлый иде. Яшьлеге иң авыр елларга туры килде, бер рәхәт күрмәде, инде фронтта, әсирлектә нәрсәләр генә кичермәгән, дип кайгырды. Дөрес, олы улы күпләр чит җирләрдә ятып калган сугыштан исән кайтты. Туган җирендә яшәргә ярамаса да, шул исәнлеге белән күңеленә ниндидер тынычлык китергән иде.

Кире әйләнеп кайтсын дип, икмәк кыерчыгы да биргән иде Зәмниха Әхмәтгалигә сугышка киткәндә. Газизәбануларга биргән кәнфитләрен үзенә кайтарган, кызларга башка күчтәнәч тоттырган иде. Әллә соң тамагы бик ач көннәрдә шул кыерчыкны бөртегенәчә ашап бетергәнме?! Бер почмагын гына булса да китеп калдыр, өеңә кадәр җиткерер, дип әйтергә башына да килмәгән.

Әхмәтгалиен ата-ана кадерен бик белә, туганнарын кайгырта дип ярата иде Зәмниха. Больницадан чыгуга ук, әле караватта ятканда да, күчтәнәч салуның җаен тапкан. Анда да гадәтенчә шаярткан, посылка килеп җиткәнче, шул хакта хәбәр итә торсынга язган хатында: «Әнәй, син бик борчылма, мин – сугышчан яралы: күчтәнәчне тутырганда, бармакларым канады», – дип язган. Кулын тартманың чыгып торган кадакларына ерттырган икән.

Таякка таянып йөрсә дә, үпкәсе чирләсә дә, күкрәкләре сулуны гыжылдап кына алса да, эшкә яраган Әхмәтгалие – шахткомга җитәкче итеп куйганнар. Соңгы хатында, яңадан сугышка керергә бик теләгән идем, фронтка китәрлек җирем калмаганлыкны әйттеләр, дигән. Тыныч заманнар җиткәч, теләүчеләр монда килерләр, бөтен авылны шахтага эшкә ала алам кебек сүзләренә кешеләр бик ышанып бетмәгәндәй күренгәннәр иде дә... Өскебашларның шактые улы янына урнашты. Әхмәтгали хәсрәтле көннәрендә Галинурны да сыендырды.

Зәмниха улына кайтырга ярамаганлыгын белгәч түзмәде, үзе күреп килергә булды. Әхмәтгалимем авыру килеш тә барып кайтты, аннан кай җирем ким, дип уйлады. Чирле вакытында әниеңне күрү – үзе бер шифа ул. Әхмәтгалим Зәмнихасы, мин дә Донбасска барам, дигәч, борчылды:

– И-и карчык, яшең бар, дөнья күргәнең юк, юлда нинди хәлләр булмас? – диде.

– Соң, шул дөньяны күрергә барам да. Аның бер почмагында көн итеп яткан улымны. Никадәр җиләк киптердем, келәттә бер капчык чикләвек бар әле. Дару үләннәрем дә җитәрлек. Кайнатып эчсә, авырган тәннәренә сихәт бирми калмас.

– Аларны бит посылка белән дә салып була.

Кешегә нык, авырлыкка чыдам күренгән Зәмниха, Әхмәтгалимем риза булмый икән, дип мышкылдый ук башлады:

– Аны күрмәүгә сабырлыкларым калмады. Җибәрмәссең микәнни инде?

Риза булмаса да ризалашты Әхмәтгалим. Алай да шушы сүзеннән чикмәде:

– Барсаң да, кодагыең белән генә барасың! Шушындый заманда берүзеңне чыгарып җибәрәмме соң!

– Өеннән китә алмаса?

– Алыр. Карты белән үзем төшеп сөйләшермен.

Сәрбиҗамал, Гаделша да тиз генә ризалык биреп ташлагач, Зәмниха белән Донбасс тиклем Донбасска баруына сөенде генә. Җитмәсә, улларында ике атна ук кунак булырга килештеләр. Сөенмәскә соң, аның да Габделкарие Донбасста яшәп, эшләп ята иде бит.

Әхмәтгалинең әнисен ике атнадан соң да җибәрәсе килмәде. Сәрбиҗамал түтәе сөйләшенгән көнне Карилардан кайткач:

– Әнәй, билетларыгызны алмаштырам, әтәйгә телеграмма сугам, – дип тә карады.

– Юк инде, улым, җитәрлек кунак булдык, монысына да бик шөкер. Әтиең ялгыз, миннән башка ике кулсыздыр.

– Рәгыйдә белән Галинур шунда бит!

– Мин аны өйдә гомерем буена бер кичкә дә ялгызын калдырмаган. Шүләнгергә барсам да, шул арада әйләнеп кайта идем. Монысын да синең хакка гына киттем.

Әхмәтгалиләрдә озаклап ятарга теләмәүнең башка сәбәпләре дә бар иде. Хатыны марҗа булса да, бик яхшы кунак итә, «анай» килеп чыкса да, татарчалап, өзелеп:

– Әнәй, – ди дә тора.

Тик анда да паёк заманы икән, аларныкын ашаган кебек Зәмнихага. Сәрбиҗамал калырга теләмәде дә теләмәде: гаугалы-җәнҗаллы, малаена көн күрсәтмәгән, эчеп тә кайткалаган үз килененнән бөтенләй арыган, бездә генә тор, дисәләр дә, Әхмәтгалиләрдә яшәргә кыенсына иде.

– Атна буе чырае ачылмады Саймәнең, – диде ул, малайларыннан әйләнеп кайткач. – Синеке менә, марҗа булса да, алдында гына шулаймы-юкмы, белмим, үзен мөселманча тотып маташа, минем татар авылында туып үскән килен көн дә диярлек салмыш.

Шахта тирәсендә башкаларга ияреп, авыл кызлары да бозыла дигәнне ишеткәне бар иде Зәмниханың, шул килеш тә кодагыеның бу сүзләренә шаккатты. Үзенекеләр арасында мондый киленгә өйләнгәннәрнең барлыгын һич кенә дә сиздерәсе килми иде.

– Аннам янында урысчалап кына сөйли күрмә бу сүзләрне берүк, шундый татарлар да була микәнни, дип аптырар. Болай безнекеләргә исе китә инде, улымны да мактап бетерә алмый, – диде ул кодагыена, башкалар ишетмәслек итеп пышылдап кына. – Килен Әхмәтгали кебек тамчысын да авызына алмый. Табиб бит югыйсә. Спирт – үз кулында.

Әхмәтгали Анна белән лазаретта ятканда танышкан икән. Ул әзмәвердәй егетнең аяктан калганын күргәч, дәвалый алмаммы, торыр җире юк, үз ягына да кайтырга ярамый икән дип, йортына алып чыккан. Бер-берсенә

иялəшкəннəр дə бергə яшəп киткəннəр. Дəвалап ук бетерə алмаса да, аягына тəки бастырган Əхмəтгалине.

Анна белəн кушылуы турында хатка язып салгач, əнисе җавабында:

– Менə шушы була ул, улым, уникегə өйлəнүлəрнең башы, – диде. – Яшь чагында уйнап сөйлəшкəн кебек кенə идең...

Əхмəтгалинең урыс кызына өйлəнүен Зəмниха гаепли дə алмады: аңа караучы, дəвалаучы, урында ятканда, янында утырырлык кеше кирəк иде. Авылдан кем аны карарга дип бара алсын? Үзе дə олыгайды.

Марҗа килен каенанасына да, кодагыена да бүлəкне күп алып кайткан. Күтəреп килгəн чемоданнарына сыймады да. Саймə салмыш булганмы – озатырга килеп тормады, əйберлəрне вокзалга Габделкари күтəреп илтте.

– Марҗаның да нindие юк, татарның да, – диде юл буе Сəрбиҗамал.

Кари кунакка кайткач, Саймəнең яман гадəтлəреннəн җəфаланган əнисенең аh-зарына каршы:

– Акыл белəн өйлəнмəдем мин, əнəй. Һəрвакытта да яратып кына өйлəндем. Əхмəтгали абыйга кара. Исəп-хисап белəн корган гаилəсе ничек нык. Беренче хатынын яратып өйлəнгəн кебек иде. Сəрвəр апа хəзер башка кеше белəн тора.

Зəмниха аларда иде:

– Тора-а... Вакыт таптымы, миңа йөгереп килə. Сагынам Əхмəтгалине, ди. Тагын бер күрə алса, үлəргə дə риза кебек сөйлəшə. Кайвакыт кайсының яхшырак икəнлеген дə белмисең. Шунысы хак: юньлене яратырга кирəк.

– Аңламассың хатын-кызны. Сугышка озатырга да килмəгəн иде...

– Ходай шуны күргəндер дə янына кайтырга насыйп итмəгəндер.

– Яратып кушылмаганнар кебек иде дə, гөрлəшеп яши Анна апа белəн, – дип кабатлады тагын Кари. – Акыл җитмəгəн өйлəнгəндə, акыл.

– Əти-əни биргəнне алмаганмын, диген.

– Марҗага өйлəнəсе булма, дигəнегезне тыңладым бит.

Зəмниха киленен ашыгып мактарга курыкты:

– Марҗа белəн дə тормышның ничек килеп чыгасын алдан белмисең.

Əхмəтгалинең озакламый малае туды. Габделбари дип кушканнар. Үзебез Бари гына дип йөрибез инде, дип язган иде шул хактагы хатында, иптəшлəре – Борис. Ананың йөрəге жу итеп китте. Мулла кушкан исемне бозарга ярыймы соң?! Икенче кешегə əйлəндерү бит бу. Барилар урынына нindидер бер урысның – Борисның язмышын бирүгə ризалашу. «Улым, берүк исемен бозмагыз, боздыртмагыз, сүземне аяк астына салмагыз», – дип җавап язса да, үзен ишетəселəренə кайдадыр күңел төпкелендə шик туды.

Зəмниха соңгы вакытларда урамга чыктымы, беренче эше итеп, почта тартмасын карауны гадəткə алды.

– Көн дə хат килəмени? – ди Галим. – Улыңны гел уйлап торып, бимазалама инде күңелеңне.

Килмəгəнен дə белə, җаны түзми. Алгач, укырга чыдамый. Начар хəбəрлəрдəн хəлсезлəнə хəзер ул. Əхмəтгалимгə, башта син укы əле, дип тə əйтми, бергəлəп укыйк əле, дигəн була. Аның йөрəгенə дə авырдыр инде ул төрле-мөрле хəбəрлəр. Хəзер гел яхшысы гына килеп торса да, йөрəк элеккечə шомланып күтəргə күнеккəн...

Нəрсəгə булыр бу Əхмəтгалимнең мондый җыры?! Тегелəй уйлап

карыйсың, болай... Әхмәтгали өчен күңеле, чыннан да, тыныч кебек аның. Ямьбикәсенә инде ни дип кайгырсын: янында ире бар. Барыбер аптырата: тормыш кормаган балалары икәү бит әле. Өчегезнең арагызда, ди. Зәмниханы да күздә тота алайса. Аңа, Рәгыйдәгә шулкадәр ышана микәнни?.. Ә нигә Галинурны жәлли? Анысы абыйсыннан да иплерәк. Эчүне-тартуны бар дип тә белми. Иптәшләре әллә никадәр. Колхозда тагын әйбәт кенә эшләп йөри. Тегендә-монда көчләп җибәрү заманнары үтте. Авылның үзенә кеше җитми.

Әхмәтгалименә кайдан гына килде бу чир?! Хасталанып ук китмәсә, әле аныкы да ярый иде... Тормышларының иң авырайган чагы иде бу ел. Җитмәсә, каралтыларын салып бетерергә маташты. Тагын да ашар өчен эшләүчеләр белән җәфаланды. Элек әле бирерләренә бар иде. Сугыш чоры да җиңелрәк булган икән аның. Хәзер нәрсәң белән эшче сыйлыйсың да, ниең белән түлисең?.. Барысы тамагыңнан өзеп кенә.

Кияү төрмәсеннән, сугышыннан исән калса да, кулын имгәтеп кайтты, бабасына ул да булыша алмады. Үзләре һаман өй салып ята. Ямьбикә ирсез калган вакытта җиткергән йортны гына тарсынды Габделкасыйм. Сугыштан кайтуга, кызының ачмаган бер баз бәрәңгесе бар иде, шуны сатып, сыер алып җибәрделәр. Мондый вакытта дип, Габделкасыйм хатынына үзе дә шаккаткан. Сыерың булгач, тамагың көн дә тук, эшчегә ашатырыңа бар дип, йорт салу хәстәренә керештеләр.

Инвалидларга урманнан делянкалар бирәләр. Киявенә дә әлегүе яхшы булды әле. Шул бүленеп бирелгән җирне Рәгыйдә белән Галинур барып чистарттылар. Башта агачларын кистеләр. Кайсы – төзелешкә, кайсы утынга ярады. Тау ягында төзелеш агачлары сирәкләнеп бара. Татар кешесе урманны да, үзен дә кызганмый... Арлар, әнә, ямап-сипләп, иске өйләрендә яши бирә. Безгә һаман яңартырга, яхшыртырга булсын.

Бер карыйсың, балаларның тормышы көйле дип сөенәсең, икенче исәплисең, хәсрәт арты хәсрәт күргәннәренә килеп төртеләсең... Каенаталарын кулакка чыгарганда, сорау арты сорау алуга йөргән Ямьбикәнең йөрәге какшады. Табиблар мондый авыруларың белән бала тапма дисәләр дә, тыңламады, фашистны җиңгән көннең беренче бәйрәмендә үк иренә малай алып кайтып тоттырды. Алдагы елны туган Абдулласы үле иде. Гамир аны югалту хәсрәтен киметте. Алла кушса, Ямьбикәләр аякка басар. Бер кулы эшкә ярамаса да, ире бар, балаларының этиләре яннарында.

Хәлимәбикәсенең дә үз тормышы. Эше әйбәт. Хезмәт хакы әйбәт. Торган җирләре начар түгел. Ирен инде әйткән дә юк: яхшының яхшысы. Хәлимәбикә белән икесенең бер авыз сүзгә килгәннәре юк. Кияве Газизҗан да бабасына охшаган. Аның кебек күзең төшәрлек матур. Телгә – йомшак, эшкә – каты. Сугыштан аягын имгәтеп кайтса да, таза ирләрне узып эшли.

Зәмниха хәленең авырая барганлыгы күренгән ире янында уйланып утырганда, аның тигез, мыш-мыш сулыш алуыннан әкренләп йокымсырап китүен аңлады. Балалар кайтып җитәсенә күп калмаган, ашарга пешерергә кирәк иде. Тик кенә, авыруга карап кына, көннәр буе янында тора алмыйсың. Ул йокымсырап киткәндә, карыйсын карыйм дип эшкә тотынды. Тотынды, тик эше бармады. Башын әле генә Рәгыйдә, Галинур белән катырса, инде туктаусыз Әхмәтгалимне уйлый иде.

Нәрсәне нәрсә, сабыр холыклы ирен шушы яшендә – кыяфәтенә картлар төсе дә керә башламаган бер чакта – паралич сугар дип, һич башына китермәде Зәмниха. Матур яшәгәч, тигез картаерлар, көннәрдән бер көнне караватка икәүләп ятарлар да бергәләп йокыга гына китәрләр кебек иде аңа.

Әхмәтгалимгә эчергән даруларның, Алладан ялварып сораган, биш вакыт намаз артыннан һич калдырмый укыган догаларының да файдасы тимәгәч, авыл аша узып барган чегәннәр сүзенә алданды.

Әхмәтгалим хәлсезмен дип тормады, кеше арасында буласым, бераз файда да күрсәтәсем килә дип, таякка таянып, урманга чыгып китте ул көнне.

Җилкәләре салынып төшкән... Җегәрсез... Алай да, чак-чак селкенеп, лапас капкасына атлады карты. Бакчасыннан да төшәр, суын да чыгар, әле тауга күтәреләсе бар бит, дип борчылып калды Зәмниха. Ай-һай, бара алыр микән, соңгы тапкыр егетләнүенә генә охшаган... Әллә инде... хушлашып йөрүеме? Ничекләр генә терелтергә соң аны?

Сатар әйберләре сатылып беткән, акчасы бик күпләрнең кесәсенә күчкән иде инде. Башка чарасы калмаганга, шул көнне Әхмәтгалимемнең нәселе рухына дога кылып кайтыйм, күңелемне басыйм дип, авыл кырындагы зиратка төшеп киткән иде ул.

Әрвахларны искә алып килүчеләргә ясап куелган утыргычны яңартканнар икән. Коймага беркетеп куйганнар. Утырды, кулларын догага күтәрим дип уйлавы булды, якында гына чегәннәр ял итеп утырганны күрде. Өскебашны чыгып, Алгайга төшеп барышларына охшаган. Җыйган әйберләрен ашарга тукталганнар. Туктале, аларны уйлар чакмыни, башыма дөнья гаме узмасын, карашыма кермәсеннәр дип, кулларын тагын да биегрәк күтәрде.

Чегәннәр үзләре дә зират коймасы буенда дога укып утырган Зәмнихага игътибар иткәннәр, күрәсең. Йөзгә сөйкемле генә, яулыкларыннан бөдрә чәче чыгып, тузгып ук торган чегән хатыны янына килде дә бик кызганулы карап:

– Мин – авыруларга шифа кылып йөрүче, ярдәмем кирәкмиме? – дип сорады.

Ничек кирәк булмасын, андый ярдәм Зәмнихага бик кирәк иде. Баш какты.

– Бирергә әйберең йә акчаң бармы?

– Юк. Булганын төшешли сәдакага бирдем.

– Монда, үзең белән, димим. Өеңдә артык бер нәрсәң дә юкмыни соң?

Рәгыйдәгә, өстендәгесе бик таушалган, җылы тотарлык түгел дип, әле генә авыл тегүчесеннән җылы эчлек белән пинжәк тектереп куйган иде Зәмниха. Аны бирсә генә инде. Бераз ризык бирсә генә.

Зәмнихага бүген бар, иртәгә бетәчәк малдан битәр, иренең терелүе кыйммәтрәк иде. Ул ныклап аякка басса, пинжәген дә, сырмасын да алып кайтыр, әллә нәрсәләр табылыр әле, дип уйлады. Күңеленә һичбер шик кертмичә тәмле теллеләнеп, бик тә кызганган булып маташкан чегән хатынын ияртеп, өенә китте.

– Иреңнең кулы тигән тагын берәр нәрсә бир инде, – диде хатын. Электән калган яссы тәлинкәләрнең берсен китереп тоттырды. Уйлап-уйлап торды да эченә ипи кисеп салды, янына дистә чамасы чи йомырка куйды.

– Ирем үстергән икмәктән – файдасы да иремә булсын, – диде. Иртән генә идән астыннан алып менгән тозлы кыяры бар иде. Аны да дәвачыга сузды.

– Шуның белән бозыгын кайтарырмын, иртәгә үк күрерсең, авырулары җил белән сыпырып алгандай булыр, – диде чегән, кыярлы банкасын, ипиле тәлинкәләрен Зәмнихадан эләктергән пинжәккә төрә-төрә. Аннан күчтәнәчләргә рәхмәт укый-укый, капкадан чыгып барганда, бик ышанычлы итеп:

– Өч көн, өч төн үз телемдә зират эчегездә дога укып утырачакмын. Намазлы карчыкка охшагансың. Сихер кайтару, сихерчедән сорау – яман эш, дип борчылма, әлеге дә баягы Ходайдан сорау инде ул, – дип өстәде.

Чегән хатыны күз алдыннан югалу белән, аңа ышанычы шунда ук юкка чыкты Зәмниханың. Вәгъдә биргән табиблары да, бирмәгәне дә берни эшли алмаганны, укымышсыз бер зат бөтенләй сызып барган иренә ниндидер файда китерерме дигән уй сукты башына. «А»ны «Б»дан аермаган чегән хатынына, ялган сөйләмәс, дәвасын белә торгандыр дип, пинжәк кадәр пинжәкне тоттырып чыгармаса! Артында артыгы булса икән. Күз буу дигәннәре шушы микән әллә, дип гаҗәпләнде Зәмниха. Ялгыш эшләдем бугай, ирем дә терелмәсә, Рәгыйдәмә дә эшкә шәрә йөрергә туры килсә, дип хәсрәтләнеп утырган чагында иптәшләре белән Галинур кайтып керде. Әзмәвер кебек егетләр иде барысы да. Хәлиме дә, Котдусы да, Галинуры да.

Зәмниха боларның кайтуына бик сөенде. Булган хәлләрнең барысын да түкми-чәчми сөйләп бирде.

– И-и-и әнәй, болай да өйдәге бер нәрсәне калдырмыйча сатып бетерден бит инде, – диде Галинур. – Чегән түгел, урыс белән татарның да файдасы тимәде. Терелтәсе булсаң, үзең терелткән булыр идең.

Галинур иптәшләре белән киңәште дә хәер эстәп йөрүчеләрнең яннарына барып карарга булды.

– Инде киткәннәрдер, – диде Рәгыйдә.

– Ерак китмәгәннәрдер әле, – диде Хәлим.

Егетләр, сөйләшергә оста дип, Рәгыйдәне дә алдылар, урам буйлап төшкәндә, тагын бер-ике егетне эләктерделәр. Зәмниха карчык чегәннәрнең бик ишле булуын, әллә ничә арбада юлга чыкканнарын әйткән иде.

Чыннан да, чегәннәр әле китеп өлгермәгән, әмма шуңа җыенып маташулары иде. Егетләрнең нык сөйләшүләренә карамастан, беркемне белмибез, беркемне күрмәдек, дип маташсалар да, тора-бара шүрләделәрме, ышанмасагыз карагыз соң, табыгыз дигән кебек, йөкләре тирәсеннән кайсы кая таралды – читкәрәк китеп бастылар.

Егетләр, җигелгән атларның арбаларын актарып, бала-чага иске-москысы арасыннан әле бер дә киелмәгән пинжәкне тиз табып алдылар. Шифа китерәсе ипи белән йомырканы, бер банка кыярны ашаган булганнардыр – алары күренмәде. Ат аунаган кебек изелгән чирәм өстендә йомырка кабыклары чәчелеп ята иде. Галинур савыт-сабалар арасында әлүмин тәлинкәне күреп алды. Пинжәкнең аякланмавыннан да күңеле бик булган, ачуы шактый басылган иде, анысын чегәннәргә калдырды:

– Балаларына хәердән китсен.

– Кара инде бу әнәйне. Чегәннәр урам буйлап йөргән көнне кеше бауга элгән керләрен дә җыя, капкасын бикләп утыра. Ул, кешесез каралтыны ачык калдырып, зиратка төшеп киткән. Ярый аларга баштан ук керми узган булганнар. Инде дә бер нәрсәмне дә урламадыгызмыни, алайса үзем

бирәм дигән кебек, күзе уттай янып торган бичәләрен өстерәп өйгә алып кайткан, – диде Рәгыйдә.

– Яшь чагы булса, үзен дә алып китәрләр иде... Узган ел күрше авылның Әхмәтша кызын егетләренә урлаган кебек.

Өмет үлмәсә, кеше яши, диләр. Шул көннәрне авылга читтән Зәмниханың яхшы бер танышы кайтып төште. Әхмәтгалимнең чирләп киткәнен белгән дә хәл белергә килгән. Әйбер-фәлән дә сорамады, Зәмниханың үтенгәнен дә көтмәде, үзе үк хатынның сүнеп барган өметләрен терелтеп:

– Шәһәрдәге бер белеш врачым даруның теләсә кайсын таба, мондый авырулардан да коткарганы бар, шуннан кыйммәтле, көчле даруларны алып җибәрермен, акчасы да кирәк түгел, – диде.

Теге кеше алдамаган икән: даруы килде. Килүе генә Зәмниха йөрәгенә шырпы сызгандай итте: Әхмәтгалим шуннан алдагы көнне вафат иде. Дарулары кыйммәтле дип, Зәмниха аларны, кире хуҗасына салсынга, Рәгыйдә кулына тоттырды. Үз башы мәет артыннан булган борчулар белән каткан иде.

Зәмниха, ире соңгы сулышларын алганда, якындагы барлык балаларын чакыртты. Әхмәтгалиенең кайта алмасын белә иде. Хәлимәбикә белән Газизҗан тиз арада килеп җитте. Ямьбикә болай да, өй салабыз, тәпи йөрми торган балам бар, кеше карарга, ашатырга кирәк, димичә, ике өйне бер итеп йөри иде.

– Берәр нәрсә булмагандыр бит? – дип сорады аның атасы яныннан соңгы кайтуында Габделкасыйм. – Без бүген эштән туктарбыздыр инде.

– Булды... Әтәй вафат...

Габделкасыйм әллә нишләп китте. Ул да бабасы болай тиз китеп барыр дип уйламаган иде. Мондый чакта әйтеләсе сүзләрне көч-хәл белән әйтте.

Әхмәтгалимне озаттылар. Өйдәге күп әйберне селте белән юдылар, стеналарны ком белән үк чистарттылар, мендәр-ястыкларны, җилләтергә дип, ишегалдындагы арбага чыгарып салдылар, юрганнарны-җәймәләрне бауларга элделәр. Башка бер вакыт булса, андый хәлләрне күргәндә, бу йортны җәйгә каршы җыештыралар, дип сөенеп узасың. Хәзер болар барысы мәет чыкканнан хәбәр иде.

Җеназадан соң күршеләре дә дәшүгә карамастан, Ямьбикәләрнең йортына җыелдылар. Табын тын, сүзсез иде. Әтиләрен башка вакытта гел искә алган, рәхмәтле булган балалар да, «бабай-бабай» дип өзелеп киткән оныклар да берни сөйләшә алмады. Өйдән Әхмәтгалим белән бөтен ямь киткәндәй тоелды.

Кияүгә чыкканнан бирле Хәлимәбикә Тәкәнештән кайтуын сирәгәйтте, каенанасы белән каенатасын олылыклап, күбрәк ир ягына бара иде. Әнәйгә хәзер аның юклыгы да нык сизелер, дип уйлады Ямьбикә. Ярый да Рәгыйдә белән Галинур әле янында, авыр эшне аннан эшләтмиләр, яшәрлек ризыкны да, башкасын да табалар.

Гомер бакый Зәмнихаларның өе тулы кеше булды. Күршесе дә, туган-тумачасы да, белешләре дә өзелмәде. Алар хәзер дә килер инде ул килүен. Аларның килүе дә кайчан гына гөрләп торган өйдә иренең юклыгын гына исенә төшерүе бар... Әнисенә карады, ул чиге булмаган уйлар диңгезендә йөзә, карашы кайлардадыр еракта иде.

Чәйдән соң Зәмниха, әллә сагышланыр, әллә булган сагышын таратыр өчен, Шүләнгернең чишмә буйларын исенә төшергәндәй, инеш буена, тирәкләр янына китте. Авыр көнендә кешеле йортта күз көеге булып йөрисе килмәде. Ул су юлында күңеле белән көткән, теләгән беркемне дә очратмасын бик яхшы белә иде.

Өскебашның су юлы да Шүләнгернекенә бик охшаган икән. Ул элегрәк моңа игътибар да итмәгән. Анда да алар янында гына иде чишмә тыкрыгы. Әхмәтгалим белән сөйләштергән тау юлында мондагы кебек үк киң ябалдашлы, куе яфраклы ботакларын иеп утырган карт тирәкләр үсә иде. Сине көткәндә, ябалаклар белән сөйләшеп тордым, дигән иде Әхмәтгалим. Бар микән монда ябалак? Әллә урманда гына яши микән алар? Ничек тирәк янында моңарчы бер тапкыр да озаклап тукталып тормаган Зәмниха?.. Чишмәгә каршы калкулыкка алъяпкычын җәеп, бик озак утырды ул: бер еламсак байгыш кына да аваз салмады. Эч поштырып, инештәге бакаларның гына тавышлары килеп-килеп китә иде.

– Су буйларыннан кошлар да качкан икән, – диюе генә булды, авыл өстеннән – Түбән урам ягыннан бер тилгән очып килде дә шунда чемченеп йөргән бәбкәләргә үк кебек ташланды. Чирәмлектә каз саклаучы малай ераккарак утырган иде – таягын да атып карады, тидерә алмады. Аның бер бәбкәсе тилгән белән очып китте. Кушканны җиренә җиткереп үти алмаган малай, әтиләр ни әйтә инде дип сукранды, бераздан еларга ук тотынды.

– Борчылма, яным, – дип эндәште Зәмниха. – Безнең әле бибиләребез чыкмаган. Әниеңә әйтерсең: берсен сезгә бирермен.

Кичәдән бирле мәет исен сизгәндәй, безнең йорт өстендә бөтерелгән тилгән булгандыр ул, дип уйлады Зәмниха. Су буенда чары бар, җанварларның бары бар, диләрме әле? Әйе, су буенда агачлыклар үсә, аларда ерткычлар да качып тора торгандыр. Яңа гына күзе ачылган каз бәбкәсен алып китте бит тилгән!

Борынгыдан калган шушы мәкальне әйткәндә, Зәмниханы төзәтә – әйткәнен үзгәртә иде Әхмәтгалим:

– Ындырында чары бар, күзе ачның бары бар...

Анысы да хак. Ындырларында кибәк булса да калганны сизүчеләр, шул кибәкне үзләренә тартып алыр өчен, никадәр алдаганнар икән Зәмниханы. Авыру хакы, балалар хакы да димәгәннәр. Ул чегәннәргә үпкәләми дә. Алар – узгынчы халык. Бер китә. Синең бәгырь кисәгеңне тамырыннан өзеп алган кайберәүләр белән алга таба да яшисе. Ындырларын бушаткан, табыннарын тараткан, балаларын, туган-тумачаларын йортсыз-җирсез иткәннәр белән чагыштырсаң... Үзе дә җирсез халыкка бөтенләй рәнҗемисең. Чегәнгә китә язган бер пинжәк – байлыкмыни ул?!

2

Көттереп кенә булса да, тагын яз килде. Апрель аенда өй кырында сугышка барырга хыялланып утырган иде Мөхәммәтгали абыйлары. Кәнфитне күп алып кайтыр кебек киткән иде, бөтенләй кайтмады. Тагын бер матур язда, тагын да шул апрельдә Галим бабайлары барысын үзеннән башка гына яшәргә калдырды. Аның елын уздырырга хәзерләнеп маташалар. Кичә Мөхәммәтгалим абыйларыннан посылка алганнар. Эчендә җимешләр дә,

кәнфитләр дә бар икән. Ашка куярга салган ул аларны, ди Миңлебану апасы, синең белән миңа түгел. Кунаклар җыйгач, аларга да эләгә бит инде ул.

Газизәбануга рәхәт: укырга бармады. Бүген ял. Ул, яз, салкын әле дип тормыйча, кояшлы көнне апасы белән бергәләп агартып юган баскыч төбендә галошларына эчлек табан – чабата астына тегәргә дип хәзерләнгән кынҗырак җәеп утыра. Апасы өйдә. Ул беркайчан да аның кебек кирәксә-кирәкмәсә ашыкмый. Газизәбану кая да китәргә җай чыкканны гына көтеп тора. Аңа урам булсын, уен булсын. Эшеннән дә курыкмый. Бүген аларга берни кушмадылар. Ял булгач, Рәгыйдә апасы белән Галинур абыйсы баздан бәрәңге чыгарышырга менгән. Әтиләре базарга киткән иде, әле һаман кайтып җитмәде.

Баскыч төбенә тезелгән ташлар тәмам җылынып беткән. Зәңгәрле-яшелле зур бер чебен шуларга килеп кунган иде, галошы белән бәрүе булды, чебен дә үлде, аяк киеме дә ярылды. Сыер аягы тиресеннән кисеп алынган кынҗырак шактый нык, тотып торыр әле, дип уйлады Газизәбану. Бераздан күрерләр дә, искереп тишелгән икән, диярләр. Искермәсә, ул сукканнан гына ярылырмы? Алаен алай, барыбер орышулары бар. Кыз, ничегрәк әйтергә микән, дип торганда, әнисе чәриләп, лапастан йөгереп чыкты да ишегалдын әйләнеп чаба башлады. Артыннан баканы тәпиеннән аскан Галинур абыйсы да күренде.

– Галинуууур, куркам!

– Ашатам!

– Яным, куркытма!

– Ашатам мин аңа сине, майабыстай!

Абыйсына шаярырга гына булсын. Газизәбану теге ярык галошы белән баканы абыйсы кулыннан сукты да төшерде. Кечкенә кызның галошыннан буйчан Галинурдан да катырак курыккан симез ак корсаклы бака лапыр-лопыр сикерә-сикерә, каядыр качты. Кое капкачын кемдер ачык калдырган. Шунда төшеп югалды мәллә ул?

Газизәбануның куркудан агарынып калган әнисе баскыч төбенә килеп утырды. Ул да аның янына кунаклады.

– Рәхмәт, кызым, коткардың, – диде әнисе, кулындагы галошын алып. Шулчак аяк киеменә әле юньләп тыгылып бетмәгән кынҗырак, Газизәбануның бөтен серләрен ачып, җиргә килеп төште. – Бәтәч, ярылган түгелме соң бу?!

Газизәбану да, башын сузып, галошны караган булды.

– Әйе-е-е. Ярылга-а-ан...

– Бакасы каты булгандыр, шәп суктың бит, – дип көлде кызы янында тынычланган әнисе.– Әле дә ярый син монда булгансың. Ничек курыкканымны беләләр... Апа кадәр апалары белән шаярмасалар! Җае гына чыксын, кирәген бирәм мин бу Галинурның!

Ничек бирә алсын ул аның кирәген?! Нинди озын этиләре дә җилкәсеннән генә.

– Баканы кайдан алган соң ул? – дип сорады Газизәбану.

– Баздан.

– Бәрәңгеләрне кимереп яткан икән.

– Юк. Йокларга төшкән ул анда. Яз җиткәч, уянган.

– Йокысыннан яңа торган бакадан да качмасаң, әнәй!

– Рәгыйдә Галинур өстенә ыргыткан аны. Абыең урынына мин курыктым, – дип көлеп җибәрде Ямьбикә. – Шуны күреп алды да артымнан куып китте. Тешләмәгәнен дә беләм дә... Апалары белән шаярмасалар, мин ничәдә дә, алар ничәдә.

– Мин тычканнан да курыкмыйм, бакадан да.

– Син маладис! – Әнисе, үзе кебек булмаганына сөенеп, Газизәбануның аркасыннан кагып куйды. – Зәмниха әбиегез, мине куркыткан өчен, Галинурның муенына бака салыр иде.

– Йөрер аннары йөгереп, – дип көлде анның юри генә әйткән бу сүзенә күңеле килгән Газизәбану. – Синең кебек.

Ямьбикә әле генә булган хәлләрне оныткан кебек табаны ертык галошны әле буйлыга, әле аркылыга куеп карый иде.

– Кызым, беткән инде бу.

– Беткән.

– Иртәгә апаңның кечерәйгән искесен киярсең.

Орышмагач, иске галошка да риза иде Газизәбану. Ярар дип, баш селекте.

Ул арада бәрәңгенең кирәкле кадәресен чыгарып та бетерделәр. Бер өлешен, өстенә ябып, лапаска җәеп тараттылар, калганын өй астына салдылар. Рәгыйдә белән Галинур, эшләрен бетереп, капкалап, Түбән урамга кайтса: бакчалары тулы кеше. Лапасның киң капкалары шыр ачып куелган. Әниләре дә шундагы буйдан-буйга сузылган каралтылар янында әле берсе янына бара, әле икенчесе.

– Рәгыйдә, бакча юлыгыздагы каралтыларны сатасыз мәллә, дип сораган иде аны Әмирхан абый. Аптырадым. Ни әйтергә белмәдем. Кешедә шундый сүз йөргәнгә ышанмаган булдым тагын.

– Әтәйне күмгәннән соң сәерләнебрәк киткәндәй тоелган иде ул миңа.

– Алмаштырып куйгандай шул.

Бакча юлында кеше күп булса да, тикшереп, алар янына бармадылар. Карыйк әле, ни белән бетәр бу эш, дип уйладылар. Карчыкның, нәрсә планлаштырса да, сүзеннән кире кайтмаячагын белә иде Рәгыйдә. Күңеленнән киңәш кирәк дигән нәрсә качты. Җизниләренә дә ике генә адым югыйсә. Ир-ат фикере, ни әйтсәң дә – ир-атныкы. Төпле. Уйланган. Аркылысын-буйга салып караган.

Үзләре дә бала-чага түгел инде. Тормыш хәзер алар өстендә бара. Әнисе генә бала саный шикелле. Менә бит, киңәшеп-нитеп тә тормаган.

– Кергәч, үзе сөйләр әле, – диде Рәгыйдә.

– Хәзер сөйләтүдән ни файда? Каршы төшсәк тә, уеннан кайтмас.

Зәмниха карчык бераздан керде. Теге адәмнәрнең ишегалды аша чыгып киткәне күренмәде. Су буеннан килгән булганнардыр. Алайса бакчага чыгаручы олы капкаларны нигә ачып куйган инде?!

– Әнәй, сез мунча тирәсендә нишләп йөри идегез? – дип сорады Рәгыйдә.

– Андагы сарай ише нәрсәләрне, мунчаны сатам.

– Ни гомер торды да...

– Мунча ишегалдында да бар. Умарталарны бетерсәк, кышын аларны саклый торган йорт нәрсәгә?

– Кирәк-ярак куя торганнары да артыкмы?

– Әйберләрен монда гына күчерербез.

Болай, тирәннән уйламаганда, акыллы гына сүз кебек. Акчаның бәясе калмаган бер вакытта әнисенең шуның кадәр әйберне сатарга җыенганын алай да аңлый алмады Рәгыйдә, шуңа күрә:

– Галинур белән нигә сатканыңа аптырадык, – диде.

– Соң... Атагыз булмагач, безгә әйбер нәрсәгә?

Рәгыйдә телсез калды. Алар исән бит әле! Әнисенең сүзе бөтенебезнең дә яшәү артык дигән шикелле ишетелде:

– Әтәй булмаса, без бар бит!

Галинур да түзмәде:

– Эштән кайткач, юынып чыгарга мунчасы бер дигән! Җылынуы тиз. Китерәм дисәң, су якын.

– Бакчада маташканнан соң, җыен пычрак шунда калганны әйтәсе дә юк, – диде Рәгыйдә.

– Монысын саклабрак керенеп, озакка җиткерсәң дә, зыяны булмас. Ике мунча ягу бер йортның ике җирендә яшьләрнең, олыларның аерым казан асуы кебек ул.

– Барыбер аңлый алмадык без сине, – диде сүз көрәштерүнең мәгънәсе юклыгын сизеп торган Рәгыйдә. Аңа әнисе бик кызганыч иде. Аларга бүген генә, беренче генә күргән кебек карап тора. Бераздан, тагын да сәерсендереп, дәшми-нитми, йомшак кына шугандай атлап, түр караватка – Әхмәтгалим үләр алдыннан яткан урынга барып ятты.

Икенче көнне әллә никадәр кеше килеп, бакчадагы бер әйберне калдырмыйча сүтеп алып киттеләр. Утырткан бар нәрсәне таптап, бакчаны такырайтып бетерделәр. Үзләренә күпләп кеше кергәнне күреп, таңнан ук Ямьбикә йөгереп төшкән:

– Ни нәрсә бу, әнәй?

– Үзем дә аптыраган. Бакчага чыксам, бөтенесе мәш килеп, атагыз салган йортларны сүтә. Нәрсә эшләвегез бу, дим. Соң, кичә генә барысын да сөйләштек, фәләнен – фәләнгә, төгәнен төгәнгә сатып җибәрдең бит, диләр.

– Ә син?

– Мин? Ни дим... Мин бит бернәрсә дә белмим.

– Галинур белән Рәгыйдә нәрсә диде?

– Алар бик иртә, таң беленгәнче үк эшкә китә. Кайтып күрмәделәр әле.

– Акчасы кайда соң, әнәй?

– Анысы... Биргәннәрдер инде... Хәтерләмим генә...

– Ай аллам.

– Вакыт-вакыт әллә нишләп китәм бугай. Көйсезләнәм. Беркөнне, үзгәрдең син, дигән иде Рәгыйдәм, рас икән. Кичә башымның рәтсез чагы булгандыр. Соңрак аңладым да бит... Кемгәдер биргән вәгъдәмне бозасым килмәде, – диде үзенең бу эшләренә бик борчылган кыяфәттә Зәмниха.

Шул арада төшке ашка дип, шушы хәлләрне дә ишетеп, Галинур белән Рәгыйдә кайтып керде.

– Күңеленә авыр ясап, берни әйтмәгез, буласы булган, – диде Ямьбикә аларга да. – Әтәйнең үлемен бик авыр кичерә әнәй. Соңгы каза булсын, дип әйтик тә онытыйк.

– Син дә әтәй кебек кыланасың, – дип каршы төште Галинур. – Ул,

кешегә вәгъдә бирдем дип, үзе торган өйдән колак какты, аннан иң авыр елда яңасын салып газапланды. Инде менә әнәй...

– Без барыбыз да әни дә, әти дә кебек, – диде апасы.

Рәгыйдә телен тешләде. Ничә яклы йортларын кешегә биреп, үзләре хәзер, зур булса да, дүрт кенә почмаклы, аш ягы бүленеп кенә алынган өйдә яшәп яталар бит алар. Салынып бетмәгәне – чоланның икенче ягына төзеләсе дигәне – ак келәткә әйләнде. Бакчадагы каралтылардан яңадан алты-сигез почмаклы өй чыгарлык иде! Лапас, абзарлык материаллары никадәр! Моннан соң бу йортны карау, Галинурны урнаштыру миңа гына калмагае, дип уйлады ул. Аның әле үз тормышының да ахыры ачык күренеп тормый иде.

Балалары Зәмниха карчык инде гел кирегә китәрме дип фаразлаганнар иде, алай булып чыкмады. Бер үлем башын авыштырып куйган кебек итсә, икенчеләре әниләрен айнытып җибәрде сыман. Ямьбикәсенең сәламәтлеге утызынчы елларда нык какшаган – төн уртасындагы сорау алулардан йөрәк хастасына әверелгән, вакыт-вакыт үлеп китә дигәндә генә, фельдшерлар йөгереп килеп, ярдәм күрсәтәләр дә алып калалар иде. Атна-ун көн аңкы-миңке ята да тагын йөреп китә. Әнәй терелерме дип, балалары ут йотып, мәктәпкә дә бармыйча, янында саклап утыра. Элек өйләрендә бер-бер нәрсә килеп чыкса, хатыны авырып китсә, җизниләре Зәмниха карчыкны эзләп төшә иде. Хәзер ярдәмгә Галинур белән Рәгыйдәне дәшәргә гадәтләнде.

Габделкасыймның врачлар арасында танышлары күп. Кайсына барса да, «порок сердца» – гомерлек хаста инде ул, дип кайтаралар. Ревматизмнан, йөрәк ишемиясеннән, кан тамырлары чирләгәннән азган, имеш. Касыйм абый, хатыныңны сакларга, борчырлык хәлләрне сөйләмәскә дә тырыш, аңа авыр эш тә, бала табу да ярамый, дисәләр дә, синеңчә буламыни әле ул? Бер-бер артлы авырга узды Ямьбикәсе. Балалары вакытыннан алда – буылып туды, үзе һәрберсендә үлемнән чак калды.

Үз балаң гына түгел, туганнарың да йөрәк түрендә утыра. Бөтенләй көтмәгәндә, авыл кешеләре, кан-кардәшләре Бурят-Монголиядән кайта башлады. Әхмәткәрим абыйлары да кайтып төште. Аңа да булышты әниләре, башка ераграк туганнарына да. Үзе ярдәмгә мохтаҗ хәзер, һаман да бөтенесе аңа килә, дип уйлады Рәгыйдә.

Күпләрнең йортында инде кеше яши иде. Иркен җирләрдә торып кайтканнан соң, уртак пуҗымны бүлеп кенә алынган йорт урыннары кайберәүләргә бик тар күренде. Кемнәрдер әйләнеп кайтса да, җанга якын икенчеләр һаман да китә торды. Аларының йорт-җирләрен инде күбрәк читтән килгән кеше алды. Зәлихалардан югары туганнарыныкында хәер сорашып йөргән арлар яши. Кызганып, авылдан чыккан дип, каяндыр кайткан бер картның торуына риза булганнар иде. Авыл халкы Җиңги дип йөргән, исемен дә белмәгән хатын икмәк сорап кергән дә, кире чыкмыйча, шуның янында яшәп калган.

Теге карт күптән вафат. Йортында шул Җиңги тора. Кечкенә баласыннан күрше-күләнгә тынгы юк: үзләренә якын торган Габделкасыймнарының әле бу әйберен алып китә, әле икенчесен. Гадәтләре дә ошамый Зәмнихага: мал суя башласаң, җылы кан сорап, табак тотып киләләр. Татар авылында яшәгәч, татарчарак булырга кирәк тә бит. Җир өстендә йөргәннәрнең барысы да – адәм балалары, ди иде мәрхүм Әхмәтгалим. Адәм балалары...

әмма һәр кавем үзенчә яшәргә тырыша. Ар авылы Люкдун урман артында гына. Аларда да буш өйләрдән буа буарлыктыр. Ризыклы, мәрхәмәтле татар арасында яшәү җиңелрәк микән әллә? Ар хатыны эләктергән йортның хуҗалары кире кайтырга уйлап торалар иде дә, авыр тормышлы кешеләрне нигезләреннән чыгарып җибәрергә кыенсындылар, кире уйладык инде, дигән хат язып салганнар.

Юанайган наратларны калын такта белән тоташтырып ясалган утыргычта хәл алганда, Җиңги һәрвакыт Зәмниха янына төшеп утыра. Аныкын тыңлый, үземнең сөйләрлегем дә юк, бөтен күз алдымда торган нәрсә – өйдән-өйгә кереп хәер сорашкан көннәрем генә, ди. Зәмниха, сүз белән онытылган чагында, еракка китеп барган казларын аннан гына кудыртып, үз янына кайтарта. Төш вакытында гаугалы тавышлы казларны ишегалдына ашарга алып керәләр дә Җиңги белән чөкердәшеп, чәй эчәләр.

– Алланың ракматы яусын, – ди ул кат-кат, чынаякны тәлинкәсенә төп ягы белән әйләндереп куйганда. Җиңгинең бу сүзләреннән иллә дә күңеле була Зәмниханың.

– Җиңги, каенанамның мин сөйгән җыруын җырла әле, – диде ул. – Шулкадәр моңсу. Әткәй дә искә төште...

– Минеке каты, авазларым арныкыча килеп чыга, – дип җавап бирде Зәмнихага гомер бакый аралашып яшәп тә, исеме һаман билгесез күршесе. – Үзең генә ерлап бермайсыңмы суң?

Зәмниха җомга көннәрендә сәдака китергән, хәл белеп кергән дус әбиләре белән дә көйләштергәли ул мөнәҗәтне. Ар карчыгына көйле бар нәрсә – җыру. Ул аңласын өчен генә шулай дип әйтә Зәмниха. Җомга чәйләрендә башкаларына бөтенләй кушылмаса да, монысын тыңлап кына утыра алмый үзе дә:

Күп нәрсәгә чыдар канат,
Тик хәсрәттин сынар канат.
Сынып китте бер канатым
Килгән хәсрәтләрдин кабат.

Килгән хәсрәтләрем күптер –
Сабыр савытларым тулган.
Шул савытлар тулганчы тик,
Пар канатларым чыдаган.

Тавышы моңлы Шәмгыйҗиһан карчык бик сирәк, анда да авыр кайгыларга бирешмәскә тырышып кына җырлый кебек иде. Көе моңлы дип отып калган иде аны Зәмниха. Әти-әниләрен, туганнарын, бигрәк тә ире Әхмәтгалимне уйларга тотындымы, шул юллар хәтерендә яңара да китә, үзәген өзәрдәй итеп яңара да китә.

(Ахыры киләсе санда.)



Гарифҗан
Мөхәммәтшин

ҮТКӘН ЕЛЛАР КАЙТАВАЗЫ

***

Мин һаман да уртасында
Үткән белән киләчәкнең.
Киләчәктән нидер көтеп,
Үткәннәрдән көләчәкмен.

Көләчәкмен үткәндәге
Бер гөнаһсыз гөнаһлардан,
Тик сез генә көлмәгезче
Минем кебек гөнаһкярдан.

***

Кешеләргә аңлашырга, һай, күп кирәк,
Берсен-берсе җиңел аңлый ике йөрәк.
Тик язмышның иң хәл иткеч мизгелендә
Йөрәк сүзен тыңлаучылар җирдә сирәк.

Андый чакта йөрәк һаман читтә кала,
Йөрәктәге хисләр тимер биктә кала,
Биктә калган изге хисләр кеше җанын
Гомер буе сүнми торган утка сала.

***

Гасыр-гасыр катламнарны ерып
Чыга күптән үткән тарихлар –
Халык иҗат иткән гүзәллекләр
Һәм хакимнәр кылган вак эшләр.

Гаҗәпләнә Кеше күреп шунда
Олылыгын үткән юлының…
Без кылганнар сокландырыр икән
Кешелекнең кайсы буынын?..

Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН (1941) – *шагыйрь; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты. «Килегез, дусларым», «Бәхет», «Робагыйлар бакчасы» һ.б. китаплар авторы. Балтачта яши.*

***

Ташкын узды, бозлар акты,
Таллар бөгелеп калды,
Бөгелмәгән имәннәрне
Ташкын суырып алды.

Җирдә нигә таллар бик күп,
Имәннәр нигә бик аз?
Яшәү өчен бөгелә дә
Белү кирәкме бераз?..

***

Кайчак барын онытам да,
Урап киләм үткәннәрне –
Дус-ишләрне, якыннарны,
Тәүге тапкыр үпкәннәрне…

Урап киләм барысын да
Ерак яшьлек эзләреннән.
Күңелемдә ниләр барын
Сорама, бел күзләремнән…

***

Басынкыланды күңелем,
Гүя көзге урман ул –
Уе башка, гаме башка,
Ярсып купмый зурдан ул.

Белә, яшьлектә кизәнгән
Зур эшләрем бетмәгән…
Узган гомерем – сослымнарга
Куелмаган көлтәләр.

***

Кемгә дә кирәк ул дөньяда
Кемнеңдер йөрәге җылысы,
Шул җылы җитмәсә, күңелнең
Килә гел үксисе, елыйсы.

Арынгач мәшәкать-борчудан,
Сискәнә бу җаным көн дә бер –
Минем дә күңелем җылысы
Кирәктер кайдадыр, кемгәдер…

***

Тау битендә кызарып кына,
Җиләкләр пешеп килә,
Шул таулардан моңсу гына
Артышлар[1] төшеп килә.

Аларның да арып-талып
Җиләктән кайтышыдыр.
Малай чагым хәтерләтә
Аларның кай төшедер…

***

Күкчәчәкләр кабат чәчәк аткан –
Зәңгәр күзләр арыш арасында,
Аяз күкнең төпсез тирәнлеге
Ул күзләрнең керсез карашында.

Зәңгәр күзләр арыш арасында –
Сабый күзләредәй ап-ачык,
Арыш арасында зәңгәр күзле
Балачагым йөри адашып.

***

Басуларның дулкыннары тынган,
Гөлчәчәкләр кипкән болында,
Адашкандай ялгыз бер ромашка
Торып калган сукмак буенда.

Бирешмичә, түзеп кичергәндер
Ничәнчесен көзге кырауның,
Вакытында аңлатылмый калган
Мәхәббәте кебек берәүнең…

***

Кырларның мул, гамьле чаклары.
Башаклар сәҗдәгә иелгән,
Аларга кушылып тын гына
Ак дога пышылдый иреннәр.

Кырларның мул, гамьле чаклары –
Ахыргы көннәре августның,
Туган җир, җәйге күк шикелле
Көннәрең догалы, ак булсын!

---

[1] Артышлар – күпбалалы гаиләдә туган балалар мәгънәсендә.

***

Күңелем – серле Галактика –
Миллион йолдыз, томанлыклар…
Бәрелешә уйлар, хисләр…
Кабына-сүнә миллион утлар.

Миллион утлар арасында
Ник соң туңам, өшим әле?
Күңелем – серле Галактика –
Серләренә төшен, йәме!

***

Кемдер җырлый кара төнне ярып,
Җанны биләп ала моңлы җыру.
Җыр сәләте миңа бирелмәгән,
Рәхәт миңа аны тыңлап тору.

Сабый чакта әнкәй тибрәткәндәй,
Тирбәләм мин шул җыр кочагында –
Кабына да сүнә, кабат-кабат
Хатирәләр хәтер учагында.

***

Әле генә шаулап таңнар ата,
Әле җитә моңсу кичәләр,
Мин ышанам, җирдә кеше гомере
Шаулап үткән бер көн, дисәләр.

Шул бер көнгә сыйган барысы да –
Ярсып яшәү, яну-көюләр…
Кояшым да инде сүнеп бара,
Туелмаган ләкин сөюдән.

***

Төнге аяз күккә карыйм,
Сердәш эзләп җаныма.
Мизгел саен бер-бер артлы
Яңа йолдыз кабына.

Кабына да Җиргә бага,
Эзли үз сагынганын –
Һәрбер йолдыз үзе белә
Кем өчен кабынганын…

***

Араларда хатлар йөрми инде,
Чоры үтте, ахры, хатларның.
Ерак калган яшьлек хатирәсе –
Синең хатларыңны актардым.

Әллә нәрсә булды йөрәгемә –
Шул хатлардан күңел нечкәргән,
Еллар үткән, хатлар суынмаган
Яшьлектәге кайнар хисләрдән.

***

Яңгыр ява, шул яңгырга
Сузып куйдым учымны –
Уч төбемдә ике тамчы
Йөгереп килеп кушылды.

Кушылды да, җем-җем итеп
Әверелде ак нурга –
Әй, мәхәббәт, син булганда
Яшәү рәхәт, матур ла!

***

Кайвакытта өзгәләнеп
Аяз күккә карыйм,
Яшьлектә бергәләп ачкан
Йолдызларны таныйм.

Яна алар әле һаман,
Сүнгәннәрдер, дисәм –
Безнең яшьлек, безнең сөю
Исән әле, исән!

***

Әй, биеде таңда бәяз[2] томан
Киң үзәндә, урман буенда –
Шатлыгыннан шашып биедемени
Назлы яшь кыз үзенең туенда.

Биетте дә шаян җил малае,
Алып китте аны кочаклап.
Көнләшүдән гайбәт сатып калды,
Пышылдашып читтә усаклар…

***

Син минем өзмәгән алмам,
Чәчәк атмаган гөлем,
Алсу алмам, ал гөлем, дип,
Мең кат кабатлый телем.

Яумаган ләйсән яңгырым,
Чыгып килгән кояшым –
Кояшлы яңгырда килә
Йөрәгемне юасым…

***

Йолдыз яуган төн иде ул,
Күкләр җиргә ауган төн,
Бәхет безне үз иттереп
Кочагына алган төн,

Күкнең җиргә иңгән төне,
Безнең күккә менгән төн...
Гомер буе онытылмый –
Әллә төш ул, әллә өн.

***

Зәңгәр күктән узып бара
Ак болытлар кәрваны,
Сизелеп тора болытларның
Зур юл үтеп арыганы.

Кая китеп барышлары,
Кай тарафка, кай илгә?
Ак болытлар узып китә,
Аклык кала күңелдә.

Редакциядән:

Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.

Бу QR-код аша сайтыбызга кереп,
авторның үзе укуында шигырьләрен
тыңлый аласыз.

[2] Бәяз – «ак» сүзенең төрки синонимы.



Вакыйф
Нуриев

КАЗАННАН – МИЯУ

ХИКӘЯ

Мәче югалды. Урманда. «Карурманда кара мәчеме?» дип сорап куючылар булыр. Юк, алай ук түгел инде. Урман дигәнем – Казан читендәге имәнлек. Метроның «Дубравная» дигән соңгы тукталышында. (Күр әле, безнең Казанда урманга да метро поездлары йөри дип мактанып алырга була икән). Мәчесе дә, сез уйлаганча, тоташ кара түгел, түше, тәпиләре ак.

Булат аны урманга һава суларга алып чыкты. Эссе көнне эссе өйдә, эссе идәндә тилмереп пешеп ята. Этләрне алып чыгалар бит әле. Эткә яраган мәчегә ярамыймы?! Чыктылар имәнлеккә. Урманга кереп, бераз баргач, егетнең куенындагы гамьсез песи үзен адаштыралар дип курыктымы, көтмәгәндә, берьюлы өреп алган кыргый этләр хәвеф барын искәрттеме, кинәт кенә Булатның күкрәгенә очлы тырнакларын батырып ябышты. Хуҗасы аны көчкә умырып алды. Умырып алуы булды – Барс кулыннан ычкынып, яшь мәче җитезлеге белән җиргә сикерде. Үләннәр арасына чумды ул. Озак ятмас, баш калкытыр, җәлт итеп килеп чыгар дип көтте аны Булат. Песи күренмәде, гүя җир йотты үзен. Кинәт исеп куйган талгын җилдә үләннәр җиргә елышып алды – песи юк. Егет аны чакыра башлады:

– Пес, пес, пес... Барс, шаярма! Чык, әйдә!

Ни песи, ни урман җавап бирмәде. Мәчене югалттым дигән уй отыры егетнең бөтен күңелен биләп алды. Вакыт узган саен ул көчәйгәннән-көчәя барды. Булат җирне, үләннәрне иелеп тә, мүкәләп тә капшый-тарый башлады. Юк инде, юк песи!.. Бер-ике сәгать эзләгәннән соң, үзе белән алган Вискасны ачты һәм үләннәр арасына куйды. Ашыйсы килсә, чыгар. Ах, бу песи үзе яраткан тәмле аштан да баш тарткан булып чыкты. Байтак эзләде Булат дустын. Карурманда адаштырып та, өйгә кайткан мәчеләр бар. Барс та кайтып утырмады микән? Булат Имәнлек урамындагы үзләре яшәгән йортка чапты. Унбишенче катка кадәр җәяү менде, җәяү төште, ишегалдын әйләнеп чыкты – мәченең исе-косы юк. Кичкә таба тагын песине йоткан имәнлеккә китте. Урман авызында, чаң суккандай сискәндереп, кесә телефоны шалтырады. Виолетта.

Вакыйф НУРИЕВ (1958*) — язучы; ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Фатих Хөсни, Абдулла Алиш исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Бүре кадәр бүрек», «Җиденче палата», «Ни хәлең бар, балам?..» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

– Привет, Булатик! Бүген күрешәбез! Син, шампан белән сыйларга вәгъдә иттең!..

– Гафу ит, Виолетта! Бүген күрешә алмыйбыз.

– Нигә?

– Минем Барсигым югалды. Урманда. Шуны эзләп йөрим.

– Мәче югалган. Харап булган икән!.. Югалса ни! Ни чуртыма хаҗәт ул сиңа?!

– Барсик бик акыллы, чиста мәче, Виолетта. Минем караватта аяк очында йоклый, иртән битен юа иде.

– Ну и что!.. Син мине шул мәчегә алыштырмакчы буласыңмы?!

– Мин Барсикны төнгә ялгызын урманда калдыра алмыйм, Виолетта. Кыргый этләрнең ботарлап ташлавы бар. Төлке дә йөри монда, Виолетта. – Баш киткәндә, каш кайгысы бу кызда, дип уйлап куйды егет.

– Ха!.. мине ялгызым калдырырга ярый, йолкыш мәчене калдырырга ярамый. Нәрсәгә хаҗәт соң ул – хәшәрәт?! Мин әбинең мәчесенең балаларын ваннада суга батырып үтердем. Аннары чүп багына чыгарып аттым. Әбигә кешеләргә биреп җибәрдем дигән булдым.

Бу сүзләрне ишетүгә, Булатның күз аллары караңгыланып, башы әйләнеп китте. Уч төбендә эреп бетәргә торган җылы, йомшак, нәфис йомгакларны, бер чите аз гына ертылган, тиздән ачылып, дөньяга, кешеләргә мөлдерәтеп-тутырып карыйсы сызык-күзләрне ничек итеп суга батырмак кирәк?! Кем диген, сөйгән кызың шулай «эһ» тә итми сөйләп торсын инде. Булат баш-аягы белән гашыйк булып йөрде бит әле үзенә. Эшләр никахка таба бара иде инде. Мәче рәнҗеше, мәче каргышы турында да уйламый микәнни бу кыз?! Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.) йоклап яткан мәчене уятырга уңайсызланып, чапанын кисеп калдырган әнә.

Виолетта телефоннан тагын нәрсәләрдер әйтте. Булат аны тыңлап тормады. Кыз тагын шалтыратты. Егет алмады. Аннары кызның исемен телефоныннан сызып атты. Һәм... йөрәгеннән дә. Ул урман буйлап барды да барды. Озак барды. Тукта әле!.. Болай бик эчкә кермәде бит инде алар. Түбәләре күккә тиярлек бу биек йортлар каян килеп чыкты соң? Булат шунда адашканын аңлап алды. Урманга кергәч, ике сукмак янәшә барган төсле тоелды аңа. Бактың исә, аерыла икән алар. Егет уңга каерган. Шуны белеп, кырт кына сулга борылды, моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән, ярлары әрсез агач-куаклар белән капланган коры елгага барып чыкты. Юлны сорарга кеше дә очрамады. Хәер, очраса ни, очрамаса ни. Синең песине кайда югалтканыңны кем белсен монда?! Берсендә шулай Болак буенда туристлар очрады аңа. Казанны карап йөргәннәр дә адашканнар. Кунакханәне таба алмыйлар. Аның ничек аталганын да онытканнар. Шунда берсе, Ходайның рәхмәте, мәчегә салынган һәйкәлне искә төшереп куйды бит. Шуңа ничек чыгарга? Көмеш төсендәге корыч песине тапсалар, кунакханәне дә табачаклар. Булат аларга Мырауҗан һәйкәленең якында гына булуын, үзләре басып торган төштән юл аша чыгып, Җәлил урамыннан туры барасын әйтте. Егет шунда кешеләре белән генә түгел, мәчеләре белән дә дан тоткан калада яшәвенә горурланып куйды. Һәйкәлгә чын-чынлап лаек алар – Казан песиләре! Явыз Иван Казанны алганда, Кремльдә ханны кем уята? Мәче! Россия империясендә Елизавета чорында Санкт-Петербургтагы патша сараен тычканнар явыннан кем коткара?

Казан мәчеләре! Бездән утыз песине алып китәләр. Бөек Екатеринага да Эрмитажны тычканнардан кем чистартып бирә? Казан мәчеләре! Әнә бүген Татарстанның башкаласы үзәгендә, Бауман, Җәлил урамнары кисешкән чатта, баганалары сырлап эшләнгән беседкадагы җыйнак сәкедә бер тәпие белән озын мыекларын бөтереп, бер тәпие белән тук корсагын кашып-сыпырып, аякларын чалмаштырып, аз гына кылый, аз гына хәйләкәр күзләрен уйнатып, мәһабәт кыяфәттә мәмнүн булып, ни фурмылый ята бит. Ял итеп ятса да, кешеләрне хәзер дә ярдәменнән ташламый. Шәһәрдә адашканнарга бер маяк ул!

Булат хәтерли әле, Казанда Санкт-Петербург урамын ачарга алар сыйныфлары белән бардылар. Тантанага төньяк башкаладан губернатор Валентина Матвиенко да килгән иде. «Без сезгә бүләккә барс алып килдек. Аны Казан зоопаркына тапшырдык», – диде ул. Минтимер Шәймиев, ул вакытта Татарстанның Президенты, олы кунакның бу сүзләренә оста гына юмор ябыштырып куйды: «Күрегез әле, кайчандыр Санкт-Петербургка тычкан тотарга киткән мәчеләребез хәзер Казаныбызга барслар булып кайта!»

...Булат ничек итсә-итте, урманнан Имәнлек урамына чыга алды. Чыгып, урманга яңадан керде. Хәзер инде белгән юлдан, көндез песи белән бергә үткән сукмактан. Мәчене югалткан урынны тиз тапты. Анда ауган, гасыр буена үзенә җирнең сутын биреп торган тамырын өскә күтәреп яткан бер карт имәнне хәтерендә калдырган иде. Урман тып-тын. Монда мәче качып ятадыр дип, эт тә уйламас. Бәлки, урман артындагы полигонга чыгып караргадыр? Барс шунда китмәде микән? Анда хет күренер иде. Егет йөри-йөри, аяксыз калды. Кояш баеганда, ул яңадан песине югалткан урынга, ауган имәнгә кайтып чүмәште.

Урманда төн чыгуның никадәр куркыныч икәнлеген Булат имәнлеккә җан биздергеч, чиркандыргыч караңгылык ишелеп төшкәч кенә аңлады. Аның күңелен шом басты, йөрәгенең хәле китте. Үзәккә үтә торган озынборыннардан да котылыр хәл юк. Песи өчен борчылу, ачыдан-ачы уйлар аны шулкадәр изделәр ки, ул үзенең бөтен вөҗүдендә сыкрану, газап, әрнү тойды. Келт иткән тавыш та аны сагаеп тыңлап торырга мәҗбүр итте. Төнге урманның үз өне бар. Берничә тапкыр «пилдерик» дип дәштеләр. Кошмы бу, җәнлекме?.. Аңламассың. Чү, әнә анда – төп башында песи утырып тора түгелме?.. Булат җәһәт кенә килеп караса, сыраданмы, суданмы бушаган шешә икән. Котырып үскән киң әрекмән яфрагы да, киселгән нәзек нарат төбе дә, тагын бик күп нәрсәләр дөм караңгыда аның күзенә мәче булып күренде. Ярый әле, җәйге төн кыска. Булат агачлар арасына саркып кергән галиҗәнап яктылыкны искәреп алганнан соң, азмы-күпме тынычлангандай булды. Бераз хәл алыйм дисә, Салмачи ягындамы, полигондамы этләр абалап өрә башлады. Аларның үзәк өзгеч тавышын урман йөзгә тапкырлап, Казанга озатты. Егетнең йөрәге чәнчеп алды. «Барс адашып, шул якка чыккандыр да, үзенә этләр ташлангандыр», дип уйлап куйды ул. Аны хәзер өзгәләп-ботарлап аталар бит. Үтерделәр бугай инде. Кинәт тындылар. Авыр уйлардан башын чайкап куйды Булат. Их, Барс! Барс! Миңа рәнҗемә инде, Барс! Күпме тырышсам да, саклап калалмадым үзеңне!..

Урманнан ул таң атканда чыкты. И Булат, шулай итеп Барсигыңны мәңгегә калдырып чыгасыңмыни инде?! Җәсәден табып җирләргә иде хет. Җитмәсә, бүген бертуган апасы Айгөл белән аның улы – Булатның пләмәше, тик тормас Кәрим килә. Ул өйгә килеп керүгә, Барсикны сораячак. Аңа ни дип җавап

бирер Булат. Үлеп яраттылар бер-берсен Кәрим белән Барсик. Уйнап туя алмыйлар иде бит. Песи ишек өстенә менеп утыра да малайга карый. Тота алмыйсың, янәсе. Кәрим нишләргә белми. Ул арада Мыраубикә үзе Кәрим янына сикереп төшә. И, аннары тотыналар бер-берсен куарга. Кәримнең кычкырып-кычкырып көлгән тавышы бөтен өйгә яңгырап тора. Шулай көлеп, чинап, чыелдап, дөньяның астын өскә китереп уйныйлар иде бит! Күңелле көннәр! Иртән йокыдан торгач, Барска «Мияу», дисәң, ул биш «Мияу» белән җавап кайтара. Үзенчә «Хәерле иртә!», «Көн уңышлы, кояшлы, матур булсын!» дип әйтүе инде. Аннары аягыңа килеп чолгана. Юкка чолганмый, җылы-йомшак Барсикны күңеле булганчы сыйпап-иркәләп аласы. Эшкә киткәндә, песи-песекәй ишек катына килеп, сагышлы, ялварулы карашын төби, текәлеп карый һәм тагын «Мияу!» – ди. Монысы: «Дөньяга «Covid 19» дигән заразы таралган, масканы алдыңмы? Сакланып йөр», – дип кисәтүе. Булат битлеген алмаган, онытып чыгып бара икән бит!..

– Мияу! Рәхмәт, Барсик!

– Мияу! (саклан!)

Песи түгел, кеше инде ул, кеше. Их!..

Үзләренең ишегалдына бик авыр уйлар белән кайтып керде Булат, песине югалткан җирдә төбе-тамыры белән кубарылып ауган имәнне җилкәсенә салып җибәрделәрмени? Шул вакыт егетнең күзенә балалар уйный торган гәрәбә комлыкта утырган, бу дөньяга исе китмәгән бер мәче чалынды.

Песи!..

Үзе кара, түше, тәпиләре ак. Бәй, Барсик ич бу!!! Кайчан кайтып утырган ул? Өйне ничек тапкан? Өзлексез машиналар йөреп торган ташкын-юл аркылы ничек чыккан? Булат Барсикны иплəп-җайлап, кулына алды һәм өйләренә алып кереп китте. Икесе дә бик арганнар иде. Ишектән керүгә, Барсик диван астына шылды. Булат башын мендәргә төртүгә йоклап китте.

Аны ишектәге кыңгырау тавышы уятты. Төш вакыты җитеп килә икән бит инде. Апасы Айгөл белән пләмәше Кәрим килгәннәр. Малайның килеп керүе кая да, Барсикны диван астыннан сөйрәп чыгаруы кая? Апасы чәй куйды. Солы прәннеге, печенье, клиндерләр алып килгән. Булат белән чәй эчәргә утырдылар. Кәримне чакырып караганнар иде – ул сагындырган мәчесеннән аерыла алмады. Бераздан малай кухняга үзе килеп керде һәм карашын Булатка төбәп, сорап куйды:

– Ул песи ә-ә нишләгән, ә-ә-ә?..

– Нишләсен?

– Уйнамый минем белән.

– Арыгандыр, Кәрим. Кичә минем белән урманда йөрде ул.

Малай чыгып китте. Бераздан тагын керде. Бу «әллә нишәгән» песинең үзен күтәреп керде.

– Безнең Барсик түгел бу?!

– Ник алай дисең? – Булат җавап көтеп, Кәримнең күзләренә бакты. – Койрыгы Барсикныкымы?

– Барсикныкы!

– Тәпиләре ак. Барсикныкымы?

– Барсикныкы!

– Шулай булгач...

– Бите Барсикныкы түгел!.. – бу сүзләрне әйткәндә, Кәримнең күзләре дымланды, алай гына түгел, яше тәрәлде, менә-менә бәреп чыгарга тора.

Булат мәчегә озак кына карап торды да авыр сулап куйды. Кәрим хаклы. Барсикның күзләре зуррак, яктырак, ачыграк, очлырак иде. Кунаклар киткәч, егет уйныйсы килмәгән, пошынмас песине кире комлыкка чыгарып куйды. Ишегалдында балаларның: «Ур-р-ра! Песи табылды!» дигән шатлыклы авазлары яңгырап калды.

Булат өенә кереп тормыйча, тагын урманга китте. Тагын Барсны эзләргә! Урман авызында аңа килешле сары футболка, ботларына сыланып торган яшел лосина кигән мәхәббәтле бер кыз очрады. Кичә дә очраган иде. «Спортсменка» дип уйлап куйды Булат. Бу кыз иртә-кич урманга йөгерергә чыга. Имәнлекне аркылыга-буйга гизә. Димәк, аңа мәченең очравы ихтимал. Башка вакытта Булат бу зәһәр «спортсменка»ны йөгереп барган шәпкә туктатырга уңайсызланыр иде. Бу юлы яраткан мәчесе хакына дәшми кала алмады:

– Гафу итегез! Минем мәчем югалды. Урманда күзегезгә чалынмадымы?

– Юк! Шушында, урманда югалдымы соң?

– Әйе. Сез йөгереп йөри торган урманда. – Булат бу мәлдә балтасы суга төшкән кеше кыяфәтендә иде.

– Мәчегезгә ничә яшь?

– Бер яшь тирәсе. – Егетнең бу чибәркәй алдында бик мескен булып күренәсе килмәде, ахры, тирән итеп бер сулады да әйтеп куйды: – Кинологлар чакыртып карарга исәп бар. Эт тапмый калмас бит.

– Ул кинолог сиңа мәче таба ала торган эт алып килер, дип уйлыйсыңмы?! Андый этләр бөтен Казанында булса да, бер-ике генәдер. Кинолог килер, эзләгән атлы булып йөрер дә чакырткан өчен өч-дүрт мең сум акчаңны каерып алып китәр. Песиеңнең өч бөртек йоны да селкенмәс. Кайда югалды ул? Төгәл урынын беләсезме?

– Монда гына, ауган имән янында.

– Тәк-тәк... Уһу!.. Шунда инде ул мәчең! Андый песи йөз метрдан артык китми. Мин ветеринарныйда укыдым. Песиләрнең холык-фигылен азмы-күпме беләм. Тәк!.. Ауган имән. Радиус – йөз метр. Алга! Эзләргә! – шулай диде дә кыз үзе дә егеткә иярде.

Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына, ди. Ничек очрады бу кыз? Күр әле, Булатның песи югалту кайгысыннан иелгән башын күтәрде бит! Йөз метрдан ары китмәгәч, әлхәмдүлиллаһ, бүген төнлә этләргә дә эләкмәгәндер әле.

Алар бер җан булып эзләделәр песине. Озак эзләп азапланасы булмады. Кызның әйтүенә караганда, мәчеләр өеп куелган ботак-сатак астына кереп ятарга мөмкин икән. Коры-сары, чыбык-чабыгы ята-ята җиргә сыланган бер күчне тузгыттылар. Икенчесен кыз актарырга өлгермәде, Булат «Таптым!» – дип, бөтен урманны яңгыратып кычкырды. Ах, бу Барсик шул ауган имән астына куыш ясап кергән бит. Егет аның ялтырап торганякты, яшькелт күзләрен күреп алды. Төн йокысын качырган, ашның тәмен алган, йөрәккә кан саудырып торган хәсрәт шуның белән бетте. Йөгерешче сылукай дөрес әйткән, мәче йөз метрдан ары китми, дип.

– Сезгә би-и-и-к зу-у-у-ур... рәхмәт! – диде Булат кызга, шатлыгыннан тотлыга-тотлыга.

Ул арада кыз йөгерешне дәвам итәргә теләп, аякларын язып алды. Егетнең

аны җибәрәсе килмәде. Ул бер мәчегә, бер кызга карап, нишләргә белмәде. Ярый әле, «спортсменка» йөгереп китәргә әзер булса да, ашык-пошык старт алмады. Таныштылар. Кызның исеме дә үзе кебек мәгънәле, матур икән – Сөембикә. Казандагы бер ветеринария лабораториясендә эшли. Кияүдә түгел. Егет бу хәлләрдән соң Барсикны ничек тәрбияләргә дигән сылтау белән телефонын сораган иде. «Урманда югалу, төн чыгу – песи өчен зур стресс. Бер-ике көн карават астында ятар да чыгар. Борчылма!» – дип, Сөембикә аның авызын каплады да куйды. Булат: «Барсик алай-болай авырып китсә, андый-мондый хәлгә дучар булса, сездән киңәш сорарга иде», – дигәч, телефонын бирде тагы. Аннары йөгерә-йөгерә китеп тә барды. Аның елмайганда, мул булып күренеп, энҗеләр түгелеп торган ак тешләреннән, өскә күтәртеп төбеннән бәйләп куйган сары чәч көлтәсеннән, озын, ак муеныннан әйтеп-аңлатып бетерә алмаслык яктылык сибелеп калды.

Булат Барсикны табу вакыйгасының бер истәлеге итеп, Сөембикәгә сувенир мәче бүләк итү нияте белән Бауман урамына төште, Мыекбай һәйкәле янындагы «Кот казанский» кибетенә керде. Монда мәчеләрнең нинди генә юк: тиредән, күннән, плюштән тегелгәннәре, фарфордан, керамикадан ясалганнары... Тик барысына да «Мяу – из Казани!» дип язылган. Егетнең исә Сөембикәгә «Казаннан – мияу!» дип, татарча язылганын бүләк итәсе килде. Тик андый юк, гәрчә Казан песиләре татарча сөйләшсә дә. Бәлки, киләчәктә Казаныбызның бөтен дөньяга билгеле тагын бер символы – мәче-бүләк кунакларга, туристларга «Казаннан – мияу!» дип тә дәшәр. Тәрҗемә итәсе юк. Теләсә кемгә аңлашыла бит!

Кибеттән чыгуга, Булат Сөембикәгә шалтыратты:

– Алло! Сөембикә! Мин – Булат... – егет телсез калды. Башка сүз табалмады.

– Әйе, тыңлыйм, Булат. Нәрсә булды?.. Әллә мәчең тагын югалдымы?

– Ю-ю-ю... Югалды шул...

– Барсик югалдымы?

– Юк!

– Алайса нинди мәче югалды соң?

– Югалды инде (телефонда озак кына пауза булып торды). Ю-ю-ю... Югалды. Нинди мәче, дисеңме?.. Ә-ә-ә... ни... ни... күршеләрнеке югалды.

– Кайда югалды соң?

– Шунда, урманда инде...

– Ничек табасын беләсең бит. Югалган урын. Радиус – йөз метр. Алга! Эзләргә!

– Синнән башка табып булмый аны, Сөембикә.

Булатның песи югалту сылтавы белән очрашырга теләвен кыз сизмәдеме соң инде?! Егет ык-мык килүгә сизде ул.

Шул көнне күрештеләр. Урман авызында озак кына сөйләшеп тордылар, таганда атындылар һәм алар алдында яшел ут булып балкыган, яшьләргә әле үзләре дә аңлап бетермәгән бәхетле көннәр, еллар вәгъдә иткән, күңел хөҗрәсен ымсындырып торган имәнлек ешлыгына кереп югалдылар.

Рифат
Җамал

ЧӘЧӘКТӘ БУЛСАМ ДА КӨЗЛӘРЕН...

Минем күңел

Тормыш мине гаярь ир-ат итте, күңел үтте ялкын, ут аша.
Ә шулай да төпкел почмагында кизләү булып ялкын-хис таша.
Корымланды күңел, өтелде дә, карашлар да гүя кургаштан.
Корымнарын кырып карасагыз, күз чагылыр күңел-кояштан.
Усалланды холык, катты бәгырь,тормыш өйгән кат-кат елларын.
Күңел күзләрегез күрә алса, бер нарасый сезгә елмаер.

***

Кешеләргә бәхет өчен бик күп кирәк.
Бөтен дөнья, җирләр, сулар һәм күк кирәк.
Ә кемгәдер бәхет бит ул – телем икмәк.
Кайвакытта бәхет өчен бик аз кирәк.
Бар да бар күк. Ә нигә соң ярсый йөрәк?!
Бу йөрәккә бәхет өчен бер син кирәк.

***

Нигә соң көзләргә кергәндә
Очынам, шашынам сөенәм?!
Нишләвем инде бу, аңламыйм.
Әллә соң сөям дә, сөеләм.
Тик менә кышларын чыгалмас
Көздәге чәчәктә алмагач.
Мин дә соң корырмын микәнни,
Кышларга көчләрем калмагач?!
Юк әле, мин көчле, мин үлмәм.
Килсә дә, Үлемгә баш имәм.
Чәчәктә булсам да көзләрен,
Алмагач түгел лә, мин – имән.

Рифат ЖАМАЛ (1951) – *шагыйрь һәм галим, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстанның фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясе лауреаты, Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты; «Күңел сүрәләре», «Ташта үскән чәчәкләр», «Өзгәләнмә, күңел» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

***

Гөнаһлымын сине сөйгән өчен,
Гөнаһлысың мине сөйгән өчен.
Бәлки, Ходам, безне ярлыкарсың
Шушы утта янган, көйгән өчен.

Бәлки, Ходам, безне ярлыкарсың
Сагыш дәрьясында аккан өчен.
Сагышларга кайчак түзалмыйча
Сөю чоңгылында баткан өчен.

Гөнаһлымын өзелеп сөйгән өчен,
Җитмәгәнгә сине ташлар көчем.
Ялгыз гына үтәр сагышларга,
Җаным, сине җитәкләгән өчен.

Җибәр кулларымны! Мин китәрмен,
Гөнаһларны алып үзем белән.
Күз яшьләрең саф, гөнаһсыз булыр...
Җаннар гына... Әллә тере, әллә үлгән.

***

Сөйдем-сөелдем, шашып сөендем.
Киттең – көендем.
Аннан киендем,чыктым урамга.
Төнге буранга серем сөйләдем
(сине сөйгәнем).
Буран улады, күңел елады...

Таңда арыдым. Синнән арындым.

***

Мин сине көтмимен таңнарда –
Нигә соң үзеңне алдарга?!
Сөймәгән кешене көтүләр –
Ул рәшә. Кирәк бит аңларга!
Мин сине көтмимен көндезен –
Көндезен түгелмен берүзем.
Өшегән җанымны җылыта
Ахирәт-дусларның бер сүзе.

Мин сине көтмимен кичләрен –
Беләмен сүнгәнен хисләрең.

Нигә соң төннәрен киләсең,
Сорамый төшемә керәсең!?
Керәсең, елмаеп көләсең –
Мин сине сөямен, күрәсең...
Әллә соң син мине сөясең?!

***

Син киткәндә шундый горур идең,
Әйтерсең лә сиңа мин тездән.
Шуңадырмы, җаның тоймады күк
Сагынасыңны мине бик тиздән.

Сагынырсың әле якты көндә
Минем чәчәкләрнең исләрен.
Кара төндә сине җылытырлар
Сиңа булган кайнар хисләрем.

Сагынырсың минем кочагымны,
Җаның эреткән татлы назымны.
Сагынырсың минем белән булган
Һәр көнеңне, көзең, языңны.

Сагынырсың. Мин беләмен синең
Кайтасыңны киткән юлыңнан.
Кире кайтып, мине эзләрсең дә
Сагынырсың, җаным.
Мин булмам!

***

Саубуллашмый гына китеп бардың.
Хушлашырга көчең җитмәде.
Әллә курыктыңмы әйтер диеп:
«Тукта, җаным, тукта, китмә әле!»
Саубуллашмый киттең.
Әйталмадым
Иң кирәкле изге сүзләрне
Син беләсең, китә алмас идең,
Әгәр күрсәң минем күзләрне.
Син күрмәдең.
Ул күзләрдә ничек
Сагыш, язмыш, ялгыш буталган.
Ул күзләрдә ничек ут янган да,
Шул күзләрдән ничек боз тамган.
Киткәннәргә: «Тукта!» – диеп әйтү
Кирәк микән, әллә кирәкми?!
Тик шулай да бары шушы сүзләр
Саклап калган сөю сирәкме?!

Еллар үтәр, бәлки, вакыт җитәр
Ачар өчен бикне, келәне.
Күпме гашыйк өзелеп көтә булыр
Тик бер сүзне: «Җаным, кил әле!»

***

Беләм инде синең карарыңны –
Без китәбез төрле якларга.
Беләм инде, күптән тартыласың,
Күптән тартыласың ятларга.

Ятлар диюем дә дөрес булмас.
Минем өчен генә ятлардыр.
Инде күптән синең йөрәгеңдә
Башка берәү урын тапкандыр.

Инде беләм – синең хатларыңда
«Сөям» дигән сүзең тик ялган.
Инде күрәм – синең күңелеңдә
Җиде ятлар булып мин калган.

***

Сөям, диеп йөрәгемә кердең.
Ничек таптың шушы ачкычны?..
Тын күл иде бит ул. Тик, күрәсең,
Һәрбер күлнең була аккошы.

Син дә аккош кебек язда килдең,
Күңелемнең эретеп бозларын.
Ярсып, ярларыннан чыкты йөрәк,
Тик оныткан алда көз барын.

Инде китә аккош. Сагышлардан
Тын күлемне бозлар каплады.
Минем күңел дөньяларны айкап,
Эзләп-эзләп сине тапмады.

Ә шулай да сине көтә әле.
Ул бит белә сине табасын.
Күл дә белә – язлар белән бергә
Аккошының кире кайтасын.

Алда ярлар бардыр әле

(«Алда гомер бар микән?» халык җыры көенә)

Без сөешкән аланнарда
Үсә иде тал-тирәк шул,
Үсә иде тал-тирәк.
Мине ташлап китәр өчен
Бик өшегән җан кирәк.

Һаман әле чәчәк ата
Син яраткан гөлләрем шул,
Син яраткан гөлләрем.
Минсез сиңа кыен булыр,
Айлы булсын төннәрең.

Күзләр диеп тормый әле
Чәчәк ата гөлләрем шул,
Чәчәк ата гөлләрем.
Әй, җаныем, алда әле
Бик сагыныр көннәрең.

Алда ярлар бардыр әле,
Мин соңгысы булмасын шул,
Мин соңгысы булмасын.
Мине искә алган чакта
Күңелләрең тулмасын.

Инде янә кышлар килә,
Мулдан булыр карлары шул,
Мулдан булыр карлары.
Минем кебек өзелеп сөйсен
Сине яңа ярларың.

***

Киткәннәргә яхшы теләк телә,
Тик киткәннәр кире кайтмасын.
Озатулар кыен. Кире кайтып
Какмасыннар күңел капкасын.
Киткәннәргә яңа бәхет телә,
Бәхет булсын яңа ярларда.
Кайтмасыннар кире. Кемгә кирәк
Бер үк утта янә янарга.
Киткәннәргә якты юллар телә.
Шул юллардан ерак китсеннәр.
Кайтмасыннар кире. Калганнарның
Ачы күз яшьләре кипсеннәр.
Киткәннәргә изге теләк телә –
Яңа юллар алда ачылсын.
Кайтмасыннар кире. Тоймасыннар
Аерылуның сагыш, ачысын.
Кайтмасыннар кире!

Редакциядән:

Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.

Илшат Винзел улы Билалов 1967 елның 22 апрелендә Казанда туган. 1984 елда 83 нче мәктәпне алтын медаль белән тәмамлап, ул Казан дәүләт медицина институтының дәвалау факультетына укырга керә. 1990 елда аны Кызыл диплом белән тәмамлап, башта хирургия кафедрасында ординатурада, аннары аспирантурада укып чыга. Казанның 6 нчы хастаханәсендә эшли башлый. Кандидатлык диссертациясе яклаганнан соң, медицина институтының йөрәк-кан тамырлары һәм эндоваскуляр хирургия кафедрасында студентларга белем бирә, бер үк вакытта «Төбәкара клиник-диагностика үзәге»ндә (МКДЦ) табиб булып эшли. Гамәлдәге табиб Илшат Билалов әнисе вафат булганнан соң кулына каләм алып, күңел кичерешләрен кәгазь битләренә төшерә башлый. Аның беренче язмалары 2014 елда «Шәһри Казан» газетасы битләрендә дөнья күрә. Бүгенге көндә ул табиблар хезмәтен сурәтләгән берничә повесть һәм хикәя авторы. Аның авыл табиблары тормышына багышланган «Мәдинә тавы» исемле әсәрен укучыларыбыз игътибарына тәкъдим итәбез.

Илшат
Билалов

МӘДИНӘ ТАВЫ

ПОВЕСТЬ *

Җәйнең беренче көне булуга карамастан, урамда салкынча, яңгыр сибәләп тора. Шәһәр уянып килә, курткаларга төренгән, кулларына зонтиклар тоткан кешеләр эшкә ашыга. Гөлшат автобус тәрәзәсе аша Казан белән саубуллаша. Ул, интернатураны тәмамлап, министрлыктан яңа эш урынына юллама алды. Алда аны яңа тормыш, яңа кешеләр көтә. Казанга тагын кайчан кайтыр? Монда туды, монда балачагы узды. Беренче уңышлар, беренче мәхәббәт, беренче хыянәт. Күпме шатлыклы көннәр булды, авыр кайгылар да кичерергә туры килде. Бүген зур тормышның беренче адымнары. Казанда да калырга була иде, ләкин үзе теләмәде. Соңгы елда башына төшкән борчу-кайгыларны, хыянәтне ул оныта алмады. Аның беркемгә дә, хәтта әтисенә дә әйтмичә, чип-чиста биттән яңа тормыш башлыйсы килде. Гөлшат республиканың берәр ерак районындагы үзәк хастаханәгә эшкә җибәрүләрен үзе сорады. Үткәне белән бернәрсә дә бәйләп тормасын өчен, ул хәтта кесә телефонын да алмады. Әтисенә дә, эзләмәүләрен үтенеп, язу гына калдырды. Автобус кузгалып киткәч, Гөлшат: «Аллага тапшырдым, хәерле сәгатьтә, хәерле минутта!» – дип,

* Журнал варианты.

эченнән генә үзенә хәерле юл теләде. Мәрхүм әбисе эш башлар алдыннан шулай әйтергә өйрәткән иде.

Автобус район үзәгенә килеп җиткәндә, яңгыр туктаган, болытлар арасыннан кояш та караштыргалый башлаган иде. Зур сумка һәм чемодан күтәргән Гөлшат хастаханәне эзләп тапты. Ул яңа булмаса да, тыштан матур итеп буялган, тирә-юне чиста. Бина янында «03» дип язылган ике яңа «УАЗ» машинасы тора. Беренче очраган ак халатлы ханымнан баш табибның кабул итү бүлмәсен сорашып, ул ашыкмыйча гына, шул якка таба китте.

Баш табиб урынында булмады.

– Бер сәгать элек главага чакыртып алдылар, ашыкмасагыз көтеп торыгыз, – диде кабул итү бүлмәсендә утырган озын чәчле яшь, чибәр кыз.

Зур булмаган кабул итү бүлмәсе бик җыйнак һәм якты иде. Сәркатип өстәлендә компьютер, ксерокс, факс тора. Барысы да тәртиптә, бер генә артык кәгазь дә аунап ятмый.

– Сез Казаннан килгән яшь табиб булырга тиеш, ялгышмасам? – дип, сүз башлады сәркатип кыз.

– Ялгышмыйсыз. Каян белдегез? Маңгаема язылганмы әллә? – диде Гөлшат, елмаеп кына.

– Илдар Азатович мине: «Казан медицина университетын тәмамлаган яшь табиб килергә тиеш», – дип кисәтеп куйган иде. Юлда арыгансыздыр, өс киемегезне салып, монда элегез, хәзер чәй әзерлим. Сез нинди чәй яратасыз – каранымы, әллә яшелнеме? – Кыз, урыныннан торып, электр чәйнеген кабызып җибәрде.

– Рәхмәт, борчылмагыз.

– Мин Гөлнара булам, былтыр мин дә медицина университетына имтихан бирергә барган идем, ләкин керә алмадым. Илдар Азатович бер елга эшкә алды. Быел тагын барып, сынау биреп карыйм, минем дә табиб буласым килә. Ә сезнең исемегез ничек? – кыз, өстәл өстенә шкафтан чынаяклар, варенье, бал, печеньелар чыгарып куйды.

– Мин – Гөлшат Равилевна. Бик зур рәхмәт, чынлап та берәр чынаяк кара чәй эчсәң, Илдар Азатович белән сөйләшүе җиңелрәк булыр иде, – дип шаяртты Гөлшат һәм өстәл янындагы урындыкка күчеп утырды.

Озак чәйләп утырырга туры килмәде, бүлмәгә Илдар Азатович килеп керде. Кызлар көлешә-көлешә чәй эчеп утырган җирләреннән кинәт тынып калдылар.

Уйларыннан бер мизгелгә генә югалып калган Илдар Азатович Гөлнара белән бүлмәдә утырган сылу гәүдәле, ачык йөзле чибәр кызга башыннан аягына кадәр ирләрчә күз төшереп алды. Кызның чәчләре бик озын булмаса да, җыйнак кына артка үреп куелган, җиңелчә генә бизәнгән, ялтырап торган күзләрдән нindiдер эчке нур бөркелеп тора иде. Колакларында кызыл ташлы алкалар, муенында нәзек кенә чылбырга эленгән ай күкрәгенә кадәр төшеп тора. Күлмәге бик кыйммәтлегә охшамаган, ләкин гәүдәсенә бик килешә, аягында биек үкчәле туфли.

– Исәнмесез, Гөлшат Равилевна. Мин – Илдар Азатович. Бирегә, түр бүлмәгә узыгыз, сөйләшәсе сүзләр күп. Гөлнара, Ринатны эзләп тап, машинасы белән монда килеп җитсен, – диде дә, бүлмәсенә узды.

Илдар Азатович озын буйлы, таза гәүдәле булса да, бик җитез кеше иде. Бүген көтмәгәндә, район башлыгы аны үзенә чакыртып, бөтен планнарын

бозып куйды. Кичә Сәламәтлек саклау министрлыгыннан шалтыратып, районга күптән көтелгән яшь табиб кайтуы турында хәбәр иткәннәр иде. Инде күптән пенсиядә булуына карамастан, терапия бүлеге мөдире булып эшләүче Румия Хатыйповнага ярдәмче бик кирәк. Участок терапевтларына түләүне арттыргач, бүлектә эшләгән табиблар участокка китеп беткәннәр, район үзәк хастаханәсенең терапия бүлегендә эшләргә кеше калмаган иде. Ярый әле поликлиникада эшләүче терапевтлар ярты көнгә генә килеп булса да, үзәк хастаханәдә дә эш алып баралар. Район зур шәһәрләрдән ерак урнашканга күрә, яшь табиблар эшкә килергә бик атлыгып тормый иде.

Район башлыгы юкка гына чакырмаган булып чыкты:

– Минем туганым Мәскәүдә ординатура тәмамлады, бу айда безгә эшкә кайта. Сез күптәннән кардиологлар җитми дип зарланасыз. Югары белемле яшь белгечне яхшы каршы алырга кирәк. Мин аңа үземнең фондтан фатир бирермен. Минем уемча, бу кызны терапия бүлеге мөдире итеп куярга кирәк. Румия Хатыйповнаны лаеклы ялга озатсагыз да була, ул пенсиядә бит. Әгәр хәленнән килсә, хастаханәдә гади табиб булып эшләр.

Көтмәгәндә, районга тагын бер белгеч кайтуы турындагы бу хәбәр баш табибны уңайсыз хәлдә калдырды. Беренчедән, район башлыгына каршы сүз әйтергә ярамый, аның боерыгын үтәргә кирәк. Икенчедән, бүген-иртәгә министрлык юлламасы белән килергә тиешле яшь табибны кая урнаштырырга? Атна азагында булачак җыелышта яшь табиб өчен район башлыгыннан бер бүлмә сорамакчы иде бит ул. Хәзер бу сорауның җавапсыз калачагы көн кебек ачык. Румия Хатыйповнаны да утыз ел эшләгән урыныннан кинәт кенә чыгарып җибәрәсе килми. Яңа кызы нинди булыр бит әле, эшли алырмы? Кияүгә чыгып китеп барса, монда кем эшләр? Аннары аның район башлыгының туганы булуы да бик яхшыдан түгел. Башта куып чыгарып, соңыннан Румия Хатыйповнаны яңадан чакырырга туры килмәс микән? Иртән яхшы гына башланган көн, бик мәшәкатьле булып чыкты. Ләкин һәр мәсьәләнең үз чишелеше була, аны табарга гына кирәк.

Илдар Азатович район башлыгы яныннан шундый уйлар белән кайткан иде. Баш табиб кабул итү бүлмәсендә кызлар тавышын ишеткәч, бераз югалып калды. Бу мәсьәләне болай ук тиз чишәргә кирәк булыр дип уйламаган иде. Ләкин ул артка чигенергә яратмый.

– Бирегә узыгыз, – дип, Илдар Азатович Гөлшатны каршысына утыртты. – Әйдәгез, сөйләгез, ничек укыдыгыз, интернатураны кайларда уздыгыз, планнарыгыз нинди? – дигән сораулар белән вакытны сузды.

Бу кызның кайда, ничек укуын, әти-әнисенең кемнәр булуын, кайда, ничек практикаларын, интернатураларын узуын ул белә иде. Шулай вакыт сузып, ул килеп туган четерекле хәлдән чыгу юлын эзләде. Аның нишләптер бу кызны кире Казанга озатасы килмәде. Район үзәк хастаханәсендә дә Гөлшатны калдырырга мөмкинлек юк, чөнки Румия Хатыйповнаны эштән җибәрәсе килми, шулай ук башлык тагын бер бүлмә бирмәячәк, ә торыр урын юк, тулай торак тәкъдим итәсе килми иде...

Куркып кына кергән Гөлшат урындык кырыена барып утырды. Өстәлдә В.В.Путин белән М.Ш.Шәймиевнең бергә төшкән фотосы тора. Сорауларга ул университетта имтиханнар вакытындагы кебек җавап бирә башлады:

– Мин дәвалау факультетын тәмамладым, соңгы сынауларны «бишле»гә генә бирдем, интернатураны Республика клиник хастаханәсендә уздым, күпчелек өлеше кардиология буенча.

– Ник Казанда калмадыгыз, нигә әти-әниегезнең туган якларына кайтмадыгыз? – дип, кинәт сорау биреп бүлдерде аны Илдар Азатович.

Көтелмәгән сораулардан бераз каушап калган Гөлшат, имтихан вакытларындагы кебек, үзен кулга алып, яңадан сөйләп китте:

– Казанда хастаханәләргә урнашу авыр, поликлиникага барасым килмәде. Анда табиблар кәгазь тутырып вакыт уздыралар. Ә минем кешеләр белән эшлисем килә. Башта хирург буласым килгән иде, Ашыгыч ярдәм күрсәтү хастаханәсенә дә барып йөргәләдем, ләкин булдыралмам дип курыктым. Аннары хатын-кызлардан яхшы хирурглар бик сирәк чыга, диләр, чыкса да, аларның күпчелеге тормышта бәхетсез була дигән сүзләр дә ишеттем.

– Сезгә дөрес әйткәннәр. Мин, үзем хирург буларак, бу сүзләрегезне дөрес дип саныйм, – дип әйтеп куйды Илдар Азатович, кинәт башында яңа фикер туууына сөенеп. – Кешеләр белән эшлисе килә, дисезме? Алайса мин сезне районыбызның иң гүзәл бер почмагына җибәрәм. Ул район үзәгеннән алтмыш чакрым ераклыкта урнашкан, утыз авыруга исәпләнгән хастаханә. Үзегез баш табиб булырсыз. Сезнең кул астында дүрт шәфкать туташы, өч санитарка, бер шофёр эшләячәк. Ничек, ризамы? – дип, мәсьәләнең шулай тиз чишелүенә шатланып куйды Илдар Азатович.

– Анда башка табиблар юкмыни? – диде, кешеләр белән эшләргә хыялланып килгән яшь табиб, борчылып.

– Ризалашыгыз. Анда хәзер бер теш табибы гына эшли. Район үзәгендә дә стоматологлар җитешми. Аны кире монда күчерәбез. Мин сезгә ышанам. «Без булдырабыз!» – ди бит безнең җитәкчеләр, – диде елмаеп, Илдар Азатович.

– Мин анда кайда торырмын икән? Мине бит министрлыктан биредә эшләргә дип җибәргәннәр иде. Тәҗрибәм дә юк, эшли алырмын микән? – Гөлшат бөтенләй куркуга төште.

– Телефон бар бит, шалтыратырсыз, ярдәм итәрбез. Анда бик яхшы өлкән шәфкать туташы эшли. Аннары ерак ара түгел, катлаулы авыруларны машина белән монда күчерерсез. Әйдәгез инде, ризалашыгыз. Андагы табигатьне күрсәгез?! Татарстанның иң матур урыннарыннан берсе ул. Табигатенә күрә, анда яшәүче кешеләре дә бик саф күңелле. Бер эшли башласагыз, кайтасыгыз да килмәс. Кияүгә дә шунда бирербез. Анда егетләр күп булмаса да, барысы да арысландай, берсеннән-берсе чибәр.

– Мин монда кияүгә чыгарга дип килмәдем, эшләргә, авыруларны дәваларга килдем, – диде Гөлшат, Илдар Азатовичның соңгы сүзләренә ачуы килеп.

– Мин сезгә эш тәкъдим итәм бит, сез шуны аңларга теләмисез. Егетләр турында әйткәнем өчен гафу итегез, ләкин хатын-кыз вакытында кияүгә дә чыгарга тиеш. Ничек, барасызмы? – диде баш табиб тыныч кына.

– Уйларга кирәк, – дип, үз көченә бик ышанып җитмичә җавап бирде Гөлшат.

– Озак уйлагач, булмый инде ул. Алдан ук әйтим, бер кимчелек бар, безнең ул авылыбызда кесә телефоны тотмый. «Киләсе елларга телефон

вышкасы куярбыз», – дип сүз биргәннәр иде дә, булырмы, юкмы, төгәл әйтә алмыйм.

– Миңа кесә телефоны кирәкми, аннан шәһәрдә дә туеп беттем. Аннары, кем белән сөйләшим мин монда, туганнарым, танышларым юк.

– Алайса килештек. Әнә, Ринат та машинасы белән килеп җитте. Ул сезне илтеп куяр, – дип, баш табиб тәрәзә төбенә сызгырып килеп туктаган «УАЗ»икка ымлап күрсәтте.

– Ярар алайса. Мин риза, ләкин минем бер шартым бар. Әгәр ярдәм кирәк булса, озак көттерми, ярдәм кулын сузарсыз.

– Ризалаштык. Әйдәгез, кул биреп саубуллашыйк. Документларыгызны Гөлнарага калдырыгыз, ул бөтенесен җиренә җиткерер, борчылмагыз. Ул сезне бер күрүдә яратты, – дип, Илдар Азатович саубуллашырга кулын сузды.

– Яратканын каян белдегез?

– Чәй эчкәндә, каен җиләге вареньесын авыз иттегезме?

– Бар иде шул, бик тәмле иде.

– Ул варенье бик якын һәм кадерле кунакларга гына чыгарыла, – дип көлеп куйды баш табиб.

Селекторга басып, ул Гөлнараны чакыртып кертте:

– Гөлнара, Гөлшат Равилевна Каратау хастаханәсендә эшләячәк. Тиз генә документларының копияләрен ал да гариза яздыр, аннары кадрлар бүлегенә илтеп бирерсең. Чәең суынмаган булса, миңа да тиз генә әзерләп керт, каен җиләге вареньесын да алып керергә онытма, – дип, Илдар Азатович Гөлшатка карап, күзен кысып куйды. Ләкин чәйләр эчеп утырырга туры килмәде, аны операцияләр бүлмәсенә чакырдылар.

– Гөлшат Равилевна, үпкәләмәгез инде, яхшы итеп каршы алып, сөйләшеп тә утыра алмадык. Районда тик утырырга бирмиләр. Эш күп, – дип, ул тиз генә чыгып китте.

– Очрашулар, сөйләшүләр күп булыр әле. Монда эшләргә килдем бит, – дип куйды Гөлшат.

– Шундый кызу кеше ул безнең Илдар Азатович. Кайвакытларны давыл кебек килеп керә дә бөтен дөньяны туздырып чыгып та китә, – диде Гөлнара.

Гөлшатның башыннан: «Аның давылларына миңа да эләгергә туры килер әле», дигән уй йөгереп үтте. Гөлнара тиз генә бөтен документларны әзерләп куйды. Бер сәгать дигәндә, Гөлшатны утырткан «УАЗ»ик, аның яңа эш урынына таба чаба иде. Машина йөртүче Ринат, яшь, чибәр табибә кызны күргәч, берничә тапкыр сүз башларга тырышып, шаяртып караган булды, ләкин Гөлшат үз уйлары-борчуларына чумган иде, сорауларның берсенә дә җавап бирмәде. Ринат ачуыннанмы, чибәр кыз алдында азрак масаерга теләпме, газга ныграк басып, машинасын тизләтте. Зур юлдан борылгач, машина тагы да катырак сикертә башлады. Ринат машинаны акрынрак алып барырга мәҗбүр булды. Еракта урманнар белән капланган таулар күренә башлады. Гөлшат сискәнеп киткәндәй сорап куйды:

– Зур юлдан авылга хәтле ничә чакрым?

– Юлдан ун гына чакрым, хәзер мин сезне тиз генә алып барып җиткерәм. Менә теге алдагы тауга күтәрелсәк, килеп җиттек дип әйтергә була.

Юл, чынлап та, тауга менеп китте. Тау башына менеп җиткәч, күз алдында зур авыл күренеше ачылды. Авыл тау итәгендә урнашкан иде.

Шул тау авылны үз кочагында саклап тотып торадыр төсле. Йортларның күпчелеге агач бүрәнәләрдән салынган. Казан шәһәре янындагы зур-зур таш коттеджлар монда юк иде. Бөтен урамнар, балалар ясаган рәсемдәге кояш нурлары кебек, авыл уртасындагы иске зур таш бинадан төрле якларга таралган. Машина шул таш бина янына килеп туктады.

– Гөлшат Равилевна, сез бу ишеккә, кабул итү бүлмәсенә керә торыгыз, мин хәзер, биш минуттан килеп җитәм, – дип, Ринат ишеккә күрсәтте.

Гөлшатның башында «Мин кая килеп эләктем? Казаннан китеп ялгышмадыммы?» дигән уйлар кайнады. Университетта имтиханга кергәндәге сыман, аны ниндидер курку биләп алды, аяклары бер мизгелгә катып калдылар. «Бисмилләәһир-рахмәнир-рахиим, Аллага тапшырдым», – дип, бу иске бинаның ишеген ачып, эчкә узды...

Кабул итү бүлмәсендә беркем дә юк, тыныч иде. Гөлшат, туктап, як-ягына каранды. Бүлмәдә чиста һәм якты. Стеналар һәм түшәмнәр аксыл буяуга буялган. Ләкин игътибар белән карасаң, ремонт күптән ясалмаганлыгы күренеп тора – идәндәге линолеум урыны-урыны белән төссезләнгән, стеналарда буяу кубып төшкән җирләр дә бар. Бүлмәнең бер чатында ятак белән кечкенә тәбәнәк шкаф тора. Аның өстендә ЭКГ аппараты урнаштырылган. Тумбочка янындагы кечкенә өстәлдә стерильләнгән бинтлар һәм хирургия кораллары куелган. Каршыда өстәл һәм өч урындык. Гөлшат шул урындыкларның берсенә барып утырды. Ул бу хастаханәнең исен татып карамакчы булды. Театр кием элгеченнән башланса, хастаханә кабул итү бүлмәсеннән башлана. Ләкин озак утырып торырга туры килмәде. Ишек төбендә машина туктаган тавыш ишетелде, кабул итү бүлмәсенә урта яшьләрдәге ике ир-ат килеп керде. Берсенең аягын ак чүпрәккә ураганнар, ул кып-кызыл канда иде. Әлеге ир-ат иптәшенең җилкәсенә таянып керде дә ятакка барып ятты. Икенчесе, Гөлшатка игътибар итмичә генә, туры хастаханәгә кереп китте.

Гөлшат, тиз генә плащын салып, кулын юды да кушеткага кереп ауган ир-ат янына килеп:

– Сезгә ни булды? – дип сорады.

– Аягыма ялгыш кына болгарка тиеп киткән иде, итен ярып атты, – дип, ир-ат ак чүпрәккә уралган аягына күрсәтте.

Гөлшат тиз генә аякка уралган чүпрәкләрне чишеп атты. Кысып бәйләнгән чүпрәкләрдән арынгач, тездән әз генә астарак булган зур ярадан кан ага башлады. Гөлшат, өстәл янына килеп, кирәкле инструментлар белән салфеткалар алды. Берничә генә секунд узуга да карамастан, кан идәнгә тама башлаган иде. Гөлшат сул кулы белән ярадан өстәрәк басты да әз генә яраны ачты, кан тагын да ныграк ага башлады. Бер генә мизгелгә яшь табиб югалып калгандай булды, ләкин тиз генә, үзен кулга алып, кыскычларны ярага кыстырды һәм кан агуын туктатты. Ятакта яткан ир-ат ап-ак булды, тешләрен кысып кычкырмаска тырышты. Кан агудан туктагач, Гөлшат тирән итеп сулап куйды. Ләкин аның канга баткан куллары әле һаман калтырый иде.

– Гөлшат Равилевна, халат һәм перчаткалар киегез, мин сезгә ярдәм итәрмен, – дип, олырак яшьтәге ак халатлы бер апа Гөлшатка халат сузды.

– Исәнмесез. Гафу итегез, сез кем буласыз? Сез минем исемемне беләсез, мин сезнекен юк, – дип, Гөлшат бүлмәнең бер почмагындагы юынгычка барып, озак итеп сабынлап кулын юды һәм биргән халатны киде. Аның башына «Юләр, кем инде, кулын да юмыйча, перчатка кимичә, ярага тотына? Җитмәсә авыртуын басар өчен бернинди укол да ясамадым. Тагын берәр акылсыз адым ясамасам ярый инде» дигән уйлар килде.

– Мин – Фәимә Вахитовна, бу хастаханәнең баш шәфкать туташы булам. Миңа Фәимә апа дип эндәшсәгез дә була.

Шул вакыт кушеткада ятучы абзый:

– Фәимә апа, аягымны нишләтәсез, минем турында онытгыгызмы әллә? Мин канап үләм бит инде! – дип тавыш бирде.

Фәимә апа йомшак кына тавыш белән абзыйны тынычландырды:

– Хәзер, Идрис, үлмисең, сабыр ит. Сез, Гөлшат Равилевна, утырып торыгыз. Мин бу яралы егеткә уколлар ясап алам, аннары сез эшегезне эшләп бетерерсез. Бәлки, Айдар Юнысовичны чакырыргадыр?

– Ә кем соң ул?

– Ул – мин, – дип, кабул итү бүлмәсенә ак халат кигән яшь ир-ат килеп керде.

Айдар Юнысович, кушеткада яткан абзый янына килеп, ярасын карады:

– Яра канамый, бәйләгез дә район үзәк хастаханәсенә озатыгыз. Столбнякка каршы анотоксин ясарга онытмагыз. Гөлшат Равилевна, мин сезне табиблар бүлмәсендә көтәм. Эшне сезгә тапшырырга да, җыенырга кирәк, – диде дә бүлмәдән чыгып та китте.

Гөлшат, тиз генә өстенә – халатын, кулларына перчаткалар киде һәм яралы абзый янына килде. Каушаудан куллары калтырауга да карамастан, абзыйның аягындагы ярасын тегеп тә куйды. «Яшь булса да, куркаклардан түгел, бу кыз белән эшләп булыр, ахрысы», дигән уйлар белән Фәимә апа Гөлшатка ярдәм итте.

– Фәимә Вахитовна, яраны үзегез бәйләрсез, мин Айдар Юнысович белән сөйләшеп алам, – дип, Гөлшат, перчаткаларын салып, кулын юды.

– Идрис белән ни эшлибез? Районга җибәрәбезме, әллә монда гына калдырыйкмы?

– Тектегез бит инде. Мин районда нишлим? Монда калдырмасагыз, мин өйгә генә кайтам, – дип каршы килде Идрис.

– Кара әле бу батырны, әле генә үләргә әзерләнгән идең түгелме соң? Гөлшат Равилевна ничек әйтсә, шулай эшләрбез, – дип, Фәимә апа сораулы караш белән Гөлшатка карады.

– Берничә көнгә монда гына калып торсын, куркыныч юк. Авыру тарихын ачарсыз, аннары, Айдар Юнысович белән сөйләшкәч, мин аны үзем тутырырмын, – дип җавап бирде Гөлшат, рольгә кереп.

Кинәт кабул итү бүлмәсенә машина йөртүче Ринат килеп керде. Ул Гөлшатның сумкасын алып килгән иде:

– Килмәс борын, сез инде эшли дә башладыгызмы? Эштән бәхетегез бар икән!

– Эш юләрләрне ярата, дип әйтмәкче буласыз инде?

Гөлшатның йөрәге дөп-дөп тибә, эчендәге калтырану әле һаман бетмәгән иде. Шуны яшерер өчен ул тизрәк бу бүлмәдән чыгып, хастаханәгә кереп китте.

Хастаханә кечкенә түгел. Зур гына бүлмәләр, биек ак түшәмнәр бу бинаны эссе көннәрдә дә салкынча тота. Коридорда авырулар күренмәде. Уртадагы шәфкать туташы өстәле янында ак халатлы яшь кенә чибәр кыз нәрсәдер язып утыра.

– Исәнмесез, мин сезнең яңа табибыгыз булам. Айдар Юнысовичны мин кайда күрә алам? – дип, Гөлшат кызга эндәште.

– Исәнмесез, Гөлшат Равилевна. Мин – Тәнзилә, монда шәфкать туташы булып эшлим. Мин хәзер Фәимә апаны табып килермен, – дип сөйләнә-сөйләнә, ул тиз генә урыныннан сикереп торды.

Гөлшат аны тынычландырырга ашыкты:

– Борчылма, Тәнзилә, Фәимә апа белән мин инде таныштым, миңа Айдар Юнысович кирәк иде.

– Аның бүлмәсе түрдәрәк, ул әле генә шунда таба киткән иде, – дип, табиб бүлмәсенә күрсәтте Тәнзилә.

Гөлшат кергәндә, Айдар Юнысович өстәлен тәртипкә китереп маташа иде. Ул, кирәкмәгән кәгазьләрне ертып, чүп чиләгенә ташлады.

– Тагын бер тапкыр исәнмесез. Мондый тәртипсезлек өчен гафу итегез, мин хәзер. Һаман вакыт таба алганым юк.

– Борчылмагыз, мин үзем җыештырырмын. Монда бит хәзер миңа эшләргә. Сез миңа бу хастаханә турында сөйләсәгез, бик шат булыр идем. Хастаханәдә күпме кеше эшли?

– Бер баш шәфкать туташы, дүрт шәфкать туташы бар, өч санитарка. Бу хастаханәнең хуҗабикәсе Фәимә апа, ул гомере буе монда эшләгән. Авылдашларын бик яхшы белә, аны да бик яхшы беләләр, хөрмәт итәләр. Дөресен әйткәндә, ул кайчакларда табиб урынына да калгалый. Үз һөнәренең остасы, минем дә аңардан күп тапкырлар киңәш сораганым булды. Ул чирләрне дә билгели белә, бала да таптыра, кечкенә операцияләрне дә үзе ясый ала. Авыр чакларда киңәш сорарга оялма, ул – бик акыллы хатын. Тәҗрибәсе зуррак булса да, беркайчан да табибларны кимсетми. Монда коллектив бик яхшы, авылда да бик яхшы кешеләр генә яши. Табигать тә искиткеч матур.

Гөлшат көлеп җибәрде:

– Бу сүзләрне миңа берничә сәгать элек Илдар Азатович та әйткән иде, шуңа күрә кызык булып китте. Мине кайда урнаштырырлар икән?

– Борчылмагыз. Бу мәсьәлә тиз арада хәл ителәчәк. Ә хәзергә хастаханә белән таныша торыгыз, – дип, Айдар Юнысович тагын бер кат бүлмәсеннән, өстәленнән күз йөртеп алды.

– Гөлшат Равилевна, әйдәгез, юлдан соң чәйләр эчеп, ашап алыйк. Айдар Юнысович, сез дә юл алдыннан тамак ялгап алыгыз, – диде бүлмәгә килеп кергән Фәимә Вахитовна.

– Бик зур рәхмәт, Фәимә апа, минем әле җыенасым да бар, сез Гөлшат Равилевнаны сыйлагыз. Ул монда каласы кеше.

– Әйдә, әйдә, күп сөйләнеп торма, ярты сәгать безнең белән чәй эчүдән бер җирең дә кимемәс, җыенырга өлгерерсең. Ринат барыбер туганнарына китте әле, тиз генә килмәс, – дип, йомшак кына әйтеп куйды Фәимә апа.

– Менә шулай, Гөлшат, бу апаның сүзе монда закон, каршы килергә ярамый. Киттек, чәй эчеп алабыз, аннары сезнең өчен экскурсия үткәрербез,

бу – бик тарихи хастаханә, – диде Айдар Юнысович, җыенуыннан туктап һәм Гөлшат белән Фәимә апа артыннан иярде.

Өлкән шәфкать туташы бүлмәсе артык зур түгел, ләкин кечкенә дип тә әйтеп булмый. Бүлмә уртасында өстәл әзерләнгән иде. Өстәлдәге ап-ак җәймә өстенә ике төрле варенье, бал, гөбәдия куелган. Бүлмәгә тәмле чәй исе таралган. Гөлшат игътибар белән бүлмәне күзәтте.

– Бу – әлеге «патша сарае» хуҗабикәсенең бүлмәсе. Табиблар киләләр дә китәләр, Фәимә апа гына беркая да китмичә, менә инде утыз елга якын монда эшләп йөри, – диде Айдар Юнысович, бүлмәгә кергәч.

– Син мине бөтенләй картайтып бетердең. Синең сүзләреңнән соң мин үземне убырлы карчык кебек хис итә башладым, – дип, Фәимә апа өстәлгә өч чынаяк китереп куйды.

– Ә без өчәү генә булабызмыни, нишләп башка шәфкать туташларын да чакырмыйсыз? – дип сорап куйды Гөлшат.

– Сез каршы булмасагыз, мин кызларны чакырам, – диде бүлмәнең хуҗасы.

– Әлбәттә, әлбәттә, шунда барысы белән дә танышырбыз, өстәл янында күңеллерәк тә булыр.

Гөлшат кая утырырга, нәрсә эшләргә белмичә югалып калды.

– Сез бүген кунак, шуңа күрә менә монда түргәрәк утырыгыз, – дип, Фәимә апа тәрәзә янындагы урындыкка күрсәтте һәм ишек ачып кына кызларны чакырды.

Аларны яшь табиб килү турында кисәтеп куйганнар иде, шуңа күрә барысы да танышырга җыелышканнар. Чакыруны ишеткәч, гөрләшеп килеп тә керделәр.

– Менә бусы – Асия, озын буйлысы – Гөлгенә, ә менә бу – гөбәдия пешереп алып килгән Тәнзилә, – дип, сүзне озынга сузмыйча, Фәимә апа арттан кергән кызга ишарәләп күрсәтте.

– Ә мин – Гөлшат Равилевна, сезнең яңа табибыгыз булам. Айдар Юнысовичны районга алалар, – диде Гөлшат, утырган урындыгыннан торып.

– Кызлар, сез кунакка килмәдегез, барыгыз әле үзегезгә урындыклар алып керегез, – дип, Фәимә апа кызларны борып чыгарып җибәрде. Кызлар озак көттермәделәр, урындыклар күтәреп, яңадан килеп керделәр дә өстәл янына тезелешеп утырдылар.

– Фәимә апа, син утыр, мин чәйләрне үзем ясыйм, – дип, Тәнзилә, Фәимә апа гөбәдия кискән арада, чәйләр әзерли башлады.

– Чәегез бигрәк хуш исле, әллә инде Һиндстан тауларының үзеннән китереп бирәләр, – дип, Гөлшат сүз башлады.

– Безгә Һиндстан да, Цейлон да кирәк түгел. Безнең үзебезнең болыннарда, тауларда үскән тәмле-тәмле, хуш исле үләннәребез бар. Менә авыз итеп карагыз әле, – дип, Тәнзилә беренче чынаякны Гөлшатка сузды.

– Тәнзилә, гөбәдияң искиткеч тәмле, – дип мактый-мактый Гөлшат гөбәдияне авыз итте.

Шулай чәй эчә-эчә кызлар бер сәгатькә якын сөйләшеп утырдылар. Айдар Юнысович кына бер чынаяк чәй эчүгә үк:

– Җыенасым бар, – дип, чыгып китте.

Гөлшат бу кешеләр арасында үзен бик иркен хис итте. Танышканына

бер сәгать кенә булса да, кызлар аңа күптән белгән, күптән бергә эшләгән дуслары кебек тоелды. Нинди холыклы кеше булыр икән яңа табибыбыз, дип борчылган Фәимә апа да тынычланды. Ул кабул итү бүлмәсендә курыкмыйча эшкә алынуын күрү белән үк Гөлшатны ошатты. Кызлар белән үзен тиң тотуын күргәч, бөтенләй тынычланды, үзебезнең кеше, гади, Казан кызы булса да, саф татарча да сөйләшә, дип уйлады.

– Ярар, кызлар, эшләргә кирәк. Сезгә ирек бирсәң, көн буе өстәл яныннан тормассыз, – дип, Фәимә апа гөрләшеп утырган кызларын туктатып, бүлмәдән чыгарып җибәрде. Фәимә апа белән Гөлшат бүлмәдә икәү генә калдылар.

– Фәимә апа, мин монда кайда торырмын икән? Илдар Азатовичтан да сорарга онытканмын, ул үзе дә бу турыда бер сүз дә әйтмәде, – дип сорап куйды Гөлшат, тәрәзәдән кич җиткәнен күреп.

– Борчылма, без сине бер әбигә урнаштырабыз. Ул ялгыз, өе зур. Эштән бергә кайтырбыз, мин сине озатып куярмын. Ул бик яхшы карчык, килешерсез дип уйлыйм. Син бар, Айдар Юнысович белән сөйләшеп кал, ул тиздән китеп тә барыр.

Гөлшат, бүлмәдән чыгып, Айдар Юнысович утырган бүлмәгә таба китте. Гөлшат кергәндә, ул җыенып беткән, машина йөртүче Ринатны гына көтеп утыра иде:

– Бик вакытлы кердегез, эшне тапшырам да китәргә кирәк.

– Мин сезне игътибар белән тыңлыйм, – диде Гөлшат күтәренке күңел белән, үзенең яхшы коллективка, яхшы кешеләр арасына килеп эләгүенә шатланып.

– Безнең хастаханәбез утыз кешелек, ләкин аның хәтле кешенең бердә беркайчан да булганы юк, күпчелек унбиш-егерме авыру ята, бик сирәк кенә егерме бишкә тула. Күпчелек әбиләр, бабайлар. Бүгенге көндә ун авыру. Унынчысын сез үзегез кабул иттегез. Күбесендә картлык чирләре – артроз, йөрәк, югары кан басымы. Сирәк-мирәк районнан бу авылда һәм якын-тирәдә яшәүчеләрне операциядән соң монда китерәләр. Аларга дәвалау белән бергә яраларын бәйләү дә кирәк булгалый. Кайчак юлда һәлакәткә очраучыларны алып киләләр. Ел буена миңа өч тапкыр бала таптырырга туры килде, дөресрәге, мин карап кына тордым, дип әйтергә дә була, бөтенесен Фәимә апа эшләде. Ләкин әйтеп куям, бала таптырган өчен Илдар Азатович һәрвакыт орыша. Дөресен әйткәндә, күп эшне монда Фәимә апа башкара, мин бит стоматология факультетын тәмамладым, кайбер нәрсәләрне бөтенләй белмим. Менә мин сезгә бернәрсә дә яшермичә сөйләп бирдем. Әйдә, хәзер экскурсиягә алып барам, – дип, алар табиблар бүлмәсеннән чыгып, хастаханә буйлап киттеләр.

– Монда процедуралар бүлмәсе, ЭКГ аппараты кабул итү бүлмәсендә, амбулатория карточкалары да шунда ук. Авырулар тарихларын мин үземнең бүлмәмдә калдырдым. Үзегез карарсыз, аңламаганны Фәимә ападан сорагыз, оялмагыз, ул күп нәрсәне табиблардан да яхшы белә. Операцияләр бүлмәсе дә бар. Заманында монда бик оста табиб эшләгән, операцияләр дә ясаган. Ул инде күптән вафат, ә менә җыйган инструментлары, оештырган операцияләр бүлмәсе хәзер дә саклана.

– Монда лаборатория бармы?

– Кан, бәвел... кебек кайбер анализларны Фәимә апа үзе эшли, кайчакта

Тәнзиләгә куша, катлаулыракларын районга җибәрәбез. Монда УЗИ, рентген аппаратлары юк. Үзеңне патша заманындагы табиб төсле хис итәсең, шул дарулары гына заманча. Хастаханә бинасы да патша заманыннан калган. Бу – зур алпавыт йорты, аны мондагы кешеләр «хан сарае» йә «патша сарае» дип йөртәләр. Шулай итеп, син «хан сарае» кызы буласың.

– «Патша сарае»ның хуҗабикәсе, – дип төзәтеп куйды Гөлшат.

– Юк, монда хуҗабикә Фәимә апа, син үпкәләмә, син «патша сарае» кызы гына, – диде Айдар Юнысович, бер дә шаяртмыйча. Гөлшат бу сүзләргә үзенчә үпкәләп тә куйды.

Алар шулай сөйләшә-сөйләшә кире табиблар бүлмәсенә әйләнеп кайттылар. Шулвакыт ишектән Ринат килеп керде:

– Айдар Юнысович, сез әзерме?

– Бер минуттан әзер булам, хәзер чыгып җитәм, көтеп тор, – дип, Айдар Юнысович, үзе белән алып китәсе әйберләрне барлады.

– Ярар, Гөлшат Равилевна, мин сиңа «пост сдал», сораулар калган булса, кабатлап әйтәм, Фәимә ападан сора. Аны элек эшләгән табибның кызы дип тә сөйлиләр, бәлки, дөрестер, минем сораганым булмады. Монда эшләргә була, кешеләре бик яхшы, ләкин бинасы гына бик иске. Көчле яңгырлар яуганда, түшәмнән ага, калганын эшли-эшли үзең белерсең һәм өйрәнерсең, – дип, Айдар Юнысович бүлмәдән әйберләрен алып чыгып китте.

Гөлшат өстәл янына барып утырды һәм өстә генә яткан авыру тарихларын карый башлады. Алар арасында аягы яраланган ир-атның тарихы да ята иде. Шуларны кулына алып, Гөлшат палаталарда ятучы авырулар янына китте. Алар белән танышып чыкты, кан басымнарын үлчәде. Әбиләр, бабайлар – барысы да кызыксынып, яшь белгечне күзәттеләр. Палаталар буйлап аның килүе турындагы яңалык таралып өлгергән иде инде. Аягын кискән Идрис тә:

– Бик батыр, минем киселгән аякны күргәч тә курыкмады, күз ачып йомганчы тиз генә тегеп куйды. Куллары да шундый йомшак, бу кыздан яхшы табибә чыгарга тиеш, – дип сөйләде.

Бигрәк яшь. Белеме бар микән? Бәлки, Айдар Юнысович кебек Фәимә әйткәнне генә эшләр, дип уйлаучылары да булгандыр. Шулай авыруларны карап чыккан арада вакыт та узып китте. Авыру тарихын язып утырганда, бүлмәгә Фәимә апа килеп керде:

– Әйдә кайтабыз. Наилә апа, телефоннан шалтыратып, аптыратып бетерде инде. Кайчан кызны алып кайтасың, юлдан арыгандыр, самавырым суынып бетте инде, ди.

– Хәзер, тагын бер генә тарих калды, шуны язып бетерәм дә кайтырбыз, – диде Гөлшат.

– Иртәгә язарсың әле, колхоз эше бетмәс. Айдар Юнысович авыру кеше кергәндә бер яза иде, чыгарып җибәрер алдыннан бер көн кала икенче яза иде. Калдыр эшеңне, монда эшнең беркайчан да бетәсе юк. Карт кешене көттереп тору яхшы түгел, – дип, Фәимә апа Гөлшатны язуын ташларга һәм халатын салырга мәҗбүр итте.

– Әйберләрем кайда икән, Фәимә апа? – кинәт сумкалары исенә төшеп, оялып кына сорап куйды Гөлшат урамга чыккач.

– Әйберләрең күптән Наилә апада сине көтәләр. Мансур илтеп куйды, борчылма, – дип, Фәимә апа Гөлшатны урам буйлап ияртеп алып китте.

Авыл урамнары чиста, аяк астында ямь-яшел чирәм. Уртача зурлыктагы йортлар. Барысы да матур итеп буялган. Күршеләр, берсен-берсе уздырырга теләгәндәй, өйләрен, капкаларын матурлап бизәкләгәннәр. Авылның үзенә күрә ниндидер яме һәм хуш исе бар иде. Гөлшат, як-ягына каранып, сөйләшмичә генә атлады. Фәимә апа да беренче булып сүз башламады. Шулай тыныч кына бара торгач, бер капка төбенә килеп туктадылар. Өй алдында төрле-төрле матур җәйге чәчәкләр үсеп утыра.

– Наилә апа, без кайтып җиттек, – дип, алар өйгә керделәр.

Өй эченә тәмле коймак исе таралган. Гөлшат, тамагы ачканлыкны аңлап, тирән итеп сулыш алды. Аларның каршысына яулык бәйләгән, уртача буйлы, матур гына әби чыкты. Гөлшат сигез ел элек мәрхүм булган әбисен күргәндәй булды һәм, үзе дә сизмәстән, каршысында пәйда булган әбине кочаклап алды. Наилә апа бу ят кыз аны кочаклар дип һич тә көтмәгән иде. Ул да кызны кочаклап, аркасыннан сөйде. Шулай берничә минут басып торганнан соң:

– Наилә апа, гафу ит, алдымда яраткан әбиемне күргәндәй булдым, ни эшләгәнемне үзем дә аңламыйча калдым, – дип, Гөлшат оялуыннан кызарып чыкты.

– Ярар, кызым, гафу үтенмә, мин карт кешене күптән болай кочаклаганнары юк иде. Синең кочагында мин дә әз генә яшәреп киттем. Әйдә, түргә уз, коймакларым суынып бетте инде. Юлдан арыгансыңдыр, ашыйсың да киләдер? Фәимә, син дә уз. Ник чит кеше кебек ишек төбендә басып торасың?

– Рәхмәт, Наилә апа, минем өйгә кайтасым бар. Өйдә эшләрем, берсе артыннан берсе тезелеп, мине көтеп торалар. Авыл кешесен үзең беләсең, кыстама, – дип, Фәимә апа чыгып китте.

Гөлшат белән Наилә апа кич буе чәй эчеп, озак кына сөйләшеп утырдылар. Гөлшат күптән узган бала чакларына кайткандай булды. Наилә апа да моны сизенде. Үзенең балалары булмаганга, ул Гөлшатны үз кызы кебек кабул итте.

Икенче көнне эшкә килүгә үк Гөлшат авыруларны әйләнеп чыкты, күбесенә язылган даруларны икенчесе белән алыштырды, кайберләренә кан тамырына ясала торган системалар билгеләде. Шулай эшкә чумып утырганда, аны кабул итү бүлмәсенә чакырдылар.

Кабул итү бүлмәсендә бер яшь малай утырып тора иде.

– Марат, нишләп йөрисең монда? – дип сорады Фәимә апа.

– Минем бер җирем дә авыртмый. Мин ярдәм сорап килгән идем.

– Ни булды, сөйлә әйдә тизрәк, эшебез бик күп, – дип, Фәимә апа бу малайның бер гаебе юклыгын аңлап, йомшара төште.

– Әти малларны караганда, билен ычкындырды, тора да алмый, бөгелә дә алмый. Өйдә идәнгә барып ятты да, авыртуына түзә алмыйча, үләм, дип ята. Килеп карап китә алмассызмы икән?

– Ник монда алып килмәдегез? – дип сорап куйды Гөлшат.

– Монда килү түгел, тора да алмый. Мин машина белән сезнең артыгыздан килдем. Тиз генә карап китә алмассызмы икән? – дип, Марат Фәимә апага карады.

Өлкән шәфкать туташы Гөлшатка сораулы караш ташлады.

– Ярар, барып килермен. Фәимә апа, безнең нинди дарулар бар? Мин биш минуттан әзер булам, – диде Гөлшат, дәрәҗәсен төшермәскә тырышып һәм хастаханәгә кереп китте.

– Бу кем? Нинди кыз тагын? Фәимә апа, син үзең бармыйсыңмыни? – диде Марат, аптырап.

– Бу – безнең яңа табибыбыз, Гөлшат Равилевна. Болай белеме бар төсле, хастаханәдә ятучы күп кенә авыруларга башка төрле дарулар бирде, системалар язды.

– Айдар Юнысович кайда?

– Ул районга китте. Борчылма, әгәр Гөлшат Равилевна ярдәм итә алмаса, кичтән үзем кереп чыгармын, – дип, Фәимә апа Маратны тынычландырырга тырышты.

– Мин әзер, Фәимә апа, миңа нинди дарулар бирә аласыз?

– Сезгә нәрсәләр кирәк булыр икән?

– Новокаин, егерме граммлы шприц, диклофенак...

– Алар барысы да безнең дарулар сумкасында бар, хәзер новокаин гына алып чыгам. Сезгә ике процентлысы кирәктер?

– Әйе, – диде Гөлшат һәм, Маратка ияреп, ишек төбендә торган машинага чыгып утырды.

Берничә минуттан, дарулар салынган сумка күтәреп, Тәнзилә чыкты. Урам буйлап тузан туздыра-туздыра җилдерткән машина авыл кырыендагы таш йорт янына килеп туктады. Артык зур булмаган җыйнак кына матур йорт. Ишегалдында трактор, үзбушаткыч «КамАЗ» машинасы тора. Гөлшат белән Марат тиз генә өйгә керделәр. Аларны каз-үрдәкләр кычкырышып озатып калдылар.

– Исәнмесез, – диде Гөлшат керә-керешкә.

– Әйдәгез, түргә узыгыз, әти анда, – дип, Марат беренче булып түргә узды һәм әтисенә: – мин яңа табиб Гөлшат Равилевнаны алып килдем, – диде.

Гөлшат бүлмәгә кергәндә, диванда йомшак мендәрләр арасында илле яшьләр тирәсендәге ир-ат ята иде. Ул:

– Исәнмесез, абый, минем исемем – Гөлшат Равилевна, сезнең яңа табибыгыз, – дип, урындык алып, диван янына килеп утырды.

– Исәнме, сеңлем, мин Рафаэль абыең булырмын, – дип, абзый торып утырмакчы иде, ләкин тешен кысып, кире ятарга мәҗбүр булды. – Менә бүген маллар караганда, кинәт билем авырта башлады, шундый нык итеп борып алды, күз алларым караңгыланды хәтта. Ярый әле улым янымда иде, ул, вакытында күреп алып, өйгә кереп ятарга ярдәм итте. Хәзер ни утыра, ни борыла алмыйм, ток суккандай авырта. Ни эшлибез инде, сеңелкәш?

– Хәзер, уйлап карарбыз, күлмәгегезне күтәрегез. Марат, булыш әле әтиеңә, – дип, Гөлшат Маратка эндәште.

Марат тиз генә әтисенә ярдәмгә ашыкты. Гөлшат озак итеп башта абзыйның эчен карады, биленә баскалады. Рафаэль абзый авыртудан берничә тапкыр кычкырып та җибәрде.

– Даруларга аллергиягез юкмы?

– Моңа хәтле зарланганым булмады, – дип, Рафаэль абзый Гөлшатка карады.

– Мин хәзер билегезгә блокада һәм уколлар ясыйм. Бүген торырга

тырышмагыз. Аннары катыга ятарга кирәк. Иркәләнеп мендәрләр өстендә йомшакта ятарга ярамый, начар гына була. Бер-ике көн катыда ятып торырга туры килер, – диде Гөлшат, тәҗрибәлерәк күренергә тырышып.

– Болай ятып булмый бит, урак өсте дә җитә, маллар да карыйсы бар.

– Сез мине аңламадыгыз, ахрысы? Мин сезгә яңадан кабатлап әйтәм: берничә көн бернәрсә дә эшләмичә каты урында ятарга кирәк. Аннары хастаханәгә килерсез, уколлар ясарбыз, әгәр файдасы тимәсә, район хастаханәсендә ятып чыгарга туры килер, – дип, салкын гына әйтеп куйды Гөлшат, аз гына тавышын күтәрә төшеп.

– Юк, нинди районга, теләсә ни эшлә, монда гына дәвала, син әйткәннең бөтенесен дә эшлим. Кирәк икән, ятып торырмын. Янымда улым бар, Аллага шөкер, барысын да эшли. Тизрәк уколларыңны яса, – дип, көчкә йөзтүбән борылып ятты. Гөлшат ашыкмыйча гына даруларны, шприцларны чыгарды. Әкрен генә, ампулаларның башын сындырып, шприцка дару җыйды.

– Болар барысы да миңамы? – дип, куркып башын күтәрде Рафаэль абзый.

– Сезгә, сезгә, хастаханәгә барырга теләмәсәгез, түзегез, – диде Гөлшат, шаяртып.

– Алла, энәсе дә бигрәк озын, кыскарагы юкмы соң?

– Бар, ләкин сезгә тирән ясарга кирәк.

– Бу энәң мине аркылыга тишеп чыга бит, Марат, син миңа кемне алып килдең? Бу «патша сарае» кызы мине җәзалап үтермәкче була, ахрысы, – диде Рафаэль абзый, һаман тынычлана алмыйча.

Марат нәрсә эшләргә дә белмичә, бер әтисенә, бер Гөлшатка карады. Малайның уңайсыз хәлдә калганын сизеп, Гөлшат:

– Марат, синең эшең юкмы әллә? Әлдермештән Әлмәндәр мондый вакытта ни әйткәнен беләсеңме?

– Беләм.

– Алайса бар, чыгып тор, эш беткәч үзем чакырырмын. Ә сез, Рафаэль абый, тыныч кына ятмасагыз, уколны тагын да озынрак энә белән, юри авырттырып ясыйм, аңладыгызмы?

– Бетте, аңладым, – дип, Рафаэль абзый, күзен йомып, башын мендәргә батырды. Гөлшат уколларын ясап бетергәч тә, ул һаман башын мендәрдән күтәрергә куркып ятты.

– Бетте, Рафаэль абый, ничек, аркылы тишмәдемме? Аркагызга борылып ятыгыз да, бүген тормаска тырышыгыз. Иртәгә, сәгать берләр тирәсендә, улыгыз мине килеп алыр, тагын күрешербез. Ә бүгенгә сау булып торыгыз, – дип, Гөлшат әйберләрен җыеп, бүлмәдән чыгып китте.

– Рәхмәт, сеңелкәем, кулларың, аякларың сызлаусыз булсын, – дип, Рафаэль абзый мендәрдән башын күтәреп, карашы белән Гөлшатны озатып калды. Шулвакыт:

– Кызым, әйдә, утырып, бер чынаяк чәй эчеп ал, – дип, Гөлшатның каршысына урта яшьләрдәге бер апа килеп чыкты.

– Исәнмесез, апа, рәхмәт, чәйләр эчеп торырга вакыт юк, мине башка авырулар көтә. Сез Рафаэль абыйның хатыны буласыздыр?

– Әйе, мин – Хәлимә апаң.

– Рафаэль абый бүген ятып торсын инде, биленә мамык шәл бәйләп

куйсагыз, тагын да яхшырак булыр иде. Аннары аңа катыда ятарга кирәк, йомшак мендәрләрегезне алып куегыз.

– Ярар, кызым, сиңа бик зур рәхмәт. Менә моны әз генә күчтәнәч итеп ал әле, – дип, Гөлшатның кулына төргәк сузды.

– Юк, бернәрсә дә кирәкми, – дип, Гөлшат чыгып китмәкче иде, Хәлимә апа пакетны барыбер аның кулына мәҗбүриләп тоттырды.

Марат Гөлшатны машинада, урам буйлап тузан туздырып, тиз генә кире хастаханәгә илтеп тә куйды. Гөлшат Хәлимә апа биргән күчтәнәчне машинада калдырса да, Марат, аның артыннан кереп, аны табиблар бүлмәсендә калдырып чыкты. Анда авыл каймагы, эремчек һәм бал салынган иде. Беренче «взятка» белән сине, Гөлшат, – дип, ул эченнән генә көлеп тә куйды.

Өйдә аны, гадәттәгечә, тәмле ризык, кайнап торган самавыр көтеп тора иде. Наилә апа:

– Кызым, синнән һаман бер әйбер турында сорамакчы булам да, оялам, бәлки, үзең сөйләрсең. Әгәр теләмәсәң, сер булса, сөйләмә. Ачуланма, карт кешеләр шулай кызыксынучан булалар инде, – дип сүз башлады.

– Сорап кара, Наилә апа, мин КГБда хезмәт итмим, ил серләрен дә бик белмим, син шпионга охшамагансың, – дип, Гөлшат һаман шаяртырга тырышты.

– Кызым, син бит ятим үскән бала түгел, мин күреп торам. Ник соң син әти-әниләрең белән бер дә хәбәрләшмисең? Телефоннан да сөйләшкәнең юк. Сөйләшәсең булса, бер дә оялып торма, шалтырат.

– Рәхмәт, Наилә апа. Әниемне мин былтыр җирләдем. Әтием башка хатын белән яши, хәзер мин аңа кирәкмим. Аның хәзер башка гаиләсе бар, мин алар янында үземне артык хис иттем. Бертуган абыйларым, апаларым юк. Башкаларның үз тормышлары, үз мәшәкатьләре. Шулай итеп, мин – япа-ялгыз...

Гөлшат, утырган урыныннан торып, тәрәзә янына килде. Аның карашы каядыр бик еракка төбәлгән иде.

– Син, кызым, әтиең белән алай араңны өзеп, дөрес эшләмисең. Ул синең бердәнбер якын кешең. Сиңа карасаң, син бик бәхетле гаиләдә үскән балага охшагансың. Әтиең дә сине бик яратадыр. Алай араны өзү дөрес түгел. Әниең чирләп үлдеме, берәр фаҗигагә очрапмы?

– Яман шеш белән чирләп үлде.

– Әтиең карамадымы?

– Әни чирләгәч, көн саен хастаханәгә килеп йөрде. Әнигә операция ясагач, мин төнгә калсам, ул көндезен янында утыра иде, ял алды. Шунда әнине караганда, бер хатын белән танышкан. Әни үлгәч, бер ел да көтмәде, шул хатынны алып кайтты. Мин әни урынында икенче кешене күрә алмадым. Талашып, араны бозып йөрисем килмәде, әйберләремне җыйдым да менә сезгә килдем, – дип, Гөлшат күз яшьләрен яшерергә тырышып, һаман урамга карап торды.

– Алай икән, гафу ит инде мине, карт, тиле әбиеңне. Төзәлеп бетмәгән яраңны яңарткан өчен. Ләкин син әтиеңне дә аңларга тырыш. Ул әле бик карт түгелдер? Шуңа күрә ялгыз тора алмый. Ирләр бит алар бала-чага төсле, аларны ашатырга, эчертергә, тәрбияләргә кирәк. Алар хатын-кыз тәрбиясеннән башка

тора алмыйлар. Син бит табиб кеше, аңларга тиеш. Минемчә, телефоннан сөйләшәсең килмәсә, хат булса да язып сал. Кайбер әйберләрне кәгазьгә язуы җиңелрәк, вакыт та күбрәк, сүзеңне уйлап, үлчәбрәк әйтергә мөмкинлек бар. Әтиең синең өчен бик борчыла торгандыр. Син бит аның бердәнбер җимеше. Мин, кызым, озак яшәгән, күпне күргән кеше, тыңла сүземне.

– Киңәшең өчен рәхмәт, Наилә апа, нишләптер минем хат турында бер дә уйлаганым булмады. Телефоннан шалтыратып, нәрсә әйтермен дип уйлап торганчы, әйе шул. Ләкин без бит хатлар язып үскән балалар түгел. Минем гомеремдә бер хат та язганым юк.

– Син язып кара. Эчең дә бушар, күңелең дә тынычланыр.

Гөлшат кинәт, борылып, кечкенә чагында бик яраткан әбисен кочаклаган кебек, бүлмә уртасында басып торган Наилә апаны кочаклап алды. Ул ничек кенә күз яшьләрен тыярга тырышса да, алар агудан туктамады. Наилә апа сабый баланы юаткан төсле Гөлшатның аркасыннан сөйде.

...Наилә апа, гадәттәгечә, иртән торып, өй эшләренә тотынды. Якшәмбе көн булгач, Гөлшат иртә торырга ашыкмады. Бүген ял көне. Эшкә бармасаң да була. Бу авылда эшли башлавына бер айдан артык вакыт узган. Куркып кына эшкә керешкән көннәр артта калды. Халык печән чаба. Бәлки, тирә-як урманнардан әйләнеп кайтсаң, яхшы булыр иде, дигән уй белән Гөлшат торып, сәгатькә карады – сәгать җиде тула иде.

– Хәерле иртә, Наилә апа! – дип, Гөлшат юынырга чыкты.

– Хәерле иртә, кызым. Ник йокламадың? Бүген ял көне бит. Кичә, эшкә бармыйм, дигән идең бит. Туйганчы йоклыйсың бар иде, – дип, Наилә апа чәй әзерли башлады.

– Наилә апа, бүген синең беркая да барасың юкмы?

– Юк, бугай. Нигә сорыйсың?

– Әгәр хәлең булса, әйдә тирә-яктагы урманнардан йөреп кайтыйк әле. Монда табигать бик матур дигәннәр иде. Мин монда бер айдан артык яшим инде, беркая да чыкканым юк. Син бит бирәдә туып үскән кеше. Тирә-якларны яхшы беләсең. Миңа да күрсәтеп, экскурсия ясап кайта алмассыңмы?

– Күрсәтәм. Мин бу якның һәр урманын, болынын, чишмәсен, сукмагын беләм. Теләсәң, Мәдинә тавына менәрбез. Ул таудан шундый матур күренеш ачыла, үзең күрерсең. Мин киптереп эчәргә үләннәр дә җыеп кайтырмын. Әйдә, чәй эчәргә утыр. Кабартмалар да пешердем, – дип, Наилә апа чынаякларга чәй ясый башлады.

– Наилә апа, ни арада шундый тәмле кабартмалар пешерергә өлгердең? Тагын берәр ай шулай ашатсаң, мин үземнең бер күлмәгемә дә сыймаячакмын.

– Сыярсың. Әйдә, каймак белән яхшылап аша. Мәдинә тавы якын түгел. Ашамасаң, кайтып җитәргә хәлең калмас.

– Кала, кала, Наилә апа, университетта укыганда, без бер бинадан икенчегә чабып йөрергә ияләшкән.

– Күп сөйләшәсең. Кашык белән күбрәк эшлә.

– Булды. Наилә апа, бик зур рәхмәт, бик тәмле булды. Мин алайса киенәм, – дип, Гөлшат бүлмәсенә кереп китте.

Наилә апа да җыена башлады. Чыгып китәр алдыннан Гөлшат, хастаханәгә шалтыратып, андагы хәлләрне белеште.

Авыл кырыеннан ук урман башлана иде. Өйдә көчкә йөргән әби яшәреп китте – авырткан аяклар, сызлаган куллар кинәт төзәлделәр. Гөлшат Наилә апа артыннан көчкә өлгерә. Олы яшьтәге бу апа урман буйлап барганда, агачлар, куаклар, үләннәр яфракларын селкеп, аның белән исәнләшәләр төсле иде. Һавада башны әйләндерерлек төрле хуш исләр таралган. Юл әкрен генә тауга таба илтә. Кинәт урман бетеп, каршыда матур алан ачылып китте. Аланда күзне сөендерә торган төрле-төрле чәчәкләр. Тирә-юньдә урман симфониясе яңгырый. Бу оркестрда кошлар сайравы, умарта кортлары безелдәве, чикерткәләр уйнавы да бар.

– Кызым, әнә тегендә каен җиләкләреннән авыз итә аласың. Мондый тәмле җиләк ашаганың юктыр әле? – дип, Наилә апа каеннарга таба күрсәтте.

– Син каян беләсең, моннан күренми бит? – диде Гөлшат, көлемсерәп.

– Монда килгәндә, зур имән агачы әйтте. Син, күрәм, арыгансың, шул каеннар астында ял итеп ал. Мин үләннәр җыя торам, – дип, Наилә апа алан уртасына китте.

Каеннар арасында, чынлап та, кып-кызыл җиләкләр үсеп утыра иде. Аларны авыз иткәндә, Гөлшат баш табиб бүлмәсендәге сәркатип кыз Гөлнара турында уйлап куйды. Бераз вакыт узгач Наилә апа:

– Хәл җыйдыңмы? Әйдә киттек, – дип, Гөлшатны үзе белән чакырды.

– Барыр юлыбыз еракмы әле?

– Арыдыңмы?

– Юк. Әз генә баш әйләнә, саф һавадан исердем, ахрысы. Мондый матурлык, гүзәллек йөрәкне дулкынландыра, күңелнең җырлыйсы килә, – диде Гөлшат.

– Чыннан да, исергәнсең, ахрысы. Мәдинә тавына тагын өч-дүрт чакрым бар әле. Барырга хәлең калдымы?

– Калды. Каен җиләкләре көч бирде. Гафу ит инде мине, Наилә апа. Мин, зур бала кебек, җиләкне авызыма гына җыйдым. Сиңа дип җыярга башыма килмәде, – дип, Гөлшат, сабый бала төсле кызарып, уңайсызланып куйды.

– Юкка борчылма. Минем үз кулларым бар. Җиләк белән бөтен алан тулган, ял итәр өчен монда иң уңай урын, шуңа күрә дә мин сине монда алып килдем. Арымасаң, әйдә, киттек, – дип, Наилә апа аркасына аскан капчыкны төзәтеп куйды.

– Наилә апа, экскурсия вакытында экскурсовод сөйләргә тиеш. Син бит бу урман, таулар турында күп нәрсәләр беләсең. Үләннәр турында да сөйләсәң, миңа бик кызык булыр иде. Мин бит ул яктан надан.

Наилә апа юл буе төрле үләннәр турында, кайсын кайчан җыярга, нинди чирләргә каршы кулланырга икәнен сөйләп барды. Көн уртасына кояш тагын да ныграк кыздыра башлады. Урман эчендә әз генә салкынчарак булса да, тамак кипте, эчәсе килде.

– Сусадыңмы? Сабыр ит. Хәзер, әз генә түзсәң, мин сиңа чишмә суы эчертермен, – диде Наилә апа.

Юл түбән таба чокырга төште. Өч-дүрт метр тирәнлектәге чокырда су челтерәп ага иде.

– Аяк киемеңне сал, елга буйлап барырга кирәк булачак, – дип, Наилә апа аягындагы галошларын салып, суга керде. Гөлшат та, тиз генә

кроссовкаларын салып, чалбар балакларын тездән өстәрәк сызганды да аның артыннан атлады. Су салкынча. Елганың тирәнлеге тездән түбән, төбе ләм белән капланган. Ләм астында вак ташлар сизелеп тора, шунлыктан аяклар батмый. Ләмдә калган эзләр су агымы белән юкка чыгып бара. Бераз барганнан соң, кәкре карт тал астыннан агып яткан чишмә күренде. Наилә апа тиз генә аккан суны яфраклардан, чүпләрдән чистартты. Чишмә, ачылып китте, тагын да ныграк челтери башлады.

– Менә хәзер суын эчсәң дә була, – дип, Наилә апа талга элеп куелган тимер тустаганны алды.

Су тешне сындырырлык салкын булса да, искиткеч тәмле иде. Гөлшат тамакка салкын тимәсен дип, куркып кына, кечкенә йотымнар белән эчте.

– Курыкма, бу бик шифалы су, күпме эчсәң дә тамагыңа тимәс, – диде Наилә апа.

– Син дә сусагансыңдыр, үзең дә эч, – дип, Гөлшат чишмә суы тулы тустаганны Наилә апага сузды.

Наилә апа, аркасына аскан янчыктан ике литрлы өч пластик шешә чыгарып, чишмәдән су тутырып алды.

– Наилә апа, Мәдинә тавына ерак калдымы?

– Без шул тау итәгендә. Тиздән безнең экскурсиябез ахырына җитәчәк.

– Ә бу елганың башы кайда?

– Кем белгән? Урал таулары арасыннан килеп, шундый чишмәләр белән тулылана, күрәсең. Бу елга вакыты-вакыты белән котырынып та аккалый.

– Ничек инде?

– Ә менә шулай, кинәт каяндыр бик күп су агып, елга күтәрелә, бу чокыр тула. Шул чагында берничек тә аны аркылып чыгарга мөмкин түгел, ташуы бик көчле була. Кешеләр бу тауда кунарга мәҗбүр булалар. Тагын су эчәсең килмәсә, әйдә, киттек, – дип, Наилә апа тустаганны кире урынына элеп куйды.

Бераз елга буйлап баргач, алар зур юлга чыктылар.

– Бу юл белән Мәдинә тавына машиналарда яңа өйләнешүче яшь парлар килә, – диде дә, Наилә апа, судан чыгып, аягына галошларын киде.

Гөлшат та, үләнгә чыгып, кроссовкаларын киде. Аякларының арыганы бетеп, җиңеләеп китте.

– Наилә апа, нигә бу тауны Мәдинә тавы диләр? Моның бер тарихы бармы әллә? – дип сорады Гөлшат.

– Безнең авыл тарихы бик борынгыдан килә. Бездә җитмешенче елларда археологик эзләнүләр дә уздыра башлаганнар иде. Ләкин берничә елдан соң нишләптер туктатылды. Хәзер тарих белән шөгыльләнүчеләр бетте, ахрысы, безнең хакта оныттылар. Безнең авыл кешеләре турында борынгыдан килгән бер хикәят бар. Дөрестерме, юкмы, борын-борын заманда шушы урыннарда зур бер шәһәр булган, ди. Яшәгән, ди, монда бик тырыш халык. Икмәк үстергәннәр, араларында төрле һөнәр осталары да булган. Монда төрле яклардан сатып алучылар килгән. Халык бик бай, мул тормышта яшәгән. Шәһәр башлыгы Сөләйман бай үз халкын хөрмәт иткән, кыерсытмаган. Шуңа күрә халык үзен бик иркен хис иткән. Шушы урман эчендә яшәгән, ди, бер карт кына хатын. Булган, ди, аның Мәдинә исемле бик чибәр кызы. Ләкин бу кызның чибәрлеге күпләрне куркыткан, чөнки әнисен «сихерче карчык» дип йөрткәннәр. Шуңа күрә алар авылда бик сирәк күренгәннәр.

Төрле сүзләргә караганда, бу карчык күп кешеләрне авырулардан терелткән, авыр яраланган кешеләрне аякка бастырган. Ләкин халык барыбер аларны үзләренә якын китермәгән. Чир, үлем куркынычы аркасында гына халык бу сихерче карчыкка мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булган.

Кызу җәйге көннәрнең берсендә шәһәргә дошман гаскәре һөҗүм иткән. Халык коралланып, каршы чыккан. Көн буе сугыш барган. Ләкин дошман көчлерәк булган. Исән калганнар шәһәр кырыендагы Сөләйман бай сараена кереп качкан. Алар арасында күпчелеге хатын-кызлар, балалар икән. Берсенең дә дошман кулына эләгәсе килмәгән. Бу сугышта Сөләйман бай һәлак булган. Аның улы Тимерхан да бик каты яраланган. Исән калучылар соңгы һөҗүмгә әзерләнгән. Дошманнар үзләренә каршы корал тотып чыгарлык кеше калмаганлыгын белгәнгә, соңгы һөҗүмне икенче көнгә калдырганнар. Шуңа күрә сакчыларны да сирәк кенә куйганнар. Төн уртасында Сөләйман бай сараена кызы белән сихерче карчык килгән. Алар исән калган кешеләрне үзләре генә белгән сукмак белән бай сараеннан алып чыгып, урманга качырганнар. Тимерханның хәле бик авыр булган. Дошманнар артларыннан куа чыкса, ерак китеп булмас дип, Мәдинә Тимерханны шушы тауга качырган. Дошманнар икенче көн иртән Сөләйман бай сараена бәреп кергән, ләкин бер генә исән затны да таба алмаганнар. Алар качып китүчеләрне эзләп чыкканнар. Шулвакыт бөтен дөньяны кара болыт каплап алган, яшенле яңгыр ява башлаган. Эзләүчеләр шушы елгага кадәр килгәннәр. Елга, аларның күз алдында ярларыннан чыгып, юлларын каплаган. Дошманнар кире кайтып китәргә мәҗбүр булган. Халык сүзе буенча, имеш, көчле яңгырны да сихерче карчык чакырган. Тауда качып калган Мәдинә Тимерханны үләннәр, чишмә сулары белән озак кына дәвалаган, аякка бастырган. Тимерхан белән Мәдинә шуннан бергә калганнар. Дошманнар киткәч, алар җимерелгән, яндырылган шәһәрне яңадан торгызырга тотынганнар. Аларның бик күп балалары туган. Безнең авыл халкының тамырлары шул Тимерхан белән Мәдинәгә барып тоташа, диләр.

– Качып киткән халык кире бу урынга кайткан микән? – дип кызыксынды Гөлшат.

– Кемдер кайткан, кемдер башка якларга китеп урнашкан – һөнәрле кеше теләсә кайда яши ала. Сихерче карчык, кире кайтып, шушы урманда яшәгән, диләр. Халык чакырса да, авылга төшеп яшәргә ризалашмаган.

– Бигрәк кызык, чын тормышка охшаган. Бәлки, чынлап та, шулай булгандыр? Син ничек уйлыйсың, Наилә апа?

– Кем белә? Һәрбер хикәяттә тормыштан алынган вакыйгалар булырга мөмкин, кайбер вакыйгаларны халык үзе дә уйлап чыгара. Мин шуны гына төгәл беләм – бу тауның үз үзенчәлеге, үз холкы бар.

Кинәт каршыда киң алан ачылды. Алан кырыендагы ярдан искиткеч күренеш пәйда булды. Юкка гына яшьләр никах туе вакытында бирегә килмиләр икән! Ярдан ачыла торган күренеш, туйның иң матур мизгелләреннән берсе булып, гомер буе истә каладыр.

– Наилә апа, яшьләр монда табигатьнең матурлыгы белән хозурланырга килә торганнардыр инде? – дип сорады Гөлшат.

– Табигатьнең матурлыгын һәрбер адәм баласы күрә алмый шул. Күбесе

биргә элеккеге гадәт буенча килә. Ләкин бу хикәятнең халык уйлап чыгарган нәтиҗәсе дә бар.

– Нинди?

– Әгәр кыз белән егет бу тауда төн куныпп, кояш чыкканын каршы алса, мәңге бергә булачаклар. Гомерләре бәхетле, бәхетләре гомерле булачак, диләр. Андый гаиләләрне тау кавыштырды, дип сөйлиләр.

Кинәт Гөлшатның күз аллары караңгыланып киткәндәй булды. Аның алдында Наилә апа түгел, ә кара күзле, кара чәчле чибәр Мәдинә утырып тора сыман тоелды. Аңына килеп, күзен ачканда, Наилә апа җиргә тезләнеп, аның битенә чишмә суы бөркеп тора иде.

– Башыңа кояш суккан, ахрысы, хәзерге яшьләр бигрәк хәлсез инде. Мә, чишмә суы эчеп җибәр, хәл керер, – дип, Гөлшатка салкын су тулы шешә тоттырды.

– Хәзер, Наилә апа, минем белән болай булганы юк иде, нинди кызу кояш астында йөрсәм дә. Күрәсең, теге сихерче карчыкның җаны башыма бәргән, – дип, уңайсызланып куйды Гөлшат.

...Тагын бер көн узып бара. Кайвакытларны Гөлшат авылга эшкә китүенә үкенеп тә куйгалый иде. «Казанда гына эшләп калса, бәлки, башкача булыр иде. Хәзер үз өенә кайтып, сузылып ятар иде. Бәлки, иптәш кызлары белән кинога, концертка барыр иде. Юк, аның өендә хәзер чит хатын-кыз. Әнисе үлгәннән соң әтисе алып кайткан хатынны Гөлшат берничек тә кабул итәргә теләмәде. Алар ачыктан-ачык әрләшмәсәләр дә, бер-берсен һаман төрткәләп алгалыйлар иде. Юк, аның хәзер туган-үскән өе юк, анда кире кайтасы килми. Монда да кем ул? Бер авылның табибы. Илдар Азатович район үзәгендә дә калдырмады ичмасам», дип уйланып утырганда, бүлмәгә Фәимә апа килеп керде:

– Гөлшат Равилевна, моңаеп утырмагыз, самавыр кайнады, әйдә, чәйләп алабыз. Колхоз эше бетмәс, тамак турында да уйларга кирәк.

– Рәхмәт, Фәимә апа, бик шатланып риза, – дип, алар өлкән шәфкать туташы бүлмәсенә кереп киттеләр. Монда барысы да әзерләнгән, өстәлдә вак бәлеш, өчпочмак, эремчек пирогы тора иде.

– Син кайчан пешереп өлгерәсең, Фәимә апа? Син ничек арымыйсың?

– Камырны эшкә хәтле куеп киткән идем, хәзер мичләр ягасы юк, газ плитәсендә тиз пешә, – диде Фәимә апа, чәйләр ясый-ясый. – Утыр, чәең суына.

Кинәт ишектән бик ашыгып, бер ир-ат килеп керде:

– Фәимә апа, әйдәгез инде тизрәк! – Ул, Гөлшатны күрмичә, Фәимә апаны халатыннан тартып ашыктырды.

– Тукта, кайда алып барасың мине? Килеп кердең давыл төсле, каядыр чакырасың, күрәсең бит – чәй эчәргә утырдык. Көн буена бер утырып, чәй эчәргә дә ирек бирмисең. Ни булды, мин бернәрсә дә аңламыйм?

– Исәнмесез, Фәимә апа?!

– Аллага шөкер, Әхмәт сине, ишек шакырга өйрәтмәделәрме әллә? Хатын-кызлар янына керәсең бит.

– Безнең башланды, ахрысы? – дип ашыктыра төште ир-ат.

– Нәрсә башланды тагын? – Фәимә апа аптырап китте.

– Лилиямнең эче бик каты авырта, бала таба, ахрысы, – дип аңлатырга тырышты ул.

– Ник соң районга илтмәдең? – диде Фәимә апа, башына ак яулыгын бәйли-бәйли.

– Ике баланы да Фәимә апа таптырды, башта «патша сарае»на керәбез, диде Лилиям. Шуңа күрә монда килдек.

– Әйдә, Гөлшат Равилевна, барып карап килик, барыбер чәй эчәргә бирмәс бу Әхмәт, – дип, Фәимә апа ир-ат белән бүлмәдән чыгып китте, алар артыннан Гөлшат та чыкты.

Кабул итү бүлмәсендәге ятакта утыз яшьләр тирәсендәге хатын ята, Асия аның кан басымын үлчи иде.

– Лилия, нигә районга бармадың, малай булса, районда табам дигәң идең бит? – дип сөйләнә-сөйләнә, Фәимә апа әлеге хатын янына килде дә уң кулын аның корсагына куйды.

– Районга барып җитеп булмас, ахрысы, суларым китте, – дип кычкырып җибәрде кинәт Лилия.

– Кызлар, әйдәгез тизрәк каталканы китерегез. Лилияне креслога күчерергә кирәк, озакламый бала күренәчәк. Ә син, Әхмәт, бар, урамда көтеп тор, пычрак аяк киемнәрең белән монда тәртипне бозасың, – дип, Фәимә апа Әхмәтне бүлмәдән урамга куып чыгарды.

Кызлар тиз генә Лилияне операцияләр бүлмәсенә алып кереп киттеләр.

– Хәзер нәрсә эшлибез? Районга шалтыратып, гинекологны чакыртырга кирәк, – дип, Гөлшат югалып калды. Аның бер дә бала таптырганы юк иде.

– Әйдә, ярдәм итәрсең, – дип, Фәимә апа Гөлшатны үзе белән алып кереп китте.

Гөлшатның университетта укыганда, бер-ике тапкыр бала туганны карап торганы булса да, бүген беренче күргәндәй булды. Фәимә апа бер дә ашыкмыйча, көн саен бала таптырган акушерка төсле үз эшен белеп башкарды. Бер сәгать дигәндә, Лилия бала да тапты. Бүлмәдә дөньяга яңа килгән сабый тавышы яңгырады.

– Кем? Малаймы? – дип сорады Лилия хәлсезләнгән тавыш белән.

– Егет, мә, кара! – Фәимә апа елаган баланы күтәреп күрсәтте дә энисенең күкрәгенә куеп алды, ике кыскыч арасыннан кендек бавын кисте һәм баланы Гөлшатка тоттырды. Гөлшат калтырап торган куллары белән баланың кендеген бәйләде. Баланы кулга алу белән Гөлшатның бөтен тәне калтыранып куйды. Сабыйдан аның тәненә ниндидер җылы дулкын таралды, күңеленә рәхәт булып китте, иңнәрендә канатлар үскәндәй булды.

– Менә, син кендек әбисе дә булдың, – дип шаяртып куйды Фәимә апа, Гөлшатның бала белән маташуын күреп. – Гөлшат Равилевна, бар, Әхмәткә чыгып әйт.

– Юк инде, Фәимә апа, ул сезне сорап килде, мин самавырны яңартып алам, суынгандыр, – дип, Гөлшат бүлмәдән чыгып китте. Асия баланы төреп калды.

Самавыр суына башлаган иде.

– Нишләп озакладыгыз, Фәимә апа? Самавыр күптән кайнады бит инде, вак бәлешләрегезне ашамыйча мин барыбер кайтмыйм, – диде Гөлшат, шаяртып, урындыкка арып кереп утырган Фәимә апага. – Әгәр сөйлисегез килмәсә, минем соравыма җавап бирмәсәгез дә була.

– Ник сорыйсың алайса?

– Хастаханәнең ишегаллары һәрвакыт чиста, себерелгән. Кем шулай

бөтенесен дә тәртиптә тота? – дип уңайсызланып, сүзне икенчегә борды Гөлшат.

– Бездән ерак та түгел бер абзаң бар, Дамир исемле. Гомере буе армиядә хезмәт иткән, тәртипне бик ярата, хәзер пенсиядә. Кулы эшкә бик оста, өйдә тик утырырга яратмый, кичләрен килеп, монда тәртип кертә. Кирәк вакытларда балта остасы, слесарь хезмәтен дә башкара. Илдар Азатович аңа күпмедер түли дә бугай, ул риза, безгә уңайлы. Тик син башка нәрсә турында сорамакчы идең бит?

– Сезне монда элек эшләгән бер табибның кызы дип сөйлиләр. Сез күп нәрсәләр беләсез. Сезнең осталыгыгыз белән табиб булып эшләргә кирәк, ник сез медицина университетына кермәдегез? – дип, кырын эштә тотылган бала-чага төсле кызарып, уңайсызланып сорады Гөлшат.

– Син миңа бер сорау гына, дигән идең. Үзең допрослый башладың? – диде шаяртып Фәимә апа.

– Гафу итегез, мин сезнең эшегезгә карап сокланам.

– Әйдә, чәеңне яса, бер сорый башласаң, барыбер туктамыйсың. Кешедән төрле нәрсә ишеткәнче, үзем сөйлим. Яшь чагымда мин бик тырыш идем. Мәктәпне «бишле»гә генә тәмамладым, сынаулар биреп, җиңел генә институтка кердем. Без укыганда, институт иде әле ул. Теләп укыдым, биш ел буена ике генә «дүртле»м булды. Табиб булырмын дип, бик нык хыялланган идем. Ләкин язмыш башкача борып куйды. – Фәимә апа берничә мизгелгә тынып калды, чынаягындагы чәен эчеп куйды, уйлары белән каядыр бик еракка, яшьлегенә кайткандай булды.

– Фәимә апа, авыр булса, сөйләмәгез. Ярагызны яңадан яңарткан өчен гафу итегез.

– Юк, яра төзәлгән, тормыш узган да инде. Институтта укыганда, кинәт кенә минем әнием үлеп китте. Ике сеңелкәш, ике яшьлек энем өйдә әти белән калды. Бишенче курсны тәмамлагач, җәйге сынаулардан соң, мин бер елга академик ял алдым. Әтинең берүзенә кечкенә балалар белән авыр иде. Монда шәфкать туташы булып эшкә кердем. Ул вакытта безнең «патша сарае»нда бер бик акыллы, тәҗрибәле карт табиб эшли иде – Разумовский Ефим Михайлович. Аның операция ясаганын күрсәң, исең китәр. Ул үз эшен бөек рәссам төсле әкрен генә башкара. Бер дә сүгенгәнен, шәфкать туташларына кычкырганын ишеткәнем булмады. Авыр операцияләр вакытында нәрсә дә булса дөрес бармаса, «кхм-кхм» дип, ютәлләп куя иде дә, бөтенебез аңлый идек. Әкрен генә эшләсә дә, операцияләре бик тиз уза. Монда нинди генә операцияләр ясамадык – ашказаны дисеңме, үпкәгә, сидек юлларына, шундый оста хирург! Белмәгән чире юк. Сезнең бүлмәдә аның китаплары белән тулы бер шкаф бар. Анда нәрсә генә юк. Кешеләр аны репрессиядән качып, монда Мәскәүдән килгән, дип сөйләделәр. Ләкин аның үз тормышы, гаиләсе турында бер дә сөйләгәне булмады. Монда, «патша сарае»нда, берүзе генә яшәп эшләде. Мине ул үз кызы кебек яратты, «кызым, кызым» дип кенә йөртте. Мин дә аны үз әтием төсле күрдем. Аңа үзем пешергән бәлешләр, өчпочмаклар алып килә идем. Ул аларны мактый-мактый ашый. «Бер ун-унбиш елымны алып атып булса, бу пешергән әйберләрең өчен сиңа өйләнер идем», – дия иде. Үземнең әтием-әнием булмагач, мин һәрвакыт киңәш сорап, аңа килдем. Ул беркайчан

да сорауларымны җавапсыз калдырмады. Кияүгә чыкканда, минем әтием урынында утырды. Үзе яһүд милләтеннән булса да, татар телен синең беләннән миннән яхшырак белә иде. Бәлки, шуңа күрәдер дә күп кешеләр мине аның кызы дип уйлый. Көн артыннан көн узды, ел артыннан – ел, мин, шулай итеп, алтынчы курсны тәмамлый алмадым. Башта сеңелләрем бераз үсә төшкәч барырмын дип уйлаган идем. Аннары әни артыннан ел ярымнан соң әтием дә вафат булды. Балалар тулысы белән миндә калдылар. Эшләдем, аларны укыттым. Берсе – институт, икесе техникум тәмамладылар. Үзем кияүгә чыктым, балаларым туды. Кая инде ул уку? Ефим Михайлович үлгәч, мин монда, дипломым булмаса да, өлкән шәфкать туташы да, табиб та булып калдым. Эшли башлаганыма быел утыз ел була. Төрлесен күрергә, төрлесен эшләргә туры килде.

– Фәимә апа, Ефим Михайлович зур операцияләрне наркозсыз ничек ясый иде?

– Кайчак новокаин кулланып, кирәк чакта башта үзе наркоз бирә, аннары операциягә тотына иде. Баштарак еш кына мин, соңрак кызлардан берәрсе, ул әйткән даруларны ясап, анестезиолог урынына басып тордык. Аннары ул мине операциядә үзенә ярдәмче итеп ала башлады. Шулай бергә-бергә озак еллар эшләдек. Мин монда алтынчы курсны да тәмамладым, интернатура да, ординатура да уздым, китапханә урынына Ефим Михайловичның китаплары булды, диплом гына юк, – дип, авыр сулап куйды Фәимә апа.

– Ә Ефим Михайлович үлгәч, туганнары күмәргә кайтмадылармы?

– Без кая хәбәр итәргә дә белмәдек, үзләре бер дә күренмәделәр, бәлки, беркеме дә булмагандыр. Үзеннән бер шкаф тулы китаплары гына калды. Без аны үзебезчә, мөселманча җирләдек. Өчесен, җидесен, кырыгын, елын да укыттым, беркем дә каршы килмәде. Авылдашларыбыз аны бик яраталар иде. Ул күп кешене үлемнән коткарды, күпме бала таптырды. Минем бөтен балаларны табарга ул ярдәм итте. Аның халыкка эшләгән изгелеге санап бетергесез. Элек районга барырга дигән сүз дә юк иде. Халык бөтен чирләр белән Ефим Михайлович янына килде. Әле якын-тирә авыллардан гына түгел, бөтен районнан аңа дәваланырга киләләр иде. Үләр алдыннан бер ел калгач кына, зур операцияләрне үзе ясамыйча, үзәк хастаханәгә җибәрә башлады. Район үзәгенә чакырдылар – бармады, кирәк кешеләр монда килерләр, диде. Монда операция ясар өчен бөтен инструментлар бар, мин кайберләренең исемен дә, нәрсәгә кирәк икәнлеген дә белмим. Ефим Михайлович бик изге кеше иде. Әбиләр, бабайлар Коръән укыганда, ашлар уздырганда, һәрбер гаиләдә аны искә алалар. Аның кызы буларак, миңа да шунда догаларның бер кисәге эләккәли торгандыр, – дип, Фәимә апа, шаяртып, Гөлшатка карап куйды. – Әйдә, кечкенә Әхмәт белән Лилия янына кереп чыгыйк та, кайтырга кирәк. Синең иртәгә Илдар Азатовичның акыллы сүзләрен ишетәсең бар әле, әзерләнеп тор, ул монда бала таптырган өчен безне һәрвакыт орыша, – дип, бүлмәдән чыгып китте. Гөлшат та өстәлдәге чынаякларны, ризыкларны тиз генә җыеп алды да Лилия янына кереп чыгарга уйлады.

Төне буе яңгыр койды. Иртән торып, урамга чыкканда, һава сулап туймаслык саф, чирәмнәр, яфраклар чистарынып, юынып куйганнар төсле иде. Койма башында чыпчыклар чыр-чыр килә, әллә сугышалар, әллә табигатьнең матурлыгына карап куанышалар. Авыл күптән уянган, сыер

савучылар иртәнге савымнан соң өйләренә кайтып киләләр иде. Гөлшатны күргәч, барысы берьюлы:

– Исәнмесез, Гөлшат Равилевна, – дип сәлам бирделәр.

Күбесен Гөлшат әле белеп тә бетерми, ләкин шулай да:

– Исәнмесез, – дип башын иде. Эченнән күңеле сөенә. Монда килеп эшли башлаганына күпме генә вакыт узды, ә аны инде бөтенесе белә, хөрмәт итә. Казанда калса, аны кем белер иде? Болай зурламаслар да иде.

Шундый күтәренке кәеф белән Гөлшат хастаханәгә керде.

– Хәерле иртә, Фәимә апа! Хәерле иртә, кызлар.

– Бик хәерле түгел шул, – диде нигәдер борчулы Фәимә апа.

– Ни булды тагын, Фәимә апа? Яңгырдан соң урамда табигать яшәреп киткән сыман, шундый рәхәт.

– Яңгыр кирәген кирәк тә инде, ләкин безнең сараебыз яшь түгел шул. Дарулар торган бүлмәнең түшәменнән яңгыр үткән, кайбер дарулар юешләнеп юкка чыкканнар.

– Янәшәсендәге палатага, коридорга да су үткән, авыруларны башка бүлмәләргә күчердек, – дип, Тәнзилә Гөлшатка карады.

Гөлшат су баскан палаталарны карап чыкты, тамчы тамып тормаса да, түшәмнәр ямьсезләнеп, юешләнеп каралган иде. Тагын су үтсә, җимерелеп төшәргә дә мөмкин. Аннары бүлмәне киптереп кенә котыла алмассың.

Гөлшат, «патша сарае»н әйләнеп чыккач, Илдар Азатовичка шалтыратты, телефонны Гөлнара алды:

– Гөлнара, исәнме! Бу – Гөлшат Равилевна, Каратаудан. Миңа Илдар Азатович кирәк иде.

– Исәнмесез, Гөлшат Равилевна! Ул әлегә бүлмәсендә юк, килгәч, мин сезнең шалтыратуыгызны әйтермен, – дип җавап бирде Гөлнара күтәренке тавыш белән.

Гөлшат, ак халатын киеп, авырулар янына китте. Озакламый аны палаталардан Тәнзилә эзләп тапты:

– Сезгә Илдар Азатович шалтырата, Фәимә апа бүлмәсендә.

Гөлшат, карый башлаган авырудан гафу үтенеп, тиз генә баш шәфкать туташы бүлмәсенә керде:

– Исәнмесез, Илдар Азатович!

– Исәнмесез, Гөлшат Равилевна, мин сезне тыңлыйм, ни булды?

– Бездә бер ЧП: төнлә каты яңгыр яуды.

– Мәдинә тавыннан агып, авылны су бастымы әллә?

– Әйе шул, су басты, авылны түгел, хастаханәне.

– Бөтенләйме?

– Юк, дарулар бүлмәсен һәм ике палата белән коридорны.

– Мин инде сезне бөтенләй юып киткән дип уйладым тагы, – дип, шаяртырга тырышты баш табиб.

– Илдар Азатович, яңгырларга киткәнче, түшәмнәрне алыштырырга кирәк.

– Түшәмнәрне түгел, анда түбәне алыштырырга кирәк.

– Шулай инде, сез мине аңладыгыз бит.

– Алай тиз генә була торган эш түгел ул. Быелгы сметаларга сезнең хастаханә кермәгән. Анда бит бер-ике калай белән генә котылып булмый, сүтә башласаң, түбәнең бәпкәләрен дә алыштырырга кирәк. Ул бит патша

заманында төзелгән бина. Киләсе елга планга кертербез, глава акча бирсә. Безнең бит буш финанслар юк, үзегез беләсез.

– Алайса, түшәмнәр ишелеп төшкәнне көтәбезме? Сез бит миңа үзегез, ярдәм кирәк булса, кулымны сузармын дип сүз бирдегез. Ә хәзер акча юк, планга кермәгән, дисез! Сез күпчелек ир-чиновникларга охшагансыз, сүзегездә тормыйсыз, – дип, Гөлшат кызулыгыннан үзе дә нәрсә әйткәнен аңламыйча телефон трубкасын куйды.

– Баш табиб белән алай сөйләшергә ярамый, Гөлшат Равилевна. Ул үпкә саклап йөри торган кеше булмаса да, үпкәләтүегез бар. Ул бит глава да, министр да түгел, – диде кырыйда басып тыңлап торган Фәимә апа.

– Катырак әйттем бугай шул, кызулыгым белән. Әйдә, ни булса, шул булыр. Үзем өчен сорамыйм бит.

– Алай да сабыр булырга кирәк. Сез, яшьләр, сүзләрегезне бер дә үлчәп сөйли белмисез шул, – дип, Фәимә апа авыр сулап куйды.

Шундый матур башланган көн бозылды. Гөлшатның бер эшкә дә кулы бармады. Уйлары һаман шул су аккан бүлмәләргә килеп терәлә иде. Вак-төяк эшләрен бетергәч, Гөлшат колхоз идарәсенә китте. Каршыга килгән кешеләр аның белән исәнләшеп уздылар. Күбесен танымаса да, ул да исәнләште. Берничә кешедән юл сорады.

Бәхетенә, колхоз рәисе үз бүлмәсендә иде. Ишек ачылыбрак торганлыктан, бүлмәдән кычкырып сөйләшкән ике ир-ат тавышы ишетелде. Гөлшат керергә куркып, тавышлар тынганын көтеп торды. Чынлап та, берничә минуттан урта яшьләрдәге бер ир-ат, кызарып-пешеп, бүлмәдән чыгып китте. Ишек ачык булса да, Гөлшат ишек шакып, рөхсәт сорап керде:

– Исәнмесез, Зөфәр Хәйдәрович, керергә ярыймы? Мин сезнең хастаханәнең яңа табибы булам.

Зур булмаган бүлмә уртасындагы өстәл янында таза гына гәүдәле ак чәчле абзый утыра иде. Алдан бу кеше белән бер дә очрашканы булмагач, Гөлшат үзен ничек тотарга белмәде. Башта бик кыю гына идарәгә кереп, рәиснең үз бүлмәсендә икәнлеген белгәч, бик шатланса да, хәзер ничектер югалып калды. Ниндирәк кеше булуын алдан сорашырга башына да килмәде. Юкка гына Фәимә апа: «Сез, яшьләр, бик кызу, эшегезне алдан уйлап эшли белмисез», – дип әйтмәгәндер шул.

– Исәнмесез, Гөлшат Равилевна! Сезнең турында халыктан күп ишеткән булды. Үзем кереп танышырга һаман вакыт таба алмадым. Менә үзегез дә килдегез, нинди йомышлар белән? Болай гына, минем сәламәтлекне кайгыртып килмәгәнсездер бит? – дип шаяртыбрак, рәис Гөлшаттан үзе сорау ала башлады.

Гөлшат аның болай ачык итеп, шаяртып каршы алуын көтмәгән иде, шуңа күрә тагын да каушап китте:

– Үзегез килмәгәч, танышырга дип килдем шул, – дип, кызларча шаяртып җавап бирергә тырышты яшь табиб. – Дөрес уйлыйсыз, кызганыч, сезнең сәламәтлегегезне белергә дип килмәдем шул. Бүген көчле яңгыр яуды, безнең хастаханәнең берничә бүлмәсен су басты. Ярдәм итә алмассыз микән, дип килдем.

– Илдар Азатовичка хәбәр иттегезме соң, сез бит аның карамагында, нишләп ярдәм сорап, миңа киләсез?

– Аңа иртүк шалтыраткан идем дә: «Быелгы планга кермәгән, акча юк», –

диде. Сезнең бит колхозыгыз бай, сезнең авылдашларыгыз бездә дәвалана. Су басып, түшәмнәр ишелеп төшсә, безне ябачаклар бит. Сезнең авылдашларыгыз район үзәгенә барырга мәҗбүр булачак, нишләп сез шуны аңларга теләмисез, Гөлшат дулкынлана-дулкынлана алдында басып торган олы яшьтәге абзыйга хәлнең ни дәрәҗәдә җитди икәнлеген аңлатырга тырышты.

– Мин сезне бик яхшы аңлыйм, Гөлшат Равилевна. Сез дә мине аңларга тырышыгыз, минем бүгенге көндә буш акчаларым да, кешем дә юк, алда – урак өсте. Менә икмәкләрне җыеп, сатып бетергәч, көзге кыр эшләре беткәч, идарә җыелышында мин сезнең мәсьәләне күтәрермен, әгәр инде идарә каршы килмәсә, ярдәм итәрбез.

– Сез мине аңламадыгыз, бәлки, сезнең үзегезгә дә якын арада ярдәм кирәк булыр, сез безнең хастаханәгә килерсез, ләкин... – Гөлшат сүзне озынга сузуның мәгънәсе юк икәнлеген аңлап, бүлмәдән чыгып китте. Ул ничек тырышса да, аны аңларга теләмәделәр, бәлки тәҗрибәсе җитмәгәндер. «Кем мине тыңласын монда?» – дип, Гөлшат әкрен генә урам буйлап барганда, аның янына, сызгыртып, бер машина килеп туктады. Аның ачык тәрәзәсеннән таныш ир-ат тавышы ишетелде:

– Сәлам, данлы һәм белемле яшь табибларга!

Гөлшат машинага борылып карады:

– Исәнме, Рафаэль абый! Тузан туздырып, кая ашыгасың?

– Нишләптер тавышың бер дә күтәренке түгел? Җәйнең иң матур көннәренең берсендә, син шундый күңелсез, әллә андый-мондый хәл булдымы? Әйдә утыр, сезнең якларга бара идем. Юлда сөйләрсең, – дип, Рафаэль абзый, машина ишеген ачып, Гөлшатның утырганын көтте. – Әйдә сөйләп җибәр, нинди борчу-хәсрәтләрең бар?

– Бүген хастаханәнең берничә бүлмәсен су басты, шул мәсьәлә буенча Илдар Азатовичка да шалтыраткан идем, менә Зөфәр Хәйдәрович янына да ярдәм сорап килгән идем, ләкин берсенең дә ремонт ясарга акчалары юк. Көзге яңгырларга китсә, түшәмнәр ишелеп төшәргә мөмкин. Аннары хастаханәне бөтенләй ябып куюлары бар. Авыл халкы, әбиләр-бабайлар районга ничек барып йөрерләр?

Үз борчуларын Гөлшат бүген инде өченче тапкыр сөйләде, ләкин бу юлы ярдәм сорап түгел, болай гына, кем беләндер уртаклашу өчен. Рафаэль абзый бер сүзсез аны тыңлады.

Алар озакламый «патша сарае» янына килеп туктадылар:

– Гөлшат Равилевна, борчылма, бер җаен табарбыз, баш исән булса, көзге яңгырларга хәтле түшәм белән нәрсә булса да эшләрбез. Бу «патша сарае» мәңгелеккә төзелгән, минем белән синең оныкларга да хезмәт итәр әле, Алла боерса.

– Рәхмәт, Рафаэль абый, җылы сүзләрең өчен, – дип, Гөлшат машинадан төшеп, хастаханәгә кереп китте.

«Кычыткан чыпчыгы, сиңа нәрсә җитми? Илдар Азатовичка, Зөфәр Хәйдәровичка да барып җиткәнсең, тик тормас», дип уйлап, Рафаэль абзый машинасы белән кузгалып китте.

Кичтән Илдар Азатовичтан бер кеше килеп, су баскан бүлмәләрне карап чыкты һәм:

– Монда куркыныч бернәрсә дә юк, – дип, «патша сарае»нда эшләүчеләрнең кәефен тагын да төшереп, кире кайтып китте...

«Алланың рәхмәте» белән узган яңгырдан соң матур көннәр урнашты. «Патша сарае»н су басу мәсьәләсе артка чигенде. Авырулар берсе артыннан берсе килеп кенә тордылар. Гөлшатның аккан түшәм турында уйларга вакыты да калмады.

Кичкә таба бүлмәгә Тәнзилә килеп керде:

– Гөлшат Равилевна, бүген безнең клубка Рәмис Әхмәтшин килә. Минем ике билетым бар, әйдәгез бергә барабыз. Гел эшләп кенә булмый бит. Кеше янына да чыгарга кирәк.

– Кем соң ул Рәмис Әхмәтшин?

– Ничек инде сез аны белмисез? Аның җырлары көн саен радиодан яңгырый. Аның бөтен җырлары хитка әйләнәләр. Ул бит безнең авылда туган. Концертына баргач күрерсез, аннары клубта дискотека була. Безнең авылда кичке яшьләр җыеннары бик күңелле, биеп, җырлап уза. Әйдәгез инде, авылдашлар белән дә танышырсыз.

– Ярар, Тәнзилә, мин ничәләргә әзер булырга тиеш?

– Мин сезгә сәгать алтыларда керермен.

– Ярар, сөйләштек.

Кичкә таба Гөлшат өйгә кайткач, бик арылгангамы, әллә Наилә апаның ашлары бик тәмле булгангамы, диванда утырган урынында үзе дә сизмәстән йокыга китте. Наилә апа, әкрен генә килеп, аның өстенә мамык шәлен ябып куйды. Алдан сөйләшкәнчә, сәгать алтыда өйгә матур күлмәктән, бизәнгән-ясанган Тәнзилә килеп керде:

– Хәерле кич, Наилә апа, Гөлшат Равилевна кайда? Киенеп, бизәнеп куйдымы? –дип, пулемёттан аткандай тиз-тиз сорады.

– Тр-тр-тр. Мин бернәрсә дә аңламадым. Ашыкмыйча гына әйт.

– Хәерле кич, Наилә апа, Гөлшат Равилевна кайда? Киенеп, бизәнеп куйдымы? – Бу юлы әкрен генә, һәрбер сүзен сузып кына соравын кабатлады Тәнзилә.

– Тавышланма, арып кайткан, йоклап китте.

– Нинди йоклау инде, без концертка барабыз дип сөйләштек, соңга калабыз бит, – диде Тәнзилә тагын да ашыгыбрак.

– Нинди концерт тагын? – дип, юри котыртып, сүзләрен сузып сорады Наилә апа. Тәнзилә, аның котыртуын аңлап, әкрен генә:

– Рәмис Әхмәтшин концерты, кич белән яшьләр кичке җыенга да җыелалар, – дип җавап бирде.

Тавышка Гөлшат та уянып чыкты.

– Гөлшат Равилевна, сез нишләп әзер түгел? Барыгыз, тизрәк киенегез, соңга калабыз бит, – дип такылдады Тәнзилә.

Әле йокыдан уянып җитмәгән Гөлшат ник ризалашканына үкенеп:

– Тәнзилә, үзең генә бар инде. Башка иптәш кызыңны ал, егетең белән барсаң, үзеңә дә күңеллерәк булыр, – диде.

– Ничек инде башка дустың, егетең белән? Сезне алып бармаганымны белсә, Фәимә апа бит минем җанымны алачак.

– Әйдә, битеңне ю, кыяфәтеңне рәткә керт тә киен. Карт әби төсле ашыйсың да йоклыйсың, беркая да чыкмыйча утырасың кыз башың белән,– дип, сүзгә Наилә апа кушылды.

Гөлшат, кулларын күтәреп:

– Бирeләм, бирeләм, киттем, киенәм, биш минуттан әзер булам, – дип, бүлмәсенә кереп китте.

Бизәнергә вакыт калмаган иде, шунлыктан тиз генә чәчен тарады да кыстыргыч белән каптырып, артка җыеп куйды.

Кызлар клубка кергәндә, шактый халык җыелган, ләкин җырчы сәхнәгә чыкмаган иде әле. Концерт ярты сәгатькә соңарып башланды. Сәхнәдә берничә хит яңгырады, бишенче җырын башкарганда, җырчының фонограммага җырлавы ачык аңлашылып торды. Халык башта көлде, аннары, ачуланып, сызгыра башлады. Алдагы җырын Рәмис Әхмәтшин, баянчы алып чыгып, тере тавыш белән башкарырга мәҗбүр булды, ләкин әле генә матур яңгыраган тавыш, нишләптер, югалды.

Залдагы халык арасыннан:

– Хәйдәр! Хәйдәр! – дип кычкырган тавышлар ишетелде. Сәхнәгә агроном Хәйдәр белән авыл гармунчысы менде. Залга көчле матур тавыш яңгырады.

Рәмис белән Хәйдәр кара-каршы берәр куплет җырладылар. Бу сынауда Хәйдәр алга чыкты. Казан җырчысы кабат тамашачы алдына чыкмады. Хәйдәр, авылдашларын куандырып, тагын бер сәгатькә якын сәхнәдә булды. Соңгы җырларын башкарганда, авыл яшьләре дә сәхнәгә менеп бии башладылар. Шулай итеп, концерт бию кичәсенә әйләнде. Гөлшат, үзе дә сизмәстән, биюче яшьләр арасына килеп керде. Бала чагында ул бию түгәрәгендә, ә студент елларында дүрт ел буе «Студентлар язы» фестивалендә биеп йөргән иде. Шуңа күрә биючеләр арасында Гөлшат үзен судагы балык сыман хис итте. Егетләр аңа каршы биеп карадылар, ләкин күбесе бу кызга каршы бии алмаслыкларын аңлап, тизрәк качтылар. Биегәндә, Гөлшат егетләргә озаттырырга да вәгъдә бирде. Хәйдәр дә берничә тапкыр аны биергә чакырды, ул да яхшы бии иде. Гөлшат аңа да кичәдән соң озаттырып куярга ризалыгын белдерде. Тәнзилә, боларның барысын читтән генә күзәтеп торганнан соң, Гөлшатны биючеләр арасыннан тартып чыгарды да:

– Сез нәрсә эшлисез? Сез бит Хәйдәрдән башка тагын өч егеткә озаттырырга ризалыгыгызны бирдегез. Тиздән кичә бетәчәк, ни эшлисез?

Гөлшат кинәт уянып киткәндәй булды, ни эшләгәнен аңлый башлады. Тәнзиләнең кулыннан тотып:

– Тәнзилә, зинһар өчен, коткар. Әйдә, тизрәк качыйк моннан, – диде.

Кызлар биюләр тәмамланганчы ук, егетләрдән кача-кача, клубтан чыгып киттеләр...

Төнге маҗаралар аркасында бөтен тән авырта, күзләр ябыла, бер дә эшлисе килми иде. Гөлшат, авыр булса да, авыруларны карап чыкты, көндәлек үзгәртмәләр кертте. Шулай әкрен генә көн уртасы җитте. Фәимә апа Гөлшат утырган бүлмәгә кереп:

– Гөлшат Равилевна, әйдәгез чәйләп алыйк, колхоз эше бетмәс, – дип, үз бүлмәсенә чакырды.

Гөлшат өлкән шәфкать туташы бүлмәсенә кергәндә, самавыр гөрләп кайнап утыра, Фәимә апа чәй әзерләп йөри иде.

– Кичәге биюләрдән соң аякларыгыз авыртадыр? – дип, көлеп сорап куйды ул.

– Әз генә бар, сизелә, кичәге концерт өчен бик зур рәхмәт. Хезмәт хакы

алгач, билетларга акчасын бирермен, – дип, Гөлшат өстәл янына барып утырды.

– Акча турында борчылма, бирерсең әле. Син кичә, биеп, кергәнсеңдә, берсен, ярты авыл егете сиңа гашыйк булган. Мине бүген телефоннан шалтырата-шалтырата аптыратып бетерделәр, эшләргә бирмиләр.

– Ярар инде, Фәимә апа, кичәге хәлләр өчен минем үземә дә оят, – диде Гөлшат.

– Хәйдәренә хәтле бүген сине сорап шалтыратты, – дип, чәйләр ясый-ясый дәвам итте Фәимә апа.

– Фәимә апа, Хәйдәрнең тавышы шундый матур, ул җырчы Рәмискә караганда, йөз тапкыр яхшырак җырлый. Кичә, аңа каршы чыгып, шундый матур итеп җырлады. Хәтта Рәмис сәхнәдән төшеп качарга мәҗбүр булды.

– Шул кирәк аңа, авылдашлары янына кайтып, фонограмма белән чыгыш ясый бит, дошман калдыгы. Бер дә ояты юк. Халык аңа акча түләп килә, ә ул? Хәйдәр белән алар инде күптәннән дошманнар, бер-берсенә, җаен туры китереп, төрттереп куймасалар, күңелләре булмый.

– Нишләп алай? – диде Гөлшат, кызыксынып.

– Алар бит туганнар. Аларның әниләре бертуган.

– Ә нишләп алайса дошманнар дисең?

– Аның сәбәбе бар.

– Йә, Фәимә апа, сөйлә инде. Беләсең бит, без хатын-кызлар, андый кызыклы әйберләрне тыңларга яратабыз, – дип, Гөлшат чәй эчүеннән дә туктады.

– Чәеңне эч, суына. Җиде-сигез еллар элек Хәйдәр Ләйлә исемле күрше авыл кызы белән йөри иде. Ул аны бик яратты. Вәгъдәләшеп, туйга әзерләнеп йөри башладылар. Шул чакта май бәйрәмнәрендә Рәмис концерт белән районга килгән иде. Хәйдәрләр икәүләшеп барганнар, концерт беткәч, сәхнә артына кергәннәр. Шунда Рәмис шул кызга күз төшергән, күрәсең. Ул вакытта әле өйләнмәгән иде, кызның Казанда укып йөргән чагы. Хәйдәр, институт бетереп, авылга кайтып эшли башлаган иде. Күрәсең, Рәмис белән теге кыз Казанда очрашкалаганнар. Туйга бер атна калганда, теге кыз Хәйдәргә: «Мин кияүгә чыкмыйм», – дигән. Рәмис тә аңа өйләнмәде, Хәйдәр дә гафу итмәде. Шулай итеп туй алдыннан аерылыштылар.

– Ә ул кыз хәзер кайда?

– Чаллыда эшли бугай, кияүгә дә чыкмаган, дип ишеткән идем. Ләкин анысын төгәл генә әйтә алмыйм. Башка монда кайтканы булмады. Минем кызыксынганым юк. Хәйдәрдән сорарга яхшы түгел.

– Хәйдәрнең кызы бармы соң?

– Юк, шуннан бирле егетнең кызларга күңеле катты. Шуңа күрә синең турында сорашуы да миңа бик сәер тоелды. Халык аның турында, ул эшкә өйләнгән, дип сөйли. Көн-төн колхоз эше белән мәшгуль. Ярый әле ул бар, колхоз күптән банкротка чыккан булыр иде, рәис күптән колхоз эшләрен агрономга тапшырган инде.

Кинәт ишек шакыдылар, машина йөртүче Мансур керде:

– Фәимә апа, районга даруларга барасыбыз бар, сез әзерме?

– Әзер, әзер. Мин хәзер, Мансур, халатымны алыштырам да чыгам. Син мине урамда көтеп тор.

– Кәгазьләрне алырга онытмагыз, – дип, Мансур чыгып китте.

– Фәимә апа, мин өстәлне үзем җыештырырмын, сез борчылмагыз, барыгыз.

– Ярар, алайса, ачкычны Тәнзиләгә калдырырсың, ул бүген дежурга килергә тиеш. Без, бәлки, бүген районда кунарбыз, иртәгә генә кайтырбыз. Син, кызый, кара, мин булмаганда, егетләрнең башларын әйләндереп йөрмә тагын, – диде дә Фәимә апа, папка белән документларны алып, бүлмәдән чыгып китте.

Гөлшат бу сүзләрдән кызарып чыкты. Фәимә апасы кичәге хәлләрнең барысын да белә булып чыга түгелме соң? Ул ашыкмыйча гына чәен эчеп бетерде, өстәлне җыештырып куйды. Тагын бер кат кичәге вакыйгаларны башыннан уздырды. «Биегән егетләрнең берсенең дә исемнәре хәтердә калмаган. Шул бер Хәйдәр генә. Аның белән Гөлшат берничә тапкыр биеде. Болай бик таза, матур кешегә охшаган. Тормышта нинди генә хәлләр булмый. Менә болар да ике туган, бер кыз аркасында гомер буе дошманлашып яшәргә мәҗбүр. Югыйсә кичә бер-берсенә каршы түгел, ә парлашып, ике тавыш белән җырласалар, нинди күңелле булган булыр иде. Алар бер-берсенең тәгәрмәчләренә таяк тыгып яталар». Шундый уйлар белән Гөлшат үз бүлмәсенә керде.

Эш көне әкрен генә бетеп килә, авырулар тарихлары язылган, барысы да тәртиптә. «Фәимә апа бүлмәсенең ачкычын Тәнзиләгә тапшырды, авырулардан чакыру булмады. Әкрен генә кайтырга җыена башласаң да була» дип уйлады Гөлшат.

Шул вакыт ишек шакып, Тәнзилә керде:

– Гөлшат Равилевна, Наҗия апа оныгын Фәимә апага күрсәтергә алып килгән, сез карый алмассыз микән? Фәимә апа районга китте бит. Алар кабул итү бүлмәсендә.

– Әйдә, нишләп карамаска, – дип, Гөлшат өстәлдән фонендоскопны алды да Тәнзилә артыннан кабул итү бүлмәсенә китте.

Кабул итү бүлмәсендә олы яшьтәге апа утырып тора, ятакта биш-алты яшьлек малай ята иде.

– Исәнмесез, нинди борчулар белән килдегез? – диде, Гөлшат бүлмәгә кергәч.

– Исәнмесез, кызым. Фәимә янына килгән идем дә, ул юк икән. Сез оныгымны карамассыз микән? – дип, олы яшьтәге апа Гөлшатның каршысына килеп, кул биреп исәнләште һәм кулы белән кечкенә малайга күрсәтте. – Кызым аны кичә генә кайтарып калдырды. Казанда балалар бакчасын карантинга япканнар, бала карарга кешеләре юк, эштән кала алмыйлар. Менә бит, оныгым кичкә таба чирли башлады, температурасы күтәрелде. Иртән җен кебек чабып йөрде, көндез әз генә ашады да йокларга ятты. Хәзергә хәтле йокыдан уяна алмый, тәне бик кызу. Температурасын үлчәгән идем: утыз сигезгә менгән. Нәрсә эшләргә белмичә, Фәимә карамасмы дип, сезгә алып килдем, ә ул районга киткән икән. Алланың рәхмәте, күршебез монда хәтле машина белән алып килде әле.

Гөлшат баланы чишендереп, игътибар белән карады. Чишендерә-киендерә торгач, бала бөтенләй уянып бетте һәм көйсезләнеп елый башлады. Әбисе, кочаклап, баланы кулына алды.

– Мин куркырлык берни дә тапмадым, бәлки, суык тигәндер, эче йомшак,

үпкәсендә берни дә юк төсле. Бәлки, районга алып барырсыз? – Гөлшат, бераз югалып калды.

– Юк инде, нинди район, ди, әнисе кичә генә кайтарды, ә мин хастаханәгә озатыйммы? Юк, юк. Иртәгә температурасы төшмәсә, кызыма шалтыратырмын. Сез миңа нинди дарулар кирәклеген язып бирегез, мин үземнең дарулар арасыннан карармын, уколлар ясап җибәрсәгез, тагы да яхшырак булыр, кирәкле даруларны иртәгә Фәимә бирер әле.

Бу апа Фәимә ападан башка табибларны санламаганын Гөлшат яхшы аңлады.

– Ярар алайса, Тәнзилә, балага аналгин белән димедрол ясa.

Укол дигән сүзне ишеткәч, бала тагы да катырак елый башлады, Гөлшат бүлмәдән чыгып китте. Үз бүлмәсенә кереп, халатларын салды, кулларын сабын белән юды. Әбигә үпкәләргә кирәк түгел, Фәимә апа гомере буе монда эшләгән, тәҗрибәле, белемле кеше. Авылдашлары аны бик яраталар, аңа ышаналар. Син дә монда егерме елдан артык эшләсәң, тәҗрибә тупларсың. Яшьләр кичәләрендә биеп тәҗрибә туплап булмый, дигән уйлар белән Гөлшат хастаханәдән чыгып китте.

Өйгә кайткач, Гөлшат нишләптер тынычлана алмады, эчендә үзе дә аңлый алмаган нindидер борчу бар иде. Наилә апа кызның уйланып йөргәнен күргәч:

– Ни булды, кызым, нинди уйларга батып йөрисең? Әллә берәр яңа авыру килдеме?

– Юк, юк, Наилә апа, кичә күбрәк биегәнмен, ахрысы, бөтен тән сызлый, – дигән булды Гөлшат.

– Күрдем инде күрдем, туфлиеңнең бер үкчәсе сынган. Әллә берәр авыл егетенә күз салдыңмы?

– Ярар инде, Наилә апа, көлмә миннән, чынлап, бөтен тән сызлый, авылда чибәр егетләр бик күп, ләкин берсе дә йөрәгемә сары май булып ятмады, – дип шаяртып, Гөлшат табак-савытлар юарга тотынды.

– Ярар алайса, сары май белән йөрәгеңне эштән чыгарма, мин кичке яңалыклар карап алыйм әле, – дип, Наилә апа телевизор каршысына барып утырды. Анда республика һәм Казан яңалыклары турында сөйли башладылар.

Гөлшат кинәт нәрсәдер исенә төшереп:

– Наилә апа, син бит көн саен яңалыклар карыйсың?

– Көн саен булмаса да, вакытым булганда карарга тырышам.

– Наилә апа, соңгы көннәрдә нинди дә булса балалар бакчасы турында сөйләмәделәрме?

Наилә апа бераз уйланып торды:

– Өченче көн ниндидер балалар бакчасы турында сөйләделәр, анда бер бала чирләгән, ниндидер бер авыр чир белән. Аннары прививкалар кирәклеге турында әйттеләр.

– Балалар бакчасы белән ни булган?

– Ни булсын? Карантинга япканнар бер атнагамы, артыкмы, мин анысын хәтерләмим.

– Ә теге бала нинди чир белән чирләгән?

– Каян белим инде мин, Гөлшат, хәзер каян бөтенесен хәтерләп бетерәсең, әле шуны искә төшергәнгә рәхмәт әйт. Безнең яшьтә, үзең

беләсең, баш бөтенесен эшләп тә бетерми. Балалар бакчасы карантинга ябылгач, куркыныч чир булгандыр инде?

Гөлшат бу сүзләрдән соң сикереп торды да яңадан киенә башлады.

– Тагын ни булды, ник тик кенә ял итеп утырмыйсың, төнгә каршы кая барасың тагы? Егетләр чакырмагандыр бит?

– Юк, Наилә апа, егетләр кайгысымы монда?

– Наилә апа, син авылдашларыңны яхшы беләсең, Нажия әби кайда яши?

– Нинди Нажия икән инде ул?

– Ялгыз, үзе генә тора, аның кызы Казанда, – дип, Гөлшат Наилә апага исенә төшерергә ярдәм итәргә тырышты.

– Син Вагыйзь Нажиясе турында әйтәсеңдер инде, ул правлениегә җитәрәк яшел коймалы йортта яши.

– Рәхмәт, Наилә апа.

Гөлшат, тиз генә киенеп, өйдән чыкты. Урамда караңгыланып килә иде, күкне болытлар каплаган. «Тагын яңгыр яуса, тагын «патша сарае»н су басачак», дип уйлап, Гөлшат идарәгә таба китте. Урамда сирәк-мирәк адашкан сарыклар, клубка баручы яшьләр очраштыргалады. Якын гына ара дип уйласа да, бер сәгатьтән артык вакыт узып китте. Идарәгә җитәрәк бөтенләй караңгыланды.

«Кайсы койма яшел соң монда, бөтенесе бер төскә керделәр, җитмәсә авыл халкы йокларга иртә ята, күпчелек йортта ут та янмый. Авыл урамнары караңгыга батты», дип уйлап барганда, бәхетенә, бер малай очрады:

– Исәнмесез.

– Исәнмесез, Гөлшат апа.

– Ни эшләп караңгыда берүзең генә йөрисең?

– Сарыкларыбыз кайтмады, шуларны эзләргә чыккан идем, ә сез кемне эзлисез?

– Бу тирәдә каядыр Нажия апа яши, ул кирәк иде.

– Минем исемем Айдар, – диде малай. – Әйдәгез, күрсәтәм, сез узып киткәнсез.

Бераз баргач, кечкенә генә йорт күренде, бер тәрәзәсендә ут та яна иде.

– Рәхмәт, Айдар, – дип, Гөлшат өйгә керергә ашыкты.

Өй ишеге ачык иде, авылда бикләнүнең нәрсә икәнен белмиләр.

– Хәерле кич, Нажия апа, – дип, Гөлшат өйгә керде. Каршысына Нажия апа чыкты:

– Оныгыгызның хәле ничек?

– Белмим инде, кызым, ыңгырашып йоклый, бөтен тәне яна, температурасын үлчәгән идем, кырыкка җитә бугай инде. Баллап, чәй дә биреп караган идем, косып чыгарды. Хәзер синең сүзләреңне тыңламаганга үкенәм дә инде, районга барсак, бәлки, яхшырак булыр иде. Иртән Фәимәгә күрсәтермен инде, ул да ярдәм итә алмаса, районга алып барырмын.

– Нажия апа, баланы тагын карап алыйм әле, – дип, Гөлшат курткасын урындыкка салып куйды.

– Әйдә, кызым, монда уз.

Бала берничә кат юрган, шәл белән капланган иде. Гөлшат бөтен өстен ачып, баланы чишендерде. Аның тәне кызарып чыккан. Табиб баланың үпкәсен тыңлады – куркыныч берни дә тапмады, йөрәге генә бик еш тибә.

Күпме тикшерсә дә, бала уянмады, ыңгырашып кына ятты. Гөлшат балада нинди чир икәнен белмәсә дә, хәле авыр икәнлеген бик яхшы аңлады. Киңәшләшергә Фәимә апа да юк.

– Нажия апа, баланың хәле бик авыр, «ашыгыч ярдәм»гә шалтыратырга кирәк, районга алып бармыйча булмый.

– Кызым, син дә табиб бит, минем даруларым күп, кара әле, бәлки, берәрсе ярап куяр.

– Нажия апа, баланың хәле бик авыр, аның белән төрле хәл булырга мөмкин.

– Фәимә булса, ул районга җибәрмәс иде дә бит, син шулай дигәч, әйдә алайса, районга алып барыйк, – дип, Нажия әби авыр сулап куйды.

– Нажия апа, телефоның кайда?

– Кызым, минем бит телефоным юк, кызым кесә телефоны алып биргән иде дә, оныгым уйнап йөреп, кая куйгандыр, белмим.

Нажия апа, Гөлшатның курыкканлыгын күреп, урындыкка барып утырды.

– Нажия апа, син баланы әзерли тор, мин машина эзләп киләм, – дип, Гөлшат тиз генә өйдән чыгып китте.

Урамда караңгы, берни дә күренми диярлек. Гөлшат «патша сарае»на таба юнәлде. Авылның бөтен урамнары шунда барып тоташканлыгын ул белә. Урамда беркем дә юк, өйләрдә дә утлар янмый, сирәк кенә этләр өргәне ишетелә. «Үзеңдә телефон булса, хәзер болай йөрмәс идең», – дип уйлады ул. Идарә яныннан узып барганда, аның янына «Нива» машинасы килеп туктады:

– Исәнмесез, Гөлшат Равилевна, – дип, машинадан Хәйдәр сикереп төште. – Сезне ничек егетләр караңгы авыл урамнары буйлап үзегезне генә җибәрде? Бәлки, тагын качып киткәнсездер? Сезгә медицинада түгел, разведкада хезмәт итәргә кирәк.

– Хәйдәр абый, шаярып сөйләшеп торырга вакытым юк, мине «патша сарае»на илтсәгез, бик рәхмәтле булыр идем.

– Рәхим итегез, – дип, Хәйдәр, машинаның ишеген ачып, Гөлшатны утыртты һәм тиз генә хастаханә янына илтеп тә җиткерде. Гөлшат машинадан төшеп, рәхмәт тә әйтмичә, хастаханәгә кереп тә китте. Аның уе авыру балада иде. Ул тиз генә үз бүлмәсенә керде һәм белешмәлек актара башлады. Тавыш ишетеп, бүлмәгә Тәнзилә керде:

– Гөлшат Равилевна, сез нишләп йөрисез төн уртасында? Китапларны иртәгә карап булмый идемени?

– Тәнзилә, районга шалтырат.

– Кемгә?

– Ничек инде кемгә? «Ашыгыч ярдәм» бүлегенә?

– Кемгә начар булды? Монда гына ярдәм итеп булмыймы соң?

– Тәнзилә, мин нинди диагноз куярга да белмим, ә баланың хәле күзгә күренеп начарлана, Фәимә апа да юк, ичмасам, киңәшләшергә.

– Нинди баланың хәле начарланды?

– Тәнзилә, күп сорау бирәсең, шалтырат тизрәк.

– Гөлшат Равилевна, мин бит кемгә чакырганымны әйтергә тиеш, авыруның фамилиясен, адресын.

Гөлшат югалып калды, ул бит баланың фамилиясен дә, адресын да белми:

– Тәнзилә, син Нәҗия апаның кая торганын беләсеңме?

– Кайсы Нәҗия апа ул?

– Вагыйзь Нәҗиясе диләр, сезнең авылныкы. Бүген кич оныгы белән килгән иде бит. Әйдә шалтырат, минем китапларны актарасым бар, диагноз куярга кирәк. Тәнзилә, Фәимә апа мондагы кайсыдыр шкафта Ефим Михайловичтан калган китаплар бар дигән иде.

– Аңладым, Гөлшат Равилевна, китаплар теге чаттагы шкафта бугай – дип, Тәнзилә бүлмәнең ерак чатында торган шкафка күрсәтте дә чыгып китте.

Ул шкафны ачып карарга Гөлшатның ничектер вакыты җитмәгән иде, хәзер менә кирәге чыккач, актарырга мәҗбүр булды. Шкафта тәртип, бер рәттә иске китаплар тезелеп киткән. Ул тиз генә алар арасыннан «Инфекционные болезни» дигән китапны эзләп тапты. Аны актарганда, идәнгә бер фоторәсем килеп төште, Гөлшат аңа күз дә салмыйча, өстәленә алып куйды. «Үпкәсендә бернәрсә дә юк, эче йомшак төсле, тәнендә канлы тимгелләр чыккан. Нәрсә булырга мөмкин? Фәимә апа бер генә көнгә китте, ә син югалып калдың, диагноз да куя алмыйсың. Тукта, тукта, Гөлшат! Балалар бакчасын карантинга яптылар диде түгелме соң Нәҗия апа. Менингит түгелме соң бу?»

Башына килгән уйдан Гөлшат үзе дә куркып куйды. Китаптан тиз генә менингит турында табып укыды. Әгәр ул хаклы булса, балага зур куркыныч яный, аны тизрәк районга алып барырга, тизрәк ярдәм күрсәтергә кирәк. Бүлмәгә Тәнзилә килеп керде:

– Гөлшат Равилевна, мин районга шалтыраттым. Өч-дүрт сәгатьсез килә алмыйлар. «Ашыгыч ярдәм» машинасы еракатагы бер авылга киткән, кайчан кайтасы билгесез, икенче машинаны безгә җибәрә алмыйлар, ул район үзәгендә йөри. Ни эшлибез?

Шулчак алар янына Хәйдәр керде.

– Исәнме, Тәнзилә. Гөлшат Равилевна, сез өйгә кайтасызмы, әллә монда гына кунасызмы?

– Хәйдәр абый, сезгә бер зур үтенеч бар. Безгә ярдәм кирәк.

Гөлшат Хәйдәр турында бөтенләй оныткан иде, аның кинәт бүлмәгә керүе килеп туган мәсьәләне чиште.

– Нинди үтенеч? Сезнең өчен мин һәрвакыт әзер, – дип, артистларча кыланып, җавап бирде Хәйдәр.

– Хәйдәр абый, Нәҗия апаның оныгы бик авыр хәлдә, аны районга алып барырга кирәк, без аңа монда ярдәм күрсәтә алмыйбыз, – дип, хәлнең бик җитди булуын аңлатырга тырышты Гөлшат.

– Әйдәгез алайса, ашыгыйк. Малайның, чынлап та, хәле авыр булса, вакыт югалтырга ярамый. Ник башта ук әйтмәдегез, шунда ук алып киткән булыр идек.

Алар кире Нәҗия апаның өенә әйләнеп килделәр. Нәҗия апа оныгын, юрганга төреп, урамга алып чыкты. Ул алга, ә Гөлшат, баланы кулына алып, машинаның арттагы утыргычына утырды. Бала юл буе ыңгырашып барды, тәне ут булып яна иде. Вакыты-вакыты белән тәнендә калтырану сизелеп куя. Барып җиткәнче беркем бер сүз кузгатмады. Гөлшат эченнән генә «Мин уйлаган диагноз дөрес булмаса гына ярар иде», дип уйлап барды. Нәҗия апа белгән догаларын укып бара торгач, йокыга китте. Хәйдәр кайвакыт машина көзгесе аркылы Гөлшатка карап куйгалады. Район

үзәге хастаханәсенә килеп җиткәндә, сәгать төнге ике иде. Баланы кабул итү бүлмәсенә алып керделәр. Аны ятакка салгач кына, Гөлшат юл буе баланы тотып килүдән, куллары оеганлыгын аңлады. Аларны хастаханәдә көтеп торалар иде. Тәнзилә шалтырата-шалтырата: «Килеп җиттеләрме, юкмы?» – дип аптыратып бетерде. Кабул итү бүлмәсендә дежур торучы шәфкать туташы:

– Зинһар өчен, Гөлшат Равилевна, Тәнзиләгә шалтыратыгыз, җаныбызны алды, сезне сорап.

– Ярар, сез, дежур табибны чакыртып төшерегез, балада менингит булырга мөмкин, шуңа күрә башка балалар белән бергә салмагыз. Аерым бер палатага урнаштырсагыз яхшырак булыр. Аннары тагын педиатр белән инфекционистны чакыртыгыз.

– Борчылмагыз, хәзер Анжела Мөдәррисовна карар. Әби монда оныгы белән кала торгандыр?

Гөлшат Хәйдәр белән район үзәгеннән авылга таба кузгалганда, офыкта кояш күренә башлаган иде.

Сүзне Хәйдәр башлады:

– Сез, теге кичне кая югалдыгыз? Сезне миннән башка да күп егетләр эзләп йөрде. Биюгез белән күп егетләрнең игътибарын җәлеп иттегез.

– Сезнең шундый матур тавышыгыз белән чагыштырганда, минем биюем бернәрсә дә түгел.

– Без кәккүк белән әтәч төсле, бер-беребезне мактап утырабыз, – дип, икәүләшеп чын күңелдән көлештеләр.

– Чынлап та, Хәйдәр абый, сез нишләп җырчы булмадыгыз? Тавышыгыз шундый матур бит, Рәмис Әхмәтшинныкыннан күпкә матуррак.

Хәйдәрнең кәефе кинәт бозылды:

– Гөлшат Равилевна, минем белән араны бозасыгыз килмәсә, мине беркайчан да Рәмис белән чагыштырмагыз. Аннары көн саен икмәк ашыйбыз, аны үстерергә дә кеше кирәк, – диде. Аның күзләре караңгыда усал ялтырап куйдылар.

– Нишләп сез Рәмисне шулай яратмыйсыз? Концертта да сез аңа каршы җырладыгыз, аны авылдашлары алдында кимсетер өченме?

– Гөлшат Равилевна, сез бит минем турында берни дә белмисез? – дип, Хәйдәр Гөлшатка карап куйды.

– Ә сез сөйләгез, юлыбыз кыска түгел, мин бит табиб, бәлки, бу чирегезнең дәвасын табармын, – дип, Гөлшат, авыруны сорашкандай, кызыксынып куйды.

– Язарга авырулар тарихы бармы соң?

– Курыкмагыз, кайткач, барысын да язып куярмын, хәтерем начар түгел әле.

– Алайса тыңлагыз, – Хәйдәр сөйли башлады. – Рәмис белән без яшьтәшләр, бер мәктәптә, бер класста укыдык. Безнең әниләребез бертуган. Бала вакыттан ук бергә уйнап үстек, башта дуслар булганбыздыр. Ләкин безне һәрвакыт чагыштыралар иде – кем яхшырак шигырь сөйли, кем яхшырак җырлый? Безнең әниләребез кунакларда бергә булганда, һәрвакыт бергәләшеп җырлыйлар, тыңлап туярлык түгел иде. Күрәсең, аларның геннары безгә дә күчкәндер. Әтием бәйрәмнәрдә гармунда уйнап бөтен

авылны җырлатып, биетеп йөри иде. Мәктәптә укый башлагач, безне тагын чагыштыра башладылар. Рәмис миннән күчереп яза иде күп чакларда, аңа – «бишле», миңа «дүртле» куялар иде. Бервакыт миңа укытучыбыз: «Син Рәмистән күчереп язгансың», – диде. Шуннан соң мин аңа күчертми башладым, Рәмиснең билгеләре начарланды. Әнием: «Син, Рәмискә ярдәм ит инде, аңа уку авыр бирелә», – диде.

– Ничек, ярдәм иттегезме соң? – дип, Хәйдәрнен сүзен бүлде Гөлшат.

– Әни сорагач, тешемне кысып булса да, булыштым. Шуннан бирле безне әнием чагыштырмый башлады. Без тагын дуслашкан булдык. Мәктәп оештырган концертларда бергәләшеп җырлап йөрдек, бер тапкыр Казанга да барып җырладык. Мәктәпне тәмамлагач, бергәләшеп, музыка училищесына документлар бирергә бардык, ләкин мин Авыл хуҗалыгы институтына бирдем, аның белән бергә барырга теләмәдем. Гел җырлап, биеп кенә йөреп булмый бит, кемгә дә булса икмәк үстерергә кирәк.

Хәйдәр бер минутка тынып калды.

– Арагыздан кара песи тагын кайчан үтте?

Гөлшатның кызыксынуы көчле иде.

– Безнең Авыл хуҗалыгы институтында татар театры түгәрәге эшли. Без спектакльләр куеп йөри идек, концертлар оештырабыз, бик күңелле була торган иде. Шунда йөргәндә, мин үз шигырьләремнең берничәсенә көй язган идем. Музыкаль белемем булмагач, ярдәм сорап, Рәмис янына бардым. Ә ул шул җырларны, үзем иҗат иттем дип җырлап йөри башлады. Шул вакытта шундый ачуым чыкты, хәтта барып кыйнап кайтасым килде. Мин бит дусларым алдында мактанчык, ялганчы булып калдым. Ләкин мин ни әйтергә дә белмәдем. Шуннан бирле аның белән очрашмадым. Тагын әнием соравы буенча, без аны туйга чакырырга дип, концертына бардык, билетларын сатып алдым. Аның беркайчан да концертларына чакыру билетлары биргәне булмады. Шуннан соң, минем яратып йөргән кызым белән аралар начарлана башлады. Башта Ләйләм нишләп үзгәргәнен аңламыйча йөрдем, мин бит укуны тәмамлап, авылда эшли башлаган идем, ә ул Казанда соңгы елын укып калды. Сабантуйлардан соң туй уздырырбыз, дип вәгъдәләшкән идек, ләкин Ләйлә башкача уйлап йөргән икән. Рәмис белән бутала башлаган. Безнең планнар бозылды, – дип, авыр сулап куйды Хәйдәр. Бу вакытта инде машина олы юлдан авылга таба борылган иде.

– Бер караганда, кызыгыз белән шундый хәл килеп чыгуның яхшы яклары да бар, – диде Гөлшат, сүзләрен сузып кына.

– Кызык, нинди яхшы яклар икән ул, бәлки, мин Рәмис янына барып, гафу үтенергә, рәхмәт әйтергә тиеш булганмындыр? – диде Хәйдәр, усал гына итеп һәм машинаны туктатты.

– Сез алай кызмагыз, мин бит үземнең фикеремне генә әйттем, – диде Гөлшат. Ул Хәйдәрнең шулай кинәт кәефе үзгәрүен күреп, куркып китте. – Минем уемча, Ләйләгез сезне яратмаган. Үзегез уйлап карагыз, кияүгә чыккач, шулай йөри башласа, сезгә тагын да авыррак булыр иде. Аллаһы Тәгалә сезнең күзегезне ачып, бу кыздан шулай саклап калгандыр.

– Бәлки, сез дөрес әйтәсездер, – дип куйды Хәйдәр, бераз уйлап торгач.

Машина яңадан кузгалып китте. Юлдашлар башка сөйләшмәделәр. Авылга кергәндә генә, Хәйдәр:

– Сезне кая илтергә, «патша сарае»намы, өегезгәме? – дип сорады.

– Наилә апаны уятып йөрмим инде, хастаханә янында гына калдырыгыз.

Хастаханә янына килеп туктагач, Хәйдәр Гөлшатка карап:

– Сезнең дәвагыз файда итә башлады, рәхмәт, сезгә тагын дәвалау сеансына килсәм ярыймы? – диде.

– Үзегезгә бик зур рәхмәт. Сез мине шундый коткардыгыз, минем аркада төн буе йоклый да алмадыгыз. Минем сүзләремнең файдасы булса, килегез, хәлдән килгән кадәр ярдәм итәрмен. Сау булыгыз, – дип, Гөлшат машинадан төште.

– Сау булыгыз, Гөлшат Равилевна, киләсе очрашканга кадәр, – дип, Хәйдәр машинаның ачык тәрәзәсе аркылы гына саубуллашты да, кузгалып китте.

Урамда иртәнге салкынлык булса да, рәхәт иде. Тау артыннан кояш чыгып, авылдагы әтәчләрне уята. Әле тегеннән, әле моннан, әтәчләр, бер-берсен уздыра-уздыра, хуҗаларын уяталар. Гөлшат уянып килгән авылга, туып килгән көнгә сокланып озак кына карап торды. Төне буе керфек тә какмаган булса да, йокысы килмәде. Ул ашыкмыйча гына хастаханәгә керде, аны эше көтеп тора. Төн йокламаса да, табибка ял юк. Авырулар көн саен игътибар, якты чырай көтә.

Төшкә таба әкрен генә арыганлык баса башлады, төнлә йокламау үзен сиздерде. Кулына каләм тотып утырган килеш Гөлшат йоклап китә язды. Йокыдан айнып өчен ул бераз урамда йөреп керергә кирәк дип, бүлмәсеннән чыгып китте. Ишек төбенә хастаханәнең «УАЗ»игы килеп туктады. Район үзәгеннән, дарулар төяп, Фәимә апа кайтты.

– Гөлшат Равилевна, безне каршы алырга чыктыңмы? – дип, Фәимә апа, Гөлшатны күреп, машинадан төште.

– Исәнмесез, Фәимә апа! Исәнме, Мансур. Әйдәгез, даруларны ташырга булышам.

– Мансур белән кызлар синсез дә ташырлар, синең белән сөйләшәсем бар, әйдә керәбез, – дип, Фәимә апа Гөлшатны үз бүлмәсенә алып кереп китте.

– Ни булды, Фәимә апа, син заговорчик төсле? – дип, Гөлшат шаяртырга тырышып, аның артыннан иярде.

Фәимә апа тиз генә самавыр куеп җибәрде.

– Син кичә кечкенә баланы районга алып килдеңме?

– Кичә түгел, бүген, – Гөлшат тагын шаяртмакчы булды.

– Сүзгә бәйләнмә, син һаман шаяртасың. Бер дә шаярырлык түгел. Син кичә алып килгән баланы бүген реанимобиль белән Казанга озаттылар, хәле бик авыр.

– Аның хәле кичә үк авыр иде, мин бит кабул итү бүлмәсендәге шәфкать туташларына, балада менингит, хәле авыр, дип әйтеп калдырдым. Хәзер табиб төшеп карый, дип ышандырып, мине кайтарып җибәрделәр.

– Кичә Анжела Мөдәррисовна дежурда иде. Ул баланы төнлә төшеп карамаган. Баланы бүген иртән реанимациягә салдылар, сулышы туктый башлаган.

– Мин бит кичә әйттем, хәле авыр, дип.

– Гөлшат Равилевна, син балага бернинди кәгазь дә язып калдырмагансың. Әгәр бала белән андый-мондый хәл була калса, син үзеңне ничек яклап чыкмакчы буласың? Ә эш шуңа таба бара.

– Ярар инде, Фәимә апа, куркытма. Самавырың кайнады, әйдә чәй эчеп алыйк. Син менә бер генә көнгә моннан китеп бардың, бөтен эш туктады.

– Эх, кызым, аңламыйсың син болытлар куерганын.

– Фәимә апа, болытлар куерыр, яңгырлар явар, аннары кояш чыгар, – дип, Гөлшат Фәимә апасын тынычландырырга тырышты.

– Мин сине кисәттем, үзең уйла. Күзеңнән күренә – бик арыгансың. Бар кайт, ял ит, әгәр кирәк булсаң, чакырырбыз. Мин чыгып, карап керәм, даруларны бушатып бетергәннәр микән?

Гөлшат, чәй дә эчмичә, өлкән шәфкать туташы бүлмәсеннән чыгып, үз бүлмәсенә китте.

Өстәлендә кәгазьләр, авырулар тарихлары таралып ята. «Өстәлеңдә бигрәк тәртипсезлек, тәртип салырга кирәк», – дип, Гөлшат үз-үзен тәнкыйтьләп алды һәм тәртип кертә башлады. «Моны урынына алып куярга кирәк» дип, алдагы төнне укырга алган китапны кузгатты, аның астыннан фотосурәт килеп чыкты. Фотода Фәимә апа төшерелгән иде, астагы уң як читендә «Ленинград» дип язылган. Гөлшат китапны урынына алып куйды, ә фотосурәтне өстәлендә калдырды.

Көндәлек эшләр беткәч, Гөлшат фотосурәтне күтәреп, Фәимә апа янына керде:

– Хәерле көн, Фәимә апа, кичәге өчен бик зур рәхмәт. Сез төнге унга кадәр калгансыз икән, кызлар сөйләделәр. Ефим Михайловичның бер китабын алып торган идем, китап эченнән сезнең менә бу фотогыз килеп чыкты, – дип, Гөлшат фотоны Фәимә апага бирде. Фәимә апа фотосурәткә озак кына карап торды да:

– Гөлшат Равилевна, син бу фотоны каян алдың?

– Китап эченнән килеп чыкты. Теге кечкенә малайга нинди диагноз куярга белмәгәч, мин шкафтан Ефим Михайловичның китабын алып укыган идем, шуннан килеп чыкты, – дип кабатлады Гөлшат.

– Бу бит мин түгел, менә кара,– дип, Фәимә апа фотоны Гөлшатка сузды.

Гөлшат бер фотога, бер Фәимә апага карады да:

– Ничек инде сез түгел? Монда яшь Фәимә, – дип, аптырап калды.

– Гөлшат, бу мин түгел. Монда «Ленинград» дип язылган. Минем беркайчан да ул шәһәрдә булганым юк.

– Бу хатын сезгә бик охшаган, сез булмагач, кем соң ул?

– Белмим, Гөлшат, Ефим Михайлович бу серне үзе белән каберенә алып киткән. Без бүген моңа җавап бирә алмыйбыз, – дип, Фәимә апа Ефим Михайловичның стенада эленеп торган фотосурәтенә карады. – Мохтар белән ни эшлибез, районга озатсаң яхшы булыр иде, ләкин ул бармыйм, ди.

– Миңа бөтенләй: «Өйгә кайтам», – диде. Тикшерүләр уздырасым бар дип калдырдым, ләкин ул барыбер озак ятмас, китәчәк, без аны бәйләп куя алмыйбыз. Рафаэль абыйга әйтеп карасак кына, Мохтар аны тыңлый бит.

– Ярар, Гөлшат, китсә китәр инде. Рафаэльга үзем шалтыратырмын, сабыйлар түгел, үзләре хәл итәрләр.

...Атналык җыелышны Илдар Азатович түгел, медицина хезмәте җитәкчесе Әлфия Әнәсовна алып барды. «Баш табиб белән күрешеп, тагын ремонт турында сөйләшермен», – дип килсә дә, Гөлшатның уйлаганы барып чыкмады. Ул мәсьәләләрне чишә торган кеше түгел иде, шуңа күрә

Гөлшат бу сорауны күтәреп тә тормады. Җыелышта атна саен күтәрелә торган мәсьәләләрне табиблар тагын кузгаттылар: дарулар җитмәү, аппаратураларның иске булуы турында сөйләделәр. Соңыннан Әлфия Әнәсовна тавышын күтәрмичә генә Гөлшатка карады:

– Киләсе атналарда безгә Казаннан комиссия килергә мөмкин. Ул комиссия Әхмәтшин Рүзәл эшен тикшерергә дип килә. Хәтерегезгә төшерәм, ул баланы без Казанга күчергән идек, ул бездән реанимация бүлегенә күчкәч, дүрт көннән соң аңына килмичә үлгән. Бүгенге көндә аның әти-әнисеннән шикаять юк югын. Шулай да без аңа әзер булып торырга тиеш.

Гөлшат Әхмәтшин Рүзәлнең төнлә Хәйдәр белән алып килгән теге малай икәнлеген аңлап алды. Димәк, ул үлгән. Нишләптер, Гөлшат ул малай турында бөтенләй онытып иде инде. Ул аның исемен дә, фамилиясен дә белми иде. Гөлшат бит аңа бернинди кәгазьләр тутырмады, алып кына килде. Икенче көнне Фәимә апа аны кисәткән иде дә, көндәлек эшләр белән ул малай онытылган. Гөлшатның үз-үзенә ачуы килде. Ничек инде ул малайның хәле белән бер дә кызыксынмады? Казанга Республика балалар клиник хастаханәсенә шалтыратып белергә була иде бит. Ләкин кемнең хәлен белергә? Гөлшат бит аның исемен, фамилиясен дә белми иде. Теләге булса, район үзәк хастаханәсеннән белергә була иде дә, хәзер ни әйтергә? Шундый уйлар белән Гөлшат җыелыш беткәнен сизми дә калды. Әлеге уйлардан аны Румия Хатыйповна уятты:

– Гөлшат Равилевна, нинди уйлар эчендә йөзәсең? Җыелыш бетте, әйдә миңа керик, бераз сөйләшеп утырырбыз.

Мәскәүдә укып кайткан яшь терапия бүлеге мөдире урынына бүген Румия Хатыйповна иде. Җыелыш беткәч, ул, гадәттәгечә, Гөлшатны чәй эчәргә алып керде. Нишләптер өлкән табиб Гөлшатны якын итте. Ул үзенчә Казаннан килгән яшь кызны шефлыкка алган булды. Ул аңа ничек эшләргә кирәклеге, райондагы хәлләр турында барысын да сөйли иде. Гөлшат кызыксынып, тыныч кына тыңлаганга күрә, кайчакта үз тормышы турында да сөйләп киткәли. Бер күрешкәндә: «Син район үзәгенә миңа ярдәмче булып эшкә килергә тиеш идең. Теге главаның туганы, «перспектива», килеп чыкмаса, без бергәләшеп әкрен генә эшләр идек, – дип тә ычкындырды. Шулай итеп, Гөлшат үзенең район үзәгенә чакырылып, ни өчен Каратау авылына җибәрелгәнен белде.

– Бүген нишләп теге кыз килмәде? – дип сорады Гөлшат.

– «Перспектива» ике атнага отпуск алып, ял итәргә китте, эшли-эшли арып беткән, мескенкәем, – диде Румия Хатыйповна усал гына.

– Әле эшли генә башлады бит, ул миннән соң килде, ничек шулай ялга тиз җибәргәннәр?

– Килсә соң, мин июльдә отпуск алырмын дип хыялланган идем дә, эшләргә кеше юк дип, Илдар Азатович җибәрмәде. Хәзер аңлашылды ничек киткәне. Теге малайны авыр хәлдә Казанга җибәрүләре – аның гаебе. Ул бит аны, төнлә карамыйча, иртәнгә хәтле калдырган.

– Ул малайны мин алып килдем бит, – дип, Гөлшат Румия Хатыйповна сүзләренә кушылды.

– Мин беләм. Беренче булып, ул баланы мин карадым. Минем иртүк

килгәнне күреп, кабул итү бүлмәсендәге шәфкать туташы миңа малай турында сөйләде. Синең менингит диагнозы куйганыңны да әйтте. Ярый әле, аерым бүлмәгә салырга акылы җиткән, башка балалар белән бергә салган булса, безне кызган табага бастыралар иде, – дип, Румия Хатыйповна чәй эчкән чынаякларын чайкап, шкафка куйды. Гөлшат та ясаган чәен эчмичә түкте дә чынаягын урынына алып куйды. Ул, Румия Хатыйповна белән саубуллашып, ишегалдында машинада көтеп утырган Мансур янына чыгарга ашыкты.

Районнан кайтуга, Гөлшат Фәимә апа үтенече белән Нәкыя әби янына керде. Фәимә апа аңа:

– Мансур аның кая яшәгәнен белә, алып барыр. Ул авылга керә торган юл өстендә генә яши. Бик яхшы бер карчык, үзе генә. Баш әйләнгәли, дигән иде. Хастаханәгә кил дип чакырган идем дә: «Өйдә балаларым күп, калдырып китә алмыйм», – дип әйтте, – диде.

Гөлшат «патша сарае»ннан ерак түгел генә Нәкыя әбиләр янында Мансурның машинасыннан төшеп калды. Бүрәнәдән салынган иске генә йорт, матур итеп буялган иске капка. Капканың астыннан Гөлшатның каршысына төлкегә охшаган бер эт өреп килеп чыкты. Эчке яктан:

– Тузик, кем бар анда, кемне каршы аласың? – дигән тавыш ишетелде.

– Нәкыя апа, мин сезнең яңа табибыгыз – Гөлшат. Фәимә апа сезнең янгызга кереп, хәлләрегезне белеп чыгарга кушкан иде.

Капкадан кечкенә буйлы, ябык кына, бөкрәйгән карчык чыкты:

– Тузик, бар әле урыныңа. Күрәсеңме, минем хәлемне белергә кунак килгән, ә син аны өреп каршы аласың, яхшы түгел, – дип, әби этне орышып алды. Эт аңлагандай, койрыкларын болгый-болгый, Гөлшат янына килеп иснәнде дә өй ышыгына барып ятты. – Әйдә, кызым, өйгә уз. Мактап йөрисең, чәй эчәргә җыена идем, Аллаһы Тәгалә үзеңне миңа иптәшкә җибәргәндер. Берүземә генә күңелсез.

Гөлшат тиз генә ишегалдына күз төшереп алды. Ишегалды чиста итеп себерелгән, берничә тавык белән әтәч җим чүпләп йөриләр. Безнең әбиебез янына нинди кеше килде икән дигән кебек кызыксынып, әтәч берничә тапкыр Гөлшатка карап алды. Гөлшат өйгә узды.

– Әйдә, кызым, Аллаһының рәхмәте, өстәл янына уз, утыр, – дип, әби урындык бирде.

– Нәкыя апа, борчылма. Фәимә апа кереп, хәлеңне белеп чыгарга кушкан иде, – дип, уңайсызланып кына, Гөлшат урындыкка утырды.

– Рәхмәт инде Фәимәгә, авылдашларын бер дә онытмый, гел кайгыртып тора. Кызым, сиңа чәйне сөтләп ясыйммы?

Гөлшатның сүзләрен ишетмәгәндәй, әби үз эше белән мәшгуль иде.

– Мин, әбекәй, синең хәлеңне генә белергә кергән идем. Фәимә апа башың әйләнә дип әйткән иде.

– Мин сөтләп яратам, сиңа да үзем яратканча ясыйм, – дип, әби Гөлшатны бөтенләй ишетмәгәндәй, чәйләр ясады. – Менә кәрәзле бал белән эч, – дип, каршысына савыты белән бал куйды. – Чәйләр эчә-эчә хәлемне сөйләрмен.

Гөлшат урындыкны өстәл янынарак куеп, чәйдән авыз итте.

– Хәлләрем, кызым, картларча инде, баш та әйләнгәли, авырткалый да, көн үзгәрергә булса, сөякләр дә сызлый башлый. Сиксәннең теге ягына чыккач була торган хәлләрдер инде.

– Нишләп безгә килеп тикшеренеп, дәваланып чыкмыйсың? – дип сорады Гөлшат, әбинең зарларын тыңлаганнан соң.

– И кызым, балаларым күп бит. Аларны кемгә калдырыйм?

– Нинди балалар, мин бик аңлап бетермим? – Гөлшат як-ягына каранып куйды.

– Этем, песием, унбишләп тавыгым, биш казым, биш баш сарыгым, бер кәҗәм бар. Аларны кем карый? – дип елмаеп куйды әби.

– Үз балаларың юкмыни?

– Алары да бар, Аллага шөкер. Дүртәү – өч малаем, бер кызым. Алар янында өч килен, бер кияү, ун оныгым бар, бөтенесе дә исән-саулар.

– Алар нишләп килеп ярдәм итмиләр соң? – дип сорады Гөлшат, шуның хәтле балалары барлыгын ишеткәч.

– Нишләп итмәсеннәр, печәнен әзерлиләр, бәрәңгесен утырталар, чүбен утыйлар, килеп, уңышын җыялар. Узган ял көннәрендә кызым белән кияү кайтып киттеләр. Бөтен дөньямны юдылар, чистарттылар. Барысы да бик булышалар, рәхмәтләр генә яусын. Һәр намаздан соң рәхмәтләр укыйм үзләренә. Киявем дә, киленнәрем дә бик яхшылар, зарланырлык түгел. Әйдә әле, тагын берәр чынаяк чәй эчик, сиңа да, үземә дә ясыйм, – дип, әби торып, тагын чәй ясады. – Сөтен, кызым, кирәгенчә үзең сал, минем кәҗәмнең сөте бик тәмле.

– Әбекәй, нигә соң син шуның хәтле мал тотасың? Үзеңә генә авыр бит? – дип, тагын да гаҗәпләнебрәк сорады яшь табиб.

Гөлшатның аяклары янына аклы-каралы песи килеп, башта иснәнгән булды, аннан сыпырына башлады. Гөлшат, иелеп, песинең башыннан сыйпап алды. Шул арада песи Гөлшатның итәгенә үк менеп утырды.

– Син дә минем кызым сүзен сөйләмә әле, менә, син, мине тыңлап кара: иртүк торасы килми, ә малларны көтүгә чыгарырга, кәҗәне саварга кирәк. Алар: «Тор инде», – дип кычкыралар. Хайваннарны карап, озатып җибәргәч, сөякләр бераз язылып киткәндәй була. Йөреп кергәч, чәйләр дә эчәсе килеп китә. Шулай торып йөрим, хәрәкәтләнәм, намазымны укыйм, көн узганы сизелми дә. Көтү кайта, малларны яңадан карыйм, ашатам, суларын эчерәм. Авылда яшәп, бер дә мал асрамасаң, күңелсез бит. Мин гомерем буе авылда үскән, авылда яшәгән кеше. Менә кара әле, үзеңне песи ничек яратты, яхшы кеше икәнлегеңне сизә ул. Син бит бөтенләй таныш түгел кеше, ә ул сине ничек яратты.

– Барыбер бу яшьтә шуның хәтле тормышны алып баруы авырдыр, – дип, песине сыйпый-сыйпый, Гөлшат әбинең йөзенә күтәрелеп карады.

– И кызым, аның шул беренче җитмеш яше генә авыр, аннары ияләшәсең икән, – дип, Нәкыя әби көлеп җибәрде.

– Әйдә, Нәкыя апа, хәлеңне белергә килгәч, тикшереп карыйм әле.

Алар түр якка керделәр. Гөлшат, әбине чишендереп, үпкәсен, йөрәген тыңлап карады, кан басымын үлчәде. Үзе тәкъдим иткән даруларны ничек эчәргә кирәклеген дәфтәр битенә язды.

– Мин, кызым, бер дә дару эчәргә яратмыйм шул. Без бит дару эчеп үскән кешеләр түгел. Хәзер бала-чага әз генә йөткерсә, төчкерсә, дару бирә башлыйлар. Без үлән чәйләре эчеп өйрәнгән. Кәҗә сөте дә бик файдалы, чәйне гел сөтләп кенә эчәбез. Намазымны да, Аллага шөкер, калдырганым

юк. Дарулар язып та торма, барыбер эчмим, миңа дарулар эчәргә түгел, үләргә вакыт җиткән инде. Габделхагымны җирләгәнгә быел унбиш ел була, соңгы елларны төшемә дә керми башлады. Озаклады бу кызый, диеп, теге дөньяда миңа үпкәләп ята торгандыр.

– Нишләп әле син, Нәкыя апа, юк сүз сөйләп утырасың? Мин сине тикшереп, тыңлап карадым, бер дә зарланырлык җирең юк. Күпме эшлисең, күпме мал карыйсың, сөбханалла. Синең әле оныкларыңны күреп, алар белән шатланып яшисең бар, – дип, Гөлшат кинәт кәефсезләнеп киткән әбине тынычландырырга тырышты.

– Рәхмәт, кызым, җылы сүзләрең өчен, минем инде өч оныкчыгым да бар. Шулар яныма кайтса, күңел шундый шатлана. Менә кара әле, алар нинди матурлар, – дип, әби Гөлшатка фоторәсемнәр күрсәтте.

Шулай сөйләшә-сөйләшә Нәкыя әби белән Гөлшат ике сәгатькә якын утырдылар. Гөлшат вакыт узганын да сизмәде. Стенадагы күкеле сәгать өчне кычкыргач кына, Гөлшат уянып киткәндәй булды:

– Нәкыя апа, чәйләрең өчен бик зур рәхмәт, минем эшкә кереп чыгасым бар әле, озакладым мин синдә, – диде.

– Рәхмәт, кызым, карт кешенең күңелен күрергә кергәнең өчен, вакытың булганда шулай кергәлә, бергә тәмләп чәйләр эчәрбез. Тукта әле, менә бүген иртән сауган кәҗә сөтен ал әле, мин кичә кичкесен дә эчеп бетермәдем, Фәимә белән бергәләшеп эчәрсез, – дип, Гөлшатка банка белән сөт тоттырды.

Нәкыя әби үзенең песие, төлкегә охшаган эте Тузик белән өчәүләп, Гөлшатны капкадан озата чыктылар. Гөлшат ашыга-ашыга, хастаханәгә китте.

Ялгыз Нәкыя әби Гөлшатның башыннан чыкмады. «Дүрт бала үстергән, картлыгында берсе дә янында юк. Эх сез, балалар, үсәсез дә таралышасыз, ялгыз әниләр көн саен сезне көтәләр, – дип, Гөлшат үзалдына көлеп куйды. – Әллә син дә картаясың инде, Гөлшат, олылар төсле уйлый башладың? Син дә шулай әтиеңне ялгыз калдырып, өйдән качтың түгелме соң? Юк, ул ялгыз түгел, аның яңа хатыны бар».

Шулай уйланып бара торгач, Гөлшат хастаханәгә килеп җиткәнен сизми дә калды. Анда бөтен авырулар каралган, барысы да тәртиптә иде. Фәимә апа бөтен эшне эшләгән. Гөлшат, аның янына кереп, рәхмәт әйтмәкче иде, Фәимә апа өлгеррәк булып чыкты:

– Рәхмәт, Гөлшат Равилевна. Нәкыя әби шалтыратты инде, бик зур рәхмәтләр укый үзеңә, – диде.

– Үзеңә рәхмәт, Фәимә апа, миңа бер эш тә калдырмагансың. Мин, Нәкыя әби белән сөйләшә-сөйләшә, вакыт узганын сизми дә калганмын. Ярый әле Мансурны көттереп тормадым, – диде Гөлшат, гафу үтенгәндәй.

– Мин шулай буласын белгән идем, үзем дә Нәкыя әби янына керсәм, бер сәгатьсез чыгып китә алмыйм. Ешрак керергә вакытым юк, кермәсәң, кызганып та куям, ялгызы яши бит.

– Ялгыз түгел бит, бер эте, песие, унбиш тавыгы, биш казы, биш баш сарыгы, бер кәҗәсе дә бар, – дип, Гөлшат көлеп җибәрде.

– Әле тагы дүрт оя умартасы да бар аның. Кәрәзле балын кабып карамадыңмыни?

– Карадым. Ничек берьялгызы бөтенесен карап бетерә икән ул?

– Балалары ял саен кайтып торалар, ярдәм итәләр, үзләре белән алып китмәкчеләр дә, бармый бит. Аякларым, кулларым йөргәндә, үз өемдә торам, ди. Шундый бер тик тормас әби ул.

...Узган җәй айлары нәтиҗәләренә багышланган җыелыш озак бармады. Район үзәк хастаханәсенең баш табибы Илдар Азатович сүзне кыска тотты. Гөлшат Равилевна бу җыелышка бик куркып кына килгән иде. Ләкин аңа карата авыр тәнкыйть сүзләре ишетелмәде.

Хастаханәдән чыккач, Гөлшат иркенләп сулап куйды. Урамда җылы көзге көннәр. Мансур үз эшләре буенча каядыр киткән иде. Ул сәгать дүрткә хастаханә янына килергә тиеш. Машина килгәнче ярты сәгатьтән артык буш вакыт бар. Гөлшат якында гына урнашкан даруханәгә юл тотты, Зиннур бабайга дарулар аласы бар иде. Бу даруханә бик зур булмаса да, Гөлшат районга килгәндә, монда кермичә китми. Анда Нурия исемле бик сөйкемле туташ эшли. Яшь булса да, бик сабыр, шәфкатьле. Гөлшат бик еш кына аңа сокланып карап торгалый.

Бу юлы да даруханәгә керүнең төп сәбәбе шул кызны күрү һәм авылдагы ялгыз әби-бабайлар сораган кайбер даруларны алу иде. Ләкин прилавка артына Нурия урынында башка хатын-кыз баскан. Ул да бик тиз эшли. Ләкин Нурия түгел иде. Сүзләрендә, тавышында корылык, салкынлык сизелеп тора. Гөлшат түзә алмыйча:

– Исәнмесез! Ә Нурия кайда? Әллә ялдамы?

– Нуриябез, егете белән юл һәлакәтенә очрап вафат булды, – дигән коры гына җавап ишетелде.

Даруханә кинәт караңгыланып китте. Гөлшатның тыны кысылып, йөрәге тибүдән туктагандай булды.

– Кайчан, ничек булды бу фаҗига? – дип сорады Гөлшат әкрен генә аңына килеп.

– Туйга әзерләнә иде. Туй урынына кырыгын уздыралар, – диде әлеге тавыш.

Гөлшат, дарулар алырга кирәклеген дә онытып, даруханәдән чыкты. Як-ягына да карамыйча, үз уйларына чумып, урам буйлап китте.

Гөлшат үз уйларыннан үзе куркып, сискәнеп куйды, як-ягына караса, аяклары мәчет ишек төбенә алып килгәннәр. Җилкәсенә салган яулыкны башына бәйләп, мәчеткә керде һәм садака тартмасына акча салды. Каршысына түбәтәй кигән, сакаллы матур гына бабай килеп басты.

– Әссәламегаләйкүм, кызым. Нинди уйлар, борчулар белән килдең? Биргән садакаларыңа дога кылып алыйк, – дип, кулларын күтәреп укый да башлады.

Гөлшат та кулларын күтәреп, эченнән генә белгәннәрен укыды. Бабай укып бетергәч, Гөлшат тагын бераз мәчеттә утырып торды. Аннары әкрен генә чыгып китте. Мәчеттән чыкканнан соң Гөлшатның уйлары тәртипкә салынгандай булды, күңеле тынычланды. Ул үзәк хастаханәгә таба юл тотты. Анда Мансур көтеп тора иде.

– Бушадыңмы?

– Әйе.

– Алайса кайтабыз, зинһар өчен, куып кайтма. Беркая да ашыгасыбыз юк, – дип, Гөлшат машинага кереп утырды.

Мансур берничә тапкыр сүз башлап, сөйләшергә теләп карады, ләкин Гөлшат, авызына су капкандай, бер сүз дә дәшмәде. «Бу кызга җыелышта Илдар Азатовичтан эләккән, ахрысы», – дип уйлап куйды Мансур.

Машина хастаханә янына килеп туктады. Гөлшат кереп, дежур торучы кызлардан хәлләрне белеште. Барысы да тәртиптә иде. Шуңа күрә ул эчкә узып тормады, ашыкмыйча гына Зиннур бабай өенә таба юл тотты. Аларның өйләренә килеп җитәрәк даруханәдән дару алмаганлыгы исенә төште. Аның күз алдына яңадан һәрвакыт елмаеп торучы Нурия килеп басты. Гөлшатның, күңеле тулып, күз яшьләре ага башлады. Тынычланыр өчен ул урам буенда үсеп утырган каеннар астындагы юан бүрәнәгә барып утырды. Кичләрен монда еш кына яшьләр җыелышалар. Ләкин хәзер бер кеше дә юк иде. Моннан Зиннур бабайның өе бик яхшы күренә.

Шулвакыт капкадан таякка таянган Зиннур бабай һәм аның артыннан ияреп, Хәдичә әби чыктылар. Колаклары начар ишеткәнгә күрә, алар кычкырыбрак сөйләшәләр. Гөлшат утырган урында әби белән бабайның тавышлары яхшы ишетелә иде.

– Нәрсә артымнан ияреп чыктың? Артымнан йөргәнче, бар самавырыңны куй. Электр чәйнегендә кайнаткан чәй тәмле түгел. Агач шакмаклар әзерләп куйдым, бар, иренмә, – дип, Зиннур бабай хатынын шелтәләп алды.

– Сиңа ярап булмас инде. Иртән бик тәмле итеп эчтең әле, – дип, каршы төште әби.

– Бар инде, Хәдичәкәй, тәмле итеп чәй эчик. Син кайнаткан самавырда чәй бик тәмле була, карлыган яфраклары да салсаң, эчеп туймассың. Әгәр инде картайдым, хәлем юк, дисәң, үзем куям, – дип төрттереп куйды бабай.

– Үзең дә яшь түгел, таякка таянып йөрисең. Мин әле сиңа караганда яшьрәк. Минем белән сүз куертып торганчы, бар, кәҗәләрне алып кайт, тәмле сөт салып чәй эчәсең килсә.

– Кәҗәләр үзләре кайтырлар әле. Иртәнге сөт бар бит.

– Иртәнге сөтне күршеләргә биреп чыгардым, балалары йөткерә. Бар, иренмә. Маруська үзе тугызсыз-унсыз кайтмый, үзең беләсең бит.

– Ярар алайса, киттем, син самавырыңны куй, – дип, бабай урам буйлап кәҗәләр артыннан китте.

Бу карт белән карчыкның сөйләшүен тыңлап, Гөлшат бөтен борчуларын оныткан кебек булды. Менә бит нинди матур картлык! Аларга карап, сокланып туймаслык. Сөйләшүләре дә ничектер матур, кызык. Күпме еллар узса да, араларында сакланган җылылык, мәхәббәт тә сизелеп тора төсле. «Картаерга язсын, бәхетле, хөрмәтле картлык күрергә язсын!» – дип уйлап, Гөлшат өенә таба атлады.

Гөлшат Казанга килгәндә, сәгать көндезге икеләр тирәсе иде. Туган, үскән шәһәреннән киткәнгә ике айдан артык вакыт узып киткән. Шәһәр ике ай эчендә ничектер үзгәргән кебек күренде; урам тулы кешеләр, машиналар – барысы да каядыр ашыгалар. Гөлшат, Илдар Азатовичтан сорап, көзге киемнәрен алып кайтырга дип, бер генә көнгә Казанга килде. Бәхетенә баш табиб:

– Ул көнне мин дә Казанда булам, кичке сәгать алтыларга Республика клиник хастаханәсе янына чыксаң, үзем алып кайтырмын, – диде.

Гөлшат фатирларына үз ачкычы белән ачып керде. Өйдә чисталык,

тәртип, күңелгә якын ис. Аяк киемнәрен салып, үз бүлмәсенә үтте. Монда бернәрсә дә үзгәрмәгән, ул киткәндәге кебек. Өстәлендә әнисенең фоторәсеме. Аны күргәч, Гөлшатның күңеле тулып китте. Кинәт әнисен күрәсе, сөйләшәсе килде.

– Исәнме, әнием! Минем барысы да әйбәт дип әйтергә була. Эшем кызык, авыр булса да, мин авылга кайтканыма үкенмим. Син үзең барысын да күреп торасыңдыр. Минем сиңа сөйләргә сүзләрем шундый күп җыелды, ләкин син ишетсәң дә, миңа киңәш бирә алмассың шул, – дип, ул фоторәсемне сыйпый-сыйпый, аңа озак кына карап торды. «Ник әниләрнең кадерләрен аларны югалткач кына аңлыйбыз икән? Гөлшат, синең әтиең дә бар, бәлки, син аңа шулай салкын карап ялгышасыңдыр?» – дип уйлап, ул әтисенә хат язарга тотынды.

«Исәнме, әтием. Минем барысы да яхшы, эшлим, сау-сәламәт. Мин күзгә киемнәремне алдым. Сау бул, яраткан кызың Гөлшат».

Гөлшат озак кына нәрсә язарга дип уйланып утырса да, хат бик кыска килеп чыкты. Бөтенесен хат аша сөйләп бетереп буламыни соң? Элек әтисен ул бик ярата иде, еш кына серләшеп тә утыргалыйлар иде. Әнисе кайчакларны көнләшепме, сөенепме: «Миңа да сөйләгез әле серләрегезне, миңа да кызык бит», – дип әйткәли иде. Ләкин әтисе өйләнгәч, аларның аралары нишләптер суынды. Гөлшат үзенең дә гаепле булуын аңласа да, якынлашыр өчен берни эшләмәде.

Ул хатны өстәлдә калдырып, әйберләрен алды да өйдән чыгып китте. Алдан сөйләшкәнчә, Илдар Азатович белән олы юлга чыккан җирдә очрашып, алар районга кайтып киттеләр. Ярты юлда яңгыр ява башлады. Тагын «патша сарае»бызны су басачак, дип уйласа да, Гөлшат бу мәсьәләне кузгатмады. Юлда алар бер дә сөйләшмәделәр диярлек. Баш табиб алдагы урында йоклап кайтты, шофёр аны уятмас өчен Гөлшат белән сөйләшмәде. Дөресен әйткәндә: сөйләшергә уртак темалар да юк иде. Район үзәгенә кайтып җиткәч, Илдар Азатович шофёрга Гөлшатны авылына кадәр кайтарып куярга кушты. Мондый боерык бик үк ошамаса да, баш табиб әйткәч, үтәми булмый. Ләкин аның бәхетенә аларга район үзәгеннән чыкканда, авылга кайтып баручы Хәйдәр очрады. Гөлшат тиз генә агроном машинасына күчеп утырды:

– Хәерле кич, Хәйдәр абый, сез ни эшләп йөрисез?

– Хәерле кич, Гөлшат Равилевна. Мин район җыелышыннан кайтып киләм, ә сез ничек Илдар Азатович машинасына эләктегез? Бергәләшеп, ресторанга бардыгызмы? Сез бит хатын-кызлар байларны яратасыз.

– Туктатыгыз машинаны, Хәйдәр абый, – дип, Гөлшат машина ишеген ачмакчы булды.

– Нәрсә, дөрес сүзгә җавап юкмы? Илдар Азатовичның бит гаиләсе, балалары бар, сез алар турында уйлыйсызмы, юкмы? Кешенең гаиләсен таратыргамы?

Хәйдәр машинасын тизләтә төште.

– Сез, Хәйдәр абый, авыру, бик каты авыру! – Утыргычка җайлабрак утырды Гөлшат. – Сез тормышыгызда бер тапкыр пешкәнсез икән, нишләп бөтен хатын-кыздан начарлык эзлисез? Мине дә юкка гаеплисез, рәнҗетәсез. Мин Казаннан күзгә киемнәремне алып кайтып киләм, ә Илдар

Азатович, хәзер сез мине алып кайткан кебек утыртып кайтты. Әгәр инде тормышыгызда Ләйлә очраган икән, минем һәм башка кызларның монда ни гаебе бар. Сез – ирләр арасында начар кешеләр аз дип беләсезме?

Гөлшат үзе дә сизмәстән, бик кызып китте.

– Сез минем чирнең гаебен белгәч, дәвалагыз, сез бит – табиб.

– Үзегездән башка, сезгә беркем дә ярдәм итә алмас. Безгә университетта бер профессор: «Кызганыч, без авыру кешене терелтә алмыйбыз, терелергә ярдәм генә итә алабыз. Әгәр кешенең чир белән көрәшәсе килми яки көрәшергә хәле, теләге юк икән – аны дәвалап булмый», – дигән иде. Шуңа күрә сез дә чирегез белән башта үзегез көрәшергә тиеш.

– Алайса, сез миңа ярдәм итегез, дарулар язып бирегез, – дип, Хәйдәр янында утырган, үзеннән күпкә яшь бу кызга, бер сокланып, бер куркып караштыргалап алды.

Машина аларны авылга җиткәндәге тау башына алып менде. Гөлшат Хәйдәрдән машинасын туктатуын сорады:

– Туктагыз!

– Ни булды? – диде Хәйдәр, Гөлшатка карап.

– Миңа карамагыз, авылыгызга карагыз. Нинди матурлык! Сез соңгы тапкыр Мәдинә тавына кайчан мендегез? Сез барлык эшләрегезне ташлап, азга гына булса да, тауга менеп, авылыгызны, аның табигатен күзәтегез, чишмә суыннан авыз итегез. Бәлки, шул чишмә сулары сезнең эчегездәге хатын-кызларга карата булган начар уйларыгызны юып чыгарыр? Сез кешеләрдә яхшылык күрә башларсыз. Тормышыгыз шулай узып та китәр бит. Сезнең үз балагызны сөясегез килмимени? Зуррак үскәч, Мәдинә тавына алып менеп, җиләкләр, тәмле чишмә сулары белән сыйлыйсыгыз килмимени? Сезгә тиздән кырык яшь тула, башыгызда чәчләр дә калмаган, сезгә кызлар карар дип беләсезме? Чынлап та, тавышыгыз искиткеч, матур җырлыйсыз, ләкин тавышыгызда җылылык юк, кешеләргә, хатын-кызларга мәхәббәтегез сизелми. Сезне бит бу дөньяга хатын-кыз тудырган. Табигатьне, авылыгызны, аның кешеләрен, хатын-кызларны яратыгыз, тормышыгызга мәгънә өстәлер. Менә шул минем даруларым, аңласагыз, кулланырсыз. Әйдәгез, киттек, – дип, Гөлшат, башка ни әйтергә белмичә, кинәт туктап калды. Шулай сөйләвенә үзе дә сокланып куйды. Ул кечкенә чагыннан ук үзенә рәнҗетеп әйтелгән сүзләргә шулай курыкмыйча җавап бирә иде. Бүген дә Хәйдәрнең сүзләре аны бик нык рәнҗетте. Хәйдәр берничә минут, аңа каршы нәрсә әйтергә белмичә, тыныч кына утырып торды, аннары машинасын авылга таба борды.

– Даруыгыз бик әче булып чыкты, моның хәтле язмасагыз да була иде, – диде Хәйдәр шаяртырга тырышып. Ләкин Гөлшат бер сүз дә эндәшмәде, әллә сүзе бетте, әллә башка сөйләшәсе килмәде. Хәйдәр дә башка сүз кузгатмады. Болай каты итеп, аңа күптән бер кешенең дә әйткәне юк иде.

Наилә апаның өенә килеп җиткәч:

– Бик зур рәхмәт, – дип, сумкаларын алып, Гөлшат машинадан төште.

Хәйдәр сүзсез генә Гөлшат өйгә кереп киткәнче аның артыннан карап торды.

Төне буе яңгыр яуды, көзге юеш көннәр килеп җитте. Иртән эшкә барганда да, яңгыр сибәли иде. Ләкин хастаханәгә кергәч, идән буйлап тезелгән табаклар, чиләкләр күренмәде. Гөлшат, аптырап, Фәимә апа бүлмәсенә керде:

– Фәимә апа, мин бер генә көн килмәгән идем, ниләр булды?

Өлкән шәфкать туташы башта сорауны аңламыйча торды. Гөлшат тагын кабатлады:

– Фәимә апа, бер бүлмәне дә су басмаган, ахрысы, ни булды?

– Ә, син түшәм турында сорыйсың икән, аңламыйча торам. Синең сорауларыңны кайчан беренче әйтүдә үк аңлый башлармын инде. Рафаэль белән Мохтар, бригадалары белән килеп, бер көндә түшәмне ямап киттеләр. Аллага шөкер, су үтми хәзер. Ләкин Мохтар: «Кыш чыгарга җитәр, киләсе елга түбәне алыштырырга кирәк булачак, такталары, матчалары бик черегән», – дип кисәтеп китте. Безгә инде кыш чыгарга булса, бәлки киләсе елларга Илдар Азатович ремонт башламасмы? «Киләсе елга ремонт ясарбыз», дип сүз биргән иде түгелме соң?

Фәимә апа бу проблеманың бүгенгә актуаль түгеллеген аңлатырга тырышты:

– Бүгенге көндә башка борчулар бар, Гөлшат Равилевна, соңгы айдан безгә дарулар бирүне киметәләр. Авыруларны нәрсә белән дәваларбыз инде? Кешегә: «Даруны үзегез белән алып килегез», – дип әйтеп булмый бит. Киләсе атнада җыелышка барсаң, Илдар Азатовичтан сора әле. Аның бит сиңа беркайчан да юк дигәне булмады, бәлки, бу мәсьәлә дә чишелер.

– Ярар, Фәимә апа, сорап карармын, – дип, Гөлшат үз бүлмәсенә чыгып китте. Вакытлыча гына булса да, түшәм мәсьәләсенең чишелүенә ул бик сөенде. Рафаэль абыйга шалтыратып, рәхмәт әйтергә кирәк булыр, – дип уйлап, көндәлек эшләренә тотынды.

Инде беренче салкыннар да җирне туңдыра башлады. Бүген туйдыра башлаган көзге яңгырлар җебетеп бетергән җир пычрагын ерып кайтырга туры килмәде. Гөлшат өйгә кергәндә, Наилә апа клубка барырга җыенып йөри иде:

– Сине дә чакырдылар бит, ник бармыйсың?

– Мин анда барыбер беркемне дә белмим, аннары кичтән тагын «патша сарае»на барып кайтасым бар. Бер авыру бабайның хәле бик яхшыдан түгел, районга барырга теләмәде, ничек кенә үгетләп карамадым. «Үлсәм, монда үләм», – ди.

– Ярар алайса, үзең беләсеңдер. Безнең председательгә көн саен 60 яшь тулмый. Мәҗлес бик бай булырга охшый. Ниндидер бер спонсор ярдәм итә дип сөйлиләр. Кичә көн буе клубны бушаттылар, өстәлләр әзерләделәр. Кешеләр сөйләве дөрес булса, артистлар да чакыртканнар, ди. Бик күңелле булырга охшаган. Бармасаң, соңыннан үкенерлек булмасын, уйлап кара, Гөлшат.

– Юк инде, рәхмәт, үзегез генә барыгыз.

– Матри, кызый, үкенерсең, – дип, Наилә апа, матур чәчәкле яулыгын бәйләп, ак шәлен җилкәләренә салып чыгып китте.

Гөлшат ялгызы гына калгач, үз уйларына чумды: авыл, чыннан да, аны бик якын итте. Кешеләре дә, Илдар Азатович әйтмешли, бик яхшы. Табигате дә искиткеч.

Наилә апа өйгә кайтканда, төнге уникеләр тирәсе иде.

– Мәҗлесләр ничек узды? – дип сорады Гөлшат йокы аралаш.

– Йокла, йокла, иртәгә сөйләрмен, мәҗлес бик күңелле узды, тик ахыры бик кызык булып чыкты.

Соңгы сүзләрне Гөлшат ачык ишетмәде.

Төнге өчләр тирәсендә өй янына машина килеп туктады һәм кемдер тәрәзәгә шакыды. Гөлшат шул тавышка уянып китте, йөрәге нәрсәдер сизенгәндәй, бик еш тибә башлады. Кинәт йокысы бөтенләй качты. Гөлшат тиз генә халатын киеп, ишеккә барды. Ишек төбендә колхоз рәисе малае Илсур басып тора иде:

– Гөлшат апа, гафу итегез, кинәт әтинең хәле начарланды, сез тиз генә җыенып, аны карарга бара алмассыз микән?

– Нишләп хастаханәгә алып бармыйсыз?

– Без аны «патша сарае»на алып килдек инде, районга барырга теләмәде.

– Ярар, хәзер чыгармын, капка төбендә көтеп тор. Син машина белән дер бит?

– Гөлшат, кем анда? – дип сорады Наилә апа.

– Минем арттан килделәр, «Патша сарае»на бер авыруны китергәннәр, мин хәзер барып, аны карап кайтам, борчылма, мин үзем капканы ябып чыгармын, – диде Гөлшат һәм тиз генә киенеп чыгып китте.

Гөлшат хастаханәгә килеп кергәндә, Зөфәр Хәйдәрович үзе генә бер палатада ята иде.

– Ничек хәлләрегез, мәҗлесләр искиткеч яхшы узган, диделәр?

Ләкин җавап булмады. Карт абзыйның күзләре кып-кызыл, битеннән язгы шарлавыктай күз яшьләре ага иде.

– Зөфәр Хәйдәрович, кай җирегез авырта, нәрсә борчый сезне?

Әтисе урынына арттан кергән Илсур җавап бирергә тырышты:

– Әти мәҗлестән кайткач, бик озак кына ишек төбендә тәмәке тартып утырды, без йокларга ятарга йөри идек. Мин дә аның артыннан урамга чыксам, ул ишек төбендә аңсыз ята. Без аны тиз генә монда алып килдек.

– Син, Илсур, бар, коридорда утырып тор, башта әтиеңне үзем карыйм, аннары керерсең, – дип, Гөлшат Илсурны бүлмәдән чыгарып, ишекне катырак ябып куйды.

Гөлшат Зөфәр Хәйдәровичны башыннан аягына кадәр тикшереп чыкты. Кан басымы аз гына югарырак һәм сул аяк белән кулының көче сүлпәнәйгән иде:

– Зөфәр Хәйдәрович, сезне ни борчый, кай җирегез авырта? Сез сөйләшә аласызмы? Миңа бит болай диагноз куярга бик авыр. Мин бит ветеринар түгел, тәҗрибәм дә бик ташып тормый. Әйдәгез, сезне районга алып барыйк. Андагы табиблар миннән көчлерәк, – дип, урыныннан тормакчы иде дә, ләкин абзый аны кулыннан тотты:

– Мине беркая да алып бармагыз, дәваласагыз, монда гына, зинһар өчен, мин сезгә ышанам. Аннары, бик борчыган җирем дә юк төсле, кинәт нишләптер аңымны югалтканмын.

– Хәзер нәрсә борчый? – диде Гөлшат, абзыйның сөйләшә башлавына шатланып.

– Эх, кызым, җаным яна минем. Мәдинә тавының чишмә суларын эчеп тә, ул ялкынны сүндереп булмастыр.

– Зөфәр Хәйдәрович, ни булды, бәлки, артыграк эчкәнсездер, бәлки мәҗлестә берәр бозылган ризык эләккәндер?

– Юк, кызым. Мәҗлес искитәрлек шәп булды. Өстәлдәге ризыкларның бөтенесе яхшыдан-яхшы иде. Гамир бик тырышты.

– Гамир? Кем соң ул, нинди граф Монте-Кристо?

– Чынлап та, ул – граф Монте-Кристо, исеме генә – Гамир Альбертович.

– Кем соң ул?

– Кызганыч, ул минем улым булып чыкты.

– Сез тагын саташасыз, ахрысы, нәрсә сөйләгәнегезне аңлап бетерә алмыйсыз.

– Саташсам яхшы булыр иде, ул – минем улым. Мин аны элек бер тапкыр күрмәгән булсам да, ул минеке.

– Мин бернәрсә дә аңламыйм, яхшырак аңлатыгыз әле. – Гөлшат ишеккә карап куйды. Ишек ябылган иде.

– Тыңла, кызым, табибка һәм прокурорга без дөресен сөйләргә тиеш: унынчы сыйныфта укыганда, безнең мәктәпкә бер кыз килде. Аларның гаиләсе безнең якларга каяндыр күченеп кайткан иде. Эльза – бик чибәр кыз. Ул чибәр генә түгел, матур җырлый, бии иде. Безнең сыйныфтагы бөтен малайлар да гашыйк булдылар аңа. Ул үзен бик иркен тота иде. Эльзаның кап-кара күзләрен, бөдрә чәчләрен күрсәң, бөтенләй башыңны югалтасың. Бәйрәмнәрдә ул гел үзәктә иде, рәхәтләнеп җырлый, бии, шаркылдап көлә. Малайлар белән шәраб та эчкәли иде, ләкин беркайчан да аның исергәнен күргәнем булмады. Баш әйләнде. Без очраша башладык. Авылда иң беренче велосипед миндә булды, аннары – матай. Матайда ул мине арттан кочаклап утырганда, минем башым күккә тия иде. Минем аңа хәтле йөргән кызым да онытылды. Дусларым минем башым әйләнгәнен күреп: «Тукта, син ни эшлисең? Ул сиңа тиң түгел, ул башка егетләр белән дә очраша, эчәргә дә ярата, тәмәке дә тарткалый. Әти-әнисе дә әллә кайлардан килгәннәр» – диделәр. Мин ул сүзләрне ишетмәдем, көнләшәләр, дип уйладым. Шулай мәктәпне тәмамлагач, бер көнне без печән эскертендә кундык. Мин аның беренче ир-аты булып чыктым.

Әнием, ахрысы, сизеп, беркөнне минем белән утырып сөйләште. Ул кыз бер дә аларга ошамый иде: «Гаиләсе дә әллә кайлардан, безнең кеше түгел», – диде. Җәйге көннәр тиз үтеп китте, көзгә мине армиягә алдылар. Мин диңгез флотына хезмәт итәргә эләктем, сәламәтлегем бик яхшы иде. Дүрт елдан әйләнеп кайтканда, Эльзалар гаиләсе яңадан каядыр китеп барган иде. Кешеләр: «Ул, имеш, корсаклы, кемнәндер бала тапкан», – дип тә сөйләде. Кеше әллә ниләр сөйләргә мөмкин. Армиядә хезмәт иткәндә, мин берничә тапкыр аңа хат та язып карадым, ләкин җавап килмәде. Әти-әнидән сорарга оялдым. Шулай итеп, минем Эльза белән аралар өзелде. Армиядән кайткач, институтка укырга кердем, авылыма агроном булып кайттым, беренче яратып йөргән кызыма өйләндем. Бөтенесе яхшы гына бара иде. 60 яшемне дә тыныч кына хатыным, балаларым белән уздырмакчы идем. Ләкин узган айны башлык үзенә чакыртты да мине Гамир Альбертович белән таныштырды. Имеш, ул бик бай, безнең колхоз җирләрендә зур терлекчелек комплексы төземәкче, ит комбинаты ачмакчы була. Районга яңа инвестицияләр, акча кайтачак, кешеләргә эш урыннары булачак дип ышандырды. Мин бу хәбәрләргә бик шатландым, ләкин ризалыгымны бирмәдем. Нишләптер мондый җиңел кергән акчалардан куркам. Гамир Альбертович, юбилеем турында ишеткәч, миңа бөтенләй каты ябышты. «Юбилееңны үзем уздырам, үзем оештырам», – диде. Мин башта каршы

килгән идем дә аннары ризалаштым. Артистлар да алып киләм дигәч, авылдашларыма зур бәйрәм ясамакчы булдым. Чынлап та, мәҗлес бик матур узды, өстәлләрдә нинди генә ризыклар юк иде. Казаннан килгән артистлар чыгыш ясады. Клубка бөтен авылдашларым килде, мондый зур бәйрәм бездә беркайчан да булганы юк иде, булмас та инде. Мәҗлес тәмамланыр алдыннан мин Гамир Альбертовичка үземнең рәхмәтемне белдердем, авылдашларыма киләчәк планнар турында сөйләдем. Аннары Гамир Альбертовичка сүз бирдем. Ул да матур планнар турында сөйләде һәм азактан: «Мин моның барысын да мине тудырган әтием өчен эшлим. Мин бит Зөфәр Хәйдәрович белән Эльза Магомедовнаның улы», – дип куймасынмы? Яшьтәшләрем барысын да тиз аңлап алды. Ә миңа кояшлы көнне башыма яшен суккандай булды, – дип, Зөфәр Хәйдәрович тынып калды.

Гөлшат та сискәнеп куйды. Шулвакыт бүлмәгә Фәимә апа килеп керде:

– Нинди дарулар кирәк? Система куярга кирәк булса, хәзер үзем куям.

– Иртәнгә хәтле реланиум гына ясап торыйк, иртә белән уйлап карарбыз, сәгать тә биш тула, ахрысы, инде. Ә сез, Зөфәр Хәйдәрович, тынычланыгыз, Фәимә апа хәзер сезгә дарулар бирер, йокларга тырышыгыз, – дип, табиб акрын гына торып, бүлмәдән чыгып китте.

Коридорда урындыкта Илсур йоклап утыра иде. Гөлшат аны уятып, өенә кайтарып җиберде:

– Әтиеңә уколлар ясадык, ул хәзер йоклый, мин монда гына калам, кайтып йөрмим. Сәгать уннарга килерсең, шунда уйларбыз ни эшләргә икәнен.

– Рәхмәт, Гөлшат апа, мин иртәгә иртә белән килеп җитәрмен.

– Иртәгәгә калма инде, бүген, тиздән кояш чыга.

– Шулай шул. Сау булыгыз, – дип, Илсур чыгып китте.

Гөлшат табиб бүлмәсенә юнәлде. «Менә, Гөлшат Равилевна, яшьтәшләрең дә, әллә зурлап, әллә картайганга, сиңа апа, диләр», – дип уйлап, бүлмәдәге көзгегә карады.

Артыннан Фәимә апа керде:

– Зөфәр Хәйдәрович йоклап китте, әйдә, Гөлшат Равилевна, чәй эчеп алыйк.

– Мин бик рәхәтләнеп эчәр идем, – диде Гөлшат, елмаеп.

Гөлшат өйгә кайтып йөрмәде. Кайтуның мәгънәсе дә юк иде. Әз генә кыяфәтен рәткә керткәч, иртәнге эшләренә тотынды. Берничә тапкыр Зөфәр Хәйдәрович янына да кереп чыкты. Ул ыңгыраша-ыңгыраша йоклый иде. Табиб авыруны уятмады, чөнки йокы – иң яхшы дару.

Сәгать тугызлар тирәсендә шәфкать туташы керде:

– Сезнең яныгызга бер абзый кермәкче була, кертимме?

– Әйдә, керсен, эшем бетте бугай, – дип, Гөлшат көзгегә карап алды.

Бүлмәгә урта яшьләрдәге озын буйлы ир-ат килеп керде. Аның йөзе бик таныш төсле иде. Чыннан да, кап-кара күзләр белән сирәгәеп килгән бөдрә чәчләрне алыштырсаң, аның алдында яшь Зөфәр Хәйдәрович басып торган кебек иде.

– Исәнмесез, Гамир Альбертович, узыгыз, утырыгыз.

Ир-ат бер мизгелгә югалып калды:

– Безнең элек очрашканыбыз булмады, сез мине кайдан беләсез?

– Мин сезнең әтиегезне беләм, – дип, коры гына җавап бирде Гөлшат.

– Миңа аның янына керергә ярыймы?

– Мин башта үзем кереп чыгарга тиеш, әгәр хәле яхшы булса, рөхсәт итәрмен, – диде табиб.

Зөфәр Хәйдәрович яткан палатада тып-тыныч иде. Авыруның битендәге җыерчыклары кимегән кебек. Бу зур гәүдәнең җаны юк иде. Гөлшат тиз генә кулын абзыйның муенына куйды – йөрәк тибеше юк, гәүдәсе суынып килә. Гөлшат Зөфәр Хәйдәровичның күзен ачып карады, ләкин реанимация ясауда мәгънә юк иде. Гөлшат чыгарга борылды. Аның артында Гамир Альбертович басып тора иде. Ул берсүзсез барысын да аңлады.

– Сез теләгән максатыгызга ирештегез, – дип, Гөлшат бүлмәдән чыгып китмәкче иде, ләкин Гамир, аның кулыннан тотып, урындыкка утыртты, үзе гафу үтенгәндәй, әтисе яткан карават янына тезләнде дә сөйли башлады:

– Эльза мине бала тудыру йортында калдырган. Мин җиде яшькә кадәр әни-әти дип әйтергә тилмереп үскән бала. Бала чаклар истә калмый, диләр. Мин яхшы хәтерлим: менә хәзер минем артымнан әнием, әтием килер дә алып китәрләр дип, без көннәр буе тәрәзә аша урамга карап утыра идек. Һәр Яңа ел бәйрәме алдыннан көн саен мин Кыш бабайдан: «Әнием, әтием килеп алсын», – дип сорадым. Ләкин ничә кыш үтте, ә мин һаман балалар йортында калдым. Бәхетемә мине балалар йортыннан уллыкка алдылар. Сигез яшемдә минем үги әтием белән үги әнием булды. Мин аларга бик рәхмәтле, үстерделәр, укыттылар, институтка керттеләр. Ләкин бу аяусыз язмыш мине тагын сынады, мин институтка кергән елны алар машинада бәрелеп үлделәр, мин тагын ятим калдым. Шул еллардамы, бәлки, тагын да иртәрәктер, мин чын әти-әниемне табарга ант иттем. Аларның күзләренә карап, ник мине балалар йортында калдырдыгыз? – дип сорыйсым килде. Аннары аңладым: мин бу тормышта мескен булырга тиеш түгел. Аларны тапканчы, мин зур биеклекләргә күтәрелергә тиеш. Шуңа күрә мин тырыша-тырмаша, тәрсәкләрем белән этенә-этенә зур үрләр яуладым, баедым. Кайсы авылдан икәнлегемне белдем. Бу авылны башта җир белән тигезләмәкче булдым, аннары минем ятим калуыма мондагы кешеләрнең гаепләре юк икәнлеген аңладым. Мине бит чит кешеләр тәрбияләделәр, үстерделәр. Мин бит чит кешеләргә «әти», «әни» дидем. Мин ятим үскәнгә бары тик әти белән әни генә гаепле. Язмыш мине ярдәменнән ташламады. Минем белән эш башлаган тугыз малай җир куенында яталар, мин һаман исән, дәрәҗәгә ирештем, баедым. Мин район башлыклары янына кергәндә, алар сикереп торып, кул бирәләр. Ләкин балачакта алган яралар һаман тынгылык бирми. Мин әти-әниемне эзләдем. Әнинең каберен генә таптым, ул кулдан-кулга йөреп эчеп үлгән. Язмыш аңа үз җәзасын биргән. Әтием, киресенчә, дәрәҗәле кеше, гаиләсе бар, бәхетле, авылдашлары аны ярата, хөрмәт итә. Ә ул бит баласын ятим иткән кеше, минем турыда бер генә минут та уйлаган кеше түгел. Язмыш миңа тагын булышты. Мин сезнең район башлыгы белән якынлаштым, зур планнарым турында сөйләдем. Калганнарын оештыру, акча булгач, авыр түгел иде. Мәҗлес буе бөтен кешеләр шатландылар, көлештеләр, минем әтине зурладылар. Мин генә, бәйрәм бетүен көтеп, һаман минутлар санадым. Кешеләр алдында әтинең

күзенә карарга иде дип, мин гомер буе хыялланып йөрдем. Менә шул мизгел килеп җитте. Мин аның күзенә карадым. Ләкин бала чагымда ясалган яра барыбер әрнеп тора. Мин бу тормышта нәрсәнедер югалттым төсле, бәлки, эзләп-эзләп тә вакытында күрмичә, узып киткәнмендер.

Гамир берничә минутка тынып калды. Аннары әтисенең үле гәүдәсенә карап, гафу үтенде:

– Әти, мин сине гафу иттем, син дә мине гафу ит, – диде дә бүлмәдән чыгып китте.

Гамир артыннан палатага Фәимә апа керде:

– Бу дошман калдыгы монда ни эшләп йөри?

– Әтисе белән хушлашты, дөресен әйткәндә, аның гәүдәсе белән. Зөфәр Хәйдәровичның җаны монда булса, ул аны, бәлки, ишеткәндер.

– Гөлшат Равилевна, саташа башладыңмы әллә? Нинди гәүдә, нинди җан? – диде өлкән шәфкать туташы, берни дә аңламыйча.

– Зөфәр Хәйдәрович үлде, туганнарына хәбәр итәрсез, минем башка авыруларны карыйсым бар, – диде дә Гөлшат, ашыкмыйча гына, палатадан чыкты.

...Төне буе буран уйнады. Авыл калын кар юрганына капланды. Гөлшат, иртүк торып, кар көрәргә тотынды, чөнки урамга чыгу түгел, хәтта өй ишеген дә көчкә ача алды. Наилә апа да ярдәмгә чыкмакчы булды, ләкин Гөлшат аны кире куып кертте:

– Авырткан аякларың белән син кая чыгасың инде? Мин карны үзем көрим. Иртәнге гимнастика булыр, – дип шаяртырга тырышты.

– Үзеңә генә авыр була бит, эшкә дә барасың бар, – дип сыкранды Наилә апа.

– Тиз генә эшкә барып кайтам да карны чистартып бетерермен, урамга кадәр сукмакны ачтым. Буран да бик тынычланып бетмәгән әле, – дип, Гөлшат өйгә керде.

– Әйдә, самавырым кайнады, кулларыңны юып, өстәл янына утыр, син кар көрәгән арада мин сиңа коймаклар пешердем.

Наилә апаның коймаклары, һәрвакыттагыча, бик тәмле, ашап туялмассың.

Тиз генә чәйләр эчеп алгач, Наилә апа:

– Бар, эшеңә чап, чынаякларны үзем юармын, минем башка эшем юк, – диде.

– Бик зур рәхмәт, бүген озак булмам, юлларны кар каплаган, эш күп булмаса, караңгы төшкәнче кайтып та җитәрмен, – дип, Гөлшат киенеп, хастаханәгә китте.

(Ахыры киләсе санда).

ӘДӘБИ ХӘРӘКӘТ ҮЗӘГЕНДӘ

Мин «Казан утлары»нда баш редактор булып 1982 елның 11 октябрендә форс-мажор шартларда эшли башладым. Журналның 11нче, ягъни элеккеге баш редакторы Зәки ага Нури җитәкчелегендә тупланган ноябрь ае саны басылып ята, 12 нче санның да эше беткән: «Обллит» аша үтеп, типографиягә төшеп киткән. Ул елларда текстлар линотипларда эретелгән кургаштан коела иде. Аны җыю, хаталарны төзәтү, сүзләрне, җөмләләрне алыштыру, берничә кат корректура уку күп вакыт ала. Шуңа күрә журнал типографиягә 3 айга алданрак тапшырыла иде. Без 1983 елның 1нче санына тотынган идек инде. Мин «Казан утлары»ның тышкы кыяфәтен дә, архитектоникасын да яңартырга булдым: рәссам Тавил Хаҗиәхмәтов белән тышлыгын үзгәрттек, журналның рубрикаларын алыштырдык, авторлар белән эшләү системасын билгеләдек...

1989 ел, язучылар съезды башланыр алдыннан.

В.ЗОТОВ фотосы.

Көтмәгәндә барлык газета-журнал редакцияләренә КПСС Үзәк Комитеты Генераль секретаре Л.И.Брежневның 12 ноябрьдә үлүе, партия Үзәк Комитеты Пленумы булуы турында хәбәр килеп төште. Китте ыгы-зыгы: республиканың төп газетасы «Социалистик Татарстан» һәм «Татарстан коммунисты» журналы тәрҗемәчеләре үзәктән килгән материалларны ашыга-ашыга татарчага аударалар, башкаларыбыз борчыла-борчыла, Брежневның, Андроповның портретларын эзли, «Обллит» аша үткән татар телендәге материалларны көтә...

Мин аптырап калдым: ноябрь ае санына инде өлгермәдек – басылып ята, декабрь саны җыелган, басылырга әзер, киләсе елның 1нче санына калдырсак, материаллар актуальлеген югалта. Әдәби журналга бу материалларны бирми калдырырга да ярыйдыр дигән өмет белән мин өлкә комитетының мәдәният бүлегенә шалтыраттым һәм «Кайсы төшегез белән уйлыйсыз?..» дигән сорау ишеттем. Барысы да аңлашылды – декабрь санын яңадан сүтеп-җыярга туры киләчәк. Ә ул сан гади генә сан түгел, чөнки СССР төзелүнең 60 еллыгына багышланган. Матәм материалларын кертер өчен ниндидер язмаларны алып ташларга кирәк, чөнки журналның бит саннарын да киметергә ярамый, хәрефләрне дә кечерәйтеп булмый – барлык 192 битне яңадан линотип аша үткәрергә кирәк... Журнал расланган көнгә чыгып җитәргә дә тиеш... Журнал вакытында чыгып җитте: беренче битләрендә үк Леонид Ильич Брежневның сул күкрәгендә 5 Алтын Йолдыз медале, СССР Югары Советы депутаты билгесе, уң күкрәгендә Ленин премиясе лауреаты медале таккан сурәте кара рам эчендә басылып чыкты... Кыскасы, әнә шундый шартларда миңа «баш редакторлык чирканчыгы» алырга туры килде. Әлбәттә, миңа Зәки ага Нури туплаган коллектив булышты: баш редактор урынбасары Ринат Мөхәммәдиев, җаваплы секретарь Роберт Миңнуллин, бигрәк тә техник редактор Роза ханым Сөләйманова, корректорлар Фәүзия Бәйрәмова (ул вакытта Кадыйрова иде) һәм Гөлшат Салихҗанова... Зур-зур материалларны линотипта җыйдырулар, сәяси хата җибәрүдән курка-курка, аларны ничәмә кат укулар,

«Обллит» (цензура) аша үткәрүләр, журнал битләренә салулар – ул заман типография техникасын белгән кешеләр аңлыйдыр – шактый матавык эш.

Форс-мажор хәлләр алда да була торды. Мин эшләгән елларда без Хисам Камаловның Бөек Ватан сугышына багышланган ике романын чыгардык: «Безне өйдә көтәләр» һәм «Үлгәннән соң яздым». Кырыс реализм ысулы белән язылган «Безне өйдә көтәләр» романы чыгасы сан әзер, аны «Обллит»ка төшереп җибәрдек һәм алдагы саннарга керештек. Мине «Обллит» чакырып алды һәм романны журналдан төшереп калдырырга кушты – әсәрнең персонажлары штраф батальоны сугышчылары икән, ә алар турында совет матбугатында язарга ярамый. Монда бәхәскә урын юк – закон барыбыздан да өстен. Журнал күләменең өчтән берен алып торган роман урынына бер-ике көн эчендә нәрсә куярга? Мин тиз генә җыелыш җыйдым – нишлибез? Әлбәттә, әзер берничә повесть, хикәяләр бар. Ләкин сугышта бер аягын калдырып кайткан авторга биргән вәгъдә дә бар! Редакциянең принцибы, абруе да бар. Мин романны яңадан укып чыктым һәм аны «коткарып» була дигән фикергә килдем, үземчә редакцияләп тә чыктым – Хисам Камал белән генә килештерәсе калды. Хисам ага бу хәбәрне авыр кабул итте. Өенә бардым. Озак утырдык... Төзәттек: бераз кыскарттык, сүзләрне, җөмләләрне алыштырдык... Персонажларның биографияләре бераз үзгәрде. Редакция, бигрәк тә корректорлар, җиң сызганып эшләделәр... Линотипистлар да безнең хәлгә керде. «Обллит»ка яңа корректура бирдек. Журнал вакытында диярлек укучысына барып җитте. Китап булып басылгач, 1986 елны бу роман Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

Көннәрнең берендә редакциягә тарихи романнар авторы Нурихан ага Фәттах килде. Бу юлы ул «Фест дисбесе серләре» дигән хезмәтен алып килгән. Борынгы Фест шәһәрендә табылган серле терракота диск турында минем «Наука и жизнь» журналыннан укыганым бар иде. Нурихан ага ул дискның фотосурәтен папкасыннан алып, аның тарихын, андагы язу бүгенге көндә дә укылмаган булуын, дөнья галимнәре бу мәсьәләдә ялгыш юлдан барулары турында мавыктыргыч итеп сөйләде. Аннары бу серле дисктагы язуны татар теле, төрки телләр нигезендә укыганлыгын әйтте. Дөресен әйтим – «диск»ны «дисбе» дип тәрҗемә итүе үк минем күңелемә шик салды, ләкин Нурихан агага да ышанасы килде. Әгәр дә башка халыкның бер кешесе шундыйрак «ачыш» ясаса, шикләнүләрне бер якка алып ташлап, һичшиксез, авторның приоритетын, беренчелеген ничек тә булса беркетергә тырышырлар иде: әгәр дә ачыш расланса – шул халыкка дәрәҗә, расланмаса – халык берни дә югалтмый. Шундый уйлар белән мин «Фест дисбесе серләре»н алып калдым һәм рәхәтләнеп укып чыктым. Нурихан аганың эзләнү логикасы, чынлап та, кызыклы, үзенә күрә бер системалы иде. Редакция хезмәткәрләре, кайбер редколлегия әгъзалары белән дә сөйләшеп алдым. Әсәрне журналда күрергә теләүчеләр дә, журналыбыз фәнни басма түгел, аны Мәскәүнең берәр фәнни яки фәнни-популяр басмасына җибәрсен, диючеләр дә булды. Ә минем исә, инде әйтеп киткәнемчә, әсәрне «Казан утлары»нда күрәсем килде – фәнни ачыш булса, бер татар кешесен сенсацион киңлекләргә чыгарачакбыз, журналыбызның, редакция хезмәткәрләренең абруе артачак, ачыш булмаса, әдәбият сөючеләр танылган авторның матур язылган, укыла торган гипотезасы белән танышачаклар. Начармыни?! Ләкин баш редактор буларак, мин авторны да, журналны да, үземне дә кайбер нәрсәләрдән гарантияләргә тиеш идем. Шул ният белән Казан университетының татар теле кафедрасы мөдире профессор Диләрә Гарифовна Тумашевага шалтыраттым һәм бу әсәрне кафедра утырышында карауны үтендем. Профессор бу эшкә алынырга теләми иде. Мин аңа икенче тапкыр әзерләнебрәк шалтыраттым: Нурихан Фәттах лингвистикада «иҗек методы» дигән яңа метод уйлап тапкан, шул метод аңа Фест дискын татар теле нигезендә укырга юл ачкан, дидем. Проблеманы татар теле белән бәйләү күренекле татар теле белгеченә тәэсир итте булса кирәк, ул ризалашты. Бер-ике атна үткәч, профессор үзе миңа шалтыратты һәм Нурихан Фәттах эзләнүләрендә фәнни нигез юклыгын, дисктагы текстның андый дешифровкасы белән килешеп булмавы хакында язып бирә алабыз дип әйтте. Мин Диләрә Гарифовнадан «әсәр мавыктыргыч, укыла, журнал укучыларына гипотеза буларак

тәкъдим ителә ала» дигәнрәк сүзләр дә өстәвен үтендем. Ул шулай итте дә. Аның хаты «Казан утлары» архивында булырга тиеш, копиясе минем архивта да саклана. Кыскасы, «Фест дисбесенең серләре» журналда басылып чыкты, ләкин сенсация булмый калды.

Баш редактор булып эшләгән елларда миңа кайбер әсәрләр өчен «кыен ашарга» да туры килде. Күп нәрсәләр вәгъдә иткән «перестройка» чоры башланды. Һәр дәвернең башы күпмедер дәрәҗәдә хаос була – идеологик бушлык барлыкка килә, ә юнәлешләр ачыкланмаган. «Ярый» белән «Ярамый» арасында да билгесезлек, ә билгесезлекне ул якка да, бу якка борып була. Әкрен генә «Идегәй» дастаны турында да сөйләшүләр ишетелә башлады. Мин ул дастанны, дөресрәге – «Совет әдәбияты» журналының 1940 нчы елгы 11-12 нче саннарын – ничәнчедер класста укыганда, Казмада (Буа районындагы әтием туган авыл) төп йорт чормасында иске чемоданда тапкан идем һәм кайбер өлешләрен күчереп тә алдым, ятладым. Журналны яшь укытучылар әтием белән әнием яздырып алганнар икән. Әтием сугышта йөргәндә, ул елларда әнием үзенең туган авылында Ульяновск өлкәсендә эшләгәндә, журналның бу саннарын, ВКПб Үзәк Комитетының 1944 елның августында чыккан карарыннан куркып, кем яшерде икән? Бәлки, Харис дәү әтиемдер, бәлки, сугыштан кайткач, әтием үзедер. Кыскасы, форсаттан файдаланып, «Идегәй»не яңадан татар укучысына кайтарырга булдым. Бу идеяне Ринат Мөхәммәдиев тә, Мөдәррис Вәлиев тә, башка хезмәткәрләр дә хупладылар. Керереңнән әүвәл чыгарыңны уйла, ди халык. Феодаллар, ханнар дастаны дигән мөһер сугылган, рәсми акланмаган әсәрне басып чыгару – хәтәр эш, аны җиренә җиткереп әзерләргә кирәк. Шул көннәрдә мин ниндидер эш белән Бакый ага Урманчеларга бардым. Сүз ара сүз чыгып, «Идегәй» турында да әйттем. Бакый абзый хуплады, ә аның хатыны, күренекле фольклорчы Флора Әхмәтова ханым уйга калды, дастанның катлаулы язмышы хакында сөйләп алды. Ул «Совет әдәбияты»нда Нәкый Исәнбәт бастырган вариантны түгел, ә репрессияләр корбаны булган Нигъмәт Хәкимнекен, ягъни төп вариантны чыгаруны яклады, чөнки 1940 ел басмасында Нәкый аганың компиляцияләре, үзе язып өстәгән кисәкләр дә бар икән. Мин Флора ханым белән ризалаштым, ә ул журналга Г.Ибраһимов исемендәге институт вариантын әзерләп бирергә булды. Без шулай иттек тә. Ләкин Нәкый ага алдында итагатьлек саклап, аның хезмәтен хөрмәт итеп, мин аңа журналның ниятен белгертеп, кереш мәкалә язуын һәм фатиха бирүен үтенеп хат яздым, берничә мәртәбә өенә телефоннан шалтыраттым... Хатка да җавап алмадык, өй телефоны да галимнең хатыны Нәҗибәк ханым тавышы белән: «Нәкый ага әлегә сөйләшә алмый», – диде.

Ниһаять, «Идегәй» басылып чыкты. Галимнәрдән, язучылардан, журнал укучыларыннан рәхмәт сүзләре ишеттек. Бу эшебез – «Казан утлары»ның кыюлыгы, редакциябезнең әхлакый, эстетик, идеологик позициясе иде. 1988 елда Татарстан китап нәшрияты директоры Ринат Мөхәммәдиев тырышлыгы, Илбарис Надиров кереш сүзе белән татар халкының бөек дастаны китап булып басылып чыкты – Г.Ибраһимов исемендәге фәнни институт әзерләгән җыелма текст нигезендә Нигъмәт Хәким варианты.

«Кыен ашаткан» әсәрләрнең тагын берсе – Гаяз Исхакый хикәясе булды. Эмиграциядә үлгән әдип әле беркем тарафыннан да акланмаган, аның әсәрләре әдәби хәрәкәткә әлегә кайтмаган. Ләкин пышылдап сөйләшүләр әкрен генә тавыш ала бара, бигрәк тә яшь һәм урта буын язучылары һәм галимнәре арасында. Ләкин республика партия җитәкчеләреннән берсенең «только через мой труп» дигән сүзләре дә ишетелгәли, сискәндерә – Дәрдемәнднең «Дилең өчен телең булсын тозаклы, Йөз аклыгың өчен – авызың йозаклы» дигән шигыре дә искә төшеп куя. Ләкин Гаяз Исхакыйны халыкка кайтаруда «Казан утлары» беренче булып юл яра ала, дигән татлы фикер дә тынгы бирми. Уйлаштык, киңәштек һәм, татлы фикергә кушылып, Гаяз Исхакыйның сәясәттән бик ерак торган «Башкорт бәхете» дигән лирик хикәясен бирергә булдык. Хикәя журналда басылып чыкты – күк күкрәмәде, яшен яшьнәмәде, таш яумады. Атна-ун көн узгач, мине партия өлкә комитетының мәдәният бүлегенә чакырдылар. Сәяси сукырлыкта

гаепләрләр микән дип, Исхакыйның революциягә хәтле үк Тукай, Ибраһимовлар белән янәшә торганлыгын сөйләргә, бәхәсләшергә әзерләнеп бардым мин анда. Ләкин проблема авторда түгел, әсәрдә, дөресрәге – хикәянең исемендә – булып чыкты. Башкортстан обкомында эшләүче бер ханымнан шикаять килгән икән. Янәсе, «Казан утлары» тугандаш башкорт халкын хурлаган. «Нәрсә, Исхакыйның башка хикәясе юк идеме?.. Ярар, аларга журналның баш редакторы белән кырыс сөйләшү үткәрдек дип, җавап язарбыз...» диде бүлек мөдире. Бу сөйләшүдән мин бер нәрсәне ачык аңладым: республика җитәкчелеге аңында кардиналь үзгәрешләр бара...

Әдәби хәрәкәт (процесс) язучының эш өстәле һәм әдәби басмалар, нәшриятлар берләшкәндә генә барлыкка килә – укучысына барып ирешмәгән әсәр, язылмаган әсәр кебек үк. Әсәрнең актуальлеген, аның әхлакый, эстетик, иҗтимагый кыйммәтен бәяләү дә әдәби процессның нигезендә ята. Ул елларда әле «Мәдәни җомга» юк, ләкин башка журналлар, хәтта партия газеталары да, әдәбият битләре аша, татар әдәби процессында хәл кадәри катнаштылар. Әмма бу эшнең үзәгендә «Казан утлары» булды. Без журналның һәр өч санын редколлегия утырышында жанрлап тикшерә идек. Редколлегия әгъзалары – күренекле шагыйрьләр, прозаиклар, тәнкыйтьчеләр – әзерләнеп киләләр, шул саннарда әсәрләре чыккан авторлар да катнаша. Мондый утырышларны редакция дә, авторлар да көтеп алалар, чөнки әсәрләре турында җәһәт тәнкыйть ишетәләр иде. Тәнкыйди фикер үсеше, ягъни әдәби тәнкыйть, иң беренче чиратта, язучыларның әдәби әсәр турында сөйләшүләреннән башлана. Әдәби хәрәкәт шунсыз була алмый.

Әдәби хәрәкәт белән идарә итеп буламы? Әлбәттә, була. Журнал, нәшрият, радио-телевидение үзенә кирәкле әсәрне күпләр арасыннан сайлап ала, үтә дә мөһимнәренә заказлар бирә, конкурслар игълан итә, кайбер язучыларны махсус иҗади командировкаларга җибәрә, үз әдәбиятында булмаган жанрларны башка әдәбиятлардан ала, тәрҗемә итә. Бу әдәби хәрәкәткә юнәлеш бирү яки аның белән идарә итү түгелмени?! Әдәби журналда һәр санның нигезендә күләмле, мавыктыргыч, укучыны җәлеп итә торган проза әсәре булырга тиеш. Үзагым белән редакциягә килеп кергән әсәрләр арасында андыйлар сирәк очрый. Шуңа күрә редакция алга карап эш итәргә тиеш. Без ул елларда һәр күренекле прозаикның нинди әсәр язганын белеп, барлап тора идек – шулай ышанычлырак. Кайбер авторларыбызны хәтта срок куеп ашыктырдык та. «Казан утлары» – үзагым журналы түгел, ә әдәби хәрәкәтне оештыру үзәге иде.

Без Габдулла Тукайны дөньякүләм билгеле шагыйрь дип әйтергә яратабыз. Тукай татар халкының иң бөек шагыйре, бәлки, иң даһи улыдыр да! Ләкин аны кайбер төрки халыклар гына яхшы белә. Тукайны, аның иҗатын киңрәк пропагандалау максаты белән «Казан утлары» шагыйрьнең 100 еллыгына әзерлекне 1984 елда ук башлады. Без союздаш, автономияле республикалар әдәби журналларына, Язучылар берлекләренә Тукайның русча әсәрләрен, йә булмаса юлга-юл тәрҗемәләрен (подстрочникларын) юлладык, фикерләрен журналга язып җибәрүләрен үтендек. Материаллар килде. Аларны өч ел буена журналның һәр санында биреп бардык – бөек халык, бөек әдәбият үзенең бөек шәхесләрен, бөек әсәрләрен пропагандаларга тиеш!

Татар әдәбиятында ерак гасырлар эпизодларына ишарәләнгән, язучы фантазиясеннән генә торган әсәрләрне без җиңел генә тарихи жанрга кертәбез. Аларның күбесе, минемчә, Вальтер Скотт, Фенимор Купер, Александр Дюма романнары кебек үк, тарихи маҗара жанры әсәрләре. Безгә андыйлары да бик кирәк. Фәнни расланган документларга корылган чын тарихи романнар, повестьлар татарда бүген дә аз. Татар язучысы нигәдер архив белән дус түгел. Шуларны истә тотып, күрше бинадагы архив белән сөйләшеп, без анда кызыклы документлар күргәзмәсе оештырдык, яшь язучыларны чакырдык. Унбишләп язучы килде, кызыксынып тыңладылар... Сүнделәр... Бүген тарихи жанрны тергезү өчен хөкүмәт грантлар бирә – дөрес итә, чөнки тарихи әдәбияты булмаган халык пассионар, үз эченнән үзе көч таба ала торган халык була алмый.

«Казан утлары»нда 7 ел эшләү дәверендә минем күзем һәм күңелем аша үткән 84–85

том татар әдәбиятының өр-яңа әсәрләре укучыларыбызга барып ирешге. Ул елларда журналда чыккан Хисам Камалның «Безне өйдә көтәләр», «Үлгәннән соң яздым», Мәхмүт Хәсәновның «Язгы аҗаган», Ибраһим Салаховның «Колыма хикәяләре» («Тайгак кичү») романнары, Мөхәммәт Мәһдиевнең «Кеше китә – җыры кала», «Торналар төшкән җирдә», «Бәхилләшү» повестьлары Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булдылар. Берничә хезмәткәребез республикабызның мактаулы исемнәре, медальләре белән бүләкләнде, яңа фатир алды. «Казан утлары»ның профсоюз оешмасы «Азат хатын» журналында иде, без үзебезнең мөстәкыйль оешмабызны төзеп җибәрдек һәм эчке эшләребезне тышка чыгармыйча, дус гаилә булып яшәдек. «Әллә полный автономиягә күчәргә исәпме?» диде җитәкчеләребезнең берсе. «Журналыбыз – Язучылар берлеге органы, иҗади хезмәткәрләребез – Язучылар берлеге әгъзалары, партия әгъзалары Язучылар берлеге партия оешмасында тора, планнарыбызны Язучылар берлеге идарәсендә раслыйбыз» – дидем мин, аны тынычландырып... 1989 елның маенда Татарстан язучыларының XI съезды булды, бик кызыклы съезд! Беркайчан һәм бер генә республикада да булмаган хәл – әдәби журналның баш редакторын сайлауны съездның көн тәртибенә кертеп, яшерен тавыш биреп сайладылар. Беренче турда ук съезд «Казан утлары» журналының баш редакторы итеп өч кандидат арасыннан Ренат Харисны сайлады. Шулай итеп, мин Россиядә, БДБ илләрендә беренче һәм әлегәчә бердәнбер съезд тарафыннан сайланган баш редактор. Кызык бит?!

Әтием татар теле һәм әдәбияты укытучысы булганлыктан, «Казан утлары»на без һәр ел язылa идек. Мин журналның баш редакторы булып эшләгәндә дә, әтием традициясен бозмадым – аны өемә яздырып алдым. Хәзер дә шулай итәм. Бүген дә «Казан утлары» минем иң көтеп алган рухи хәзинәм. «Казан утлары» аша мин, үзем өчен генә булса да, татар язучысының иҗади, иҗтимагый, эстетик, әхлакый, милли аңы дәрәҗәсен билгелим. Журналның һәр яңа санын кулыма алган саен 38 ел буе үзгәрмәгән тышлыгын күреп куанам. Миннән соң редакцияне җитәкләгән Равил Фәйзуллин, Илфак Ибраһимов, Рөстәм Галиуллиннар «перестройка» модасына бирелмәделәр, журналның инде укучы күңеленә кереп урнашкан кыяфәтен саклап калдылар, ә эчке архитектоникасына сак кагылдылар.

Менә почта ящигыннан алып кергән журналның 2021 елның июнь ае китабы: № 6 янында җәяләр эчендә 1184 санын күрәм. Бу – төрле елларда «Безнең юл», «Атака», «Совет әдәбияты», «Казан утлары» дигән исемнәр йөрткән, Бөек Ватан сугышы вакытында да тукталмыйча-өзелмичә чыккан журналыбызның йөзгә якын ел дәвамында нәшер ителгән китапларының гомуми санын күрсәтүче цифралар. Аларны да мин эшләгән чорда архивларда актарына-актарына тапкан идек, «Казан утлары» җитди, классик журналга хас тагын бер күрсәткечкә ия булды дип шатланган идек. Мин шул елларны, әлбәттә, сагынам, бергә эшләгән каләмдәшләремне рәхмәтләрем белән искә алам. Ринат Мөхәммәдиев, Рәдиф Гатауллин, Роберт Миңнуллин, Зиннур Мансуров, Мөдәррис Вәлиев, Мансур Вәлиев, Рәшит Әхмәтҗанов, Тәүфикъ Әйди, Фәүзия Бәйрәмова, Җәүдәт Миңнуллин, Нияз Акмал, Рашат Низамиев, Солтан Шәмси (кемнедер оныткан булсам, гафу үтенәм) – нинди талантлы язучылар, кызыклы шәхесләр белән эшләгәнмен мин! Алар арасында соңыннан халык шагыйрьләре, Язучылар берлеге җитәкчеләре, телевидение баш мөхәррирләре, газета-журналлар баш редакторлары, университет укытучылары, нәшрият директорлары булып үсеп киткәннәре дә, Тукай, Җәлил, Державин, Исхакый һәм башка премияләр лауреаты булучылар да бар. Алар миңа ихлас булыштылар, «Казан утлары» редакциясе мәктәбе аларга да тормышларында ярдәм иткәндер дип уйлыйм.

1989 елның 25 сентябрендә мине башка, тагы да җаваплырак, катлаулырак, хәтәррәк эшкә күчерделәр – ил олы болганышлар бусагасына басарга тора иде...

Ренат ХАРИС,
Татарстанның халык шагыйре,
Россия Федерациясенең Дәүләт премиясе лауреаты (2005),
журналның 1982-89 еллардагы баш мөхәррире.

ЮНӘЛЕШ БИРҮЧЕ БАСМА

Әдәбиятка килү юлында миңа төп юнәлешне «Казан утлары» бирде, дисәм, хилафлык булмас. Әлеге сүзләр һич тә журналның 100 еллыгын каршылаган көннәрдә гавам алдында да ниндидер шәп сүзләр әйтеп калырга тырышудан түгел.

Балачактан, ягъни хәреф таный башлаган мәлләрдән үк, уку – минем табигый халәтемә әйләнде бугай. 1968 елдан башлап, журналны яздырып алучы һәм һәр санын укып баручы кеше бит мин. Кемнәрдер миннән дә күбрәк чорны колачлыйдыр, кемнәрдер әле соңгы елларда гына ала башлагандыр, анысында эшем юк, әмма 53 ел дәвамында журналның мин укымый калган саны булмагандыр. Тарихи журналыбызның «Совет әдәбияты» булып чыккан елларын да беләм. Аның латин графикасы белән язылган аерым саннары мәктәп китапханәсендә бар иде. Китап укуны бик яраткан малай, уку өчен күземә ни чалына, шуңа чытырдап ябыша идем. «Совет әдәбияты»н кулыма тотып, латин хәрефләренә аптыраулы кыяфәттә актаргалап торганым истә калган. Иң нык хәтердә калганы – журналның «Казан утлары» исеме алып, якты, ачык төстә басыла башлавы. Ул күңелгә рәхәтлек биреп торган кебек иде. «Совет әдәбияты» ничектер салкынрак, аннан ниндидер тымызык сулыш бөркелгән сыман иде. Хәзер аңлыйбыз, Рафаэль Мостафин журналның исемен алыштырып кына калмаган, татар халкын үз асылына кайтару юлында да искиткеч кыю адым ясаган икән.

Урта сыйныфларда укыганда, анда Фатих Хөсни, Габдрахман Әпсәләмов, Мирсәй Әмир, Ибраһим Гази, Сибгат Хәким, Хәсән Туфан, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Аяз Гыйләҗев, Гариф Ахунов һәм башка әдипләребезнең әсәрләрен укып, иләсләнеп йөрдек. Ул чактагы тәртип-кагыйдә буенча язучының әсәре, китап булып дөнья күргәнче, иң элек бердәнбер әдәби журналыбызда басыла (шулай тиеш дип кабул ителә иде), аны укучылар ябырылып укыйлар, ул арада газета битләрендә тәнкыйтьчеләрнең саллы мәкаләләре, төрле һөнәр ияләре – хезмәт кешеләре, студентлар кавеменнән булган укучыларның уй-фикерләре басылып чыга. Әсәр буенча һәр китапханәдә китап укучылар конференцияләре, диспутлар үткәрелә. Алар хакында да хәбәрләр ирешеп кенә тора. Шуннан соң автор үзе сүз алып, әйтелгән һәм әйтеп бетерелмәгән фикерләргә җавап биреп ала, әсәрне китап итеп әзерләгәндә күрсәтелгән «кимчелек-теләкләрне» истә тотарга вәгъдә итә. Китап булып басылып чыккач та, шундый ук хәл кабатлана. Ябырылып уку, тәнкыйть, уй-фикерләр...

Журналда чыккан һәр зур әсәр буенча безнең авыл клубында укучылар конференциясе була иде. Кайбер чакларда мондый конференция-диспутларга минем дә кереп утыргалаганым булды. Китап укырга ятратканымны беләләр, миңа каты бәрелмиләр иде. Мондый чараларда төп фигура – Нәгыйм абый Гайсин. Аның татар һәм урыс әдәбиятыннан укымаган әсәре булмагандыр. Ул үзе – математика һәм тарих мөгаллиме. Озак еллар мәктәп директоры булып эшләгән, нык тавышлы, әңгәмәдәшенә бер текәп караса, тегене шундук «сакауландырырга» да мөмкин.

Башта китапханәче Мәрзия апа журналда басылган әсәр хакында әңгәмә башлап җибәрә, аннан авыл интеллигенциясе вәкилләре – бухгалтериядә, медпунктта эшләүчеләр, колхозчы-укучылар сүз алып, әсәр хакында «әсәрләнеп» сөйләп алалар,

аннан мәктәптә укытучы яшь мөгаллимнәр (ул чакта мәктәпләрдә дистәләп яшь укытучы эшли, мәктәп-клублар гөрләп тора) әсәр хакында фикерләрен җиткерәләр. Аларга журналның һәр санын укып бару, сүз әйтү мәҗбүри иде кебек. Болар сүз әйтеп бетергәч, мәктәп директоры (мәктәпне Нәгыйм абыйдан кабул итеп алган) Җәннәт апа Галиева «эшкә керешә». Ул – югары белемле татар теле һәм әдәбияты укытучысы. Җәннәт апа үзенең хәлен аңлый – әгәр әсәргә бәя биргәндә «ялгышып» китсә, Нәгыйм абый аны пыр туздырып атачак! Шуңа күрә ул бөтен белемен эшкә җигә, дөнья, рус әдәбиятын, марксизм-ленинизм тәгълиматларын, бүгенге партия, ил тормышыннан гаҗәеп шәп мисаллар китереп, үзенә булачак (ягъни була калса!) «һөҗүмне» алдан ук шактый йомшартуга ирешә.

Иң ахырдан сүзне Нәгыйм Галиевичка бирәләр. Ул эре адымнар белән алга, китапханәче утырган өстәл янына чыга, кайчакта шактый кырыс итеп, кайчакта үтә җылы рәвештә, әсәргә бәя бирә, чыгыш ясаучыларны әсәрне аңлап җитмәүдә бераз шелтәләп тә алгалый. Җәннәт апага каты кагылмый, еш кына аларның әсәргә биргән бәһаләре туры килә. Әмма минем күзәтүем буенча, Җәннәт апа һәр конференциядә Нәгыйм абый каршында имтихан тоткан сыман иде.

Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Икмәк тәме» әсәре буенча булган конференция истә калган. Чыгыш ясаучылар авторны мактадылар, авыл кешесенә, икмәк үстерүчегә мәдхия укыган дип зурладылар. Ахырдан сүз, гадәттәгечә, Нәгыйм абыйга бирелде. Ул үзенә сүз бирелгәнне ишетмәгәндәй, чалара башлаган керпе чәчле башын аска иеп бер минут чамасы уйланып утырды, аннары авыр гына урыныннан кузгалып, алга үтте. Конференциягә килүчеләрнең һәрберсен кырыс караш белән күздән кичереп чыкты, аннары ачу катыш берничә сүз әйтте:

– Мөсәгыйт Хәбибуллинның бу ипие пешмәгән! Мондый әсәрне биреп, журнал зур хата ясаган! – диде дә, эре атлап, клубтан чыгып китте.

Кулыма каләм алып, шигырьләр, хикәя ише әйберләр яза башлаган яшүсмергә Нәгыйм абыйның бу сүзләре нык тәэсир итте. Шул мәлдә язучы эшенең никадәр җаваплы икәнен аңлый башладым сыман. Әгәр кулыңа каләм алгансың икән, сине беркем дә «пешмәгән» әсәр язган дип гаепләрлек булмасын! Төп нәтиҗәне үзем өчен шул чагында ясадым.

Үземә беренче әсәрләремне журналда бастыру, хәтта бераз редакциясендә эшләү бәхете дә насыйп булды. Хәтта берничә ел журналның идарә әгъзасы булдым, идарә утырышларында, еллык йомгаклауга багышланган җыелышларда чыгышлар ясарга да туры килде. Журналның ул чактагы алтын баганаларын: Равил Фәйзуллин, Флүс Латыйфи, Марс Шабаев, Мансур Вәлиев, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташны һәрчак хөрмәт белән искә алам.

Факил САФИН,
Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

«Аһ, туган каумем газиз!» әдәби конкурсы

Сәмига
Сәүбанова

ӘТКӘМ ЧЫБЫРКЫСЫ

хикәя

Мин үземне белә башлаганнан бирле кемнеңдер күзәтеп йөргәнен сизәм. Әле чәчемнән сыйпагандай итә, әле битләремнән иркәли.

Аны эзләп, тирә-ягыма каранам, тик беркемне дә күрмим.

Сәерлегемне өлкәннәр дә сизә иде.

– Җүләр, дияр идең, җүләр түгел, башына зыян килгәнгә охшамый, мөгаен, йорт иясе шаярадыр, – диләр.

Тора-бара мин аңа шундый ияләндем, ул үзен озаграк сиздерми торса, күңелсез булып китә. Ләкин бу турыда бүтәннәргә белдерергә ярамавын да аңлыйм. Югыйсә «тиле Сәхия», – диюләре бар. Кемнең инде үзенә «тиле», дип әйттерәсе килсен?! Күзгә күренмичә, мине иркәләүче зат чыннан да бар иде, мин аның барлыгын шулхәтле ачык тоя идем!

Үземне күзгә күренмәс затның күзәтүе белән килештем. Бүтән балаларның әниләре, әтиләре, әби-бабалары үзләренә сиздереп тә, сиздермичә дә күзәтчелек итәләр бит. Бәлки, аларның да күзләре әллә кайлардан күрәдер? Күңелемнән күз күрмәгән җирләргә китеп, үземне очсыз-кырыйсыз мәйданда дип хис итәм, анда кемнәр, нәләр барлыгын белергә омтылам. Тик берни дә күрә алмыйм.

«Үсеп җитмәгәнмендер әле, – дип уйлыйм мин. – Тиешле яссылыкка буем җитмидер». Һәм мин ул биеклекне тояр өчен өй түбәсенә йә агач башына менеп китәм.

Аннан соң мин әтиемне күзәтергә яратам. Миңа аның чыбыркы шартлатуы ошый. Чыбыркы тавышы әллә нинди хисләр уята, күңелгә матур көй уела. Инде үсеп, җиткән кыз булгач та, чыбыркы моңы колагымда яңгырап тора.

Бер генә көй чыгаручының да бу аһәңне күңелемдә уелып калырдай җыр-моңга тапшыра алганы юк әле. Ә ул моң һаман да колагымда «чың-чың» килеп, бала чагыма алып кайта.

Әткәйнең үзе белән көтүгә дә алганы бар. Ул мине ат өстенә күтәреп утырта һәм болынга алып китә. Аның белән әле утлап, әле ял итеп яткан көтүне әйләнеп чыгабыз. Әткәйне күргәч, колхоз басуына биләмгә керергә яраткан мут сыерларга хәтле кире борыла. Бу вакытта минем өчен җир йөзендә әткәйдән дә кодрәтле кеше юк сыман.

Миңа әткәй мондый кодрәтне чыбыркысыннан ала кебек. Аны селтәп җибәрсә, болынга хәтле чайкалып куя. Ә ул исә, үз чиратында, шук малайлар кебек чикне бозарга җай гына көтеп утлаучы сыер халкын кисәтә. Алар тагын шактый вакыт чыбыркы аһәңенә буйсынып, күшәүләрен дәвам итәләр.

Сихерләнгәндәй, аларны күзәтәм. Чыбыркы очы белән сыер койрыгында ниндидер бәйләнеш бар кебек. Чөнки чебен-черкине бертуктаусыз куып күшәгән малларның, чыбыркы тавышын ишетүгә, койрыклары бермәлгә туктап кала, аннан соң селкенеп куя, елан кебек өскә күтәрелә һәм бер мизгел шулай тора. Ә ул арада кунган чебен-черки, кигәвен, сыерларның канын күбрәк эчәргә теләп, борынын аларның тәненә батыра. Койрыклар, махсус команда булган кебек, аларны себерә-себерә уйнаклый, юк итә башлый һәм өчпочмак формасын ала.

Шул чагында чебен-черки дә, канымны ризык итәргә чамалап, баш очымда кара болыт кебек бөтерелергә тотына, һәм мин ярдәмгә койрыгымны эзли башлыйм. Минем дә койрыгым чебен-черкине куар, янәсе. Аннан соң миндә генә түгел, гомумән, бер кешедә дә койрык юклыгы исемә төшә. Әмма вакыт-вакыт аның барлыгын шулхәтле ачык тоям: «Әллә чынлап та койрык үсте микән?» – дип капшап карыйм.

Вакыт-вакыт кемдер минем күзгә күренмәгән, кул белән капшап булмаган койрыгымнан тартыпмы-тарта гына бит. Мин ул кулны да, койрыкны да аермачык сизәм.

Һәр нәрсәгә ияләнеп була икән. Мин дә үземнең шушы күзгә күренмәгән койрыгыма да, аны тарткалап торуларына да шулхәтле ияләштем, игътибар да итми башладым. Үзләрен сизмичә торсам, юксына башлыйм хәтта. Кеше үзе эчкән суга, үзе яшәгән мохиткә шулай ияләшә бит.

***

Әткәем миңа, кешене туган көненнән алып иңендә ике фәрештәсе саклый, дип кабатларга ярата. Аның берсе – рәхмәт фәрештәсе, кылган уңай эшләрен язып бара, бәла-казадан йолып калырга тырыша. Ә икенчесе яман эшләрен үлчи, тик ул да кешене яманлыктан сакларга тырыша, ди. Шулай булгач, миңа куркырлык сәбәп юк. Фәрештәләрем яманлык теләмәс. Ә ул затның шул фәрештәләрнең берсе булуына шигем юк. Әллә икесе дә минем койрыгым белән шаярамы?

Еш кына күз алдымда искиткеч гүзәл планета пәйда була. Бу уйның каян башыма килүен дә төгәл генә әйтә алмыйм. Бер караганда, ул миңа күктән иңә, икенче караганда, үз башымда туа шикелле.

Ата-ана йортында бала озак яшәми.Үсеп җитү белән үз көнен үзе күрә башлый. «Син үз көнеңне бездә күрәчәксең, биредә яшәмәячәксең», – ди бер тавыш. Әти-әниемнән башка ничек яшәрмен? Тавыш иясе дәшми.

Күз алдымда аның илаһи йөзе пәйда була. Йа Хода! Мондый матурлыкны күргәнем юк иде әле. Йөзен аерып карап булмый – бөтен җиреннән, күзне чагылдырып, нур сибелә.

Мин, кулыма кәгазь-карандаш алып, әлеге илаһи затны, илаһи нурны сурәтләргә талпынам. Гүя төсле карандашларым әткәемнең чыбыркысы кебек озынаялар – кәгазьдә алардан барлыкка килгән сызыклардан өчпочмакны хәтерләткән сурәтләр пәйда була. Ерактанрак карасаң, төрле зурлыктагы пирамидаларны хәтерләтәләр. Һәммәсеннән нур сирпелә, тик барыбер ул илаһилыкны тулысы белән сурәтли алмыйм.

Бу рәсемнәр бер-берләренә охшаганнар да, охшамаганнар да. Ничек кенә сурәтләргә тырышсам да, кемне генә ясасам да, төрле зурлыктагы озынча өчпочмак-конус сыман фигуралар хасил була – җир үзе дә, табигать тә, җан ияләре дә... Әйтерсең, кулымда төсле карандашлар түгел, әткәемнең чыбыркысы һәм кемдер аны үзе теләгәнчә кәгазь өстендә уйната.

Ясаган рәсемнәремне укытучыларым җыеп бара. Аларны әледән-әле төрле күргәзмәләргә җибәрәләр.

– Бу бала мондый сюжетларны каян ала икән? – дип аптырый алар. – Гаҗәп бит, һәр рәсем, нинди дә булса мәгънәгә ия булуы өстенә, өчпочмак та.

Алар шушы мохитне үзем тойганча сурәтләвемне генә түгел, ә шул үзем тудырган мохит эчендә яшәгәндәгедәй хис итүемне аңламыйлар.

Тоемлауларымны бүтәннәр белән дә уртаклашасым килә. Тик әлеге тавыш иясе, илаһи зат тыеп тора.

– Җир кешеләре сине аңламас, алар сине тилегә санар, – ди ул.

Үземне тиле дип уйлауларын теләмим. Шуңа күрә кулыма тагын кәгазь, карандаш, буяулар алам. Ә кәгазьнең мине сатарга теле юк.

Рәсем укытучысы, кәгазь белән генә чикләнмичә: «Киндердә эшли башларга вакыт», – дип киңәш бирә. Ә мин исә рәссам булырга уйламыйм да. Җанымда тупланган, менә-менә шартлап ярылырга торган энергиямне кәгазьгә күчерәм генә. Кәгазь – сердәшем, кәгазь – дустым. Аңа тулысынча ачылам.

Ә бу җирдә мин вакытлыча гына. Мин анда үсәм, алга таба яшәр өчен көч туплыйм, килер бер көн, аны ташлап китәрмен.

Тик бу җирдән кайчан китәсемне белмим...

Бүтәннәр мәхәббәт хатлары алыша. Миңа да килә андый хатлар. Тик мин генә җавап язмыйм. Миңа хат язучының кемлеген дә беләм – Фәйзелгаян булмый кем булсын? Тагын кәгазь, буяуларыма тотынам. Күңелемдәге билгесезлек хыялый сурәтләргә әверелә. Сурәтләгән дөньям искиткеч матур. Тик нишләптер анда ярату юк. Андагы һәр җан иясе ялгыз. Шуңа анда шатлык та, кайгы да, үлем дә, мәхәббәт тә юк, анда кеше мәңгелек.

Сөймичә, сөелмичә яшәүдән дә авыррак нәрсә бар икән?! Син бар, син эшлисең, син – мәңгелек, тик моңа беркем дә көенми, сөенми, сине берәү дә яратмый, берәү дә көнләшми. Табышлар да, югалтулар да юк.

– Хатлар язып, хатлар алып, җирдәгеләр уенын уйнамый тор, – ди илаһи зат. – Синең бүтән яссылыкның алиһәсе буласың бар...

Илаһи зат миңа үзенең барлыгын еш белдереп тора. Ул беркайчан да тавышын күтәрми, тик вакыт-вакыт мине куркыта да.

Урта мәктәпне тәмамлагач, рәссамнар әзерләүче уку йортына кергәч, беркем гаҗәпләнмәде. Алар фикеренчә, җир кешесе һөнәрен сайларга тиеш тә түгел идем. «Дөньяда моңарчы күрелмәгән рәссам үсеп килә. Тормышның бүтәннәр күрмәгән мизгелләрен, бүтәннәр күрмәгән чагылышын сурәтли алырдай рәссам», – диделәр.Тик кайчан да булса, үзем яши башлаячак яссылыкны күзаллавым турында берсе дә белмәде. Моны үзем дә белмәдем.

***

Көннәрне – төннәр, төннәрне көннәр алыштырды. Академияне тәмамлап, төрлебез төрле якка таралды, ә мин Рәссамнар берлеге каршындагы күргәзмәләр залында консультант булып калдым. Шуның өстенә мастерскойда эшләр өчен урын бирделәр.

Эшли башлавым республика һәвәскәр рәссамнарының зур күргәзмәсе ачылу көннәренә туры килде.

Профессионаллар белән генә түгел, һәвәскәр рәссамнарның да күбесе белән таныш идем инде. Картиналарда җир үзе, җир кешеләре сурәтләнә. Карасана, җир дә шундый гүзәл икән бит! Аеруча таң аткан чагында. Һәр җан иясеннән, һәр агачтан, хәтта һәрбер үләннән нур бөркелә. Нишләп мин шушындый гүзәл планетада яшәмичә, башка яссылыкта яшәргә тиеш әле?

Бу тетрәнү шулхәтле көчле иде ки, андагы бүтән картиналарга игътибар итмичә, почмакта торган урындыкка барып утырдым. Күз алдымда куе томан болыты чайкала. Каяндыр нур бөркелә. Таныш, бик таныш нур. Алдымдагы куе томан чайкалудан туктады һәм әкренләп таралды. Чү! Кемдер каршыдагы диварга яңа картиналар элә. Нур алардан сирпелә икән!

Бу картиналарда мин ташлап китәргә тиешле җир түгел, ә яшәргә тиешле яссылык күренешләре чагыла иде!

Гаҗәпләнүдән аһылдап куйдым. Кемдер дигәнем миңа таба борылды.

– Хәлегез киттеме әллә? – дип сорады ул. – Хәзер валидол табам.

Ул кесәсеннән валидол чыгарды. «Менә бит кирәге чыга икән, – диде ул. – Нигәдер кесәмә тыгарга уйладым. Сезнең өчен булган икән».

Күз алдым яктырды.

– Мин дә, йөрәгемнең кайдалыгын белмәсәм дә, сумкамда валидол йөртәм, – дидем. – Берәрсенә кирәге чыгуы бар, дип...

Көлештек.

– Икебез бертөсле уйлыйбыз икән.

– Шулай булып чыга. Тик нишләптер сезне бер дә күргәнем юк иде. Каян, кем сез?

– Ә сез кем?

– Мин монда эшлим. Яшәвем дә биредә. Сез кайда яшисез?

– Бүген минем яшәвем – урманда.

– Ә иртәгә?

– Анда күз күрер.

– Бу рәсемнәр каян?

– Болар җир рәсемнәре түгел.

– Ә кайдан?

Хәер, мин аларның чыганагын беләм. Шуңа соравым да мәгънәсез тоелды, ахры.

Сорауга каршы җавап:

– Каян дип уйлар идегез?

Мин аны кладовка бүлмәләренең берсенә алып кердем. Үземнең картиналарымны күрсәтә башладым.

Картиналарны күргәч, ул бик гаҗәпләнде.

– Бу рәсемнәр нәрсә аңлатырга тели, дип уйлыйсыз? Димәк, сез дә күңелегез белән бу җир кешесе түгел?

– Шулай уйлыйсызмы?

– Җир кешесе бүтән яссылыкка омтылмас иде.

– Мин омтылмыйм... Мине кемдер этәрә... Миңа үз җирем якын.

Бу очрашуның очраклы түгеллеген икебез дә аңлый идек. Тик ачылып китәргә ашыкмадык.

– Сүз юк, сезнең картиналарыгыз әсәрләндерә, уйландыра, әмма анда җирдәге җылылык юк.

Без яңадан күргәзмә залына менәбез. Аннан берничә картинаны алып төшәбез һәм чагыштырабыз.

– Без табигатьне төрле нурланышта сурәтләгәнбез. Сезнең рәсемнәрдә Кояш өстенлек итә, минекендә – Ай, йолдызлар... Беребезнекендә – көн, беребезнекендә – төн... Тәүлекнең төрле вакытын сурәтләгәнбез...

– Елның төрле фасылына ишарә дә юк түгелме?

– Бу җир түгел, бу бөтенләй бүтән яссылык! Ул Кояшка да, Айга да, йолдызларга да бүтән мөнәсәбәттә. Анда кояш офыкка керү белән, күктә йолдызлар калка. Күрәсезме, алар бездәге йолдызлар кебек түгел, берничә кояш булып, төрле яклап, офыктан күтәрелә. Монда көн көндезгедән күп тапкыр яктырак, күп тапкыр эссерәк. Чөнки җирдә төнлә яктырта торган ай һәм йолдызлар да бирегә көндез яктырта. Төн исә сездәгедән караңгырак, анда ай да, йолдызлар да юк. Мондагы төн – тереклекне кояш эссесеннән коткаручы ул.

– Картиналарны язганда, моңа игътибар итмәгән идегезмени?

– Мин аларны ничек бар – шулай ясадым, үземә якын булган күренешләрне генә сурәтләдем. Тик безнең дә җир элек болай түгел иде. Бу картиналар – минем күңел җәрәхәтем дә...

– Ә сез? Сез үзегез кем?

– Минме? Мин – кеше.

***

Җирдән кайчан да булса аерылып китәргә тиешлегемне белә идем. Тик әле бүген дә, иртәгә дә түгел, гомумән, әле тиздән түгел кебек иде. Кеше үзенең кайчан да булса җанының тәненнән аерыласын яисә җирдәгеләр әйткәнчә, үләсен белә торып, мәңге үлмәс кебек яшәвен дәвам итә, үлем аны һич тә куркытмый. Ә инде үзенең гомере азайганын сизгән саен аңа теше-тырнагы белән тагын да ныграк ябыша. Минем белән дә шулай. Элек үземне монда вакытлыча кунак кына итеп караган Җир хәзер тагын да матуррак, тагын да мәһабәтрәк, шул ук вакытта кызганыч та тоела. Шулай да ул минсез яши алыр. Ә мин?

Бу тетрәнү шулхәтле көчле иде ки, төне буена йоклый алмыйча азапландым. Таң алдыннан әкрен генә өскә күтәрелә башлавымны сиздем. Менә түшәмгә җиттем, аның аша берннди тоткарлыксыз үтеп чыктым, өскә әллә ничә кат болытлар аша үтеп, очар кошка әвереледем һәм җир тирәли әйләнә башладым.

Юлымда үзем кебек кошларны күп очраттым. Алар миңа гаҗәпләнеп карыйлар һәм: «Карагыз әле, кешегә охшаган нинди кош безнең арада», – дип гаҗәпләнәләр.

Күктәге кошлар барысы да парлы-парлы. Алар арасында минем генә парым юк.

Җир тирәли кат-кат әйләнәм, аны аркылыга да, буйга да күрәм. Менә үзем яшәгән авыл, үзем үскән йорт. Әнә, анда әнкәй, әнә, сеңелләрем. Әнә, әткәй чыбыркының яңасын үреп утыра. Үзе җырлый:

Оҗмахларда яшәсәң дә,
Сагындыра туган җир...

Әнә, икәү бергә уйнап үскән Фәйзелгаян.

Фәйзелгаян чыбыркы селтәнеп маташа. Әткәм чыбыркысы! Ничек килеп кергән аның кулына, кем биргән? Әллә көтү чиратьı аларга җиткәнме?

Каяндыр әмер килә:

– Кит! Син бу җирне озак карап торырга тиеш түгел! Синең урының – биектә. Шунда күтәрел!

Бу әмергә буйсына алмыйча катып калам. Югарыга күтәреләсем һич килми. Туып-үскән җиремнән аерыласым бөтенләй килми! Мин Фәйзелгаян тоткан чыбыркыдан күземне ала алмыйм. Нишләп әткәй аңа бирәсе итте икән?

Һәм кире төшәм. Күз алдым томан белән каплана. Ә инде томан таралгач күрәм – бүлмәдәш кызым Кафиянең йөзенә карарлык түгел.

– Әллә берәрсе үлдеме? – дип сорыйм.

Ә ул җавап урынына:

– Уяндың! Уяндың! – дип кочаклап ала.

Аның сүзләреннән шуны аңлыйм: өч тәүлек буе йоклаганмын икән. Битемне чәбәкли-чәбәкли уятып та караганнар, уята алмаганнар. Шуңадыр, бит алмаларым чеметтереп кызыша. Аптырагач, табиб чакырганнар. Ул:

– Уянганчы тимәгез, уятырга тырышмагыз. Иҗат кешеләренең, әсәр өстендә утырганда, атналар буе йокламаган кебек, соңгы ноктаны куйгач тынычланып, берничә көн буена йоклавы гадәти хәл, – дигән.

Мин Фәрваз белән очрашырга булдым. Ул да киләсемне белгән кебек иде.

– Монда күргәзмәгә дип килүегез күз буяр өчен генә. Максатыгыз бүтән.

– Әйе, бүтән, – диде ул. – Урман кешесе табигатьне сакларга тиеш. Җирдә хәзер тоташ җинаять. Кеше кешене ботарлый. Ерткычлар да үз кавемнәре белән алай кыланмый.

– Ләкин ул – минем туган җирем!

– Безгә бүтән планетада яшәү мөмкинлеге бирелде.

– Сез шуннанмыни?

– Әйе. Мине җиргә сине алып китәр өчен җибәрделәр. Тик мин сине бүтән җирдән эзләгән идем.

– Кайдан?

– Әткәң чыбыркысы яныннан!

– Мин беркая да китмим!

– Синең сайлар мөмкинлегең юк. Безнең яссылык күптән көтә үзеңне. Анда да кешеләр яши. Анда хәзер гомер мәңгелек. Элек алай түгел иде.

Ул «мәңгелек» сүзе урынына «мәңгелек төрмә» дияргә теләгәндәй тоелды...

Язмышымның шулай җиңел генә хәл ителүен теләдеммени? Җирдә туып, үс тә, сине ансат кына бүтән яссылыкка алып китсеннәр әле?

Әткәем, әнкәем, туганнарым, дусларым миннән башка нишләр? Ә үзем нишләрмен? Мәңгелек гомерем белән бөтенләй башка планетада яшәргә тиешмени? Ник кирәге бар мондый мәңгелекнең?

***

Күргәзмәгә бу хәтле халыкның күптән килгәне юк икән. Аны Фәрваз картиналары бигрәк әсәрләндерде. Озак тукталып, якынрак килеп тә, ераккарак китеп тә карадылар. Ара ераклыгына мөнәсәбәтле рәвештә шушы

күренешләргә яктылык сибелеше дә үзгәреп, төрле балкышка керә икән. Бер карасаң – көмеш сыман, бер карасаң – алтынсу, бер карасаң – зәңгәрсу алар. Ә бу конуслар – өчпочмаклы пирамиданы хәтерләткән рәсемнәр эчендә кешеләр бар сыман. Яктылык уйнавына мөнәсәбәтле рәвештә аларның күзләре, колаклары, иреннәре, күкрәкләре шәйләнә. Нәкъ безнең җир кешеләре шикелле! Бу рәсемнәр бергә тезелеп киткән пирамидаларны хәтерләтә. Мисыр пирамидаларын ничек төзергә булдылар икән дип, ничә гасыр баш ваталар, әмма барыбер җавап таба алмыйлар. Чит планеталар белән җир кешеләренең элемтәсен белгертүләре түгелме?

Остаханәдә эшләнеп беткән һәм языла гына башлаган картиналарымның фрагментларын кат-кат карыйм. Космик киңлектәге өчпочмаклы тормышны чагылдырган рәсемнәрем Фәрвазныкы белән чагыштырганда тоныкланып калды кебек. Остазларымның аларны мактавына, иҗатта яңа үсеш дип бәяләүләренә элек тә аптырый идем. Үз йөрәгем аша үткәреп язмадым бит. Кемдер кулымнан тоткандай, киндер өстендә йөртте генә.

Ниһаять, күргәзмә эшен туктатты. Бүтәненә әзерлек башланды. Картиналар җыеп алынды һәм кабат рәссамнарның үзләренә кайтарылды.

Фәрвазның адресын табарга тырышсам да, каталогта аның турындагы мәгълүматлар юкка чыккан иде.

Хәзер миңа болар барысы да төш кебек тоела. Тик берара тыныч кына яшәгәч, тагын сәер хәлләр була башлады.

Кич белән тыныч кына йокыга китәм. Ә төшемдә үземне ымсындырган да, шул ук вакытта куркыткан да яссылыкка сәяхәт итәм. Миңа анда рәхәт кебек, җиргә кайтасым да килми. Җиргә әткәм-әнкәм кире чакыра. Әнкәм:

– Син – җирнеке, син – безнеке, кайт! – дип ялвара.

– Алтын таулары вәгъдә итсәләр дә, ышанма. Адәм баласының кадере – үзе туып үскән җирдә генә, – ди әткәем. – Читтә солтан булганчы, үз илеңдә олтан булу мең тапкыр яхшырак. Бер солтан урынын алыр өчен мең башкисәр тозак кора.

Сәер инде. Бу яссылыкка беркайчан да үзем теләп менмим. «Менәсеңме?» – дип сорап та тормыйлар. Ә уянгач, үзем күргән төш тә тоныклана.

Вакыт-вакыт мондый сәяхәтләр озакка сузыла. Уянгач:

– Тагын берничә тәүлек йокладың, үлдең дип курыктык, – диләр.

***

Беренче отпускам вакыты җитте. Ял вакытында бер генә картина да язмадым. Бу елны ике планета, ике яссылык арасында йөреп үткәрдем, алҗыткан. Мондый сәяхәтләр көчне күп ала, ике шәһәр арасында гына йөрү түгел шул.

Остазларым бу тынлыкны хыялый картиналардан соң реаль тормыш турында иҗат итә башлау алдыннан булган эзләнү чоры итеп кабул иттеләр бугай. Ә ялга чыгар алдыннан эштән китәргә гариза язып кергәч, директор кәгазьне тегеләй дә, болай да әйләндереп карады:

– Кызганыч, – диде ул. – Бик кызганыч. Тик сезне дә аңлыйм. Иҗат кешесенең дәүләт эше белән бәйләнеше аның иреген кыса. Ул азат булырга тиеш. Матди ягың җайланганчы, картиналарыңны монда калдыр, күтәреп җәфаланып йөрмә. Куйган урыннарында торсыннар, буш бүлмәләр җитәрлек. Җаең булгач алып китәрсең. Безнең илдә генә иҗат кешесенең кадере юк, бу рәсемнәрең белән

чит илдә яшәсәң, черегән бай булыр идең инде. Бер кечкенә генә картинаны да Кытайда җиңел машинага алыштырып була, ди. Көлмә, көлмә.

– Агыйделнең аръягында бер инәгә – бер сыер, – дим.

Картиналарны күтәреп йөрергә җыенмый да идем әле. Бәлки, тагын яңа күргәзмәләр булып, анда берәрсенә урын табылыр һәм килүчеләрне үзенә җәлеп итәр? Фәрваз картиналары янындагы кебек озаклап карап, төрле мәгънә эзләрләр? Минем фикеремчә, дөньяга танылган бүтән рәссамнар өчен дә җир аларны бүтән яссылыкка әзерләүче тәүге бишек булгандыр. Әнә бит, Мәрьям-ана болытлар өстеннән, канатлы фәрештәләр ярдәмендә Гайсә пәйгамбәрне күтәреп, җиргә – кешеләр янына тиккә төшмәгән. Вакыты җиткәч, тагын күккә иңгән. Бүтән яссылыкка. Мәңгелеккә...

Тик болар турында беркемгә дә әйтә алмый идем. Алдымдагы буяулар, пумала һәм киндер сыйдырды уйларымны. Хисләрем төрле сурәтләргә әверелеп, билгеле бер сюжет булдылар. Мондый хисләр җир кешесендә була алмый иде. Җир кешесе бүтәнчә яши. Ул яна, көя, сөя. Бу рәсемнәрдә яну да, сөю дә, көю дә сизелми.

Картиналарымның санын белер өчен директор белән аскы катка төштек. Алар ничек куйган булсам, шул хәлдә торалар иде. Тик беренче рамны әйләндереп карауга, йөрәгем «жу» итте. Минем картиналардагы рәсемнәр бер дә булмагандай юкка чыкканнар, киндер тартылган рамнар гына калган иде. Рәсемнәрем бүтән яссылыкка күчтеләр микәнни?

Минем йөземдә үзгәреш күрмәгәч, директор җиңелрәк сулый башлады.

– Әллә экстрасенслар үзебезгә белгертми генә шаяртмакчы булдылар микән? – диде.

Директордан бу турыда берәүгә дә әйтмәвен үтендем.

Димәк, җирдә кирәгем бетеп бара. Димәк, мине анда дәшәләр.

Җаным бүтән яссылыкка күчкәч, тәнем монда калыр. Аны шунда ук җиргә күмәрләрме, әллә: «Тагын йоклаган», – дип, бераз көтәрләрме?

Әнкәем сәер кызының еш кына мәрткә китүен белә. Бүтән җирдә озак уянмасам, тереләй күмүләреннән курка. Шуңа да ул мине гел авылга кайтырга чакыра.

– Үзебезнең янда гына яшә, олы якны мастерской ит, икебезгә бәләкәй як та бик җиткән, – ди.

Миңа хәзер алар белән саубуллашырга кирәк.

***

Өйдәгеләр мине көткәннәр. Әнкәй олыгайган, әмма ак чәчләре үзенә килешеп тора. Әткәй дә тигез җирдә сөртенгәли. Тик торганда да, башы әйләнеп китүдән зарлана. Бичара әткәй, әнкәй? Тиздән нишләрсез икән?

Мин кайткач, әнкәй яшәреп китте. Аның ак чәчләре рәсемнәре юкка чыккан киндерне хәтерләтә.

– Кайтуың әйбәт булды әле, – диде ул. – Синең белән ни генә булса да, үзем исән чагында тереләй күмдермәм. Шуңа күрә авырырга ярамый.

Әнкәй – көчле хатын. Ул һәрвакыт үзен кулга ала белә. Аңа минем җаным ташлаган тәнемне күпме сакларга туры килер әле. Ә кайтмасам?..

– Кайберәүләр кебек тормыш авырлыклары килгәндә дә, үземне кызгандырып йөрмәдем. Дөньяңны онытып кайгырып йөрү – кулыннан бер

эш килмәгән җебегән кешеләр эше. Безнең аңа вакытыбыз да, теләгебез дә булмады. Дөньялары җитешләргә еласалар да ярый. Ә безгә андый «бәхет» тәтемәде. Әтиең белән тормышыбызны көйләргә, сезне бүтәннәрдән кимхур итмичә үстерергә кирәк иде. Без дөньяны юктан бар иттек, – диде ул.

Әткәем, кадерлем минем! Син дә бит кызың кебек иләс-миләсрәк булдың. Әллә ниләр вәгъдә итеп, кайларга гына чакырмадылар, нинди генә эшләр тәкъдим итмәделәр, көтүеңнән һәм чыбыркыңнан аерылмадың. Әйтүеңчә, ул чыбыркы тылсымга ия. Үзеңнең бар яратуыңны чыбыркыга да кушып үреп, тылсым өстәдеңме әллә?

Бәлки, күрүем соңгы тапкырдыр дип, урманда, болыннарда йөрим.

Әнә, тал сызасы. Монда без балан җыярга йөри идек. Әнә, кыр станы. Монда мин кечкенә чагында хуҗалык сыерларын җәйләүгә куалар иде. Әнә, андыз аланы. Андыз җыяр өчен әллә кайлардан кайталар иде. Җыйган саен күбрәк үсә иде. Бу иңкүлектә шомырт, карлыган күп. Күрәм, хәзер берәү дә җыймый аларны. Берәү дә көтү кертми, чөнки хуҗалык сыерлар асрау белән шөгыльләнми. Тоташ чытырманлыкка әйләнгән, усал кычытканнар баскан.

Кулларымны, аякларымны яндыра-яндыра аларны аралап, алга атлыйм. Чытырманлык икегә аерылып, сукмак барлыкка килә. Димәк, болыным мине көткән.

Менә болыным да. Берни үзгәрмәгән, шул килеш. Урман эченнән аккан чишмәгә кадәр челтер-челтер килеп ятуын белә. Ник бу чишмәгә суга килмиләр? Әллә Табигать-анабыз, урман җәнлекләре өчен саклап, кешеләр күзеннән яшерде микән?

– Исәнме, чишмәкәй, – дип, суында кулымны юам, битләремә сибәм, уч тутырып, көмеш су эчәм. Бу суның шифасы зур. Бала чагымда чикләвек ватып, тешемне сындырган идем. Чишмә суы эчкәч, аның урынына тагын да матуррак теш калкып чыкты. Ә икенче тапкырында аягымны пешердем. Чишмә суы белән юа торгач, төзәлмәстәй күренгән җәрәхәтнең эзе дә калмады.

Менә мин утырырга ярата торган түмгәк. Бу түмгәктә урмандагы барлык җәнлек-җанварлар да утырып ял итәдер кебек. Янына ук килеп җитмичә, ул күзгә дә күренми. Табигать-ана аңа баскыч киртләп куйган, ул һаман да минем бала чагымдагыдай үзгәрешсез тора. Кеше кулы эшләгән баскыч мондый булмый.

Баскычтан менеп, түмгәк өстенә утырам. Яшел келәм белән капланган бу өчпочмаклы түмгәктә шундый рәхәт. Гүя ул минем балачагым белән бүгенемне тоташтыручы антенна. Баскычлар нибарысы җиде. Җәннәт белән тәмугны да бер-берсеннән җиде күпер аерып тора, диләр. Хәер, баскычсыз да түмгәккә менәргә була. Тик баскыч бар, бар икән – димәк, кирәк.

Менгәч, түмгәк өсте киңәеп, тагын бер аланга охшап кала. Анда йөзтүбән ятып, бөтнек, мәтрүшкә исним. Мондагы хуш исләр бүтән болыннан аерыла. Бу хуш исләрне тагын да ныграк сулар өчен куе үлән арасына башым белән чумам. Шул чагында әткәм чыбыркысының очы кебек үзем генә белгән, әмма күзгә күренмәгән койрыгым өзелердәй булып тартыла. Берәр урман җәнлеге шаярамы әллә? Алай дисәң, кыргый җәнлекләр кеше белән шаяра беләмени? Гүя кемдер миңа әмер бирә. Башымны күтәреп, якягыма карыйм. Болын буйлап тездән югары чәчәкләрне, үләннәрне аралап, кемдер миңа таба килә.

Ничек килеп чыкты соң ул монда? Каян белгән бу аланны, кем әйткән, кем чакырган? Ул, бәлки, кеше түгел, фәрештәдер. Юк, фәрештә түгел. Ул – Фәрваз.

– Уф, куркыттың, – дим. Әйтерсең, без аның белән аерылып тормаган.

– Ә мин сине көттем.

– Шулаймыни?

– Бу без очрашырга тиеш урын.

– Син минем язмышыммы әллә?

– Юк, минем язмышым җирдә түгел.

– Кайда?

– Бүтән яссылыкта.

– Син чынлап та җир кешесе түгелмени?

– Мин аннан төштем. Сине алырга...

Ул миңа зәңгәр башмаклар бирде. Мин сокланып, тел шартлаттым.

– Бигрәк матурлар!

– Сиңа дигән башмаклар!

– Олырак курчак аягына гына ярый бит алар!

– Ә син киеп кара башта.

Кызык өчен генә башмакның берсен чәнти бармагыма кидертмәкче булам. Таман гына икән.

– Гаҗәп!

– Алар гади башмаклар түгел. Без яшисе яссылыкка алып барыр өчен алар.

Фәрвазның аягында да шундый башмаклар икән.

Фәрваз янәшәмә басты, уң кулымны үзенең сул кулы белән тотып, һавага күтәрде. Без, җирдән аерылып, зәңгәр күккә күтәрелдек.

Мондагыдай күзләрне камаштыра торган яктылык җирдә юк. Җир аста калды, ә без – йолдызлар арасында. Мондый яктылык алардан. Хәер, җирне яктыртучы кояш та йолдыз бит.

Күкрәкне авырттырып, тын кысыла, һава җитми, кайнар мунчадагы кебек эссе. Фәрвазның:

– Ач күзеңне, дөнья бу, – дигән тавышын ишеткәч, курка-курка гына күземне ачам. Юкка курыкканмын икән. Куркырлык берни дә юк. Тирә-якта искиткеч гүзәллек. Күкне берничә кояш яктырта. Алга карасаң да, ян-якка карасаң да, артка борылып карасаң да – кояш. Тик барыбер агачлар, куаклар, тирә-якта үскән чәчәкләрдә җанның әсәре дә сизелми. Күбәләкләр, кошлар гына түгел, чебен-черкиләр дә күренми.

Җирдә ясаган картиналарым да монда. Әллә хәрәкәтләнәләр дә инде?

Рәсемнәрем дә күккә ашкан! Әнә алар барысы да миңа таба килә. Юк, аларга кешеләр яшеренгән икән.

Иң алдан барган, бәйрәм чыршысын хәтерләткәндәй күренгәне безнең янга килеп туктады һәм җәймә сузды.

– Тизрәк ябыныгыз! – диде.

Мин тиз генә җәймәне өстемә каплыйм. Тын алуы җиңеләеп китә. Тәнгә шифалы салкынча һава өрә. Бу җәймә кондиционер кебек!

– Элек синең җаның гына безнең белән була иде. Хәзер тәнеңне дә алып килдең. Син хәзер бөтенләең белән безнең кеше.

Фарваз?.. Ул нишли соң? Аңа карыйм. Ул да мондагы кешеләргә охшап калган.

– Җир кешеләренең өйләре мондый түгел. Ә без җирдәге әкәм-төкәм кебек өйне үзебез белән йөртәбез. Мондый өйләр безгә бик кирәк. Тузган саен яңага алыштырырга туры килә. Син аларны җирдә чагында безгә җитәрлек ясаган да идең...

– Сезгә шуның өчен кирәк идеммени?

– Әйе. Соңгы вакытта планетабыз тагын да кайнарланды. Аны суытырга кирәк. Син безгә кондиционерлар ясарга тиеш.

– Үзегездә ясаучылар юкмыни?

– Моны бары тик җир кешесе генә башкара ала. Бу программа сиңа ана карынында чагында ук көйләнде. Син тоеп яшәгән күзгә күренмәс койрык, мондагылар белән элемтәдә торып, кайчан җитлегүең турында хәбәр бирүче антенна иде.

***

Эсседән беркайда да качып котылырлык түгел кебек. Җир астында махсус җайланган блиндаж сыман корылмаларда да тынга капланырдай эссе. Миңа кешеләр иркенләп тын алсын, иркенләп йөрсен өчен көнне-төнне белмичә, ял итмичә эшләргә кирәк. Мин ашамыйм да, эчмим дә, армыйм да, йокламыйм да. Чөнки җир кешеләре өчен әһәмиятле булган гадәт-сыйфатлар монда яшәүчеләргә бөтенләй хас түгел.

Фәрваз белән шул көнне аерылдым. Үземнең җир кызы булуымны оныттым, әткәем-әнкәемне, туганнарымны сагыну хисе дә миңа ят иде.

Алдымда нибары киндер тартылган рам. Яшәү урыным, яшәү рәвешем шул гына. Мин анда махсус кондиционер-җәймәләр ясыйм. Ясап бетерү белән алар киндердән үзеннән-үзе аерыла һәм аларны тотып карарга да, күтәреп йөртергә дә, өскә ябарга да, кереп яшеренергә дә була.

Тик җир кешесе кайда да җир кешесе булып кала икән. Әледән-әле күңелемне сагыну хисе баса. Ул җылы хисләр рәсемнәргә күчә. Сагыну хисен сагыш алыштыра. Колагымда әткәемнең әкрен генә җыр сузганы ишетелә:

Кай җирләрдә яшәсәм дә,
Сагындырды туган җир...

Минем бу тыныч мәңгелектән, бу хиссезлектән, ялгызлыктан качасым килә. Ә беркөнне кулыма пумаланы тотмаска булдым. Урамга чыктым. Үлән өстенә ятып, болытларны күзли башладым. Чыдап булмаслык эссе дә куркытмады.

Болытлар арасыннан күкне ярып, яшен сызылып үтте. Бер тапкыр, ике... Әйтерсең, ул әткәм чыбыркысы болынны иңләгән кебек уңга да, сулга да еландай бөтерелә, җитезлегенә күз иярми. Әллә инде бу чынлап та әткәм чыбыркысы? Кояшта ялтырап, яшен хасил итә? Юк ла, булмас, саташам гынадыр...

Йа Хода! Монда да шул бер күк икән бит!

Безне биредә каршы алган һәм һәрчак яныбызда булган Гөлфәридәнең куркынган тавышы ишетелә:

– Син нишлисең? Күккә алай озак карап торырга ярамый!

– Ник ярамый?

– Бар бозыклык шуннан килә.

– Нинди бозыклык?

– Төрле хисләр, мәхәббәт, талаш-сугыш һәм үлем.

– Нишләп алар бозыклык булсын?

– Андый хисләр яшәгән планетабызны җылыта. Ул җылылык, йөрәкләребезгә күчеп, гомерне кыскарта торган хисләр тудыра. Без барыбыз да, син дә – мәңге яшисе кешеләр. Күккә озаграк карап торсаң, йөрәгеңне сагыш басар. Ә сагышлы кеше мәңге яши алмый. Аның гомере кыска.

– Ничек яшәргә соң миңа?

– Ул хисләргә ирек бирмәскә, эшләгән эшеңне дәвам итәргә!

Пумалага тотынам. Әйе, бу япмалар кирәк. Юкса, бүтән планетада яшәүчеләрнең кешегә хас булган хисләре, үзләренең галактикасына гына сыймыйча, бирегә дә үтеп керә һәм кешеләрнең күңелендә урын ала. Әлеге япмалар шундый йогынтыны нейтральләштерү өчен дә кирәк. Бу эш белән кулларым мәңге бәйле булса, гомерем дә мәңгелек. Тулы бер планетаның!

Мәңгелек гомер һәм мәңгелек эч пошыргыч шөгыль. Сөймә, сөелмә! Янма, көймә! Кулларымда тулы бер планета гомере. Мондый бәхет ничә миллиард кеше арасыннан миңа эләккән. Димәк, мин бу яссылыкның, бу планетаның Алиһәсе?

Иңнәремә мондый зур бурычны аласым килми. Җил искәндә дә сыгылырга торган камыш кебек нечкә кыз өчен бу артык зур йөк. Иңнәрем озак чыдармы? Күпме түзәрмен?

Бу уйларыма рәсемнәрем җавап кайтара сыман:

– Син беркайчан да үлмәячәксең! Чөнки монда бөтенесе мәңгелек! Син дә мәңгелек!

Җаныма котып салкыннары исә. Мәңге шулай бер урында, башымны да күтәрмичә, кулыма буяуга манылган пумала тотып яшәргә тиешмени? Мәңгелек кабер бу!

Юк, мин мәңге яшәргә теләмим. Мин – җир кызы. Монда үзем генә түгел. Монда җирдә яшәүнең тәмен белгән Фәрваз да бар. Ул да мәңгелек тормышта хиссез яши микәнни? Алай дисәң, җирдә ясаган картиналарындагы җылылыкны каян алган? Аларда бит сагыш та, сөю дә, юксыну да, өмет тә, тагын әллә нинди хисләр бар.

Кайда соң әле ул үзе? Нигә безне аердылар? Мине бирегә алып килде дә берүземне ташлап калдырды. Ник килми ул яныма?

Пумаламны куеп, урамга чыгам. Мондагыдай матурлык җирдә юк. Тирәяктагы агачлар, юллар буйлап тип-тигез итеп утыртылган чәчәк түтәлләре – үзләре бер сәнгать әсәре. Тик бу матурлыкны тотып карап та, иснәп тә булмый. Якынрак килсәң – җил бәрә, әллә аларга да салкын булдыра торган кондиционерлар куйганнармы? Җирдә өзелгән чәчәкләрне озаграк торсын өчен салкын урында тотканнарын ишеткәнем бар.

Җирдәге чәчәк тә – мәңгелекнең бер кисәге, берләре шиңә, яңалары үсә. Табигатьтәге туктаусыз алмашу процессы – җирнең мәңгелеге.

Һәр куак, һәр үсенте, хәтта кешеләр белән дә шулай. Җаннары мәңгелеккә иңә, алар урынына бүтәннәр килә, табигать мәңгелек хәрәкәттә, яңарышта.

Әгәр җирдә тормыш шулай мондагы кебек тукталып, кешеләр шулай мәңге тораташтай калсалар? Тереләр, әмма йөзләрендә нур юк, янмыйлар, көймиләр, сөймиләр, аның каруы алар мәңгелек.

Минем түтәлдәге чәчәкләргә кулым белән кагыласым килә. Нинди материалдан ясалганнар икән? Юк, мондагы салкын безнең февраль салкыннары кебек түгелдер әле. Ике араны кисеп торган күзгә күренмәс чикне үтеп, шунда атлыйм.

Менә беренче түтәл. Ипләп чәчәкләрне сыйпыйм. Чәчәкләр, шуны гына көткәндәй, таҗларын селкетеп тирбәлә башладылар.

Алга атладым.

Тик миңа табигатькә җан өрергә ирек бирмәделәр. Гөлфәридә йөгереп килә, ашыга, кабалана, инәлеп-инәлеп кычкыра:

– Тимә! Без сине моның өчен чакырмадык! Алар хәзер һәлак булачак. Син аларны мәңгелек йокыларыннан уятасың!

Кая киткән аларның сабырлыгы? Җир кызыннан бер дә аерылык түгел үзен!

– Уятса, ни булган?

– Алар кибәчәк, корыячак.

– Яңалары үсәр.

– Алары да шиңәр.

– Тагын яңалары үсәр.

– Шиңгән саен гөл утыртып азапланыргамы?

– Мин арыдым, гарык булдым. Хәрәкәтсез мәңгелектән җаным туңды. Күрәсеңме, бармакларым да селкенми. Ә мин мәңге читлек ясарга тиеш.

– Читлек түгел, ә чатыр-кондиционер.

– Барыбер читлек инде!

Гөлфәридә сүз көрәштерүнең файдасыз булуын аңлады. Ул мине җитәкләде һәм җир асты коридорына алып керде. Аннан зур, киң мәгарәгә килеп кердек. Мәгарә салкын, караңгы иде.

Ул мине бүлмәләр буйлап йөртә башлады. Андагы караватларда төрле яшьтәге сабыйлар йоклап ята иде.

– Монда тормыш дәвам итми дип уйлыйсыңмы әллә? Монда да кешеләр хаталанып, гашыйк та булалар, бала да табалар, тик үзләре газапка дучар булалар. Әнә, күрәсеңме бу балаларны? Мәхәббәт нәтиҗәсе алар. Бу яссылыкта закон каты – әгәр аның законнары белән исәпләшмисең икән, рәхмәт көтмә. Туган балалар монда кала, эти-әниләр читләштерелә. Ә баласы булуы турындагы мәгълүмат хәтерләреннән җуела.

Без ятаклар арасыннан йөрибез. Сабыйлар, төрлесе төрле халәттә ятуларына карамастан, кайсы мендәрен, кайсы юрганын кочаклаган.

– Бу балалар мәңгелек йокыга талмагандыр бит?

– Юк. Алар әниләренә тартылу инстинкты юкка чыгу белән уяначаклар.

– Ә чыкмаса?

– Берәрсе генә әнисен хәтерләсә дә, мәңгелек юкка чыга.

– Алар да мәңге шулай хәтерсез яшәргә тиешме?

– Әйе.

– Ә әниләрнең берәрсе хәтерләсә?

– Шулай ук була.

– Бу бит коточкыч!

Гөлфәридә миңа гаҗәпләнеп карады:

– Мәңгелек тормыш коточкыч буламыни?

– Сөймә, сөелмә. Кайгырма, сөенмә. Адәм баласы сөяргә, сөелергә тиеш. Сез дә шул сөю җимешләре бит. Кем сезнең эти-әниләрегез? Кайда алар? Бу сабыйларга кара! Аларны эти-әниләреннән, сөю-сөелүдән мәхрүм итүегезгә йөрәгегез сыкранмыймыни? Яратуга ихтыяҗ аларның геннарында бит. Юкка гына алар мендәр, юрган кочакламаган!

Бичара сабыйларның берсенең башыннан сыйпыйм. Гөлфәридә коты очып, кулларымны читкә этәрергә тырыша. Ләкин соң иде инде. Сабый, уянып, урыныннан сикереп торды да:

– Әни! Әнием! – дип, аңа асылынды.

– Ярамый! Ярамый! – дип кабатлады Гөлфәридә, югалып. Ә үзенең күзләреннән яшь тама башлады. – Ярамый!

Һәм ул, баласын кочаклап, урамга атылып чыкты. Аның күзләреннән чыккан яшьләр җиргә төшү белән чәчәкләргә әверелделәр, тирә-якта талгын җил исте, ул агач башларын сыйпап үтте, кошлар сайрап җибәрде.

Халык мәйданга җыела башлады. Алар безне кочаклап алдылар, үзләренең күзләреннән яшь ага, яшь тамчылары шифалы яңгыр булып җиргә тама. Менә бераздан җил күк йөзенә зәңгәрсу каурый-каурый болытлар алып килде, һәм җылы яңгыр ява башлады. Күк йөзен яшен телеп үтте, күк күкрәде. Юк, бу яшен түгел, бу – әткәм чыбыркысы бит! Әнә Фәйзелгаян әткәм үзенә тоттырган чыбыркыны селти һәм:

– Син – Җир кызы, кысыр мәңгелеккә алданма! – дип, миңа дәшә. Аның тавышы, күк күкрәве булып, бу яссылыкка тарала...

Серле, тылсымлы әткәм чыбыркысы. Син минем талисманым, син ике яссылыкны тоташтыручы күпер икәнсең бит! Мине саклаучы! Мине яклаучы! Мине генәме соң!

Кешеләр бер-берсен кочаклыйлар, бер-берсен эзлиләр, аларның күзләреннән шатлык яшьләре тама.

– Син безне мәңгелек төрмәдән азат иттең, хәзер без дә җир кешеләре кебек иректә булдык, – диләр.

Алар өстендәге кондиционер җәймәләр һавада эреп юкка чыктылар.

Еракта атлар кешнәде, ыгы-зыгы башланды, кыңгыраулар чыңлады. Мондый ыгы-зыгыны кызыл туйларда һәм Сабантуйда гына күргәнем бар иде. Соңгы вакытта җирдә дә яшь кияүләр кәләшләрен кыңгыраулы атларда алып кайта. Әйтерсең лә, халкыбызның борынгыдан безгә мирас булып, ләкин оныттырырга тырышылган гадәт-йолалары котсыз мәңгелектән җылы яңгырдай җиргә сибелә.

Әнә, тояклары җиргә тимәгән, очып кына килгән кыңгыраулы атлар күренде. Бизәкле тарантаста чәчәкләргә төренгән кияү егете утыра, ат тояклары тигән урында кыр чәчәкләре пәйда була. Менә атлар якынайды. Мин сыйпап уяткан кызчык каршы йөгерә.

– Әткәй!

Аттан Фәрваз төште. Ул Гөлфәридәне һәм кызчыкны кочаклап алды.

– Ниһаять, без бергә, – диде ул. – Тулы бер планетаны әсирлектә тоткан мәңгелектән котылдык.

Бәйрәм шаукымы белән миңа игътибар итүче дә бетте. Хәер, моңа мохтаҗ да түгел идем бит. Мин бу яссылык кешесе түгел, мине туган җиремне юксыну хисе басты.

Фәрваз! Аңа карата күңелемдәге хиснең гади генә түгеллеген сизә идем. Ул хис мине биредәге бер урында тукталып калган тормыштан саклады. Ул булмаса, биредә мәңгегә калуым бар иде. Әллә монда булмас та идем микән? Аннан соң әткәм чыбыркысына рәхмәт! Аталар мәхәббәте менә шундый булырга тиеш.

Кем, ни өчен каһәрләнгән бу яссылык?

Күзләремнән яшь коела. Бу – гади күз яше, гөлгә дә, яңгырга да әверелми. Кемдер иңемә кулын куя. Бу – Фәрваз.

– Мин сине яраттым, – диде ул.

– Мин дә.

– Мин сине рухи туганым итеп яраттым.

– Ә мин – җир кызы булып.

– Синең мәхәббәтең – җирдә. Мин җир кешесе була алмыйм.

– Беләм.

– Сине анда көтәләр.

– Беләм.

Гөлфәридә икенче иңемә кулын куя.

– Безнең планета каһәрләнгән иде. Яшен алласы хәтеребезне алырга теләде. Хәтерсез без ничек яшик? Ризалатыр өчен, алмашка мәңгелек гомер вәгъдә итте. Аңлыйсыңмы, берни хәтерләмичә, үткәнсез һәм киләчәксез, бер урында тукталып калган мәңгелек тормыш! Вакыт алга да бармый, артка да китми.

– Сезнең хәтерегез аңа ник кирәк?

– Хәтерсез халык Яшен алласы ни эшләсә, шуңа риза булып тора. Ә без, яшьнәгәндә, янгын чыкмасын өчен, яшен тоткычлар куйдык, яшен чыбыркысын катырак уйнатмасын өчен, болытларны тараттык. Артык кояш һәм йолдызларны үз орбиталарына җибәрердәй җайланмалар уйлап таптык.

Ә ул һаман безне буйсындырырга теләде. Йолдызларны Кояш белән чыгарга, Кояш белән батарга мәҗбүр итте. Шуңа күрә безнең күктә көндез берничә кояш яктырткан сыман булды. Ләкин без барыбер аны җиңеп килдек. Ул планетабызга хуҗа була алмады. Безгә хәтле яшәгән буыннарның тәҗрибәсеннән файдаланып, төрле ысулларны камилләштердек. Бер генә агачка да, бер генә җан иясенә тияргә дә ирек бирмәдек. Тик ул бик хәйләкәр, барыбер безнең хәтерне юкка чыгарды. Тормыш бер урында туктап калды. Үзе теләгәнчә хакимлек итә башлады. Җирдә коточкыч эсселек башланды. Без аңардан җәймә-кондиционерларда гына качып тора ала идек. Ә күңелдә боз кебек салкынлык... Анда шуннан башка берни дә юк...

Ләкин ул минем дә, Фәрвазның да бер-беребезгә мәхәббәтен бөтенләй үк хәтердән чыгара алмады. Вакыт-вакыт бүтәннәр дә, онытылып китеп, андый хисләрне хәтерләделәр, яраттылар, нәфрәтләнделәр, кайгырдылар. Без барыбер Яшен алласына каршы килдек! Безгә үзләрендә Яшен алласы хакимлек итмәгән бүтән җир баласы гына ярдәм итә ала иде. Ә ул мәңгелек тормыш биреп, сине дә үзенә хезмәт иттермәкче булды. Үзеңне яратучы, бер мизгелгә дә онытмаучы әткәң, әнкәң, туган җирең барлыгын искә алмады.

Тиккә генә яңа туган сабыйларыбыздан аермадылар безне. Бала мәхәббәте, ана мәхәббәте, ата мәхәббәте яшәгәндә, хәтер дә яши. Хәтер булгач, без дә яшибез. Чөнки хәтер ул – үзе үлемсез!

– Миннән башка бүтән кеше юк идемени? Минем кай җирем бүтәннәрдән артык?

– Без сайлап тормадык. Бу миссия синнән башка бүтән теләсә кайсы балага да тапшырыла ала иде.

– Алайса, минем бүтәннәрдән бер җирем дә артык түгел?

– Түгел, әлбәттә. Син дә башкалар кебек гап-гади кеше. Сезнең җир кешеләре барыгыз да шундыйлар – нәкъ бездәге кебек. Тик сезнең арада да вакыт-вакыт хәтерегезне югалттырырга тырышучылар килеп чыга. Сезгә дә сак булырга кирәк. Ярдәм кирәк булса – тартынмагыз, сорагыз. Без һәрвакыт булышырга әзер.

Ул минем алдыма рамга тартылган киндер һәм пумала-буяулар куйды.

– Йөрәгеңә кайсы якын – шуны яса, – диде. – Әгәр планетабызны якынрак тапсаң, бәхетле гомер итәр өчен бөтен шартлар бар. Син бездә дә үз кеше. Аңла, хәзер мондагы тормыш җирдәгедән күпкә яхшырак булыр. Авырлыкларны бергә җиңдек, шатлыкларны да бергә уртаклашырбыз. Без сиңа мәңгелек гомер биреп, планетабызның алиһәсе итәрбез. Син беркайчан да картаймассың, һәрчак яшь калырсың.

Мәңгелек гомер! Мәңгелек Алиһә! Колагымда әткәм тавышы ишетелә:

– Чит җирләрнең солтаны булганчы үз илеңнең олтаны бул, балам! Соңыннан илең үзе үк сине солтаны итәр!

Мин үземнең болынымны, шифалы чишмәмне, шул болын уртасында Фәрвазны ясадым. Тик Фәрваз дигәнем бүтән егет булып чыкты. Бу – Фәйзелгаян бит! Шул үзе, билгеле. Әнә, ул болында каерылып-каерылып, печән чаба. Печән пакуслары күк белән җир арасын тоташтыра торган баскычка әверелә. Менә ул баскыч минем аяк очына ук килеп терәлә. Баскычка аяк басам. Аякларым, үзләреннән-үзләре шуып, аска, туп-туры Фәйзелгаян кочагына алып төшәләр.

Оҗмах та оҗмах, монда да оҗмах. Менә нинди ул җир кешесенең мәхәббәте! Моны вәгъдә ителгән хәрәкәтсез үлемсезлек белән алыштырып буламыни?

Әнә, ак яулыгын җифердәткән әнкәй, түбәтәен кыңгыр салган әткәй йөгерә. Әнә, туй атлары пәйда булды, тантанага килгән халык – олысы-кечесе, бөтен туганнар, дуслар бирелә. Әнә Фәйзелгаянның әтисе сабыр гына, бик канәгать төстә мыегын бора, әнисе аяк астыма ак җирлеккә чәчәкләр чигелгән мендәр куя.

– Төкле аягың белән, кызым! – ди.

Җир әйләнә, күк әйләнә, алар белән әллә үзем, әллә башым әйләнә, әллә Фәйзелгаян белән икебез әйләнәбез – мин моны аерырлык хәлдә түгел, чөнки мин, җирнең иң бәхетле баласы!

ЧАТЫР ТАУДАН ДӨНЬЯ ШӘП КҮРЕНӘ

(Бер сәяхәт тарихы)

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВКӘ 75 ЯШЬ

Унбиш еллар элек, май азакларында, унлап язучыны бер районга әдәбият көненә чакырдылар. Әдип халкы сабыйларча беркатлы бит инде, без дә үзебезне китап җене кагылган укучылар белән очраштырырлар, арада шәхсән үз әсәрләребез турында да сүз купмыйча калмас, һәркайсыбызга ике авыз сүз әйтергә җай бирерләр, дип өметләнеп, ышанып барган идек. Бактың исә, болар ике яшь егетнең яфрак калынлыгы гына китапчыгын үзләренең район типографиясендә район акчасына нәшер иткәннәр дә, хәзер шулар өчен зур сәхнәдән «хуҗа» кешегә мәдхия укымакчылар, берочтан яшь авторларның үзләренә дә, «хуҗага» рәхмәт укып, бил бөгү мөмкинлеге бирeләчәк икән.

– Монда безнең абруй белән уйнамакчы гына булалар бит, – дип кабынып китте берчак күптән «бөек» даны алган Марсель Галиебез. – Безгә спектакльләрнең массовкаларындагы шикелле роль генә каралган.

Мин – рульдә утырып килгән бик «кыйммәтле» әдип. Шул сәбәптәндер, ахрысы, Марсель Гали мине читкә дәшеп алды.

– Башка «бөекләр»гә койрык сыман тагылып йөреп булмас. Әйдә, безнең Азнакайга киттек. И-и, андамы? Безнең Азнакайдамы!..

Туган ягы турында сүз кузгаткан чакта Марсельнең шөпшә сыман очына торган гадәте барлыгын мин күптәннән беләм. Үзебезне кадерсезләүгә дә күрәләтә торып күзне йомып булмый. Шулай да, «сынып төшмим» әле, бәяне арттыру өчен өзеп җавап бирмим. «Бөегебез» яңа җимнәр ташлый.

– Синең юа дигән малны татыганың бармы?

Минем баш кагуга да карамастан, «бөек» үрсәләнә.

– Элекке гасырларда немецлар юаны иң затлы ризык санаган. Аларның рыцарьлары, замокларын ташлап, ел саен йөз иллешәр чакрым арага юа ашар өчен генә җыенып бара торган булган. Үзең тарихи романнар язган буласың, шуны да белмисеңме? Немец ашаган икән, татарга мең фарыз. Ә Чатыр тауда юаның иң өлгергән чагы. Казаннан Разил белән Гәрәйне дә дәштем. Әйдә, киттек. Чатыр тау юасын бер татысаң, син яңадан аңа мең кат киләчәксең.

«Әй, йөз илле чакрым олы арамыни? Чукынсын дөньялары, әйдә, киттек», – дидек тә, «корыч айгырны иярләдек» тә без.

Бу районнан чыккан гына идек, җен алыштырып куйгандай, чиләкләп, яңгыр коя башлады, бар дөньяның асты өскә килде. Азнакайга чаклы әле Мөслим аша үтеп китәсе бар. Юл дигәне асфальт асфальтлыгын, әмма торбадан аккан шикелле шыбырдаган яңгыр астында аны юньле-рәтле күреп кенә булмый. Мәгәр без кире чигенүне белә торган «камыр аяк» түгел, үҗәтлек баштан ашкан, күлдәвекләр эченә чума-йөзә сыптырабыз гына! Янда Марсель ара-тирә аваз биреп ала.

– Син чамала, егет, татар халкын берьюлы ике «даһи»дан мәхрүм итә күрмә.

Һич югы шундый минутта булса да, үзе белән рәттән куйган өчен мин сөенеп алам. Ул, чыннан да, хаклы, мондый юлда авыз ачып йөрсәң, үзе әйтмешли, «кәңкәеп» куюың бар. Мин һәр чокырны чамалап, артыгын кызмый барам. Каенана холыклы Марселебезгә бу да ярамый. Сәгатенә күз ташлый да тагын бимазалый.

– Без болай мыштырдап барганчы, Разил белән Гәрәй Чатыр тау түбәсен ялтыратып чыкмаса ярый инде.

Бүтән чара калмагач, мин чокыр-чакырларны, канау читләрен «сыйпап» бара башлыйм. Зиһендә, теләсәң-теләмәсәң дә, «бөек» Марсель Гали белән танышкан еллар карындагы сабый сыман уянып-тибеп ала.

* * *

Без аның белән этле-мәчелерәк – ырлашып һәм тырмашыбрак танышып киттек бугай.

Мин Чаллыда яшим, ә Марсель ул вакытта «Казан утлары»нда эшли. Республиканың төрле төбәкләрендә яшәгән унбишләп авторны 1985 елның декабрендә яшь прозаиклар семинарына чакырдылар. «Казанга иң өметлеләрне генә җыялар, һәр авторның кулъязмаларын, ким дигәндә, ике өлкән язучы укып чыга, файдасы зур булачак», дип кисәткәннәр дә иде. Мин аңа чаклы ук инде Язучылар берлегенә «Ир канаты» исемле повесть белән унлап хикәя җибәреп куйган идем. Аларны Гариф абый Ахунов белән Рашат Низамиев «ерып» чыккан икән. Хәзер инде мин фәкыйрегез килеп җиткәч, Бауман урамындагы Матбугат йортының бер бүлмәсенә бикләнеп утырабыз, Гариф абый белән Рашат шунда минем «бөек» әсәрләрне сүтә. Кулъязмам турында сүз һәм бәя алданрак та ишетелгән бугай. Берзаманны безнең бүлмә ишекләрен бер көтү ир каерып ачты. Ринат Мөхәммәдиев, Марсель Гали, Мәгъсум ага Хуҗин, Камил Кәримов, Мансур Вәли... Сөрән салган сыман кычкыралар болар.

– Семинарда яңа талантлар ачабыз, дип шапырынган идегез, йә, ачтыгызмы соң?

Шул чагында Марсель Гали үтә вәкарь төртмәсен өстәп куя.

– Минем сымак берәр бөек бармы?

Әлбәттә, мин су капкандай тынсыз гына утыруны беләм, җавап сүзен Гариф абый тота:

– Яңа талант ачтык. Синнән ким булмаган бөекләр бар, Марсель.

Кәмит уены бетте, болар юкка чыкты. Ә безне, «экзекуция»гә мәҗбүр ителгәннәрне, Тукай клубына җыеп, хөкем укыдылар. Шунда унбиш автор кулъязмалары арасыннан фәкать үз әсәрләремнең генә аерым җыентык булып чыгачагын белдем...

Ничәдер айдан соң китабым дөнья күрде. Шул җәйдә үк яшьләрнең «Идел» лагерена җыйналып, төннәрне кайнар учак янында бәхәсләшеп үткәрдек. Ул бәхәсләр әдәбиятчылар өчен беркайдан да укып-табып булмас олы мәктәп иде, андый җыелулар бүгенге яшьләрнең төшенә дә керми.

Марсель Гали – бүген иң якын каләмдәшләремнең, дусларымның берсе. Бер-беребезнең фатирларында кунак булгаладык. Мин фәкыйрегезнең әллә ничә әсәре турында тәнкыйть түгел, хуплау сүзе язды. Ә «Утлы дала» романы дөньяга килгән өчен мин, иң беренче чиратта, аңа бурычлымын. Чыңгызхан язмышы турында зур күләмле роман язарга җыенып йөрүемне белгәч тә, «бөегебез» миңа Хара-Даван атлы калмык эмигранты алтмыш ел элек иҗат иткән «Чыңгызхан – бөек җиһангир» дигән әсәрнең, Югославиягә баргач, үзе өчен дип күчертеп алдырган нөсхәсен әле сиксәненче еллар ахырында ук бүләк итеп бирде. (Бу әсәр Рәсәйгә рәсми юллар аша биш-алты елдан соң гына кайтып керә алды). Мин татар әдәбиятында иптәшенә бу рәвешчә ярдәм кулы сузган әдипләрнең исемен хәтерләмим...

* * *

Азнакайның хакимиятенә килеп керсәк, Марсель Гали дөрес чамалаган – соңга калганбыз.

– Хакимебез Казан кунакларын алып, әле генә ресторанга китте, – ди кизү торучы хатын.

Марсель өйрәткән кыска юл буенча алга сыдырабыз. ГАИ тезгән тыю билгеләренә игътибар биреп вакланулар бетте, унлап кагыйдәне бозып уздык бугай. Ниһаять, оҗмах капкасы сыман кадерле ишегалды. Таныш машиналар. Ике-өч баскычны берьюлы сикереп ашыккан «бөек»кә ияреп, ресторанга узам. Район хуҗасы Әнәс әфәнде киң кочагын җәеп каршы ала. Разил Вәли белән Гәрәй Рәхим, билгеле ки, шунда. Болардан тыш, әле тагын Дәүләт Советы депутаты Рөстәм Зәкуанов та кайтып төшкән икән. Терсәккә чаклы пычракка баткан кулларыбызны чайкап, без дә кушылабыз...

Кабат урамга чыкканда, төнге уникеләр тулып килә иде. Без Азнакайдан унбиш чакрымлап читтәге «махсус тыюлык»ка, төн кунарга барачакбыз икән.

– Президент аппаратындагылар гына туктала торган затлы, шәп урын ул, безне шулар дәрәҗәсенә куеп, кунак итмәкчеләр, – дип, «бөегебез» масаердай форсатны ычкындырмый.

Каен урманнарын ера-ера, күл буендагы гаҗәеп шәп йортка барып җиттек. Марсель гел «Азнакай – ул Татарстанның Швейцариясе», дип мактанып йөри иде, төп хикмәте менә кайда икән!..

Затлы йортның икенче катында бильярд өстәле тора, тозлы су сипкәндәй, шунда җыелыштык. «Бөегебез» әле элек тә гел «союзда мин беренче», дип шапырына торган иде, таякларның берсен ул эләктерде. Аңа каршы Рөстәм әфәнде дә, Разил да уйнап карый, юк кына бит, каһәрең, Марсель өстен чыга. Берзаманны Гәрәй дә бильярд кийен кулына алган булды. Мәгәр «иртә уңмаган – кич уңмас» бит инде ул, «корыга» оттырды бу. Ә Гәрәй Рәхим якын-тирәдә булдымы, Марсель аннан көлеп рәхәтләнә инде!

– Бу сиңа Разил янында пүртәфил тотып йөрү генә түгел. Синең бильярд, теннис, шахмат ише шаһлар уеннарын бөтенләй күргәнең юк.

Гәрәй Марсельнең чеметкәләүләрен ыжлап та карамый, кет-кет көлә генә...

Бер уенда мин Марсельне оттым. Кәефе шәп иде, кара көймәде бу. Иртәнге биш тулганчы шарлар тәгәрәттек. Сигездә кабаттан аягүрә бастык. Ишеткән беренче хәбәребез үк кәефләрне кырды.

– Әнәс Исхаковның туганнан туган абыйсы вафат булган икән, шунда китеп барган.

Барыбыздан да бигрәк Марсель Галинең канатлары сынып төште бугай. Байтак вакыт сүз катмыйча йөрде. Ә мин хәтер йомгагын актарып, Марсель белән Әнәс Исхаковны бәйләп торган җеп очларын эзли башлаганмын.

* * *

Иренмәгән берсе гәҗит битләрендә Марсельне «татарның иркә баласы», дип тибеп китәргә тарсынмый. Имеш, Марсель университетны тәмамлауга ук Язучылар берлегендә эшли башлаган да, янәсе ул, хәтта Хәсән Туфан чаклы Туфанның үзеннән калган фатирны эләктергән. Имеш, тәнкыйтьчеләр аңа дистә еллар буе авыр кагылмаган. Янәсе, Марсель җитәкчеләр белән мөнәсәбәттә һәрвакытта оста, шома булган, шуңа күрә ул гел Гагра-Ялталарда гына ял иткән, дөньясының артына тибеп яшәгән икән...

Хөсет җаннар һәм көндәшләре белән бәхәсләшеп тормыйм. Бер генә мисал китерү дә таман булыр сыман. Марсель Гали ун елдан артык Товарищеская урамындагы биш катлы, обком кешеләре өчен төзелгән йортның ике бүлмәле фатирында яшәде. Әле ярый, якташлары юньле, унсигез ел буе район башлыгы булып эшләгән Әнәс Исхаков үзе – шагыйрь кеше. Ул Марсельнең хатын Минтимер Шәймиевкә биреп, бик тиз арада егетебез Чистай урамында төзелеп ята торган яңа йортта бернинди дә эчке эшләр үткәрелмәгән «фатир» алуга иреште. Аңа чаклы якташ нефтьчеләре Марсельгә дүрт томлы сайланма әсәрләр тупланмасын чыгарырга булышкан иде. Марсель шул томлыкларны сатып, «фатир»ны җиренә җиткереп керде. Мин якташлары тарафыннан мондый дәрәҗәдә кадер-хөрмәт күргән башка бер генә талант иясен дә белмим.

* * *

Джип юкка чыккач, «бөегебез»гә иске бишмәтне искә төшергән шикелле минем «әрхәрәй»гә утырырга туры килде тагын. Азнакайга кайтып керүгә үк, әллә нинди Миргаяз атлы егетне эзләргә алып китте.

– Ул – икенче Илһам, аны Чатыр тауга алып менеп җырлатмасак, кайтуның яме булмый, – дип тәкрарлый бит.

Мин һәр районда «Шаляпиннар» белән таныш түгел, «бөек»нең бәясенә ышанып, «ияреп» йөрим инде. Азнакай урамнарында тагын кырык тапкыр кагыйдә боза-боза, «Шаляпин»ның йортын эзләп таптык. Хуҗа кеше үзе өйдә түгел. Марсель мыр-мыр килә.

– Итәк саклап йөри микән, мәлгунь?

«Мәлгунь» ун минут узуга пәйда булды. Илле яшькә җитсә дә, бик тә ыспай, чибәр ир-егет булып чыкты бу. Куллар бирешеп танышуга ук, хакимият бинасы янына ашыгабыз. Анда инде Разил, Гәрәй, Рөстәм Зәкуаннан тыш, Әнәс әфәнде күрсәтмәләр биреп калдырган ярдәмчеләре дә безне көтеп тора. Мәгәр хәлләр агымына болар хуҗа түгел, дилбегәне Марсель үз кулына ала.

– Азнакайга килеп, Татарстанның Швейцариясен күрми калу гөнаһ. Чатыр тауга киттек.

Кул сузымында булып күренсә дә, Азнакайдан ун чакрымда яткан Чатыр тау зур түбәтәй шикелле үзенә дәшеп тора. Бер-бер артлы тезелеп сыптырабыз. Итәгенә җиткәч, «хуҗа» Марсель безне машиналар эченнән йолкып-йолкып ала.

– Бу сезгә Гәрәйләрнең Федотовкасы янындагы сыер белене түгел. Моңа машиналар белән менеп булмый. Аннары машиналар белән менгәч, Чатыр тауның биеклеген сизми дә каласыз сез.

Алай икән, иттиттери! Сулыш кабуларын сиздерергә теләмичә, тирә-яктагы табигать манзарасын күзәтер өчен тукталган булып, кыртлый-кыртлый югарыга таба үрмәләргә туры килә. Югарырак менгән саен сайрый гына Марсель.

– Әнә, тау астындагы чокырга карагыз сез. Уникe суыр йөгерешеп йөри, шуларны күрәсезме? Мин санадым.

Мондый җәнлекләрне башка төбәк халкы байбак дип белә. Ләкин алар барыбер дә үзгә, Чатыр тау тирәсендәге суырлар аерым бер төркем булып яши торган сирәк җәнлек бугай. Ияләшкәч, якын ук килеп йөрделәр, аларны күп күрдек. Ә «хуҗабыз», билгеле ки, алга таба мактануын белде.

Чатыр тауның түбәсенә җиткәч, Марселебез актык нокта куя.

– Татарстанның иң биек тау башында басып торасыз. Күреп калыгыз, моныңише таулар юк бит сездә.

Һәммәбез чамалыйбыз, Марселебез, гадәтенчә, борчак сибә инде. Татарстандагы иң биек нокта Бөгелмә районында. Әмма моны «хуҗабыз»ның үзенә сиздермибез. Әйдә, очынсын ул. Аның мондый бәхетле һәм канатлы минутлары сирәк була. Өстәвенә, Бөгелмә районындагы биек тауны күп кешеләр белми. Ә Азнакай янындагы Чатыр тау калкулыгы һәр кешегә мәгълүм. Аны данга күмгән өчен биеклек үзе фәкать Марсель Галигә генә бурычлыдыр.

– Чатыр тауны Марсель генә ачты, – дип куәтли үзе бу районнан үсеп чыккан Рөстәм Зәкуанов. – Аңа чаклы Чатыр тау турында белүче юк иде.

Әйе, ул алдамый. Марсель һәр әсәре саен Чатыр тауга мәдһия укымыйча урап уза алмады. «Чатыр тау» дигән махсус җырны язып, аны бар татар дөньясына яңгыратты. «Татарстанның Швейцариясе» дигән гыйбарә кертмәсә, гомумән, татар халкы үзенең таулары һәм урманнары белән бу кадәрле горурлана һәм мактана башлар идеме икән?!

Менә, без шушы легендар тау башында гаҗәеп манзарага сокланып торабыз. Ботактан-ботакка күченгән кош шикелле, Марселебез очына-очына сайрый.

– Күрәсезме, әнә тегесе Әсәй дигән авыл. Аннан Нур Әхмәди чыккан. Флёра Гыйззәтуллина да шуннан. Илдус Гыйләҗев – Урсайдан. Нәҗибә Ихсанова белән Әзһәр Шакиров – Ташлыярдан. Барысының да чумып-йөзеп үскән сулары шәп. Мең кат сынаган бар, суга тилмереп яшәгән авылдан шагыйрьләр дә, җырчылар да чыкмый. Талант, тавыш дигәннәре шәп сулы елга буйларында үссәң генә көйләнәдер инде ул...

Марселебез Гәрәй тарафына ук очырып ала.

– Мин дөрес сөйлимме, Гәрәй? Сезнең Федотовка янында чыпчык батып үләрлек тә ерганак юк. Син йөзә дә белмисең бугай.

Һәммәбез дә кет-кет көлешәбез, «даһи» тыйнакланып кына дәвам итә.

– Ну, әнә тегендә качып утырганы минем авыл инде, Балтач үзе...

Без биектән тирә-якны күзәтеп кинәнәбез, Марселебез «хуҗа» дилбегәсен җилкетүне белә.

– Шашлык килеп җитте, аны әнә теге уйсулыкка төшеп әзерлибез. Анда балтырган оясы. Әй, Гәрәй, дим! Ул син күреп үскән затлы нәрсә түгел...

Мәҗлес озак барды. Марсель күптәннән шапырынган «Шаляпин» – Миргаяз Шәрәфиевны да тыңлап кинәндек. Юкка Марсельне гаепләп сөйләнгәнбез, Миргаяз шикелле җырчылар Казанда юк, сәхнә ыгы-зыгысыннан бигрәк, аның артындагы чүп оясына, ызгыш-талашларга керәсе килмәгәнгә күрә шушы мәшһүр баритон иясе район үзәгендә яшәп ята икән. Илһам Шакиров бу якларга килеп чыга калса, Миргаязны сәхнәгә үзе белән янәшә бастырып җырлаттырмый китми. Ләкин һәрбер талант иясе шикелле үк, моның да кадере юк. Егетне мәдәният йортында юк-бар сәдакага сәнгать җитәкчесе итеп тинтерәтәләр икән...

Мәҗлес тәмам, иплəп-иплəп, аска юнәләбез. Чатыр таудан аерыласы килми, күңелдә зур моңсулык.

Чатыр тау итәгендә мин Марсельнең яңакларында күз яшьләре күрәм.

* * *

Учак янында сөйләшмәгән сүзләр калмады да сыман. Ә минем хәтердә, җилдәге ут сыман, Марсельнең «Казанымның җиде капкасы» дигән җыры гел лепелдәп ала. Шушы җырын бер ел буе машинаның магнитофоныннан алмыйча тыңлап йөргән идем. Аның «Су буеннан әнкәй кайтып килә» җыры инде кырык ел буена телебездән төшми, күңелләрдән китми! Аның «Шәрекъ кызы», «Кайту», «Казанымның җиде капкасы» җырлары да тагын дистә еллар буе дистәләгән шигырьчеләрне көнләштереп яшәр һәм Марсель алар яныннан узып барган чакта чүгәләргә мәҗбүр итәр әле!

Шунысы гаҗәп: шагыйрь җанлы кеше булса да, Марсель Гали гомере буе татар тарихына мөкиббән китеп яшәде. Мин үз милләтенең узган тарихы өчен бу чаклы да сызланып һәм ачынып яшәүче башка шагыйрьне белмим. «Карпат тауларыннан алып Татар бугазына чаклы җәелеп яшәгән татар» дигән гыйбарәне безнең тарихчылар һәм гомуммилләт теленә Марселебез кертте. Ул – Чыңгызхан, Сүбүдәй, Аксак Тимер, Туктамыш, Ногай морза язмышлары, Алтын Урда тарихы белән җенләнеп беткән кеше. Хара-Даванның хезмәтен татарчага тәрҗемә итеп, «Идел» журналында фәкать ул бастырды. Заманында Казан тәхетен тоткан Олуг Мөхәммәдләр, Латыйф, Илһам, Сафа-Гәрәй, Ядегәр хан – һәммәсе дә аның өчен газиз, якын булды. Чөнки Марсельнең күңелендә-җанында тик бер учак яна – бүгенге татарны да Алтын Урда, Казан ханлыклары биеклекләренә күтәрәсе килү. Аның Чатыр тауга балачактан купкан мәхәббәте дә үзенең милләтеннән аерылмаган көе биеклеккә омтылудан килә.

Марсельнең публицистикасы башка бер әдипләр язмасы белән янәшә китереп куярлык та түгел. Марсельнең публицистикасы да җыр юллары сыман, чишмә суы сыман челтерәп бара. Гыйбрәт өчен аның «Догалы еллар»ын гына уку да бик җитә. Анда тупланган газиз милләтеңнең ачы язмышы, үзара тыныша, юл куя белмәгәнгә күрә коллыкка төшеп мескенлектә яшәве Марсель йөрәгеннән агып чыккан гарьләнү һәм сабак яшьләре!

Аның инде мәрхүм булган Аяз ага белән берлектә Испаниягә баргач күргәннәрен тасвир итүләре хәтеремнән мәңге җуелмас, китмәс сыман. Газиз халкы өчен юл аралаш елап гарьләнүләр. Дөрес яза Марсель. Азатлыгын, илен җуйгач, татарның бүген Барселона белән Севильялардагы шикелле мәһабәт соборлары, чит-ят милләтне көнләштерә алырдай таш сыннары, дөньякүләм шедевр булырдай рәсем полотнолары да юк шул. Урак-чүкеч тоткан игенче йә сөт чиләге тоткан савымчы сыннары һәм «Коммунистик хезмәт ударнигы» значогын таккан буш рәсемнәр белән Европаны шаккатырып булмый. Милли биюләреңне дә испан болеролары югарылыгына күтәрерлек түгел, аларны башкару өчен мунча ләүкәсенең мәйданы да җитә, чөнки һәрбер биюченең адымыннан коллык белән тарлык саркып тора. Их, татар рухын, аның мин-минлеген янә Алтын Урда чорларына кайтарасы иде дә бит, Чыңгызханнар, Ногай морзалар, Олуг Мөхәммәдыләр күге, алар горурлыгы җитми бүген безгә!

Язу өстәле янына барып иңгәч, Марсель үз каләмен тыеп та тормый сыман. Күңелендә ни бар, шуны учлап сибә. Шулай булмаса, ул үз күңелендәге генә түгел, ә бар милләткә хас беркатлылыкны да алай ансат кына ачып салмас иде. Аларның Аяз абый белән бергә Испаниядә үткәргән соңгы кичен хәтерләгез әле. Официант өчме-дүртме шешә сыра китереп биргәч, «монысын күргән бар ла, испан хәмерен авыз итеп калу күпкә шөһрәтлерәк», дип, бу «осталар» үтә дә нечкә «хәйлә»гә керешәләр. Сыра шешәләрен кире биреп, катырак эчемлек китертә болар. Аннары официантны «төп башына утыртканнарына» нык сөенеп, кет-кет көлә-көлә рәхәт чигәләр соң! Татардагы барча беркатлылык, сабыйлар садәлеге менә шушы күренештә уч төбендәге сырлар шикелле ачык ярылып ята. Артык та түгел, ким дә түгел, һәммәбез дә шундый: күршенең әле тишелергә өлгермәгән иске кәвешен өч тиенгә сатып алдык исә, алтын каурыйлы кош тоткан шикелле тилереп сөенәбез. Бу яман чир әле булса каныбыздан китми. Әнә, Казан юбилеена илбаш килгәч, аның ике-өч сүзне татар телендә вата-сындыра әйткәненә дә дәүләт азатлыгы алган сыман сөендек бит әле. Әйтерсең лә, Россия Президенты татарча эндәште дип кенә безнең милләт өстенә алтын-көмеш ява.

Марсельнең «Догалы еллары» – ул элеккеге тәүфыйклы заманны, әз булса да рәте-чираты булган сиксәненче елларны сагыну да сыман. Юк, Коммунистлар партиясен сагыну түгел инде, ә итагатьле, гамьле, талантларның абруйлы, җитәкчеләрнең ваемлы вә намуслы заманын сагыну иде сыман. Чөнки бүгенге мәхшәр белән тәртипсезлек үзәкләргә үтте. Хәзер карак белән бай гына зур пачутта. Талант ияләре белән асыл кешеләрне канау читенә төртеп китерделәр. Югыйсә мәчетләр төзиләр, муллалар пәйда булды, никахлар укытып ярәшү башланды, ә чынында исә, догасыз еллар хөкем сөрә бүген. Ил дигәнең доганы белмәгән, иманны оныткан миһербансыз хуҗалар кулына торып калды. Моны яңартасы, җанны әчеттергән гаделсезләргә үзгәрешләр кертсәң иде дә, ни аяныч, офык читендә Олуг Мөхәммәдләр, Акай-Кучемнәр, Гаяз Исхакыйлар гына күренми шул...

* * *

Әнәс Исхаков хакында «төш вакытларына кайтып керүе бар», дип кисәтеп куйсалар да, кабат күренмәде, ул туганының җәсәден зиратка тикле озатырга киткән. «Хуҗа» Марселебез хәзер инде безне бөтен районны айкап чыгарга дип алып китте. Илбәк авылында яңа мәктәп корып куелган, Татар Шуганында урамнарны, күперләрне яңартканнар икән. Шуларны күрсәтми калу гөнаһ саналыр шикелле, яңа «хуҗа» авылдан-авылга өстерәп быжгыта гына бит. Кичкә таба ияк өстенә тел салынып төште. Туйдыруын сизеп алды бугай, янә авырткан бармакка китереп басты теге.

– Бездә нефтьчеләр йөз дә җиде чишмәне төзекләндереп, яннарына нәни-нәни йортлар корып чыкты. Сезнең якта моны белмиләр дә. Мәсәгут авылы ягында, әнә, җиде чишмәне бергә кушып куйдылар. Күз алдыгызга китереп кенә карагыз. Җиде яктан җиде чишмә агып килеп кәрә бер чокырга, икенче яктан ташкын сыман булып

ялгыз чишмә генә агып чыга. Гәрәйләрнең Федотовкасында, вапшы, чишмәләрне карый белүче юк. Бу чишмәне күрсәтмичә булмый, әйдә, киттек.

Сүз көрәштереп, баш тартып маташуның мәгънәсе юк. Инәгә тагылган җеп шикелле, моңа иярәбез. Чыннан да, җиде чишмә бергә килеп кушылган тарихи урынга китереп, ушсыз калдыра бу. «Инде янә кая алып барыр?» дип хафалана башласак, сизеп алган икән, майлы табага саласы борчак урынына иләүләрдән тәки туктады бит.

– Давай, Җәлил бистәсе янындагы соңгы чишмә янына гына барып җитәбез дә шунда аерылышабыз.

Барып җиттек. Талгын чишмә челтерәп агып ята. Гаҗәеп матур урын. Ышыккарак тезелешеп утыргач, әле берәү, әле икенчебез төрле-төрле җыр башлаган була. Гәрәй Рәхимгә ияреп, «бардым күлгә, салдым кармак»ны суза гына башлаган идек, вәкарь «хуҗа» шундук шып туктатты.

– Сез керәшен җырының тәмен Гәрәй шикелле үк белмисез, җәмәгать. Юылмаган кул белән казанга кергән шикелле, аны керләндермәгез. Керәшен җырларын елатырлык итеп, Гәрәй үзе генә җырлап бирә ала.

Шушы пассаждан соң, Гәрәй тарафына махсус бер үтенеч.

– Син теге рекрутлар җырын бик шәп башкарасың. Әйдә, шуны җиффәр.

Мин Гәрәй репертуарын ишеткән кеше түгел, авыз ачып көтәм. Гәрәй сузып сала.

Биек кенә ләй тауның башларында
Микәй Пауллары бау ишә.
Керәшен халкын нигә рәнҗетәсең,
Татар беткәнмени, падиша?!.

Мин, ярты гомерем буе тарих белән җенләнеп яшәгән кеше, шушы җырны тәүге тапкыр ишетеп, тораташтай калам. «Бөегебез» күз кысарга онытмый, ул аны, бактың исә, мин наданга ишеттергән икән.

Монысы артыннан башка җырлар калка. Миргаяз Шәрәфиев нәкъ Илһамча итеп «Карурман»ны суза.

...Карурманны чыккан чакта
Кисеп алдым куш каен,
И-и, аерылмаек, дускаем...

Уй-хыяллар борынгы чорларга алып китә. Чукындырудан карурманнар эченә кереп качкан газиз бабаларыбыз күз алдына килә. Өч тиенлек бакыр хакына яртышар ел буена шалаш-землянкаларда торып газап чиккән лашманчылар йөгерешеп үтә. Шушы ук урманнарга качып илне дер селкеткән Мәсәгут Гомәров, Бәхтияр Канкай, Нагайбәк Хәсәновлар күтәргән азатлык әләмнәре үз янына дәшә... Берзаманны керфекләрем ачсам, Гәрәй, Разил, Марсель, Рөстәмнәр, кочаклашып баскан көенчә, һәммәсе дә елый. Аеруча Марсель өзгәләнә. Күңелендә бәхетсез милләте өчен сызлану да бардыр. Туган туфрагының җылысын тоеп тору, безгә сый-хөрмәт күрсәтә алган өчен шатлану да бардыр…

Вахит ИМАМОВ

Бу QR-код аша сайтыбызга кереп,
Марсель Галиев шигырьләрен һәм
аның шигырьләренә язылган җырлар
тыңлый аласыз.

Авылымның башлангыч мәктәбе.
Беренче рәттә сулдан җиденчесе мин.



Студент чак. 1970 ел.

Наис Гамбәр,
Нәбирә Гыйматдинова,
Фәннур Сафин,
Марсель Хәйретдинов,
Мөдәррис Әгъләмов,
Марсель Галиев. 1979 ел.

Рөстәм Мингалим, Рәисә Ишморатова, Марсель Галиев, Җәвәһирә Сәлахова,
Гәрәй Рәхим, Мәхмүт Хәсәнов. Азнакай, 1978 ел.

Әмирхан Еники өендә. 1990 ел.

Каләмдәшләр: Марсель Галиев, Гәрәй Рәхим, Равил Фәйзуллин, Айдар Хәлим. 2012 ел.

Фәндәс Сафиуллинда кунакта. Наил Камбиев, Фуат Рафиков, Рафаэль Сәхабиев, Разил Вәлиев, Гәрәй Рәхим, Марсель Галиев, Фәндәс Сафиуллин, Халит Вәлитов. 2011 ел.

ҮЗГӘ ДӨНЬЯ СУРӘТЕ

НӘБИРӘ ГЫЙМАТДИНОВАГА 65 ЯШЬ

Татарстанның халык язучысы Нәбирә Гыйматдинованың иҗаты классик совет әдәбияты чоры тәмамланып, яңа дәвер әдәбияты килүен хәбәр итүчеләрдән булды. Узган гасырның 90 нчы елларыннан алып, бүгенге көнгә кадәр актив иҗат итүче язучыларыбызның берсе буларак, ул эзлекле рәвештә әдәбиятта үзе салган сукмакны киңәйтә, укучылар аудиториясен яңадан-яңа образлары, үзенчәлекле сюжетлы әсәрләре белән сөендереп тора. «Нәбирә Гыйматдинова повесть жанрына тугрылыклы автор. Елга бер мәртәбә повесть бастырмаса, Нәбирә Нәбирә Гыйматдинова булмас иде», – диюе белән Л.Лерон тулысынча хаклы.

Аның соңгы елларда язылган «Нурулла» бәяны проблема куелышы ягыннан да, әдәби алымнар кулланылышы җәһәтеннән дә аерым игътибарга лаек. Әсәрдә татар иренең аң төпкелендә язылган тыйнак-горур, заман шаукымына буйсынмас асылы ачылу тарихы сөйләнелә. Нурулла белән бәйле вакыйгалар аша автор кешедәге курку хисенә бәя бирә, курку хисен тормышка, кешеләргә, сөйгән ярга мәхәббәтне тану гына җиңә ала, дип раслый. Бәян экзистенциаль мотив белән өретелгән: төп герой Нурулла тарихы яшәү-үлем чикләрендә бирелә. Клиник үлем кичергән Нуруллага авылдашлары Әүлия дигән кушамат тага. Мәдәни герой образы алга чыгарыла: җиргә җаны-тәне белән береккән Әүлия-Нурулла бетү юлына чыккан авыл-колхоздагы иманны тергезү өчен фани дөньяга кайтарыла. Аның рәислектән алынуының сәбәбе «авылыбызга дуңгызларны кертмибез», дип, чаң сугарга йөрүе белән бәйле булса, янәдән хуҗа булгач, Нурулла берникадәр куркып кала: «Аннары ул үзе дә икеләнә башлады. Буяласы буялган инде... Әллә тимәскә микән? Хуҗалык өшәнгән, җирләр сөрелмәгән, сыерлар картаеп, сөтен киметкән иде. Бердәнбер карап торган нәрсә – шушы тукмак борыннар». Авыл-җәмгыятьне хәрәмнән тыелу, иманга килү генә коткарып кала ала, дигән автор карашы әрвахлар тавышы – Киләхмәт бабай сүзе кебек ишеттерелә. Нәсел-буыннар сөйләшүе төш, үлем саташуы алымнары, Чурайбатыр атамасы аша мәгълүм миф белән тоташтыру, Әүлия кабере дип бирелгән урын образын сакральләштерү аша бирелә.

Субъектив образ – хикәяләүчесе ярдәмендә автор «тавышы» яңгыратыла, буыннардан килгән милли яшәеш фәлсәфәсе үткәрелә.

Үз туеннан качып киткән, ләкин шул ук вакытта үлем ягына борылган сөйгәнен фани дөньяга кайтарган Туйбикә-Нурулла сызыгы романтик яссылыкта сурәтләнә. Әдәбият галиме Д.Заһидуллина Н.Гыйматдинованың 1980-2000 нче еллар иҗатын анализлап, аның әсәрләрендә романтик геройларның вазифаларын тәгаенләштергән иде. Бу әсәрдә язучы реалист Нурулланы олы хисләр, яшерен әрнү-сызланулар ярдәмендә «чистарта», романтик итә. Чөнки Нуруллага йөкләнгән миссияне – авыл һәм җәмгыятьне гөнаһ баткагыннан тартып алуны реалист герой гына башкарып чыга алмаячак. Әсәрдә романтик сызык авторның мөнәсәбәтен күрсәтү өчен кирәк булып чыга. Әйтелгәнчә, Нурулла-Туйбикә сюжеты шушы йөкләмәне үти. Табигать тарафыннан идеаль чынбарлык кору өчен салынган көчне тою кешене бәхетле итә – гармониягә якынайта, ди автор. Кияүне каршылаган яртылаш бөкрәйгән «ананың чырае болыт сарган сыман караңгы иде». «Туйбикәбез кичәгенәк зур укуларга дип,

Казанга китте» дигән сүзләр Нурулланың «гәүдәсен тораташка әйләндерә», «ул телен дә көчкә кыймылдата». «Күзен хәсрәт элпәсе каплаган» Нурулла башка сыймаган гамәл кыла – юлында беренче очраган кызга өйләнә, шулай үзеннән кача, кальбенә гамьсезлек, курку хисе кертә. Гамьсезлек – кешенең матур хисләрен үле хәлгә китерергә сәләтле халәт. Укучы күңеленә курку хисе кешедәге иң матур тойгыларны җимерә алучы, аны түбән тойгыларга таба боручы көч, дигән хакыйкать урнаша. Әмма күңелендә курку хисе урын алган кешеләр асылда үзләрендәге бу хисне күралмый, аның табигый түгеллеген белә, хөрлеккә, бәйсезлеккә ирешү юлларын эзли. Тыйнак, басынкы, «мыштым» Саҗидә Нурулланың йөрәгенә тирән оялаган әрнүләрне, билгеле, баса алмый, Туйбикә турындагы хыял берөзлексез ирнең күңелен тырнап тора, ымсындыра, кызны күрүгә, ир заты янәдән үз асылына кайтырга омтыла.

Н.Гыйматдинова кешегә үзгәрер, дөрес юлга чыгар өчен бирелгән мөмкинлек бирелгәнлеге турында кабатлап әйтә. Туйбикә үлеп барган Нурулланың тәнен яшәү ягына алып чыга, ләкин җанын коткару өчен яратуын таныргa өйрәтергә кирәк, шуңа шарты да катгый: «Өйлән миңа, Азизов, минем капризым шул». Шул рәвешле, күңелдәге мәхәббәт хисен танып, аның өчен җаваплылык тоеп яши башлаганнан соң гына ир заты горур-буйсынмас холкын кайтара ала, үзенә ышанып яши башлый. Нурулла аң төпкелендә моңа әзерме соң: «моңарчы яшәлгән гомер»не «балта белән чабып ыргытып булмый», ләкин «яраткан кешеңне сагынып узган елларны да гамәлдән сызып булмый. Булмый! Берни эшләп булмый!» Шул рәвешле, югарыда китерелгән фикерне җөпләп китик: әсәрдә йөрәктәге курку хисен тормышка, кешеләргә, сөйгән ярга мәхәббәтне тану гына җиңә ала, дип дәлилли әдибә. Кешелек горурлыгын гамьсезлеккә алыштырып, аны бер тапкыр әйләнеп үткәннәргә – яшәеш тәртибен курку хисенә көйләгәннәргә тормыш-яшәеш төзәлү мөмкинлеге бирми дип, Нурулланы янәдән яшәү-үлем чигендә калдыра.

Милли яшәеш фәлсәфәсен әдибә милләт хәтере, нәсел тарихы төшенчәләренә бәйләп аңлата. Татарстандагы иң бай кешеләрнең берсе дип тасвирланган Минһаҗев образы аша нәсел-ыруны инша язу өчен генә барлау, үзенең дөньяга ник килгәнен дә абайламый, иренең исемен дә кыскартып әйтә торга куркак Саҗидә образы аша кем баласы икәнеңне белмичә ятимә булып йөрү проблемалары кабыргасы белән куела: «Дәфтәргә исем теркәп кенә, шәҗәрә ботакларында яфрак бөреләнми ул», – дигән Нурулла фикере автор тавышы кебек кабул ителә.

Шул рәвешле, А.Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» әсәрендә күтәрелгән мотивларны дәвам иттереп, үстереп, Н.Гыйматдинова кеше тормышының мәгънәсе – рухи камиллеккә омтылу, гамәлләреңнен нигезен шул омтылыш белән үлчәү, үлем ноктасыннан бәяләү дип раслый.

Н.Гыйматдинова әсәрләрендә экзистенциаль мотивлар калку билгеләнә. Еш кына өметләрнең өзелүен, рухи бушлыкны кичерү кешене яңа сынау – яшәүне, матурлыкны юкка чыгаручы үлемне кабул итәргә әзерли дигән мотив алга чыгарыла. «Ачкыч» әсәрендә шул ук фәлсәфә тәкъдим ителә. Хикәяләүче сөйләме буларак тәкъдим ителгән автор тавышы: «...бәндәнең күкрәге бик-бик тар итеп яратылган. Тәкъдир бизмәнендә һәркемгә үз өлеше генә үлчәп бирелә. Шуңа канәгать бул, шуңа шөкрана кыл, димәк». Авыл мулласы Йосыфның кан туганы Шакир авылдагы изге урынны ата-баба ядкаре Әүлия тавын бозып, йорт салдыра, таудагы суырлар адәм ыңгырашуы белән елый. Озак та үтми, Шакир, җыйган барлык мөлкәтен комарлы уенда оттырып, йөрәк белән егыла, үлә. Йосыф исә – балта остасы. Ул үз хезмәтен яратып, җиренә җиткереп башкара. Йосыфның үз куллары белән эшләнгән әйберләре аның күңел матурлыгын чагылдыра: «Йа Хода! Нәрсәләр генә юк иде монда! Идәннән түшәмгә кадәр тезелгән биек киштәләрдә кечкенә күләмдәге ишек, тәрәзә, өстәл, урындык үрнәкләре... Тылсымчы кулы һәрберсенә аерым-аерым бизәкләр «чиккән». Яшәешне нәрсә матур һәм мәгънәле итә? Кешенең хезмәте, башкаларга ихлас мөнәсәбәте,

җиренә җиткереп башкарган гамәлләре белән башкалар алдында ышаныч яулавы, дип җавап бирә әдибә.

Шакирны соңгы юлга озатырга килгән Илсөяр язмыш борылышы алдында: «Илсөяр артистмы, әллә тамашачымы? Тамашачы икән, кәмитчелектән туеп, залдан чык. Әгәр артист икән, аның уенны өзәргә хакы юк, ул, җебен җепкә ялгап, ахырга кадәр үз ролен башкарырга тиеш». Автор хикәяләүче теле белән фәлсәфи проблеманы иҗтимагый мотивлаштыра, күз алдына «иман йортларының саны артып, бәндәдән иман югала башлаган замана» – XX гасырның 90нчы еллары килеп баса. Илсөярнең дусты Дамирә теле белән бу хакыйкать даими кабатлана, ул кызын ялагайлану, директорга төчеләнү, ясалма елмаю, ясалма көлү, гайбәт ташу талантына өйрәтергә тырышып карый. Әмма «иҗат колы» Илсөяр ни йорты, ни гаиләсе, ни акчасы булмаган мескен булып яши. Шакир белән танышу «халыкны җырлары белән елаткан» кызны үзгәртә, ир йорт ачкычын артистка Илсөяргә васыять итә. Ләкин Илсөяр йортны инде саттым, инсафлы, тыйнак Йосыфны үземнеке иттем дигәндә, Дамирә бу изге тауны бозып, халыкны рәнҗетеп салынган йортны алудан чиркануын әйтә... Автор тавышы: «Табигатьне адәм заты гына пычрата бит. Кулы белән дә, уе белән дә».

Бу өлештә янәдән инде күп тапкырлар әйтелгән фикерне кабатлыйсы килә. Н.Гыйматдинова иҗатында да мифлаштыру күренешенең колачы сокланырлык. Ислам диненнән мәгълүм детальләрне, әдәби мотивларны уйнату, мәдәни мәйданга чыгару яссылыгында әдибә иҗатын фәнни якын килеп өйрәнәсе бар әле. Ә.Еникиләрдән, М.Мәһдиевләрдән килгән милли-әхлакый нигезләрне саклау проблемасы калку куелган иҗатында әдибә әхлаксызлыкны, диниятсезлекне каракош дип тамгалый, ак торналарның – күңелдәге изгелекнең юкка чыгуына, «уңган халкының кырылганлыгына» сызлана, Минсаралар тавышы болынны кисеп үтә: «Татар – үз-үзен санламаган халык! Һәркайсы үзенчә бәхетле һәм бәхетсез дә».

Н.Гыйматдинова повестьларына фәлсәфи гомумиләштерүләргә алып килү дә хас. «Тәкъдир» әсәре яшәү/үлем бинар оппозициясен үзәккә ала. Утыз биш яшьлек талантлы артистка «әкрен генә үлеп баручы» Нәзирәнең җан халәте ул уйнаган образ – сөйгәненең Әфганстанда үлгәнлеге хакында ишеткән Нуриянеке белән тәңгәл: «Мин исә сәхнә уртасына тезләндем дә сулыгып-сулыгып еларга тотындым. Бәгыремнән актарылган авазлар, һәр хәрәкәтемне күзәткән залны тетрәндереп, бер мәлгә сулышсыз итте. Андый мизгелләр сирәк туа, бит монда ике хатынның фаҗигасе бергә кушылган иде». Ире хыянәтен кичергән Нәзирәгә язмыш мәрхәмәтле кебек, хатын, үзен җуйган хәлдә, Саматны очрата, яшәү серен ача, ләкин «тәкъдирдә язылган роль катлаулырак» булып чыга. Нәзирә сөеклесе белән кавышканнан соң яңа, тагын да авыррак сынау кичерә. Хатынга Чечня сугышында башын салган Саматның улы нәни Саматны тәрбияләргә, тәүге мәхәббәте Илһамның таянычын тоеп яшәргә язган икән. Автор тавышы: «Бер уйласаң, тормыш үзе дә сәхнә, тик аерма шунда гына: син анда үзеңне уйныйсың».

Н.Гыйматдинованың «Тыңла, сөйлим...» повестенда Мәликәнең сакраль/профан чиген үтүе тәкъдир ителә. «Бөтенесенә дә кәҗәләр гаепле иде» дип башланып киткән әсәрдә кабатлау алымы уңышлы кулланыла: төп образ Мәликәнең кушаматы да кәҗә: «Чөнки мин «катымөгезлеләр»нең карендәше идем, минем кушаматым Кәҗә иде». Башка кешеләрдән үзенең нечкә күңелле булуы белән аерылып торган Мәликә образы табигатьнең, хайваннарның телен аңлый кебек. Мәликә үз тормышы турында уйлана, ялгыш адымнары өчен үзен битәрли: «Йөрәгемне нәрсәдер борып-борып чеметте. Көя күбәләге төсле җанымны тапаган ялгызлык иде ул, ялгызлык! Кем өчен чәчем белән җир себерәм соң мин?! Ирсез, баласыз хатын көн-төн акча эшли! Ни кызыгы, йә?!»

Шул рәвешле, Н.Гыйматдинова хатын-кыз кичерешләрен тирән, үтемле, уйландырырлык итеп сөйләп бирә, моның өчен психологизмның төрле алымнарыннан уңышлы файдалана.

Бу җәһәттән, «Хатыннар сагышы» әсәренә игътибар итик. Биредә дус хатыннар язмышы тасвир ителә. Ниса Әхмәрова образы эшләнешенә игътибар итик. Язучы ханымның яшәеш фәлсәфәсе «төче ялганга караганда – ачы хакыйкать кыйммәт!» – дигән гап-гади канун: «Ниса теле белән көрәшмәде, эчке халәте белән һәр ялганга, һәр икейөзлелеккә каршы чыкты». «Эшсезлектән арган журналистлардан», горур хатын хәзерге җәмгыятьтә кыргый булып тоелган ялган сөймәү гадәте, китап укырга хирыслыгы белән аерылып тора. Бай ир хатыны Сандугач исә дустының кемгәдер кирәк булуына кызыгып карый, чөнки аның «өч кешелек гаиләсендә һәркемнең үз урыны».

Әсәрләрдә субъектив фикер катламын сакраль/профан оппозициясе оештыра. Өч хатынның язмышын хикәяләүче субъектив герой автор тавышын ишеттерүче буларак кабул ителә, аңлана: «Адәм баласына тынгы юк: ул гомере буе көйсез җанын көйләп яши. Яраларымны тизрәк дәвалыйм, хаталарымны тизрәк төзәтим дип өметләнә. Ә җан, үчеккәндәй, мәшәкать арты мәшәкать өстәп тора. Чөнки ул фани дөньяныкы түгел. Аны шушы ыгы-зыгылы һәм гөнаһлы Җиргә вакытлыча гына очыртып җибәргәннәр һәм җан, бу тарлыктан, бу кысанлыктан туеп, һаман каядыр билгесезлеккә ашкына».

Табигать күренешләренең сурәте дә сакраль/профан оппозициясенә буйсындырыла. Мисалга «Икебезгә дә авыр» повестенда сюжетка керергә әзерләүче пейзаж элементына игътибар итик: «Бу төн бик караңгы иде... Әйтерсең, җиһан, күктә йолдызларын кабызырга онытып, йокларга яткан. Айдан саран гына яктылык сирпелсә дә, күңел сөенер иде. Кайчагында төн кояшы бер иптәш кебек була. Тик төпсез «Тоба»ны анысы да яктырып та кинәндерми шул: яңгырлы төннәрдә дөньяга чыраен сытып, болытлар арасына чума». Урман, бүреләр – мифологик мотивларны барлыкка китерүче символлар. Үзен мәңгегә ялгыз иткән «бәндәләр буйсынган законнар белән, бәндәләр үтәгән гадәтләрне үтәргә ярамаган чокыр»да көн күрүче Зәмзәмия сыкрана, зар елый: «Аның «өстәгеләр» белән уртаклыгы калмаган». Повестьта герой әнә шулай серле, могҗизалы чынбарлыкта сурәтләнә, төгәлрәге, кеше күзеннән читтә торган, шом тудырган гап-гади чокырга сакраль мәгънә салына. Әтисе Хәбир күрсәткән башка чынбарлык кызын да кешеләр җәмгыятендә хөкем сөрүче явызлык, гаделсезлектән коткара, аның киләчәк язмышын билгели. «Чәчләре арыш саламы төсендәге кызны көтеп картайган» Вәгыйзьне дә үзгә чынбарлыкның бер вәкиле итеп күрәбез.

Шул рәвешле. Н.Гыйматдинованың сакраль/профан оппозициясе алга чыккан әсәрләрендә лейтмотив булып дөньяны хис аша танып-белү, мәхәббәт ярдәмендә хакыйкатькә якынаю турындагы фикер тора.

Н.Гыйматдинова повестьлары – хәзерге татар прозасының энҗе-җәүһәрләре. Язучының әсәрләрендә тәкъдим ителгән дөнья сурәте чынбарлыкның үзгә моделен төзи, гомумкешелек кыйммәтләрен ныгытуга хезмәт итә.

Гөлфия ГАЙНУЛЛИНА,
филология фәннәре кандидаты



Гомәр Гали





1930 елдан соң «Безнең юл»ның дәвамы булып «Атака» (Татарстан Пролетариат Язучылары Ассоциациясе – ТАПП органы – редакторы Гомәр Гали) һәм «Яңалиф» (Татарстан Мәгариф халык комиссариаты һәм Совет язучылары оешмасы органы – редакторы Фатих Сәйфи-Казанлы) чыга.

Фатих Сәйфи-Казанлы





1933 ел башыннан журнал «Совет әдәбияты» исеме белән чыга башлый (редакторы Галимҗан Нигъмәти). «Совет әдәбияты» 1939 елга кадәр латин имласында, аннан соң кириллицада 1965 елга кадәр басылып килә.



Галимҗан Нигъмәти

«Казан утлары» архивыннан

Татарстан Республикасы Президенты аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәровка (уртада) бу айда 60 яшь тула. Котлыйбыз! Рәсемдә ул язучылар Фәүзия Бәйрәмова һәм Равил Фәйзуллин белән.

Салават КАМАЛЕТДИНОВ фотосы.

Әдәбият галиме, шагыйрь, филология фәннәре докторы Әнвәр Шәриповка бу айда 80 яшь тула. Котлыйбыз!

Шагыйрь, прозаик, драматург, публицист, тәрҗемәче, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Равил Бохараевның тууына 70 ел (1951-2012).



Бу QR-код аша сайтыбызга кереп, күренекле шагыйрьләр Равил Бохараев белән Гәрәй Рәхимнең 2000 еллар башындагы әңгәмәсен тыңлый аласыз.

Дуслар. Уңнан сулга: язучылар Шәһинур Мостафин, Рафаэль Сибат (1946-2003. Бу айда аңа 75 яшь тулган булыр иде), җырчы Фән Вәлиәхмәтов.

Сәхифәне **Равил ФӘЙЗУЛЛИН** *әзерләде.*

«МӘХӘББӘТТӘ КАЙЧАК ЯЛГЫЗЛАР БЕЗ...»

Иске Байсар.

Актанышның иң матур авылларының берсе! Бәрәңге бакчалары артында ук – Сөн елгасы. Ул тын гына, талгын гына ага. Моң кебек... Яр кырыендагы талларга да сеңгән бугай аның моңы: су өстенә иелгәннәр дә ишетелер-ишетелмәслек итеп кенә, нидер көйлиләр сыман...

Бер-берсенә гашыйк җаннар өчен иң аулак урын шушы таллар ышыгыдыр.

Су өстендә – ай шәүләсе. Ул яп-якты юл булып сузылган – җитәкләш тә икәү киләчәккә атла...

Алар Сөнгә карап, башка гашыйклар кебек менә шулай хыялланып утырырга өлгерделәрме икән, белмим. Әмма аларны гомер буе озатып барачак мәхәббәт нәкъ менә анда – Сөн ярында, Байсар авылында кабына.

Рафаэль Сибат һәм Розалия Казыйханова.

Әйе, бу язма язучы Рафаэль Сибат һәм аның мәңгелек мәхәббәте, үзе яратып дәшкәнчә – Розалия – Розаль – Розали хакында.

1967 елның сентябре. Ул елны авылга бәрәңге алышырга Казан дәүләт университетының тарих-филология факультеты студентлары килә. Бер айга! Авыл гөрли, бигрәк тә кичләрен. Яшьлек ару-талуны белми: көне буе колхоз кырында бәрәңге чүпләгән егет һәм кызлар кояш батуга клубка ашыга. Бер ай озын бит ул! Бу вакыт эчендә әллә кемнәр белән танышырга, үлеп гашыйк булырга һәм... аерылышырга да мөмкин.

Розалиянең мәктәпне тәмамлап, Зөбәер авылында пионервожатый булып эшли башлаган елы бу. Байсар белән Зөбәер арасы – 25 чакрым. Яллар җиттеме, кыз туган авылына әти-әнисе, туганнары, дус кызлары янына ашыга. Шимбә көнне, гадәттә, авыл клубында башта кино була, аннан танцылар башлана. Икенчесе – иң кызыгы: бию бер урында таптанып тору гына түгел бит ул – үз-үзеңне күрсәтү, башкаларны күзләү, сиңа төбәлгән күзләрнең иясен эзләү...

Розалия ул көнне клубка әнисенең туфлиен киеп чыга. Матурын-матур да, тик зуррак була – бик теләсә дә, уртага чыгып бии алмый, кызлар белән читтә генә сөйләшеп басып тора.

Биергә аны Ул да килеп чакыра. Бәрәңге алышырга килгән студент егетләрнең берсе! Авылныкыларга бөтенләй дә охшамаган: өстендә озын ак плащ, кара чалбар, чәчләре озын...

Кайтырга чыккач, үзен озатырга дип ияргән егетләр арасында Аны да күреп, йөрәк кысылып куя. Ә Розалия артыннан ул көнне дүрт егет кайта! Тыкрык уртасына җиткәч, таныш түгел студент егет белән Ул сөйләшеп кала. Үз кешеләр бит аңлашалар – теге кыска буйлы егет кире борылып китә. Еллар узгач кына, Розалия аның шагыйрь Нур Әхмәдиев икәнен белә. Хәер, ул чакта әле гап-гади Нур гына... Күрше егете Фәритне: «Ә син нишләп йөрисең әле монда?» – дип, Розалия үзе туктата. Егетләрнең өченчесе – колхозга яңа килгән агроном һаман да янәшәдән атлый.

– Ә син соң кая барасың?

Кызның турыдан-туры биргән соравына агроном башта бермәл югалып кала.

– Ничек инде кая? Сине озатып кайтам...

– Практика узарга кайтканда, нигә килмәдең соң? Мәрвә артыннан йөрдең бит. Мине хәзер генә күрдеңмени?

Агроном егеткә борылып китүдән башка чара калмый.

Розалияләрнең өйләре янына алар икәү генә кайтып җитәләр. Капка эченнән сеңлесе Гүзәлнең: «Апа, кер! Югыйсә әнигә әйтәм!» – дип кычкырганы ишетелә. Егет абайламый да кала: кыз аны этеп җибәрә дә капка артына чума...

Ул кичне алар хәтта бер-берсенең исемнәрен дә белергә өлгермиләр.

Икенче атнаны ялга Розалия тагын авылга кайта. Барысы да кабатлана: клуб, кино, танцылар. Юк, бөтенесе дә түгел. Розалия киноның яртысыннан чыгып китә. Клуб яныннан бераз китеп, караңгы урамга атлауга, берәү аны кулыннан тотып ала. Ул! Барысы да менә шулай килеп чыга: алдан берни сөйләшмичә, килешмичә. Йөрәкләр ничектер аңлаша да, алар аннары бер-берсен эзләп кенә таба...

Егетнең исеме Рафаэль икән. Розалиядән бераз гына өлкәнрәк. Казанга укырга Киров өлкәсеннән килгән. Нократ Аланы районының Түбән Шөн дигән авылыннан. «Шигырьләр язам», – ди. Сөйләшеп сүзләре бетми, әйтерсең лә, кичә генә очрашып аерылышканнар. «Без инде киләсе атнага китәбез. Син мине озатырга кайтырсыңмы?» – ди аңа Рафаэль, аерылышканда. «Кайтырмын!» – дип җавап бирә Розалия.

Шимбә көнне мәктәптә дәресләр бетүгә кайтырга чыга кыз.

Юл буенда озак кына «попутка» көтә. Кул күтәреп басып тора-тора арып бетә – машиналар шундый сирәк йөри. Ниһаять, берсе туктый. «Байсарга ашлама илтәбез», – диләр. Кабинада май заводында эшләгән бер таныш абзыйны да күргәч, Розалия бөтенләй тынычлана... Байсарга барабыз дисәләр дә, машина бераздан Олыимән авылы ягына борыла. «Борчылма, минем хатын шушы авылныкы. Тиз генә бабайларга кереп, хәлләрен белеп чыгабыз», – ди шофёр кызга. Кияүне күрүгә тиз генә табын корыла, түренә бер ярты да менеп утыра... Сентябрь ахыры бит – көннәр шактый кыскарган чак: караңгы төшә. Ут йотып утырган кызда берәүнең дә гаме юк – табын артындагыларның сүзләре бетми дә бетми. «Олы юлга чыкмыйбыз, Яхшый аша гына барабыз», – ди шофёр. Ә анда юл гел яр кырыйлап бара...

Үзләренең чокырга төшеп барганын аңлаган Розалия читкә сикерергә өлгерә. Башта бер генә уй: «Пальтом гына каядыр эләкмәсен, югыйсә машина астында калам!» Бераздан машина ауган тавыш ишетелә. Дөнья бер мәлгә тып-тын булып кала... Аннан машинадагылар сөйләшкән тавыш килә. Исәннәр! Ул арада яңгыр сибәли башлый. Күз караңгыга ияләшә төшә. Зират яны икән. Бер аягына баса алмаганын белгәч, таянып кайтырга дип, Розалия зират рәшәткәсен каерып алырга тели – көче җитми...

Олыимән авылына кире абаланып, үрмәләп диярлек кайта ул. Шофёрның бабайлары йортына барып егыла. Йорт хуҗасы сынган-тайган сөякләрне караучы булып чыга. «Кызым, бабаң хәзер исерек инде, йоклый, иртән ул сине карар. Ә хәзер, әйдә, ят», – ди әбисе...

Розалия сынган аяк белән өйдә ятканда, Рафаэльдән беренче хат килеп төшә. Шигырь юллары белән язылган! Байсарның бөтен кызлары өчен дә вакыйга була ул – берсенә дә мәхәббәтне болай аңлатканнары юк бит әле. «Бер күрүдә кешене яратып булмый», – ди аңа язган хатында Розалия. Казаннан җавап бик тиз килә. Тагын шигырь белән! «Була!» – ди егет, үзсүзләнеп.

Ике араны ялгап, хатлар йөри башлый.

«Казанга килсәң, хәбәр ит, очрашырбыз. Үзем каршы алырмын!» – дип яза аңа Рафаэль хат саен диярлек. Колхоз идарәсе икенче елны Розалиягә башкалага бухгалтерлыкка укырга барырга тәкъдим иткәч, кыз шунда ук ризалаша. Барысы да булгандыр инде: яңа һөнәр алырга теләве дә, зур шәһәрдә яшәп ятучы җанына бик якын берәүне күрергә теләве дә... Юлга кузгалыр алдыннан: «Мин киләм!» – дип, телеграмма суга кыз. Актаныштан Казанга ул чакта әле су юлы белән йөриләр: әмма пароходтан төшкәч, күпме генә көтсә дә, аны каршылаучы күренми...

Телеграмманың Рафаэльнең булачак хатыны кулына эләгүе, егетнең бу хакта белми дә калуы бик күп гомерләр узгач кына ачыкланачак әле...

Розалия Казанда туганнан туган абыйларында – Илдарларда туктала. Ул да Казан дәүләт университетында, филология факультетында укый. Рафаэль кебек... Моны кыз беренче көннән үк күңеленә салып куя.

Казан – зур кала шул, күпме өметләнсә дә, сукмаклар кисешми. Ялгыш кына да очрашмыйлар. Бар да мәгълүм шигырь юлларындагыча кабатлана: «Яратмаган кеше янда йөри. Юлларыма чыкмый яраткан»... Янып, чәчрәп торган чибәр кызга егетләрнең күзе төшми тора, димени?! Розалиягә үзләренә кода тиешле берәү гашыйк була: Казан ветеринария институтының соңгы курсында укучы ул егет кыздан бер адым да калмый – лекцияләре тәмамлануга көн саен Розалия янына ашыга. «Өйләнешик, бергә булыйк!» – ди. Аны якыннан белгән туганнары да кызга шул сүзне кабатлый: «Белемле, төпле, өметле егет – сиңа тагын кем кирәк, чык!» – диләр.

Акылы белән барысын да аңлый Розалия, тик күңел дә бар бит әле. Кыз Казанга килгәннән бирле – инде елга якын бер хәбәре булмаган кешене һаман көтә бит ул күңел дигәнең. Бер үк һаваны сулаганыгызны, бер үк урамнардан узганыгызны, кайчак бер үк ишекләрдән кергәнегезне белми бит ул, белсә, хәзер очып килер иде яныңа, ди...

Һәм Розалия тәвәккәлли.

Туганнан туганы Илдардан, 502 нче группага кереп, Хуҗин дигән егеткә хат тапшыруын сорый. Ак кәгазьгә бер генә җөмлә яза: «Рафаэль, мин шушы адрес буенча бухгалтер курсларында укыйм, очрашырга иде...»

Килә! Килә Рафаэль! Иртәгәсен үк! Укытучылары, булачак бухгалтерларны дәрестән соң алып калып, имтихан сорауларын әйтеп торып яздырган көн була ул. Берничә генә сорау калганда, кабинет ишеген шакыйлар. Ишекнең теге ягында басып торучы кеше үзе күренмәсә дә, тавышы, нәрсә әйткәне ишетелеп тора – Розалия аны әллә кайдан таный. Тик укытучылары гына егетнең соравына нигәдер: «Юк, андый кыз бу группада укымый!» – дип җавап бирә. Бөтен аудитория алдында басып: «Мин монда!» – дип кычкыра алмыйсың бит...

Сорауларны язып бетерүгә, иң беренче булып парта артыннан ашыгып, Розалия күтәрелә: бәлки әле, ерак китмәгәндер, бәлки әле, тукталышта булса да куып җитәр ул аны...

5 нче трамвайга берсе – алгы, икенчесе арткы ишектән керәләр. Кыз ялгышмый: әйе, Рафаэль университетның тулай торагына шушы маршрут белән генә кайта ала.

Бераз тын алгач, трамвайдагы кешеләрне аралап, ул аның янына ук килеп баса.

– Исәнмесез...

Рафаэль кызны аның абыйларына кадәр озата кайта.

– Мин инде бер ел Казанда. Телеграмма биргән идем – каршыларга төшмәдең...

Егет бер сүз дәшмичә аптырап, аңа карап тора.

Кыз дәвам итә:

– Кияүгә чыгам... Гариза бирдек инде... Моны сиңа әйтмичә генә бөтенләйгә югаласым килмәде. Нигәдер...

Егет аны тагын дәшмичә генә тыңлый. Ә аннан:

– Раф больше этого не может терпеть! – ди дә... борылып китеп бара.

Алар шулай аерылышалар.

Ул көнне тулай торакка кайткач, Рафаэльнең үксеп елавын Розалия белми. Ә Рафаэль үзенең бераз вакыт узгач: «Тезләнәсе калган алларыңда, / Вокзалларга каршы төшәсе...» дип язачагын...

«Р.гә

Усал язмыш кара пәрдә-чәчен
Тарап салды безнең арага.
Син берәүгә көлеп, кулың бирдең –
Алып булмас инде аралап...

Синең кебек якын кеше эзләп,
Кемгә микән килеп дәшәсе?
Бер-беребезне инде күрмибез дә...
Нишләсе соң хәзер, нишләсе?!

Сине күреп сөйгән күзләрем дә
Дучар әнә шундый язмышка –
Бер-берләрен мәңге күралмыйлар,
Күралмыйлар хәтта ялгыш та...

Тезләнәсе калган алларыңда,
Вокзалларга каршы төшәсе...
Нихәл итим! Җирдә тормыш итү –
Күзем күреп, сукыр яшәсе...

...Синнән башка җәе җайсыз узды,
Бигрәк моңсу үтә көзләре...
Читләр сине:
«Бәхетсез ул, кара!» – димәсеннәр –
Күрми башлар шундук күзләрем.
28.10.68.–18.02.91»

«Нигә мин сине ул көнне туктатмадым икән?!» Бу сүзләрне Розалиягә бик күп тапкырлар кабатлаячак әле ул... Соңарып, бик күпкә соңарып... Алга китеп булса да әйтим: Рафаэль Сибатның «Р.гә» дип куелган шигырьләре барысы да Розалиясенә багышланган.

Розалия кияүгә чыга. Ә Рафаэль... югала. Студент чакта ук «Казан утлары» журналында рәсеме белән бер шәлкем шигырьләре басылган өметле шагыйрь иҗаттан нигәдер кинәт ерагая: матбугатны күпме генә карап, күзәтеп барса да, Розалия аның яңа иҗат җимешләренә юлыкмый. Рафаэльнең аңа язган хатлары да югала. Дөресрәге, булачак ире, бер көнне Розалиянең туганнарына аннан иртәрәк кайта да, кызның чемоданындагы хатларны табып укый. Аннан, мең кисәккә ваклап, аларны кире тутырып куя. Кызның аптырап: «Нигә кагылдың? Нигә ерттың ул хатларны?» – диюенә исе дә китмичә, сорауга сорау белән: «Ә сиңа алар хәзер нәрсәгә кирәк инде?!» – дип җавап бирә...

Хатирәләргә генә берсе дә кагыла алмый.

Ире белән ул 1977 елда аерылыша. Ике баласын ияртә дә өйдән чыгып китә – балаларның олысы беренче классны гына тәмамлаган була әле. Тел белән дә, кул белән дә кыйнауларына түзә алмый. Эчкән чакта булса – бер хәл, аек килеш тә кул күтәрә бит.

Аерылышканнан соң, Розалия Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлый. Кызыл дипломга! Укытучылары: «Кайтышлый ук документларыңны Казанга, институтка тапшыр! Укуыңны, һичшиксез, дәвам итәргә тиешсең!» – дип калалар. Ул шулай эшли дә – читтән торып, Казан дәүләт ветеринария институтына укырга керә. Һәм Менделеевск районына селекционер булып, эшкә китеп бара. Әмма Казан аны гел үзенә тарта...

II курсны тәмамлаган елны Розалиягә институтта эш тәкъдим итәләр – читтән торып, уку бүлегенә методист кирәк икән. Уйлап та тормыйча: «Мин риза!» – дип җавап бирә ул. Дүртенче класста укучы кызы, икенче класста укучы улы белән тулай торакның кечкенә генә бүлмәсенә күчеп килә. Методист хезмәт хакына гына тормышны алып барып булмый – урам җыештыручы булып та урнаша. Иртәнге сәгать алтыга кадәр кар көри, урам себерә, аннан институтка йөгерә...

Читтән торып укучыларның контроль эшләрен җыйганда, көтмәгәндә, бер студентның адресына игътибар итә ул: Нөкрәт Аланы, Югары Шөн авылы. Рафаэльнең күрше авылы лабаса бу! Әлеге студентның исем-фамилиясен хәтерләп кала һәм җәйге сессия җиткәч, җай табып, аңа сүз куша:

– Сезгә бер сорау бирим әле... Түбән Шөн авылы сездән еракмы? – ди.

– Юк, ерак түгел, өч кенә чакрым, – ди студент. – Без – бер колхоз.

– Ә сез Рафаэль Сибатны... Рафаэль Хуҗинны белмисезме?

– Ничек инде белмим?! Билгеле, беләм! Сибат псевдонимы белән язганын да...

Розалия сорау арты сорау тезгәнен үзе дә сизми кала:

– Ә кайда эшли ул? Язамы? Гаиләсе бармы? Балалары? Әнисе исән-саумы? Мин аның студент чактагы танышы... Сәлам диярсез.

– Ә кемнән дияргә?

– Актанышныкы берәү сәлам әйтте дисәгез, ул үзе аңлар...

– Ярый, әйтермен, – ди студент. – Тик үз хәлләрен Рафаэль абый сезгә үзе сөйләр. Ул бу көннәрдә Казанда булырга тиеш, мин аны эзләп табарга тырышырмын...

Шул көнне үк эш сәгате беткәндә, кабинет ишеген ачып, Розалия янына Рафаэль килеп керә.

Таңга кадәр сөйләшеп утыралар алар. Балалар каникулда, авылда чак була.

Рафаэль дә хатыныннан аерылган икән. Аның үз сәбәпләре... Инде шактыйдан әнисе, улы белән генә яши. Әйе, аерылышканнан соң, Алмаз аның белән калган. Әле мәктәпкә дә кермәгән булган. Хатыны инде башка бер кешегә кияүгә чыккан, ике кыз бала тапкан. Ә ул улын ялгызы гына үстерә... Әлфия белән аерылышкач, нык кына сала башлаган – мәктәп директорлыгы вазифасын ташлаган. Машинасы булган – аның белән һәлакәткә очраган. Хәзер Кировта көрәшчеләр әзерли – тренер икән.

Кыскача шулай.

Розалиянең тулай торактан үз почмагына күчәргә җыенган чагы була бу. «Адресымны әле тәгаен белмим, күчүгә мин сиңа хат язып салырмын», – ди ул иргә. Яза хатны. Әмма Розалиянең «Зур Урам» дигәнен Рафаэль конверт тышына үзенчә дөреслэп язып җибәрә: «улица Большая». Хат иясен тапмый, билгеле – Казанның йөзләгән урамнары арасында югала. Розалия белән Рафаэль дә тагын бер-берсен югалтышалар.

Ун еллап вакыт уза.

Еллар узган, күңелдән сагынулар, якын итүләр, көтүләр генә узмаган.

– Айгөл, әйдә, Рафаэль абыеңның авылына барып кайтабыз, – ди ул берсендә кызына.

Җыеналар да чыгып китәләр! Башта электричка белән баралар, аннан автобуска күчеп утыралар. Сорашып, йортларын эзләп табалар.

Өйдә әнисе үзе генә булып чыга.

– Рафаэль Пүләнкәгә киткән иде, – ди ул. Вятские Полянины – Нократ Аланын олылар шулай Пүләнкә дип йөртәләр икән аларда.

– Кайтырмы соң?

– Кайтыр...

Көтмәгәндә килеп кергән кунакларга карчык чәй куя.

Рафаэль кичкә таба гына кайта. Аптырап кала, билгеле. Үзен ничек тотарга да белми.

– Нишләп йөрисең? Кайдан килеп чыктың син? – ди.

– Килдем әле менә, – ди Розалия. – Бөтенләй юкка чыктың бит...

Туксанынчы еллар була бу. Киров өлкәсендә татар телендә «Дуслык» газетасы чыга башлаган вакыт – Рафаэль шунда Нократ Аланы районының үз хәбәрчесе һәм әдәбият-сәнгать бүлеге җитәкчесе булып эшләп йөри икән. Үз авылларында клуб мөдире дә. Ул кичне клубка бергәләп чыгалар. Ә икенче көнне Рафаэльләрнең каршыларында гына торучы туганнан туганнары аларны чәйгә ала...

Розалиянең кызы Айгөлнең дус кызы Рафаэльнең бертуган Мөнҗия апасы торган авылга кияүгә чыккач, аралашулар ешая. Хәер, күбрәк Рафаэль үзе килә. Бу вакыт Розалиянең инде Дәрвишләр бистәсендә аерым фатиры була. «Синдә язарга рәхәт миңа», – дия торган була ул. Хатынны эшкә озата да үзе язып кала. Бик озак уйлап, кат-кат төзәтеп яза торган була ул, бәлки, шуңадыр үзе язганны төзәткәннәрен яратмый. Бер елны «Хәтер көне» алдыннан яңа язган шигырен «Казан утлары»на, Рашат Низамига илтеп кайтуын сорый ул Розалиядән. «Әмма бер сүзен дә төзәттермә, каләм тыкмасын», – дип озата. Шигырьне шунда ук укый Рашат Низами һәм: «Менә бу җирен болай итик әле», – дип, каләмгә үрелә... «Рафаэль төзәтергә кушмады», – дип, Розалия шигырьне редакциядән кире алып кайтып китә...

Розалия дә Түбән Шөнгә кайткалап йөри. Рафаэльнең әнисе инде шактый олы – йортта барыбер хатын-кыз кулы җитми. Кайткан саен юып, җыештырып, тәрәзә пәрдәләрен, урын-җирләрен алыштырып – бар җирне тәртипкә салып килә. Розалия апасы кайтуга Алмазның йөзенә дә елмаю куна – хатын-кыз җылысы иңгән йорт башка бит инде ул...

Бусагадан атлап керүгә, иң элек Рафаэльнең язу өстәлендәге көндәлеген кулына

ала Розалия: аннан башка бу берничә атнаны ничек яшәгән,ниләр эшләгән, кемнәр белән көрешкән... Хуҗасы үзе әйтергә кыймаган сүзләрне, хисләрне дә җиткерә көндәлек. Алгарак китеп булса да әйтим – көндәлегенә язган иң соңгы юллары да Розале турында була аның.

Алмаз армиягә киткәнче үзләрендә төзелеш техникумында укый. Әмма армиядән кайткач, нигәдер укуын дәвам итәргә уйламый. «Диплом барыбер алырга кирәк – кулыңда бер һөнәр булыр. Кировта укырга теләмәсәң, әйдә, Казанга кил. Дәрвишләр бистәсендәге техникум директоры белән үзем сөйләшәм – укуыңны бездә дәвам итәрсең», – ди Розалия апасы. Алмаз сессияләргә килгән чакта гел аңарда туктала – укуын шулай тәмамлый.

Аларның икесенә дә: «Өйләнешегез инде», – дигән сүзне бик еш әйтә Алмаз.

Берсендә Розалия төш күрә: «Икәү Мөнҗия апаларына кунакка барганбыз икән, имеш. Кире кайтырга машина таба алмыйбыз. Рафаэль машина эзләп, ары йөгерә, бире йөгерә. Аннан: «Син шушында гына утырып тор», – диде дә каядыр юкка чыкты. Чыгам да карыйм – һаман юк бу. Ул арада каяндыр эшемдәгеләр килеп чыкты. «Әйдә, утыр, китәбез. Аны көтсәң, кайчан кайтасың әле», – диләр. Ризалаштым. Һәм шул вакыт уянып киттем. Димәк, мин аңа кияүгә чыкмаячакмын икән, дип уйладым».

2001 елда Татарстан китап нәшриятында Рафаэль Сибатның «Ялгызак» дигән беренче китабы басылып чыга. Ул китапка шул исемдәге романы һәм «Яулар кичкән кульяулык» дигән повесте кергән. Шул уңайдан язучы туган авылында китапны тәкъдим итү кичәсе оештыра. Түбән Шөнгә аның дусты язучы Шаһинур Мостафин кайта. Телевидение килә – Рафаэль Сибат хакында кыска гына фильм төшерәләр. Туганнары җыела. Әлбәттә, Розалия дә чакырулы була. Кызганыч, автор үз кулы белән аңа ул көнне бүләк иткән китап сакланмаган – кемдер алган да кире кайтармаган. Сибат, гомумән, кайда нинди генә мәкаләсе чыкса да, шигыре басылса да, аны Розалиягә биреп барган.

«Ялгызак»тагы төп геройны – Заһидулланы күпләр язучының үзенә охшата. Розалия ханым да кат-кат шул ук сүзләрне кабатлый: «Рафаэль романында үзе турында язды. Автобиографиясе дип укысагыз да була...»

Алар бик авыр аерылышалар.

Дөресрәге, Рафаэль авыр аерылыша. Әллә аның күңеле нидер сиздеме икән соң?

Ул аны мал чалган җиргә кайтырга чакыра: зур эш бит – хатын-кызсыз авыррак. Розалия ул көнне өйдә аш-су әзерли, аннан Рафаэльгә ат итен урнаштырырга да булыша. Соңыннан ир аны озатып җибәрә. Розалия Алмазларга барып кунарга, ә иртән автобус белән үзенә кайтып китәргә тиеш була. Саубуллашып, берничә сәгать узуга кабат шалтырата ул аңа:

– Розаль, әйдә, кире кайт әле!

– Ничек кире кайтыйм?! Әле Алмазларга килеп кенә кердем бит, аннан иртәгә миңа эшкә...

– Кайт, Розаль! – дип кабатлый ир. – Такси ал да кире кайт! Акчасын да үзем түлим. Эшеңнәң сора, аннары гариза язарсың...

Розалия кире борылмый.

Бу вакытта инде ул Түбән Кама шәһәренә күчкән була. Туганнарына – сеңелкәш-энекәшләренә якынрак. Эшләгән урынында акчаны вакытында түләми башлыйлар, ә Түбән Камада сеңлесенең стоматология клиникасы бар – кичләрен шуны җыештыра. Анда күчкәннән соң Рафаэль белән дә аралашулар сирәгәя.

Розалия туган авылында йорт салырга керешә. Ирдән моны яшерә. Менә төзеп бетерәм дә «Рафаэль, әйдә әле, яшьлегең үткән җирләрне бер карап кит», – дип, кунакка чакырам дип хыяллана...

2003 елның 15 августында иртәнге сәгать дүрттә, эш өстәле янында нидер язып утырганда, Рафаэль Сибатның йөрәге тибүдән туктый. Әнисеннән соң ике генә ел яши ул. Аңа нибары 56 яшь була.

– Апа, сине эзлиләр, Рафаэль Сибат үлгән дип әйтәләр, – дип шалтырата аңа энекәше.

Розалиянең авылда – Байсарда чагы була. Әлеге дә баягы – йорт төзү мәшәкатьләре белән чапкан вакыты. Шунда ук Рафаэльнең килене Ларисаның номерын җыя:

– Мин хәзер төнлә үк килергә чыгам, көтегез!

– Розалия апа, этине бер атна элек үк җирләдек инде... Бүген җидесен үткәрдек... Сезне таба алмадык шул. Кырыгына көтәбез...

Рафаэль Сибатның кырыгына Казаннан бер төркем язучылар да кайта. Коръән ашыннан соң алар бергә төшкән фотосурәт тә саклана әле. Тик алар арасында Розалия Казыйханованы тапмассыз. Барысыннан аерылып, Рафаэльнең кабере янында ялгызы гына калып, бик озак елый ул. Әсәрләре басыла, исеме халыкка таныла башлагач кына, Рафаэльнең менә шулай көтмәгәндә китеп баруына әрнеп, үкенеп тә елый ул...

Начар гамәлләр дә кылмадым –
һич ялганлаштырмадым.
Сөю бирдең миңа, Ходаем –
әмма кавыштырмадың...

Мин аны гомер беркемгә
Бер көнгә алмаштырмадым.

Сөю бирдең миңа, Ходам –
Әмма кавыштырмадың...

Минем өчен бер генә Ул!!! –
башка гүзәл затлар белән
һиччак чагыштырмадым.
Рәхмәт! Сөю биргән өчен, Ходам!
...Бары... Кавыштырмадың.

Бу шигыренең ахырында шагыйрь язган датасын куймаган. «Р-гә. Соңгы тапкыр очрашканга 10 еллап вакыт үтсә дә, күңел сине барыбер онытмады. Хәер, яшьлек хисләре мәңгелек инде ул», – дип кенә өстәгән.

Ә менә монысы бакый дөньяга күчәр алдыннан язган соңгы шигыре:

Р.-гә

Ни әйттем: онытам, ташлыйм дип,
Сөюдә яңаны башлыйм дип...
Ник киләм эзләнеп эзләрен?
Югыйсә ул миннән качмый бит.

Хәтерне үтереп буламы?
Әйтсәм дә: онытам, ташлыйм дип –

Иске ул мәхәббәт, бик иске
Сәндә яңалык ачмыйм бит...

Ни әйттем: онытам, ташлыйм дип –
Катырак ярата башлыйм бит.

Вакыт – җил кебек исеп кенә тора. Исән булса, Рафаэль Сибатка быел 28 октябрьдә 75 яшь тулыр иде. Ә аның җир куенына кереп ятуына да инде ике дистә елга якын. Язучының исеме халык күңелендә яшәсен өчен кулыннан килгәннең барысын да эшләгән Розалия апа. Шигырьләрен сәхнәләрдән сөйләп йөргән. Хатларын кадерләп саклаган. Киров өлкәсенә махсус барып, язучының архивын барлаучы да ул булды. Әгәр Розалия апа Рафаэль Сибатның улына кайтып, язучының әле моңарчы беркайда да дөнья күрмәгән әсәрләрен юллап алмаса, алар, мөгаен, шулай кадерсез булып ятарлар, аннан, бәлки, бөтенләй юкка да чыгарлар иде. Көндәлекләре кебек. Кызганыч, Түбән Шөндәге йорты сатылганнан соң, язучының ничә еллар алып барган көндәлекләре югалган әнә.

Еллар тузаны кунган папкаларны сак кына ачам. Язучының үз кулы белән язган кулъязмалары. Энҗе кебек хәрефләр. Гадәттә, ул язганын кире кайтып төзәтмәгән. Һәм бик тиз язган. Бер утыруда 70–80 шәр бит!

«Кызыл мәче» *(повесть)*, «Җир кызы. Кыз тәкә» *(роман),* «Каргыш» *(әдәби-документаль кыйсса)*, «Канәфи, Катифә һәм җыр тыңлаучы ат» *(жанры күрсәтелмәгән)*, «Урман Шүрәлесенең кызы» *(сәхнә әсәре)*, «Портрет» *(хикәя)*, «Үпкә» *(хикәя)*, «Иблис» *(хикәя)*, «Тамаша» *(хикәя)*.

Язучы, Гаяз Исхакый исемендәге премия лауреаты Рафаэль Сибатның китап киштәсенә менә шуның кадәр яңа әсәре өстәләчәк хәзер. Саргайган бу кәгазь битләренең кыйммәтен бәяләү дә авыр. Татар укучысы, татар әдәбияты өчен үзе бер хәзинә!

***

– Арагызда шундый мәхәббәт булган! Ә нигә кавышмадыгыз икән?

Розалия апага бу сорауны әле дә бирәләр.

– Тормыш хатлардан, шигырьләрдән күпкә аерыла шул, – ди ул. – Язучы кеше белән бер түбә астында яшәү башка...

Хәер, гадәттә, бу сорауга ул бер генә сүз белән җавап бирә:

– Язмыш...

Инде сүз – хатларга. Алар бу тарихның без сөйләп бетермәгән өлешен җиткерер.

«Сәлам Түбән Шөннән!

Исәнме, Розалия! Сәлам белән Рафаэль.

Менә язган хатыңны алдым, каршы җавап языйм әле дип уйладым. Соңгы тапкыр очрашканга 10 еллап вакыт узса да, күңел сине барыбер онытмады, кем әйтмешли: «Ул безнең көчтәмени?!» Хәер, яшьлек хисләре мәңгелек инде ул.

Үзең ни хәлләрдә соң? Балаларың? Яңа квартирага күчкәнсең бугай.

Үзем турында шул: улым көз армиядән кайтты, хәзер авылда өчәү (әни, мин һәм улым Алмаз) яшибез. Мин Киров өлкәсенең Малмыж шәһәрендә (бездән 80 км) чыга торган «Дуслык» газетасында безнең Вятские Поляны буенча корреспондент һәм бүлек мөдире булып эшлим. Язгалаган кешегә яраклы һәм бата торган хезмәт. Атнага бер көн – җомга – барып кайтам редакциягә, калган көннәр өйдә һәм район буйлап йөрүдә. Иң мөһиме, эш ошый, алга таба да шул уй-хис белән яшәргә язсын.

Ярый, хуш, сау бул!

Вакыт тапсаң һәм мөмкин булса, үзең турында күбрәк яз. Рафаэль Сибат.

13 январь, 90 ел.

P. S. берәр айдан Казанга барып чыгасы бар. Бәлки, очрашырбыз, ә... Ни дисәң дә, без ничә еллар таныш инде.»

«Сәлам Түбән Шөннән!

Исәнме, Розалия!

Сәлам белән Рафаэль.

Язган хатыңны алдым, синең хәл-тормышлар белән кыскача булса да, таныш булдым.

Мин үзем элеккечә бер көйгә эшләп һәм яшәп ятам. Улым Алмаз армиягә Киров төзүчеләр техникумының өченче курсыннан киткән иде, кайткач укырга бармады. Вятские Поляныга заводка эшкә керде. «Военизированная охрана»да зам начальника поста булып йөри. Эш хакы хәйран түгел, алга таба бер уңае чыгар әле.

Казанга 14 февральләрдә килергә исәп, 15–16–17 февральләрдә Татар иҗтимагый үзәгенең II корылтае (съезды) булачак, ә мин бу Үзәкнең әгъзасы (члены) саналам. Бездә аның теләктәшлек группасы бар, мин – аның рәисе.

Шулай итеп, Розалия, синең белән шул чорларда очраша-күрешә алабыз. Безнең соңгы очрашудан соң 10 ел гомер узды инде. Гомер дигәнең – чыннан да, агымсу, элек картлар: «Күз ачып йомганчы узды гомер!» – дигәч, ышанмыйрак йөри идем, хәзер менә яшь барган саен ышандыра. Әмма, кем әйтмешли, безне бабайлар ротасына списать итәргә иртәрәк әле. Шулай бит! Очрашуның максатын да әйтәм – минем сине күрәсем килә, Розалия! Үзең аңлыйсың инде – студент елларындагы минем иң көчле хис – сиңа иде...

Кабат сәлам белән, яхшылыклар теләп: Рафаэль.

06.02. 90.»

«Сәлам Түбән Шөннән!

Исәнме, матурым! Сәлам белән Рашка (ха-ха-ха дип усал елмаюыңны күз алдына китерәм), ә чынлап әйткәндә: сәлам Рафаэлеңнән һәм аның якыннарыннан. Айгөл туташка «молодой япь-яшь сәлам!!!» (өч өндәүле – Айгөл гүзәл өч өндәүгә тора ул!)

Мин кайтып җиттем. Әни түшәктә, ул да грипп эләктергән, йөткерә-йөткерә ята. Алмаз озын берлектә, кайткач күрербез никадәр озынлыгын, бәлки, кыскасы да эләкмәс.

Кайтуга ук сине сагындым инде, карт тиле! Чирле һәм дә хәлсез алаша! Соңгы сүзләремне турыдан-туры аңлама, син мине беләсең бит: кайчак үземне хурлап мактыйм. Мактанчык чукынчык бит мин. Әмма вакыты белән ифрат тыйнак та. Шуңа хәтта үз-үземне дә аңламыйм.

Гомумән, әйдә, болай килешәбез: ике-өч ай вакыт эчендә бер-беребезнең күңелләренә тигән һәм күпмедер рухи рәнҗеткән сүзләрне онытыйк! Дөрес, аларны онытып булмый, шуңа уенга алыйк. Җитди сүзләр икән – гафу итик! Бер-беребезгә шәфкатьлелек һәм... Ярату шул булыр!

Минем өчен өч саны дөрес. Өч «Р»..., шуларның беренчесе һәм бердәнбере син – беренче «Р». Бу тәтәйләнеп язу түгел: мин сине яраттым, аерылгач та сагынып яшәдем. Син иң кадерле, хәтта ике «Р...»дан күпкә көчле, мәңгелек «Р». Хәзер генә аңладым, без тагы аерылсак та, мин сине барыбер яратачакмын. Үземчә, әлбәттә, Рафаэльчә, шуңа Рафаэль бит инде мин, башка түгел. Әмма аерылмаска иде, гомер картлыкка бара. Хәзер яшь чак түгел, бер көрешүләр дә – бер гомер.

Сиңа саулыклар һәм шатлык-бәхет кенә телим. 04. 01. 91.»

«Розалия!

Язмыш сукмаклары безне сирәк кенә булса да, очраштыра килә. Әллә инде әнә шул «сирәк»кә күрә минем сиңа булган хисләр салкынаймады, хәтта, әйтергә кирәк, урыны-вакыты белән «кайнар» да калды.

Гомер уза, инде менә без дә урта яшьтәгеләр рәтенә керәбез. Яшьлек торган саен ерагая, гомер офыклары артына күмелә. Әмма яшьлекнең иң матур мизгелләре бервакытта да онытылмый. Шундый мизгелләремнең берсе итеп, минем сиңа булган хисләремне саныйм. Студент елларымдагы иң саф, иң тирәнтен мәхәббәтем – Син идең!

Рафаэль Сибат. Казан. 18. 02. 91.»

«Сәлам Түбән Шөннән!

Исәнме Розалия! Сәлам белән Рафаэль.

Мин исән-сау гына кайтып җиттем. Ни сәбәптер, 19 февраль көнне Казаннан китәсе килми башлады. Электричкага утыргач та, сине генә уйлап бардым.

«Гомерем буе сагынып яшәдем мин сине!»

Кинәт туган шушы уйдан соң, күңелгә шигырь юллары килде:

Мин сине сагынып яшәдем
Яшьлегем таңнары чорыннан.
Сагынып исемә төшердем
Моңланып җырлаган җырымда.

Күп еллар акса да вакыт – су,
Мин сине сагынып яшәдем.
Син булгач бу якты дөньяда,
Пар булып ярларга дәшмәдем.

Мин сине сагынып яшәдем...
Ләззәт ул, хәсрәт ул – сагыну.
Иң зур хис, иң көчле тойгыдыр –
Сөюдә берәүгә табыну.

Менә шулай, матурым!

Бабайның (миңа карата ярату сүзең!) бу сиңа багышланган өченче шигыре, берсен беләсең, өстәлеңдә – җырлар китабында. Мин хәсин – берсөяр (однолюб) бит! Авыр дуслашам (яратам!), яратам икән, оныта алмыйм.

Тагын ни?! Соңгы кичне аракы ягына басым ясаганым өчен, «дуңгыз» булуым өчен гафу! Яме!! Эт елында тусам да, «дуңгызлану» булгалый кайчак. Хәер, эттән дуңгызга ерак түгел.

Тагы... Синең белән очрашудан мин бик риза! Рәхмәт!!! Айгөлгә сәлам әйт.

Бабаең.

20.02.91.»

«Сәлам Түбән Шөннән!

Исәнме, матурым! Сәлам белән Рафаэль («бабай»). Сәлам әнидән, Алмаздан.

Исән-имин генә кайтып җиттегезме? Юлда комачаулыклар булмадымы? Картаела,

кызый, хискә бирелүчән булып киттем әле: сине озатуга ук юксына башладым. Күңелгә моң тулды, җанга сагыш өелде. Сине яратканымны тагын бер кат аңладым.

Аракы парларыннан арына киләм. Мин үземне артык «развязно» тоттым бугай, бигрәк тә Вәсилләрдә өй туенда. Нишләрсең, дуңгызлана торган гадәт бар инде минем, аннан соң «показной» әйбәт булырга тырышкан да юк. Әгәр сине рәнҗеткәнмен яки күңелеңдә авыр хис калдырганмын икән – гафу ит! Ул якны онытырга тырыш.

Син киткән көнне эшкә төшкәч, кызлар (кияүдәге 30–35 яшьлек хатыннар) сораштырдылар. «Рафаэль абый, кайда эшли ул, интеллигентлы күренә. Мөлаем – симпатичный үзе. Кызы да матур!» Мин: «Институтта!» – дип җавап бирдем. Гомумән, син бездә яхшы тәэсир калдырдың. Рәхмәт! Молодец!

Хатымны тәмам итеп: «бабай».

11 март, 91 ел. Айгөлгә күптин-күп сәлам.»

«Сәлам Түбән Шөннән!

Исәнме, матурым! Сәлам белән Рафаэль, сәлам әнидән, Алмаздан, башка туганнардан. Бик күп сәлам Айгөл туташка!

Розалия, нишләп әле син өч «Р»га үпкәләп ятасың? Болай гына әйтелгән коры сүзләр түгел: мин сине яраттым!.. Һәм хәзер дә яратам!!! Яшьлегемдә дә иң яраткан кешем син идең. Инде хәзер дә шул хисләрне саклыйм синң.

Ә өч «Р»га килгәндә, мин дә синсез торганда (хәтта хат белән дә хәбәрләшмәдек) кемнедер якын итәргә – яратырга мәҗбүр булганмындыр. Мин дә җанлы кеше, гадәти бер «мужик». Әмма ул вакытта да сине онытмадым, искә төшеп тордың.

Туфан бассын – мин сине чынлап яратам. Шуны аңла, матурым!!! Рафаэль

15.4. 91.»

Кичер мине
(Розалиягә)

Беләм, җаным! Синең
миннән күңелең кайткан,
Мәхәббәтнең шадра булып,
куле каткан:
Сөйгән өчен бары сине –
Гафу ит лә, кичер мине...

Беләм, җаным! Гаепледер
синең алда,
Сабырлыгың сыдырылып –
иңеп калды:
Сөйгән өчен бары сине –
Гафу ит лә, кичер мине...

Беләм, җаным! Үпкәләүләр
һәр күзеңдә,
Мәрхәмәтсез мәхәббәт юк
җир йөзендә:
Сөйгән өчен бары сине–
Гафу ит лә, кичер мине...

Беләм, җаным! Һәрчак искә
төшерәләр –
Кичергәннәр матур сөю
кичерәләр:
Сөйгән өчен бары сине–
Гафу ит лә, кичер мине...»

«16.03.91.

Сәлам Түбән Шөннән!

Исәнме, Розалия! Сәлам барчабыздан!

Язган хатыңны алдым – зур рәхмәт. Хатың буенча берничә сүз:

1. Яхшы гына кайтып җитүеңә һәм күңелең кителеп китмәгәнгә сөендем (миннән күңелең төшәр моментлар да аз булмады бугай...)

2. Мин һаман да «баш төзәтеп» йөрмим – 12 марттан «ялга чыктым» – хәзер бер ай тирәсе ураза, тем более ураза – Рамазан ае да 17 марттан башлана.

3. Әни хакында әйткәннәрең дөрес, әмма безнең аның белән үз арабыз – мөнәсәбәтебез (син әтиең хакында сөйләгән идең бит әле – шуңа охшашлы хис саклыйм мин аңа).

4. «Картаясы бар бит әле» турында шуны әйтергә мәҗбүрмен: соңгы биш елда мин үземне картаймам дип йөрим. Ник дисеңме? Картайганчы үлеп китәрмен дигәнгә.

Менә шулар.

Ә болай – сиңа рәхмәт! Сине бездә ошатып калганнар (туганнар да, күргән кешеләр дә.) «Теге кара матур хатын кем ул? Өйләнәсеңме аңа?» – дип йөдәтәләр. Хәтта Алмазны да Айгөлгә өйләнгән дип чыгарганнар. Авыл халкы шуңа авыл халкы инде ул. Синең белән мине кода-кодагый ясаганнар. Ә без бит – кем? Үзең беләсең...

Телефон начар эшли өйдә, вакыт-вакыт өзелеп тора. Переговор көнне дә өзделәр. Сәгать 7дән соң клубка звонить итә аласың, номеры – 4-34-34

Мин Казанга апрель башларында барып чыгармын, әйтик, 5 апрельдә кичкә табан, бәлки, иртәрәк тә. Хәбәрләшербез әле.

Син – минем бүгенге көнне бирдәнберем – шуны да аңла!

Хатны бик тиз яздым, клубка төшәсем бар. Ачуланма, яме, матурым. Рафаэль».

«Сәлам Түбән Шөннән!

Алмаз: «Розалия апа белән Айгөл булмагач, әллә ничек, өй күңелсез кала. Өйгә керәсе дә килми», – ди. Ул бу сүзләрне 8 Март бәйрәменнән соң да әйткән иде инде. Син аны үзең дә беләсең. Бүген тагын шуны миңа кабатлады. Шулай инде, хатын-кызлы өй – ямьле өй инде ул! Сиңа гына Май бәйрәме тәтемәде, биш көн буена эш аты булдың. Гаепләмә инде, матурым. Сине эшләтәсе килгәннән түгел, ә башкача мөмкинлек булмаудан шулай килеп чыкты.

Пессимист рухлы хатым өчен гафу ит!

Алдагысын яхшыга юрыйк!

Кабат сәлам белән Рафаэль.

04.05.91.»

«Сәлам Түбән Шөннән!

Исәнме, Розалия! Исән-сау гына кайтып җиттеңме? Айгөл ни хәлдә? Аңа Алмаздан (һәм миннән дә) күп сәлам!

Розалия!

Яңарак кына бездә булып китүеңә карамастан, сиңа хат язарга булдым әле. Эпистоляр жанр мине нык тартмаса да, синең белән очрашып аерылышуга син мине үзеңә тартасың. Сагындырыпмы, моңландырыпмы...

Шулай кызый, тарткалашып торсак та һәм кайбер дисгармония күренешләре нигәдер поляр каршылыклар китермиләр – Хак Тәгалә һәм үзем генә беләм: шул 67 нче елның көзге киченнән соң сиңа мине нидер тарта. Дөрес, «ул» шактый елларга онытылып торды, әмма кабат очрашу – барысы да яңарды! Онытылу дигәне дә истән чыкты мәгънәсендә түгел, ә тормыштагы аерылышуга күпмедер килешеп кару дип карарга кирәк.

Тагын «өйләнү»не искә алам. Тукай «өйләнү – түгел сөйләнү» дигән һәм хак әйткән. Минеке сөйләнүдән ары узмый әле. Ә мине авылда сиңа өйләнүем белән котлаучылар да бар. Берсе, мәсәлән, 90 яшьлек әби, икенчесе 30 яшьлек япь-яшь кеше. Шулай булгач, заочно булса да, мин сиңа өйләнгән саналам. Алла боерса, фиктивно түгел, фактивно өйләнү дә булыр. Аз гына көтик. Иң мөһиме: безнең үзара мөнәсәбәтләр, алар җылы икән, киләчәк өметле! Минем уемча, безнең арага беркем дә, хәтта балалар да керергә тиеш түгел! Үзебезнекен үзебез алга таба хәл кылырбыз. Әлбәттә, алар ризалыгы белән дә... Шунсыз мөмкин түгел!

Саулыклар, бәхет-шатлык теләп: Рафаэль.

3 июнь, 1991 ел.»

«Сәлам Түбән Шөннән!

Исәнме, Розалия! Сәлам белән Рафаэль.

Телефоннан шалтыратсаң да, хат язып салыйм әле, дидем.

Беренче мәсьәлә.

Мин – нормада. Син уйлаганча, аракы артыннан йөрмим. Түбән Шөн Сабан туеннан соң бер көн (дүшәмбе) әйбәт үк салдык та, сишәмбе көнне, символик рәвештә, бер ярты белән иртүк баш төзәтеп, «эчмәү» дигән изге юлга кердек. Чөнки:

бердән, эшләр күп җыелды (клубта ремонт, «Дуслык»ка мәкаләләр, өйдә – чеби

оясы, колорадо коңгызына каршы агу сиптерәсе һ. б. эшләр, әле апаларның (Мөнҗия) өен обшивать итәсе бар; икенчедән Корбан гаете килеп җитте (хикмәт диндар булуда түгел, ә хөрмәт итү дә бар);

өченчедән, йөрәккә каты килде, туктыйм-туктыйм дип тибә, тагы бөер-бавыр, кан басымы, гомумән, хәлсезлек һәм башка, врачлар әйтмешли, «целый букет» чирләр;

дүртенчедән, «эчә», «сала», «әлкәш» дигән тәмсез сүзләр һәм үз-үзеңне битәрләү өстенә, «әби»нең мырлавы һәм тагын синең – Розальнең битәрләве... Әйтик, телефон аркылы булса да.

Икенче мәсьәлә.

Шөн Сабантуенда сүзгә килдек: син миңа кычкырдың, дөрес, мин дә үземне «на уровне» тотмадым (ихтыярсызлык!). Шулай да, әйдә ачуланышмыйк әле, матурым! Туйдым инде мин дөньядагы талашлардан. Әлфия белән торганда да, соңгы еллар гаугалы булды, аннан соң да тормыш тыныч булмады һәм хәзер дә... Син хәзер телефоннан да кычкыра башладың. Әйдә, ташлашыйк әле ул талашны, җаным! Мин бит сине тыныч, җайлы, ипле, әкрен, иркә, иркәләүчән, шул ук вакытта практик, тере, энергияле, эшчән һәм тагын сөйкемле, тәм табып сөйләүчән, матур-мөлаем Розалия буларак яратам. Әлбәттә, син дә мине уңай яклар өчен якын итәсеңдер. Бу – логика! Беркемне дә яман яклар өчен яратып булмый.

Ә талашка килгәндә... «Әби» белән дә талаш, редакциягә бардым, планёркада кычкырыш, авыл советына җыелышка мендем – анда әрләшү...

Йа Аллам! Шуның өчен генә яшибезмени бер минутлык дөньяда?! Без бит җирдә кунак кына. Монда күпме байлык, акча-мал җыйсаң да, тегендә берни алып китеп булмый. Булганына риза була белик. Аллага шөкер, дия белик. Иң зур байлык – саулык икәнен онытмыйк.

Тагын бер мәсьәлә.

Кабат әйтәм: мин синең белән икән – синең белән генә! Мин – берсөяр (однолюб), кемемдер бар икән – башка беркем дә кирәкми. Аңла, чын күңелдән әйтәм, һәм – онытма!

Син җыйган чәчәкләр һаман вазада торалар...

Син җыйган чәчәкләр
Син җыйган чәчәкләр вазада...
саклана аларда аз гына –
күңелең аһәңе – азаны,
Шулай ук кулларың назы да...

Син җыйган чәчәкләр вазада...
Кушылып бу моңым сазына,
Казанның гөлсөяр кызына,
Алардан җыр-сәлам языла...

Син җыйган чәчәкләр вазада...
Шиңәрләр – калмастыр азы да...
Тик бездә яшәсен яз гына.
Уралып сөю-гөл назына!

Өстәп, ни яза алам?

Бу хат болай да озын – буталчык, үзем кебек беркатлы, мәгънәсезрәк чыкты бугай. Шулай икән, гафу ит! Кем әйтмешли, кыек җирләрен төзәтеп укы!

Синең хакта гына уйлап: Рафаэль.

22 июнь, 91 ел.»

«Р.гә

Хәтерлимсең: сөю бөреләнде –
Чәчкәсенә аның кар аттык...
Озак еллар узгач, очраштык та –
Бер-беребезне тагын яраттык!

Шундый олы яратудан тормыш
Матуррак булды, баерак.
Ләкин мәңге бергә булганнар да
Китәчәкләр – Үлем аера...

Без түзәрбез! – язмыш гөрзиләре
Яратуга безнең мең орсын.
Бәхет саныйм: Әҗәл килгән көнне
Яннарымда минем син торсаң...

Хәер... Кара бәхет булыр ул чак –
Кемнәр анда шатлык тояр соң?
Мин үлгәчтен... бер көн тып-тын гына
каберемә чәчәк куярсың...

Һәм хәтерлә: сөю бөре иде –
Чәчкәсенә аның кар аттык.
Озак еллар узгач, очраштык та –
Бер-беребезне шундый яраттык!

14 ноябрь, 1991 ел, Түбән Шөн.»

«Сәер хәлләр еш була. Клубта өстәл тартмасындагы кәгазьләрне актарып утырганда, культура бүлегеннән килгән конверт эченә язылган шактый озын гына шигырь юлларына юлыктым. Укый башладым һәм аптырап ук калдым. Бу – Розалиянең туган көненә клубта алдан язылган әйбер икән. Күрәсең, мин аны 30 августта, туган көнендә укырга җыенганмындыр. Барып кына чыкмады, ул Алтай, Бийск якларына китте августта.

Розалиянең туган көненә

Күп меңнәрдән тик бер очрак белән
Килгән икән адәм бу җиргә.
Эше белән матур кеше булып,
Гүзәл җирне тиеш бизәргә.

Килгәненә тиеш сөенергә,
Киенергә тиеш патшадай.
Тик кибеткә керсәң, әйбер диеп,
Сатучылар тора: «Акча дай!»

Син акчага торма һич табынып,
Бакчаларга чык син, чык кырга –
Яшьлегеңнең гүзәл мизгелләре
Үткәннәргә сине чакыра.

Кырык ике җәең үткән икән –
Кырык ике җәең тоттыңмы?
Оттырышлар күпме тормышыңда?
Иң зур бәхетеңне оттыңмы?

Иң зур бәхет – сәламәтлек, диләр,
Саулыкларың булсын гомерлек!
Балаларың белән биеп-көлеп,
Оныкларың сөеп йөрерлек!

Кемнәр байлык эзләп яшәсеннәр...
Иң зур байлык – кызың һәм улың!
Сине алар һәрчак хөрмәт итсен –
Иң зур хөрмәт – Җирдә хак юлың...

...Күпме гомер узды очрашудан
Очрашуга кадәр арада.
Җирдә хатын-кызлар бихисап та –
Тик сине мин алдым аралап.

Мин моңарчы синнән башка гына,
Әмма онытмыйча яшәдем.
Кырык ике тулган ипле көнне
«Бердәнберем!» – диеп дәшәмен.

Кырык ике яшьлек яшь хатын син,
Гүя сиңа һаман унсигез.
Холык-акыл, бәлки, төрледер дә –
Мәхәббәттә булсын җан тигез.

Күп меңнәрдән тик бер очрак белән
Килгән икән кеше дөньяга –
Исәнлегең белән бәхетле син!
Дип әйтәсем килә мин аңа.

02. 12. 91»

«Телефоннан апа белән сөйләшү. Розальне мактый. Хм-м! Лариса да Казанда аны бик яратып кайткан икән. Мөнҗия апа: «Розалия белән аерылышмагыз – кушылыгыз!» – ди. Безгә кунакка чыгыгыз, ди. Да-а-а. Дела-а-а! Болай булгач, кушылмыйм дисәң дә кушылырсың әле. Ә кушылудан бер дә матур тормыш чыкмас шул... 11. 12. 91.»

«Розалия!

Мин сине 8е һәм 9ы дүрт күз белән көткән идем, ләкин син ярты, хәтта чирек күзлек тә күренмәдең. Аңладым – үпкәләгәнсең! Мин гаепле – кичер!

Шул салуны – дуңгызлыкны һич тәртипкә китерә алмадым инде. Әмма хәзер ант бирәм – ул әшәкелектән арыначакмын!!! Иначе – Үлем. Хәтта үз-үземә шундый ант бирдем.

Аңла, әнә шул 2–3 көн беспробудно, хайваннарча эчеп алу миндә соңыннан бер атналык, хәтта 10–13 көнлек депрессия, күңел төшенкелеге тудыра. Үз-үземә кул салырга йөргән мизгелләр дә юк түгел. Нидер саклап кына кала...

Сез киткәч, бавыр авыртып интектем, пессимизм, рухи бушлык, үкенеч...

Бүгенге көнне син – минем иң яраткан кешем, шуңа безгә аерылырга ярамый. Белмим, мин синең өчен кемдер... Үзем, шәхсән, сиңа мәхәббәт күзлегеннән карыйм.

Үзем гафу итә белмәсәм дә, гафу үтенәм!

Яратып: Рафаэль.

P.S. «Ватаным Татарстан» газетасының 8 май санында минем шигырьләр чыккан. Фоторәсем һәм Зөлфәт сүзләре белән. Биш шигырь. Тапсаң – кара.

10 май, 1992 ел.»

«Розалия ханым Казыйханова!

Мин бәндәгез татар конгрессына килә алмады. Төп сәбәп: делегат буларак чакыру кәгазе юк иде. Дөресен әйткәндә, нигәдер аягым да тартмады. «Дуслык»тан конгресска безнең редактор баргач, җитәр дип уйлаганмындыр. Соңгы вакыт Казан да тартмый.

Килүен дүшәмбегә чамалап хәл кылган идем, чөнки язу-сызу буенча да күрәсе кешеләрем бар иде. Хәер, аларның атна башында эш урынында булмаулары көн кебек ачык инде. Шуның өстенә Алмаз да Казанга куалады: «Бар, әйдә, Розалия апага обещать иттең бит киләм дип». Бердән, сиңа биргән вәгъдә – сүзне үтәтәсе килә, икенчедән – кызы белән бездә аулак өй ясыйсы килгәндер. Кемдә ни кайгы, дигәндәй!

Алай дисәң, мин сезнең квартирда аулак өй ясадым. Әлбәттә, тыйнак кына, әмма үземне үзем сыйлап кына: сосискалар пешердем, бер килолы лещ (татарча лүтшә дибез) балыгыннан уха иттем. Квартирагызда мин яраткан мохит иде: тыныч, кеше юк, язарга мөмкинлек – тынлык. Шуңамы биш-алты шигырь, бер заметка язып, алты-җиде гәҗит һәм бер китап укыдым (Әнәс Галиев «Намус кушканча»).

Шигырь димәктән, минем «Ватаным Татарстан»да басылган әйберләрне Ш.Мостафин, Асия Юнысова, рәссам һәм шагыйрь Зөлфәт Хәйруллин мактап телгә алдылар. Ни өнәмичәрәк йөрешкән Рәдиф Гаташ та: «Кызыклы гына табышларың бар», – диде. Шаһинур: «Син оригиналь, беркемгә дә охшамаган шагыйрь», – ди. «Көзгә Язучылар Союзына алырга кирәк сине», – ди. Мин каршы, әлбәттә. Союзга омтылганым да юк. Язу язучы булу өчен түгел. Язар өчен! Тагы шунысы да бар: «Ватаным Татарстан»да теге эш һаман саклана икән. Күрүгә, Асия сүгеп-тиргәп ташлады: «Синең өчен саклап тордым, бүген үк күч, бүген алабыз», – ди. Хезмәт хакы аена 3 мең тәңкә + гонорар. Кызыктыра, чукынгыры! Әле редактор Мөнир Әһлиуллин да: «Күч безгә, Рафаэль!» – дип тора (ул мине шигырьләр буенча, Асия сөйләве аша белә икән).

Эх! Ух!!! Нигә 81–82 елларда чакырмадылар алар?! Хәзер әнә шаяртып, «үз иркеңдә эшләү», хәтта шаярып «квартиралы хатын» табарга да вәгъдә итәләр. Мин: «Бар инде минем квартиралы хатыным», – дим. «Чын хатынмы?» – диләр. Мин: «Закон алдында чын түгел инде...» – дим. «Ә-ә-ә, – дип көлешәләр. – Любовница инде алайса!» Ә мин каршы төшәм: «Любовница эзләп, Казанга йөримени кеше? Вятские Поляныда бар ич алар». «Хатының да түгел, любовница да түгел, кем соң инде ул?» – диләр. «Студент еллары мәхәббәте!» – дим. (Мин юләр һәм беркатлы һаман шул чагыңа гашыйк: «Я Вас любил...»)

Менә шунда тыналар. Сине (мине дә) зурлап тыналар. Синең турыда бер-ике характерлы сүз әйткәч, Асия: «Акыллы-төпле хатынга охшый», – ди.

«Сирәгрәк очрашу» кайдан килде күңелгә? Әнә шул очрашкан саен тарткалаш, тәмсезлек, несовместимостьтан соң... Без күрәсең, несовместимые люди. Вообще, синдә күбрәк ир-атлар билгесе: идарә итәргә тырышу, һәрнәрсәдә алдан бару, үзеңнекен генә сөрү... Ә бит хатын-кыз нечкә күңелле, нәфис, йомшак, податливая булса – кемгә дә ошый. Ирләргә юл кую күбрәк кирәктер. Хәер, кем ничек өйрәнгән инде. Нинди мохиттә яшисең бит.

Тагын нәрсә бар соң әле? Ә! Синең өйдә юклыгыңны поездга утыруга сизендем. Интуиция! Дөрес. Азнакайда бәби туенда димәдем, Сабан туеннан соң берәр иптәш хатынында кунып калачак инде бу, дидем. Шулай да өйдә юклыгың рас килде, әмма изге эш белән йөрисең. Синең беренче оныгыңа саулык-сәламәтлек һәм бәхетләр телим! Менә син дә чын әби булдың хәзер.

Хәзергә сау бул! Очрашканга кадәр.

Хөрмәт вә ихтирам белән үз итеп һәм якын күреп: Рафаэль Сибат.

Казан. Дүшәмбе. 22.06. 92.

«Апрельдә сиңа багышлап, берничә шигырь яздым.

Розалия

Оныт диде кемдер... Сөю шундый –
Тән, киемдәй ул да туза ди.
Хәтер исән чакта һич онытмам,
Розалия – Розаль – Розали...

Оныт диде көннәр... Аны сөю
Айлар буе тоташ җәза ди.
Көннәр түгел, кем дә оныттырмас
Розалия – Розаль – Розали...

Оныт диләр еллар... Уза гомер,
Сагынулар булып уза да.
Еллар түгел, Үлем оныттырмас!
Розалия – Розаль – Розали...

Сагынып, яратып, очрашу көтеп: Рафаэль
18 апрель, 1993 ел.»
«Розалия!

Без фәкыйрегез үз ягына олакты. Соңгы көннәрдә искә төшеп, хәтта төшкә дә кереп, сагыну дигән хис уяткан идең – менә үзеңне күрдем.

Вакыт агып, айлар үткәч,
Сиңа мин килдем тагын.
Синсез миңа яшәүләр юк,
хет сагынма, хет сагын.
30 үктәбер, 1993 сәнә.»

«Бисмиллаһир-рахманир-рахим!

Сәлам Сезки гыйззәтлү вә хөрмәтлү Рәфкать кызы Рузалия Казыйхан оныгына!

Ошбу сагынычлы сәламне дүндерүчегез Сезнең 25 сәнәлек колыгыз, Сөю дигән җәннәти утта янучы фәкыйрегез Шәйхуҗа угылы Рафаил Сибат оныгыдыр. Бу көнне мунча ягуб йөргәндә, хасин күңелемез Сездән гали, вәли, шәрәф, гүзәл ханымызны уйга китереб, биш тапкыр суга баруыбызның һәркаюсында да гел исемдә улдыгыз. Әлмисахтан бирле Адәм балалары инсаннарда хоббес нәфес белән берлә чит бер кешене ярату да бар. Хак Тәгалә мәңгелек вә Чын Сөю өчен һәр ир яисә хатынга бер генә зат яраткан. Мәнем өчен тудырылган Олуг Зат Сезләрдер. Үктәбер аеннан соң булган очрашудан соң ярты еллап вакыт узса да, Сезки гыйззәтлү вә хөрмәтлү ханымга булган сөю кимисе урынга нигәдер арта гына төште. Без фәкыйрегез аңлады: дөньядагы бернинди Раулялар. Әлфияләр, Гөлфияләр, Алияләр Сезне алыштыра алмый икән. Хәер, без моны электән үк сиземли идек. Әлеге аталганнарның барысын бергә җыеп, мәхәббәтнең үлчәү тәлинкәсенә салсаң – бер Рәфкать кызы Рузалияне басачак түгелләр! Әлегеләр нуль булмасалар да, Сезки ханумҗан каршында сан түгелләрдер. Сез, чырагым, мәңгелек!

Әлегеләрне искә алуымызга ачугыз килмәсен. Сибат сәфаләт эзләмәсә дә, сәфаләт Сибатны эзләде. Рафаил булсам да, үземне фәзаил санамыйм, чөнки Сибатта фасид улмаслык сәбат бар. Сибатлар шундый сибаттан. Бер хатын-кызга гына егылалар.

Аллаһыма рәхмәт! Ләүхелмәхфүз безне очраштырды. Инде ниичәнче кат тәкрар кылам:

– Мин Сезне яратам!

Без колыгыз буны калҗбан әйтәдер. Сезне хәтерләб зикер укыйм, мәгәр сез ханумны бервакытта да тәхкыйрҗ итеп йөрмәдек. Әлгаязе билләһм. Мәктүбебез тәмам.

Хәер хаһ берлән Рафаил – Алла колы һәм Сезнең колыгыз.

Розаль, матурым!

Сиңа шундый искечәрәк хат юлладым әле. Нигә искечә?

Хисләрем искечә калганга. Дәлилгә, көндәлектән берничә юл китерәм:

«Сөю дисәм, мәхәббәт дисәм – Ул искә төшә. Ул гына..

(23 март)

***

Үтереп аяк сызлый. Розаль Казанда шешне бетергәннән соң болай сызлаганы, интектергәне юк иде әле.

***

Үлеп Розальне сагындым! Мин аны үлгәнче яратачакмын!!! Хәтта үлгәч тә...

(29 март)

***

А. белән очраштык. Рәшитләргә киттек. Ә нигә Р. сагындыра? Янда – хатын-кыз, ә ул искә төшә. Ник алай? Ратканга!

(2 апрель)

***

Мин аны яраттым... аерылдык. Әмма мәңгегә түгел.

(10 апрель)

«Розалия матурым!

Менә мин тагын тәртиптә. Бүген зәм-зәм суы белән ике тапкыр керделәр – бер айга пас. Казаннан кайтуга, гадәтемчә, кисәк кенә эчүне туктаттым, чама белән берәр айга. Кич үзем генә китап укып, телевизор карап утырам. Ташкентка шагыйрь Хәмит Төхфигә, Казанга – сиңа хат яздым. Шулай килеп чыкты, Хәмит агага хат язгач, сиңа да язасым килде. Нигәме? Әнә шул өч көндә матур гына итеп синең туган көнеңне икәү генә уздыра алмаганга. Матур мәҗлес кора алмаганга...

Ярый инде, гафу үтенеп тормый, гел дә кичерү сорап йөрү – саилчелек, мескенлек һәм шапшаклык ул. Булганы – булган! Бары да – мин!

Ә бит үземчә нинди матур уй-хыяллар белән синең туган көнне уздырырга килгән идем. Истәлеккә берәр бүләк тә алырбыз дигән идем. Юк, булмады. Минем РОК – бәхетсез язмыш инде бу. В-Полянычдагы туган көн мәҗлесе һ.б. бозды инде, ә төп гаеп – әлбәттә, үземдә. Кемнәрдә дә түгел.

Йә, ярый! Синең туган көнне мин отпускага чыккач (сентябрь йә октябрь), соңга калып булса да, икәү генә уздырырбыз әле. Нигә азапланырга, выше себя не прыгнешь.

Саулыклар теләп, элеккечә хис белән Рафаэль.

P. S. «Казан» журналының өченче санында минем «Югалтулар табышы» повесте чыгарга тиеш. Күрсәң – ал: анда 1968 ел, 28 октябрь – синең белән аерылу да сурәтләнгән.

Хат көтмим. Язып торма.

Бер горурга
(Р.гә)

Синең өчен күкнең бакчасыннан
Өзәр идем тәлгәш
йолдызлар:
Мәхәббәттә кайчак
ялгызлар без,
Мәхәббәттә кайчак
юлсызлар...

Ә син матур, гаҗәп горур
матур!
Матурлыкның, әйе, үзедәй.
Мине дә бит ул көн биләп
алды
Горурлыкның үзе
әй...

Без – кешеләр, шулай
болай гына
Кайчак юри горур торабыз.
Син гаҗизсең...
Сиңа карамый да
Мәрмәр сындай басып тора
кыз.

Сөйгәнне дә белдең...
Горур булдың...
Аерылыштык инде, сылуым,
Шунысы яман – белми
киттең тәки
Горурлыкның...
Миндә артыграк булуын.»

Хатларны **Гөлнур САФИУЛЛИНА** *укыды.*

Әкбәр Гошалы – Әкбәр Мәһди улы Йолчуев – Азәрбайҗан ССРның Товуз районы Гоша авылында туган. Шагыйрь, тәрҗемәче, журналист. Кырыктан артык китап авторы. Азәрбайҗанның Тәрәккый медале һәм Азәрбайҗан Республикасының 100 еллыгы уңаеннан юбилей медале белән бүләкләнгән. Бакуда яши.

Әкбәр
Гошалы

ҺӘР АВАЗДАН ДА СҮЗ ЯСАП БУЛМАС

Дин булганчы, сөю үзе дин иде

Дин булганчы, Сөю үзе Дин иде,
Гашыйк ярлар, анда һәрбер җан – гашыйк.
Тәүге сүзе тавышсыз бер өн иде,
Бер бизәктер хәзер сүзсез карашы.

Чорлар үткәч, соңгы сүзләр дин илә,
Гыйшык юлын кисәргәме, дин иңә?
Акыл – хаким, җанда – сөю, дин – тышау,
Туктап калма, киртәләрне ват, Гашыйк!

Әкбәр әйтер, бу мәңгелек зилзилә,
Йөрәктә – син, телем генә «кит» дия.
Калеб – әмир, мин – хадиме; «кал!» дисәм,
Ни диярсең, әй мәңгелек юлдашым?!

Тауларга яңгыр явачак

Болытлар диңгезгә ташланды,
Бүген кич яварлар тауларга.
Ирешер гарешкә һәр догаң,
Капусын күкләрең ачар да.

Яңгырлар коелыр бүген кич
Бар кеше йөгерер тирмәгә.
Бер мәҗнүн кулларын күтәрер
Иң изге теләген теләргә.

Агылыр һәркем дә өенә,
Тауларда эрер бар гүзәллек.
Киткәннәр, килгәннәр Тәңре, ди,
Тирмәнең түренә тезләнеп.

Талышның өстендә – болытлар,
Диңгезгә ятарлар бу кичә.
Капусы ачылмас күкләрнең
Ак йөзле гүзәлне күрмичә.

Дәшәр

Син уңга киткәндә, сул сине дәшәр,
Йокыга киткәндә, юл сине дәшәр,
Һәр аваздан да сүз ясап булмас,
Калеб сагыш гизәр, тел гамьне дәшәр.

Шул ук җирдән килер, башкадыр исме
Моң тәме башкадыр, башка сүз тәме.
Иң гүзәл моңнар кара саздадыр,
«Кәрәми» чакырыр, «Дилгәми»* дәшәр.

Үлемсез диләр сүз, моңнар да үлми,
Үлгәннән соң нигә ул моңнар килми?
Киләдер, киләдер,
Ишетелми генә,
Үталмый гынадыр ул кәфен аша.

Шагыйрьләр янып кавышыр

Мәтләб Агага багышлап

Шагыйрьләр янып кавышыр:
Янды шәм вә күбәләк...
Иртән үлеп, кич терелә,
Оча шәмнәр тирәләп.

Күрсәләр сөю тынганны,
Мең сүз кайта әйләнеп.
Сиңа да килер кыямәт,
Канатыңа бәйләнеп.

Булган булды,
Кичкән кичте,
Чынга ашканда һәр сөю,
Канатларың бәйләнде.
Яндырды күбәләкне шәм,
Яндырды күбәләк шәмне!

* «Кәрәми», «Дилгәми» – азәрбайҗан халык көйләре.

Нинди атага угыл без?

Атабызга нинди угыл без?
Нинди угылга ата?..
Угылларыбыздан безгә
Атабыз нуры кайта.

Әтиебездән тусак та,
Атабыз булып булмас.
Атабызга тиң булырга
Яңадан туып булмас.

...Беләм мин: «Үлем килер»
Дисәм дә үлем килер.
Тагын бер кат Булым килмәс,
Килсә дә Үлем килер.

Керфегемә төргән идем

Керфегемә төргән идем
сөюемнең чаткысын,
Сине күргәч, нигә җанга
кайнар утлар капты соң?
Мәхәббәттә янган дуслар
Киңәш бирде үземә:
Йөрәгеңдә янган утны
Җиткер, диләр, үзеңә.

Син теләсәң, башканы сөй,
Ул минем утым гына.
Сөю минем йөрәгемне
Ягучы утын гына.
Кемдә калды, кемгә калды
Безнең сөю урамда?
Күкрәгемдә йөрәк янмый,
Йөрәк үзе ут анда.

Мин дөрләдем, утта яндым,
ни дәшмәдең, ни тындың...
Әллә инде син үзең дә
Йөрәксез кеше булдың?
Ни динсезлек, ни дин түгел –
Мәхәббәт тә бер тына.
Әгәр яна алмый икән,
Йөрәк үзе ут була.

Азәрбайҗан теленнән **Рифат СӘЛАХ** *тәрҗемәләре.*

Сажидә Сөләйманованың туууына 95 ел

ТУГАН ЯККА УЗА КОШ ЮЛЛАРЫ...

Татарстан радиосы дулкыннарында Сажидә Сөләйманованың исеме тынып торганы юк. Аның шигырьләреннән һәм аларга иҗат ителгән җырлардан төзелгән әдәби-музыкаль композицияләр, иҗатына багышлап әзерләнгән тапшырулар әледән-әле эфирда яңгырап тора. Җырлары исә тематик тапшыруларда музыкаль иллюстрация сыйфатында да, аерым концертларда да файдаланыла. «Туй җыры» (Ш.Кашапов музыкасы), «Әлмәтем, мәхәббәтем» (С.Садыйкова), «Нефтьчеләр маршы» (М.Имашев), «Урсал тауда» (Р.Нәгыймов), «Казан вальсы» (Р.Бикбулатов), «Җил дә үтә алмас арада» (Ю.Юнысов), «Аһ, җаныем Бибисара» (С.Чуганаев), «Җырчы кызга» (Р.Яхин), «Кәккүк» (А.Монасыйпов) кебек җырлары тыңлаучыларыбыз тарафыннан һәрвакыт күтәп алына. Татарстан Язучылар берлеге һәм «Татнефть» ААҖ гамәлгә куйган Сажидә Сөләйманова исемендәге әдәби премияне тапшыру тантаналарыннан репортажлар бирү ныклы бер традициягә әверелде. Шагыйрәнең туууына 95 ел тулу уңаеннан махсус тапшыру әзерләнә.

Хәзер без журнал укучылар игътибарына радио фондында саклана торган кадерле бер язма тәкъдим итәбез. «Туган якка уза кош юллары» дип исемләнгән бу тапшыру танылган язучы Зәки Зәйнуллин тарафыннан 1990 елларда әзерләнгән иде. Бу язмага игътибар юнәлтүебез юкка гына түгел, чөнки биредә шагыйрәнең тормыш юлы да, иҗат сукмаклары да, иҗатының олылыгы турында уйланулар да урын алган. Монда без Сажидә Сөләймановaның үз тавышын да ишетәбез. Тапшыруны Тәлгать Хаматшин алып бара, текстны Ренат Таҗетдинов укый.

Бу QR-код аша сайтыбызга кереп, тапшыруны тыңлый аласыз.

Мөдәррис Әгъләмовның тууына 75 ел

ТУЗГА ЯЗГАН СҮЗЛӘР ГЕНӘ КАЛДЫ



«Тузга язган сүзләр генә калыр,
Дөрес сүзләр генә калыр безнең хакта»,

– дип язган иде Мөдәррис Әгъләмов.

Чыннан да, адәм баласы бу якты дөньяда яшәгән чагында, фанилык тузаннары арасында йөреп, төрле төсләргә, төрле килбәтләргә керә, аның турында төрле сүзләр йөри, ә инде ул бакыйлыкка китеп баргач, еллар үткән саен әлеге тузаннар тарала һәм шәхеснең чын асылы, үзәге ачыла. Менә без дә Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Мөдәррис Әгъләмовның (1946-2006) иҗатына салынган әнә шул асылын ераккарак киткән саен ачыграк аңлый, Аллаһы Тәгалә безгә нинди олы шагыйрь биргән булган икән бит, дип төшенә барабыз. Аның фикере, хисе, әйткәннәре бүген, менә шушы буталчык бер вакытта, безнең өчен зиһен һәм күңел ихтыяҗына, кыйбланамәгә әверелде. Мөдәррис Әгъләмов үзе исән вакытта да узган гасырның 60 нчы – 80 нче елларында туып-үскән милләттәшләребезнең зыялы катлавына көчле йогынты ясаган, аларның шәхес булып формалашуына этәргеч биргән шагыйрьләрнең берсе булды. Һәм менә ул калдырган рухи ризыкны бүген мәйданга чыккан буыннарга да тапшырып бару таләп ителә. Монысы инде – Әгъләм рухында тәрбияләнеп үскәннәрнең бурычы.

Әнә шул бурычны күздә тотып, әдипнең тууына 70 ел тулу уңаеннан Татарстан радиосы фондында аның тавышы сакланган язмалар хәрәкәткә китерелә. Болар – шагыйрь катнашында әзерләнгән тапшырулар, төрле кичәләрдә, шигъри митингларда ясаган чыгышлары, аның артистлар башкаруындагы әсәрләре, шигырьләренә иҗат ителгән җырлар. Хәзер игътибарыгызга тәкъдим ителә торган тапшыруда әлеге язмаларның берничәсе туплап бирелде. Шунысын да әйтик, 11 – 17 октябрь көннәрендә «Татарстан» радиосы дулкыннарында Мөдәррис Әгъләмов шигърияте атналыгы игълан ителә.

Бу QR-код аша сайтыбызга кереп,
тапшыруны тыңлый аласыз.

Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире **Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

1917 ЕЛГЫ ИНКЫЙЛАБКА КАДӘР ҖАНИСӘПЛӘР: ЙОМГАК УРЫНЫНА

XVIII гасырда ревизия кенәгәләрен файдалануның бер мисалы турында. Патша Россиясендә яшәгән татарлар арасында 1917 елга кадәр үзләренең нәсел-нәсәпләре белән максатчан рәвештә, нигездә, сәүдәгәрләр һәм морзалар, йомышлылар катламы вәкилләре кызыксынган. Моның төп сәбәбе – күчемсез милке булган һәр ир-атның хәләл көч түгеп туплаган мал-мөлкәтен мирас итеп, нәсел дәвамчыларына тапшырырга омтылуында. Әлбәттә, һәр гаилә ата-бабаларына бирелгән рәсми документларны кадерләп саклаган.

Аграр илдә төп байлык булып җир биләмәләре саналган, ә алар дәүләт кулында тупланган. Ясаклы, 1721 елдан соң дәүләт крестьяннары итеп язылган ата-бабаларыбызның исә, каралты-курасыннан кала, күчемсез милекләре булмаган дип әйтергә мөмкин. Татар җәмгыятенең тормышын гаделлек, тигезлек принцибы буенча оештырырга омтылган игенчеләр, халык саны артуны һәм даими рәвештә ревизияләр узуны исәпкә алып (салымнар шул ревизия кенәгәләре мәгълүматлары буенча бүленгән), 6, 8, 12 елга бер яки башка бер даимилек белән дәүләт тарафыннан вакытлыча куллануга бирелгән җирләрнең һәр басуын гаиләләргә, алардагы ир-атлар саныннан чыгып бүлеп биргәннәр. 1887 елдан башлап җир биләмәләрен шәхси милеккә әйләндерү өчен мәҗбүри түләп барылган «выкупной платеж» 1907 елдан башлап, гамәлдән алынгач, кишәрлекләрне күмәкләп куллануны туктату һәм хәллерәк игенче хуҗалыкларын аерып чыгару өчен дәүләт татарлар арасында популярлык тапмаган П.А.Столыпин аграр реформасын гамәлгә куйган.

Нәсел-нәсәпләрне ачыкларга омтылуның икенче сәбәбе 1773-1775 елгы Е.Пугачёв җитәкчелегендә баш күтәрүдән соң, Екатерина IIнең мөселманнарның югары катлау вәкилләре белән мөнәсәбәтләрне хезмәттәшлеккә нигезләп кору сәясәтенә бәйле була. Аның кануни чагылышы дип, 1788 елның декабрендә Мәхкәмәи шәргыя оештыру турында һәм 1784 елның 22 февралендә «Татар кенәзләренә һәм морзаларына Россия дворяннарының барлык өстенлекләреннән файдалануны рөхсәт итү» дигән патшабикә кул куйган указларны күрсәтергә кирәк.

Бу катлаулы һәм четерекле реформаны мәгълүмати һәм хокукый яктан әзерләү 1770 нче еллар азагында җирле хакимият тарафыннан башкарыла. Беренче зур масштаблы хезмәт нәтиҗәләре 1780 елда җирле хакимият тарафыннан Казан губернасы генерал-губернаторы Платон Мещерскийга тапшырылган исемлектә чагылыш таба. Исемлекне төзү өчен кирәкле кәгазьләр гаилә һәм хакимият архивларыннан туплана.

Әлеге исемлеккә нәсел-нәсәпләре һәм яшәү урыннары белән Казан губернасының Казан, Зөя (Свияжск), Сембер һәм Алатыр өязләренә караган татар кенәзләре һәм морзалары туплана. Башта аңа үзләренең аксөяк килеп чыгышы хакында шактый зур дәлилләре булган иң билгеле фамилияләр (Яушевлар, Янбулатовлар, Ишиевлар, Богдановлар, Енгалычевлар, Акчуриннар һ.б.) кертелә. Исемлек ахырында 1 нче, 2 нче һәм 3 нче ревизия мәгълүматларыннан тыш, кулларында башка дәлил-документлары булмаган морзалар китерелә. Аерым исемлек белән Казан өязенең үзләрен аксөяк нәселдән килеп чыккан дип исәпләгән, әмма 2 нче һәм 3 нче ревизия кенәгәләре буенча алдагы исемлектәгеләрдән аермалы буларак, кенәзләр һәм морзалар дип түгел, бәлки, йомышлы татарлар буларак теркәлгән нәселләр күрсәтелә.

Кәгазьләрне әзерләү 1780 елны башкарылса да, алар 1762 елны уздырылган 3 нче ревизия кенәгәләренә нигезләнә. Кешеләрнең яше дә шул 3 нче ревизиядәгечә алына. Барлыгы, тупланган мәгълүматлар буенча, Казан губернасының дүрт өязендә ир-ат җенесеннән булган 911 морза яшәве, аларның 426сы Казан (28 нәсел), 193е Зөя (12 нәсел), 257се Сембер (19 нәсел), 35е Алатыр (1 нәсел) өязләрендә булу ачыклана. Шунысын да әйтергә кирәк: документка теркәлгән нәселләр саны шартлы була, чөнки кешеләрне исемлеккә нәселләргә карап язмаганнар: бер нәсел вәкилләре төрле авылларда яшәсә, төрлечә теркәлә алган, шул ук вакытта әгәр бер авылда ике яки аннан да артыграк затлы нәсел дәвамчылары яшәгән очракта, алар бер сан астында китерелә алган. Аннары, күрсәтелгән 60 морза нәселенең 25е үзләренең аксөяк килеп чыгышы хакында, ревизия кәгазьләрендә язудан тыш, башка бернинди дәлил тапмаган. Кайберәүләр, саллы дәлилләргә таянып, үзләренең теге яки бу морза нәселеннән булуын расласалар да, исемнәре әлеге нәселнең шәҗәрәләрендә күренмәгән.

Дәлилләр төсендә хезмәт иткән өчен кенәзлек дәрәҗәсе бирү турында грамоталар, хәрби төрле чиннарда (ротмистр, поручик, хорунжий) хезмәт итү хакында белешмәләр, крестьяннар тотуга, кабакларга, кичү урыннарына, тегермәннәргә, умартачылык биләмәләренә хуҗа булуга рөхсәт кәгазьләре файдаланылган. Әгәр асыл нөсхәләре юк икән, җир биләмәләренә, печәнлекләргә һәм крестьяннарга хуҗа булу хакындагы кәгазьләрдән күчермәләр дә яраган. Хәтта «хезмәткә эләкмәгән өчен кеше башыннан бер сум» җыю хакында грамоталар, ягъни ата-бабаларының дәүләткә хезмәт итүенә кагылышлы теләсә нинди документлар исәпкә алынган.

Исемлектә шулай ук морзаларга беркетелгән хезмәтчеләр санына игътибар ителгән. Берничә очракта хезмәтчеләрнең морзалар өчен кырда яки башка эшләр башкаруы, аксөякләрнең моның өчен җан башыннан түләве (Яушевлар, Байкиевлар, Еникиевлар, Хуҗасәитовлар, Үрәкәевләр, Алишевлар, Дулатовлар, Сөндековлар) теркәлеп калган.

Бу исемлектә, нигездә, мөселманнар булып, керәшен татарларыннан да берничә фамилия күренә *(Файзрахманов И.З. Мурзинские роды Казанской губернии: свидетельства их именитого происхождения согласно сведениям Казанской губернской и провинциальных канцелярий за 1780 год // Средневековые тюрко-татарские государства. 2019. №9. С. 119-162).*

Тарих фәннәре кандидаты Илшат Фәйзрахманов тарафыннан әзерләп, фәнни әйләнешкә кертелгән бу исемлек, һичшиксез, морза һәм йомышлы татарлар нәселләреннән булган замандашларыбызга кыйммәтле бүләк булды. Аларның бүгенге нәсел дәвамчылары аны – җанисәп мөмкинлек биргән бер әзер чыганак буларак файдалана һәм үзләренең оныкларына калдыра алалар. Үз чиратында, бу мисал җанисәп мәгълүматларының кулланылыш кырын киңәйтә.

Узган гасырның 80-90 нчы елларында җәмгыятьтәге демократик үзгәрешләрнең бер чагылышы буларак, милли үзаң ныгу, татар тарихы белән кызыксыну көчәю сәбәпле, татарларда нәсел-нәсәпне ачыклауга ихтыяҗ артты. Нәсел җепләрен барлап, шәҗәрәләр эшләү зур бер хәрәкәт төсен ала. Үз чиратында, нәсел тарихларын милләт тарихына бәйләү өчен төбәк тарихчылары белән галимнәрнең хезмәттәшлеге һәм авыллар буенча төбәкләп ревизия кенәгәләрен бастырып чыгару таләп ителә.

Инде тагын бер – шушы мисалдан үсеп чыга торган сорауга җавап биреп карыйк: ни өчен 1897 елгы җанисәп материалларын барлык татарларның нәсел-нәсәпләрен барлауда тиешенчә файдаланып булмый соң? Югыйсә җанисәп кәгазьләрендә кеше турында 14 төрле мәгълүмат теркәлгән бит. Эш шунда ки, Үзәк статистика комитеты 1905 елны җанисәп материалларын бастырып бетергәч, Россия империясенең барлык төбәкләреннән җыелган һәм һәр гаилә турында мәгълүмат тупланган беренчел статистика чыганакларын, башкалада саклау чыгымлы дип, көнкүрештә кулланыла торган кәгазь бәясе куеп сатып бетерә. Бу вазгыятьтә беренчесе югалган очракта кирәк

булырга мөмкин дип хәзерләнгән һәм губерна хакимият структураларында сакланучы 2 нче данә документларның да кирәге калмый...

Шулай да губерна һәм өяз җанисәп комиссияләре фондларында кайбер 2 нче данә җанисәп кәгазьләре сакланып калган. Әйтик, кызыксынган кешеләр Татарстан дәүләт архивында Казан губернасы торак пунктларыннан мәшһүр татар язучысы Гаяз Исхакыйның туган авылы Яуширмә (Чистай өязе, 104 нче фонд), Мамадыш, Әкил, Татар Танае, Олы Кошман (Зөя өязе, 106нчы фонд), Иске Салман, Абдул Салманы (Спасс өязе, 100 нче фонд), Үри Чаллысы, Чаллы башы, Казак Чаллысы, Курса (Лаеш өязе, 103 нче фонд) һәм берничә рус авылының җанисәп материаллары белән танышырга мөмкиннәр.

1897 елдагы типтәр, мишәр һәм башкортлар саннарына 1926 елгы Бөтенсоюз җанисәбеннән караш. Җанисәп материаллары аерым бер гаилә, нәсел-нәсәп турында гына түгел, милләтара аңлашылмаучылыкларны ачыклауда да билгеле бер роль уйный ала. Шундыйлардан, 2021 елгы җанисәп алдыннан калкуланган типтәр-мишәр-башкорт мәсьәләсенә кагылырга мөмкин.

1926 елны СССРда халык санын исәпләү методикасы һәм системасы 1897 елгы Беренче гомуми җанисәп тәҗрибәсенә таяна. Күрәсең, совет статистлары шул ысул белән яңа мәгълүматларны 20 ел элек җыелганнары белән чагыштырырга исәпләгән булганнардыр. Мондый дәвамчанлык халыклар / телләр һәм сөйләшләр исемлеге буенча Үзәк статистика комитеты номенклатурасына да кагыла.

1897 елгы җанисәптән аермалы буларак, 1926 елны сораштырылучыларның этник килеп чыгышын «халык» атамасына һәм «туган тел»енә бәйләргә исәплиләр. Инструкция буенча туган тел дигәндә, сораштырылган кеше «яхшырак белгән һәм сөйләшә торган» тел күздә тотыла *(Всесоюзная перепись населения 17 декабря 1926 г.: краткие сводки. Вып. 4. Народность и родной язык населения СССР. М, 1928. С.III).*

Шушы яктан чыгып караганда, татарларга кагылышлы гомумиләштерелгән статистик мәгълүматлар бик күп сораулар уята. Туган тел буларак «татар теле»н күрсәткән кешеләр саны барлыгы 3 558,4 мең килеп чыга, ә татар булып 2 913,7 мең кеше, ягъни 644,7 мең кешегә кимрәк теркәлә. Совет статистикасы алар янына «керәшеннәр» дип язылганнарны (101,5 мең кеше) өсти. Нәтиҗәдә СССРда җәмгысе 3015,2 мең татар яшәгән кебек килеп чыга *(Всесоюзная перепись населения 17 декабря 1926 г.: краткие сводки. Вып. 4. Народность и родной язык населения СССР. М, 1928. С.IX).*

Бу вакытта Идел-Урал төбәге халыклары милли автономияләрдә яшиләр. Башкортстан Автоном Совет Социалистик Республикасының чикләре берничә тапкыр күрше төбәкләрне кушу юлы белән элеккеге Уфа губернасының Уфа, Бөре, Стәрлетамак, Бәләбәй, Златоуст өязләре (Минзәлә өязеннән кала), элеккеге Оренбург губернасының 2/3 өлеше, элеккеге Пермь губернасының беркадәр өлеше һәм Самара губернасының бер волосте хисабына сузыла.

Шунысын да әйтергә кирәк, 1926 елда узган Бөтенсоюз халык санын алу вакытында туган телләр (һәм халыклар) исемлеге 1897 елгы җанисәп исемлегеннән күчереп алына. Нәтиҗәдә Урал буе төбәгендә 1926 елгы җанисәп кәгазьләрендә Советлар тарафыннан сословиеләр юкка чыгарылганнан соң анахронизмга әйләнгән «типтәрләр» һәм «мещеряклар» (мишәрләр) урын ала.

Урал төбәгендә яшәгән «халыклар» турында совет статистлары тарафыннан ясалган беренче мөһим нәтиҗә мондый була: «типтәрләр буларак, халыкның сословиедән килеп чыккан төркеме теркәлә, шуңа күрә җанисәптә бу атаманы халыкның төгәл булмаган һәм туган тел турында теркәлгәннәргә карап ачыкларга кирәк булган атамасы дип карарга кирәк» *(Всесоюзная перепись населения 17 декабря 1926 г.: краткие сводки. Вып. 4. Народность и родной язык населения СССР. М, 1928. С.Х).*

1926 елгы статистик материалларда БАССРда гадәти булмаган этносаратопография

күзәтелү Бөтенсоюз халык санын алуны оештыручыларны шулкадәр гаҗәпләндерә ки, алар үзләренең күзәтүләрен таблица рәвешенә китереп, китапның СССРда яшәүчеләрнең милләтенә һәм туган теленә багышланган «Кереш сүз»енә урнаштыралар. Бу материаллар 1897 елгы мәгълүматларга каршы килә. Алдарак (беренче мәкаләдә) әйтелгәнчә, 1897 елда Үзәк статистика комитеты җанисәп кәгазьләрендәге «Туган тел» графасындагы мәгълүматларны «Сословие» баганасындагыга алмаштыра, шул юл белән «башкорт», «типтәр» һәм «мещеряк» үзаңын коруга һәм ныгытуга омтылыш ясый.

1926 елгы Бөтенсоюз халык санын алу материалларында БАССРдагы башкорт, типтәр, мишәр һәм татарларның туган телләре хакындагы күрсәткечләр

(Всесоюзная перепись населения 17 декабря 1926 г.: краткие сводки. Вып. 4. Народность и родной язык населения СССР. М, 1928. С.X).

Халык	Халыкны билгеләү буенча (мең)	Шул исемдәге туган тел (мең)	Халыкны билгеләү буенча күбрәк (+) яки азрак (-)
Башкортлар	637,5	356,5	- 281,0
Типтәрләр	23,3	-	- 23,3
Татарлар	464,3	906,5	+ 442,2
Мещеряклар (мишәрләр)	137,9	-	- 137,9
Барлыгы	1263, 0	1263,0	0,0

Иң беренче чиратта шунысын әйтергә кирәк, 1926 елны типтәрләрнең күпчелеге һәм мишәрләрнең бер өлеше татар булып язылa. Таблицадан күренгәнчә, үзенчәлекле үзаңга ия булган типтәрләр барысы 23,3 мең кеше булып чыга, әмма алар, барлык мещеряклар (мишәрләр) кебек үк, үзләренең туган телләре дип «татар телен» күрсәтәләр. «Татар телен» туган тел буларак 44 % «башкорт» терки, бу билге буенча башкортлар саны 281 мең кешегә кими. Югарыда аталган төркемнәр арасында туган телгә кагылышлы мондый үзгәреш үзләрен татар дип атаган (464,3 мең кеше) һәм туган телен татар теле дип таныганнар арасында гаять зур аерма, дисбаланс китереп чыгара. БАССРда мондыйлар 2 тапкырга якын артык (49%) – 906,5 мең татар телле кеше була.

1926 елгы СССР статистика мәгълүматларындагы мондый хәлнең тарихи сәбәбе империя Үзәк статистика комитетының «башкорт», «типтәр» һәм «мещеряк»ларның туган телләре хакында әйткәннәренә күз йомып, аларны сословиегә караган баганадагы күрсәткечкә алыштыруы белән аңлатыла.

Шул рәвешле, 1926 елда узган Бөтенсоюз халык санын алу материаллары 1897 елгы җанисәпне фәнни яктан яңабаштан бәяләргә, нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә.

1897 елгы җанисәп материалларының төрле иҗтимагый көчләр тарафыннан XX гасыр башында сәяси максатларда кулланылуы.

Империядә яшәгән дин тотучыларның гомуми саннары тупланган басма 1901 елда *(Распределение населения империи по главным вероисповеданиям. Разработан Центральным статистическим комитетом министра внутренних дел по данным Первой всеобщей переписи населения 1897 г. – СПб., 1901),* ә халыклар саны турындагысы 1905 елда дөнья күрә *(Общий свод по империи результатов обработки данных Первой всеобщей переписи населения, произведенной 28 января 1897 года. Т.II. – СПб., 1905)*. Илдә 13,9 млн мөселман (Бохара һәм Хива ханлыкларын исәпкә алмыйча) яшәгәне, аларның дин тотучыларның 11, 1% тәшкил иткәнлекләре ачыклана.

1897 елгы җанисәп материаллары белән танышкач, мөселман иҗтимагый хәрәкәтенең лидерлары төрки этнослар санына караган төгәл цифрны күрәләр. Төрки халыклар 13,6 млн кеше, яки илдә яшәүчеләрнең 10,8% булып чыга. Иң күпсанлы төркемне күчмән-казакълар – 4,1 млн кеше тәшкил итүе ачыклана *(Россия в начале XX века. Под редакцией академика А.Н. Яковлева. М.: Новый хронограф, 2002. С.89).*

Бу заманда империя хакимияте, нигездә, халыкларның нинди дин тотуларына игътибар бирә, төрки халыкларның җәмәгать эшелләре сәяси берләшүдә ислам динен нигез итеп ала. Шул сәбәпле, сәясәт өлкәсендә «мөселманнарның саны» дигән шигарь үзәккә куела.

1905 елның 17 апрелендә «Дин иреге нигезләрен ныгыту» турында канун игълан ителгәннән соң, илдә өр-яңа конфессияара вазгыять туа. Беренче тапкыр бер диннән икенчесенә иркле күчү мөмкинлеге булдырыла. Әмма Николай IIнең 1907 елның 3 июнь көнне кул куйган Икенче Дәүләт думасын куып тарату һәм Думага яңа сайлау кагыйдәләрен раслау турындагы указларыннан соң, илдә инкыйлаб чорының демократик казанышларына тискәре караган реакцион сәясәт көчәя.

Яңа сәяси вазгыятьтән беренчеләрдән булып, Казан епархиясе миссионерлары файдаланып калырга омтылалар. Миссионерлар татар-мөселманнарның саны тиз үсүнең табигый туу белән генә түгел, бәлки, төбәктәге җирле халыкларның (чувашлар, чирмешләр, мордваларның) исламга чыгуы, «татарга әйләнүе» белән дә бәйле булуны дәлилләргә тотыналар. Бу исә, үз чиратында, мөселманнарны актив миссионерлык алып баруда гаепләргә җирлек бирә. Дәлил сыйфатында миссионерлар XX гасыр башына караган статистик мәгълүматларны файдаланалар. Мондый берьяклы нәтиҗә мөселманнарга һәм мәҗүсиләргә каршы көрәшүче епархия миссионеры С.Багинның 1909 елның 24 августында тәмамланган «Казан епархиясендә чукындырылган инородецларның мөселманлыкка чыгуы һәм бу кайгылы күренешнең сәбәпләре турында» язмасында ясала *(Особое совещание по выработке мер для противодействия татарско-мусульманскому влиянию в Приволжском крае 1910 года: документы и материалы / сост., авт. предисл., прим. и сокр. И.К. Загидуллин; сост. указ. Р.М. Залялетдинова. Казань: Изд-во Академии наук РТ, 2015. С. 122).*

«Рус мөселманнары мохитендә заман хәрәкәтләре» (1909) китабында үзенең аргументларына сәяси яңгыраш бирергә омтылып, аның авторы, Чистай епископы Алексий ислам динен тотучыларның хакимияткә каршы юнәлтелгән эшчәнлегенең «куркыныч» булуын ассызыклап, болай дип яза: «1897 елгы җанисәп буенча Россиянең Европа өлешендә генә дә алар 17 миллион булып, Хива, Бохара һәм Төркестанны да кушып санаганда – 30 миллионнан артык килеп чыга, аннары, кырык мең мөселман рус армиясендә хезмәт иткәнлекне дә онытырга ярамый. Бу мәйданда без шушы 30 миллионлык массада милли бердәмлек аңы, аңлап, иманга, белем алуга, тел берлегенә, сәяси азатлыкка омтылыш уянуга күпсанлы фактларны күрәбез» *(Особое совещание по выработке мер для противодействия татарско-мусульманскому влиянию в Приволжском крае 1910 года…С.302).*

Төрки халыкларның иҗтимагый хәрәкәте өстеннән контрольне көчәйтү максатыннан, кирәк булганда, башкала чиновниклары да сан факторын бик оста файдаланалар. Мәсәлән, 1914 елгы мөселманнар эшләрен тикшерү өчен җыелган Махсус ведомствоара киңәшмәдә җирле халыкларны өйрәнү өчен махсус вакытлы орган булдыруны нигезләү максатыннан илдә «төрле кабиләләргә һәм халыкларга караган 16 миллионнан артык мөселман яшәве, мөселман халкы сан ягыннан күпчелекне тәшкил итә торган гаять зур төбәкләр булу» телгә алына *(Особое Совещание по мусульманским делам 1914 года: Журналы / сост., авт. предисл., прим. и сокр. И.К.Загидуллин. Казань:Изд-во «Ихлас»; Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2011. С. 238).*

Татарлар арасында 1897 елгы җанисәп мәгълүматларын шәрехләүләр Беренче рус

инкыйлабы чорында күренә башлый. Уфа корылтаенда (1905 елның 10-15 апреле) казый Р.Фәхретдин Мәхкәмәи шәргыя округы территориясен киңәйтү тәкъдиме белән чыга. Аның фикеренчә, казакъларны да кушкан очракта, Мәхкәмәи шәргыя округы мөселманнарының санын исәпкә алганда (якынча 4,8 млн кеше) *(Россия в начале XX века / под ред. академика А.Н.Яковлева. М., 2002. С.89)*, диндәшләрнең саны 2 тапкыр диярлек артыр иде. Шул юл белән Р.Фәхретдин дини эшләр белән шөгыльләнү өчен казнадан елына 1 млн сум акча сорарга мөмкин булыр иде дип белдерә. Мәхкәмәи шәргыянең Корылтайда расланган устав проектында бу мәсьәлә түбәндәгечә беркетелә: аның округына Россиянең Европа өлешендә (Таврия мөфтиятенә караган Кырым ярымутравыннан һәм Көнбатыш губерналарыннан; Кавказ артыннан (анда сөнни һәм шигый руханиларының автоном дини идарәләре була. – *И.З.*) кала), Кавказның төньяк өлешендә, көнбатыш һәм көньяк Себердә (Акмулла өлкәсендәге кыргыз-кайсаклардан тыш) яшәүче барлык мөселман-сөнниләр керә (4 нче маддә) *(Загидуллин И.К. Уфимский курултай 1905 года: монография. Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2018. С.240)*. Күрәбез, Мәхкәмәи шәргыянең чикләре Казакъ даласы һәм Төньяк Кавказ хисабына киңәергә тиеш дип табыла. Әмма Беренче рус инкыйлабы җиңелгәч, империя хакимияте өчен Мәхкәмәи шәргыяның 1905 елгы устав проекты кирәксез бер кәгазьгә әверелә. Без бу документны берничә ел элек Россия дәүләт тарих архивының 821 нче фондыннан табып алдык...

Уфа корылтае белән бер үк вакытта 1897 елгы мәгълүматларны саллы аргумент буларак файдалану петицияләр бирү кампаниясендә чагылыш таба. Илдә сәяси киеренкелекне йомшарту һәм лояль иҗтимагый көчләр белән диалог урнаштыру максатын куйган «Иҗтимагый көчләргә ышаныч сәясәтенә» бәйле, 1905 елның язында илдә петицияләр бирү кампаниясе җәелә. Төрле этноконфессиональ, профессиональ җәмгыятьләр, сословие корпорацияләре вәкилләре Министрлар комитетына үзләренең үтенечләре һәм халык-дәүләт хәлен-яшәешен яхшыртуга юнәлтелгән тәкъдимнәре белән мөрәҗәгать итә башлыйлар. Идел һәм Урал буе мөселманнары исеменнән 500ләп үтенеч җибәрелә, аларда диндәшләрнең саны «күпмиллионлы» дип күрсәтелә. Әмма тагын да төгәлрәк мәгълүматлар да файдаланыла. Әйтик, Казан шәһәре татарлары исеменнән 1905 елның июнендә язылып, граф Игнатьев рәислегендәге Дин эшләре буенча киңәшмәгә бирелгән, империянең сәүдә оешмаларында хезмәткәрләрнең ялын оештыруга кагылышлы үтенечтә Россиянең 15 миллионлы мөселман халкы телгә алына *(Россия дәүләт тарих архивы (РДТА), 821 нче фонд, 10 нчы тасвирлама, 15 нче эш, 7 нче бит)*.

Үзләренең үтенечләренә сәяси төсмер бирү өчен Европа белемле иҗтимагый эшлеклеләр, әйтик, Оренбург мөфтие М.Солтанов илдә 20 миллион мөселман яши дип яза. Граф Игнатьев рәислегендәге Дин эшләре буенча Махсус киңәшмә әгъзасы В.П. Череванский шул петицияләрне анализлаган язмасында, әлеге цифрга карата канәгатьсезлек белдереп, «чиктән чыгу» буларак бәяли *(РДТА, 821 нче фонд, 10 нчы тасвирлама,23 нче эш,47 нче бит)*.

1905 елны «Автономия, яки Идарәи мохтарият» дигән теоретик хезмәтендә Габдерәшит Ибраһимов 25 млн. мөселманны телгә ала *(Ибраһимов Г. Автономия яки идарәи мохтарият // Габдерәшит Ибраһим: фәнни-биографик җыентык / төс. М.Госманов, Ф.Галимуллин. Казан: Җыен, 2011.94 б.)*, 1909 елгы тагын бер язмасында 20 миллион мөселман-илдәшләрен искә төшерә *(Ибраһимов Г. Стремление татар к независимости // Габдерәшит Ибраһим: фәнни-биографик җыентык / төс. М.Госманов, Ф.Галимуллин. Казан: Җыен, 2011. 166 б.)*.

1897 елгы җанисәп материалларын күздә тотып, Бөтенроссия мөселман берлеге уставында(1906 ел) мөселманнар яшәгән Россия губерна-өлкәләре 16 районга бүленә, аларның үзәкләре ныклы этноконфессиональ мәхәлләләре булган эре шәһәрләрдә билгеләнә: 1) Кавказ ягында – Бакуда, 2) Кырымда – Акмәчеттә (Симферополь),

3) Мәскәү һәм Петербург тирәсендә – Петербургта, 4) Литва ягында – Минскида, 5) Түбән Иделдә – Әстерханда, 6) Югары Иделдә – Казанда, 7) Уфа төбәгендә – Уфада, 8) Оренбург җирләрендә – Оренбургта, 9) Төркестанда – Ташкентта, 10) Себердә – Иркутскида, 11) Дала өлкәләрендә – Уральскида, 11) Омск ягында – Омскида, 12) Семипалатинск өлкәсендә – Семейда, 14) Җидесу өлкәсендә – Верныйда, 15) Акмулла өлкәсендә – Петропавловскида, 16) Каспий артында – Ашхабадта *(Материалы и документы по истории общественно-политического движения среди татар (1905–1917 гг.) / сост. Р.Р. Фахрутдинов.Казань: КГПИ, 1992. С.17).*

Тагын бер кызыклы мисал: III Бөтенроссия мөселман съезды (Түбән Новгород, 1906 елның августы) делегатлары Ирандагы демократик үзгәрешләргә бәйле кабул иткән резолюциядә күрше ислам дәүләтенә үзләрен Россиянең 20 миллионлы мөселман халкы вәкилләре дип ассызыклап мөрәҗәгать итәләр *(Материалы и документы по истории общественно-политического движения среди татар (1905–1917 гг.) / сост. Р.Р. Фахрутдинов. Казань: КГПИ, 1992. С.33).*

Җәмәгать әһелләре 1906 елда эшли башлаган Дәүләт Думасы эшчәнлегендә статистика саннарын ике сыйфатта кулланалар. Беренчесе – сайлау кампанияләре вакытында мөселманнар волость, өяз, губерна җыелышларында вәкилләр сайлаганда, дини бердәмлек принцибын алга куеп эш йөртәләр. Алар сайлаган мөселман депутатлары Дәүләт Думасы трибунасыннан сөйләгәндә, үзләренең Россиядә көн күрүче 20 млн дин кардәшләренең вәкилләре булуларын һәм күтәргән мәсьәләләрнең мөһимлеген күпсанлы мөселман халыкларына кагылышлы икәнен даими ассызыклыйлар *(Мусульманские депутаты Государственной Думы России. 1906–1917 гг. Сборник документов и материалов / сост. Л.А. Ямаева. Уфа, 1998. С.28, 29 һ.б.).*

1897 елгы җанисәптән соң вакыт узган саен, халыкның артуын исәпкә алып, татар җәмәгать әһелләре үзләренең язмаларында мөселманнарның санын да арттыра бара. Моның классик мисалы буларак, Садри Максудиның эчке Россиядә һәм Себердә яшәүче,ягъни Мәхкәмәи шәргыя округына кергән 10 миллион (!) мөселманнар исеменнән Париж тынычлык конференциясенә (1919-1920) мөрәҗәгатен күрсәтергә була. Идел буе татарлары арасыннан беренче профессиональ сәясәтче, «түгәрәкләп» Россиядә 30 млн. мөселман: азәрбайҗаннар – 3 млн, төркестанлылар – 10 млн, кыргызлар (казакълар) – 6 млн, кырым татарлары – 1 млн, эчке Россиядә һәм Себердә яшәүче татарлар – 10 млн кеше дип яза *(Меморандум (Национальные требования татар Внутренней России и Сибири) // Айда Адиле. Садри Максуди Арсал. Пер. с тур. М., 1996. С.255).*

Шулай итеп, җанисәпкә бәйле язмаларда без татар халкының төрле дәверләрдә әлеге чарага мөнәсәбәте, җанисәп мәгълүматларының милләтебезнең иҗтимагый-сәяси, икътисади, мәдәни тормышын ничек күз алдына бастыруы турында сөйләштек. Халык санын алу чылбырының өзелмәве – илдә, билгеле бер төбәктә, шәһәрдә-авылда, хәтта нәсел-гаиләдә барган үзгәрешләрне күрергә дә, бер халыкның тарихи барышын шактый төгәл күзәтеп барырга да мөмкинлек бирә. Халкыбызның ни өчен дөнья буйлап сибелеп яшәве, дөньяга карашы һәм фәлсәфәсе, милли сыйфатлары да җанисәп мәгълүматларында ачык билгеләнә. Соңгы язмада китерелгән мисалларны да күздә тотып, гомуми нәтиҗә ясаганда, халык санын исәпләүләрнең, ахыр чиктә, татарларны берләштерүгә, аларның милли үзаңын үстерүгә, үз хокуклары өчен көрәшү юлларын күрсәтүгә хезмәт итүен дә билгеләү дөрес булыр.

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН,
тарих фәннәре докторы

УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

Зимфира ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА

Без күрәсен кеше күрмәс, диләрме әле? Нәкъ шулай. Безгә очрарга һәм биографиябезгә йогынты ясарга тиешле кешеләр, нинди генә «бакча артларыннан» йөрсәң дә, тиешле вакытында очрый. Яртылаш рус мәктәбенең азсанлы татар сыйныфында татар телен һәм әдәбиятын дәрестән соң калып укыган кыз кайчан да булса шул әсәрләрне язган әдипләр белән бергә эшләр, алар белән сөйләшеп, киңәшләшеп яшәр дип хыяллангандыр, дисезме? Хыялланмадым, әлбәттә, хыялланмадым. Артистларын әйт әле. Алары да буй җитмәслек югарылыкта, сурәтләре экранда һәм радиода гына иде бит. «Үселде инде, үселде», – дигән ди башлап язучы берәү, юка гына брошюра чыгаргач. «Күрелде инде...» – дим мин, язучылар, артистлар, җырчылар белән аралашканнан хәтергә уелган истәлекләрне барлап. Туфан абый җитәкләгән «Сәхнә» журналында җаваплы сәркатип булып эшләгән еллар үзе бер кадерле чор булып истә калган. Шул чаклардан Туфан абый турында истәлекләрнең бер шәлкемен тәкъдим итәм.

Мескен бию карамыйм

Редакциябез Мөштәри урамында чак. Бервакыт Туфан абыйның телефоны шалтырады, теге яктагы тавыш аны ниндидер концертка чакыра, концерт бию белән бәйле иде кебек. «Бармыйм. Егетләрегезнең биюе – кеше көлкесе. Вак-вак атлап, ботларын кысып, котлары чыгып бииләр. Мескенлек! Башта татар ирләренең олпатлыгын, горурлыгын күрсәтә торган бию куегыз, аннан чакырырсыз», – диде Туфан абый.

Ватабыз аны, диген, Асия!

Театр журналы нәниләр басмасыннан бүленеп чыгып, аерым бинада Туфан абый кул астында эшли башлагач, Туфан абый беренче эше итеп, хуҗалыкны кайгыртты. «ТАТМЕДИА» безгә Оконишников йорты ишегалдындагы флигельне шәпләп ремонтлап биргән иде, техника, җиһаз – өр-яңа. Суыткыч, микродулкынлы мич, электр чәйнеге ишеләрне Туфан абый үз акчасына (!) алып куйды. Аларга редакция бюджетында акча каралмый бит инде. Шаккаттык. Эштән иске суыткычны йортына ташыганнарны күргән булса да, үз акчасына эшкә әйбер ташыган җитәкче белән минем беренче очрашуым иде. Туфан абый матур чынаяклар ярата иде, эшкә бик матур «Германский» сервиз алып килеп куйды. Редакциябезнең асылташы Асия апа Юнысова юган чакка туры килгәндә, шул «немец кызларының» төшеп ватыла торган гадәтләре бар иде. Шулай кулдан сикерә-сикерә тегеләр алты пардан ике парга калгач, Туфан абый махсус бәрсәң дә, ватылмый торган бокаллар алып кайтты.

«Болар ватылмаячак инде!» – дидем мин, редакция белән җыелышып чәй эчкәндә.

«Ватабыз аны, диген, Асия!» – диде Туфан абый.

Туфан әтәче

2011 елның җәендә бугай, Туфан абый Нагорныйдагы бакчасында тавыклар тотарга уйлады. Аларга үз куллары белән чын кетәклек ясады. «Ничә тавык алырга икән?» – дип, безнең белән киңәшкәндәй дә итте әле. Әтәче гаярь әтәч булса, тавыкларның тугыздан да ким булмаска тиешлеген ишеткәнем бар иде. «Тугызны алыгыз, Туфан абый!» – дигән булдым. «Аның кадәр тавык белән нишлим, алты җитәр», – дип, Туфан абый үзенчә эшләде.

Ярый, хуш. Безгә тавыкларның, кайтып кетәклеккә урнашуы турында хәбәр килеп җитте. Бик тә горур кыяфәттәге Туфан абый алып килде аны. Ләкин... 3 көн уздымы-юкмы, Туфан абый эшкә сөмсере коелып килде. Әтәч дигәннәре бөтенләй дә кычкырмый икән. Их, диештек, проблеманы хәл итәргә, хуҗаларын гына түгел, күршетирәдәге кәттә йортларда яшәүчеләрне дә таң тишегеннән кычкырып уята алырлык әтәч табарга кирәк бит хәзер! Саткан фатирымны, нәкъ тавык сату белән шөгыльләнә торган кешеләр улларына дип алган иде. «Быргыдан да катырак кычкыра торган әтәч табып китерегез», – дип, шуларга шалтыраттым. Ике көн, өч көн узды – күренмәделәр. Теге җан көеге әтәч тә кычкырырга уйламады, телен яшерә торган булып чыкты. Инде Туфан абыйның бу хәсрәтен белгән, терәлеп торган кәттә йортта яшәүче бер күршесе дә беркөнне борчылып: «Туфан Абдуллович, что, так и не кукарекает?», – дип сорагач, Туфан абый гарьләнеп, кычкыра торган әтәчне каяндыр үзе табып алып кайтты.

Яңа әтәч соклангыч матур, аякларына кадәр аллы-гөлле йон каплаган, дип мактанды Туфан абый. Бенефисын ясасаң – купшы киеме өстендә. Теге кычкырмый торганын Туфан абыйны 15 ел йөртүче шофёры Ришат авылына җибәрделәр. Авылда аннан башка да әтәчләр җитәрлек, бу кычкырмый дип, көтү чыкмый калмаячак иде.Теге гаярь әтәч кайтып, озак та узмады, бер-ике тавык таушалып, җан тәслим кылдылар, кәнишне. Яңа тавыклар аласы булды. Ләкин Туфан абый, барыбер, минем «тугыз тавык кирәк» тәкъдимен кабул итмәде. «Хатын-кыз сүзе белән йөрүчеләр – без түгел» дигәндер инде.

Берзаман безгә чибәр әтәчнең сөекле тавыклары салган эреле-ваклы йомыркалар килә башлады. Офис-менеджерыбыз Рәйсә Борһаниева ул йомыркаларны пешереп, юмарт итеп өеп куя иде.

Мәрәтхуҗа баланы

2011 елның көзендә Туфан абыйның туган авылы Мәрәтхуҗага кайттык. Туфан абый йортларын кышка әзерләп калдыра, без Рәйсә Борһаниева белән бакчасында балан җыябыз. Туфан абыйның өч йорттан торган утарында «уртанчы» зурлыктагы йорт эче кашагалар, чиккән сөлгеләр, кульяулыклар белән бизәлгән. «Яз көне кайтып, бу өйне юарга кирәк булыр», – диде Туфан абый. Авыл җиренең матур гадәте бит ул яз көне өй юу. «Туфан абый, әйдәгез кашага-пәрдәләрне хәзер алып кайтып юыйк, яз көне килеп, өй югач элеп үк китәрбез», – дидем мин. Туфан абый каршы килергә дип авызын ачканда, мин кашагаларны җыя башлаган идем инде. Рәйсә дә миннән калышмады.

Казанга кайтканда, тәрәзәдән Идел, Чулман җиленә иркәләнеп үскән үләннәр, чәчәкләр, җиләкләр йорты – киң болыннарга карап: «Киләчәктә бу җирләрдә ничек дип аталган кытай авыллары булыр икән?» – диде Туфан абый... Калган юлны сөйләшмәдек. Без Туфан абый башлаган сөйләшүгә катнашып китәбез, аннан узып сөйләшми, сәбәпсез сүз башламый идек. Туфан абый белән туктамый сәгатьләр буе сөйләшә алучы Асия апа Юнисова нindидер сәбәп белән балан җыярга кайтмый калган иде...

Ictimağı-mədəni tormışıbızdan
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

ДӘҮЛӘТ ДУМАСЫНА ДЕПУТАТЛАР САЙЛАНДЫ

VIII чакырылыш Дәүләт Думасына депутатлар сайланды. Татарстанда тавыш бирү 2810 сайлау участогында өч көн барды. Партия исемлеге буенча тугыз (сигезе – «Бердәм Россия»дән, берәү – КПРФтан), бер мандатлы округлардан алты депутат (барысы да «Бердәм Россия» партиясе әгъзалары) сайланды.

МИЛЛӘТ ҖЫЕНЫ

Бөтенроссия халык санын алу алдыннан Казанда, Г.Камал театрында «Милләт җыены» узды. Җыенда Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм чыгыш ясады. Ул әлеге чарага килгән татарларга рәхмәт әйтте, аларның халык санын алуда ярдәм, таяныч булуын искәртте һәм бер төркем милләттәшләребезгә дәүләт бүләкләрен тапшырды. Җыенда ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, юрист Гөлнара Сергеева, «Татарларның һәм башкортларның Казакъстан конгрессы» иҗтимагый берләшмәсе идарәсе рәисе урынбасары Гриф Хәйруллин, Бөтендөнья Татар конгрессының Башкортстандагы вәкиле Альфред Дәүләтшин, Приморье краеның Уссурийск шәһәре имам-хатыйбы Айдар хәзрәт Гарифуллин, Себер татар-мәдәни үзәге җитәкчесе Гөлсинә Ташкеева, Самара шәһәренең аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган «Яктылык» мәктәбе директоры Радик Газизов, җырчы Фирдүс Тямаев һ.б. чыгыш ясады. «Милләт җыены»н ТР Премьер-министр урынбасары, Бөтендөнья Татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразиев алып барды.

МӨСЕЛМАН КИНОФЕСТИВАЛЕ

Татарстан башкаласында XVII Халыкара мөселман кинофестивале булып узды. Кинофорум дәвамында төрле мәйданчыкларда 113 фильм күрсәтелде. Фестивальне йомгаклау тантанасы «Пирамида» күңел ачу үзәгендә үткәрелде. Казакъ режиссёры Фәрхәт Шәриповның «18 килогерц» фильмы Гран-пригага ия булды. «Милли конкурс» номинациясендә төп премия «Прохлада глаз» фильмы өчен режиссёр Айнур Зиннәтовка һәм төп рольне башкарган Эдуард Айткуловка тапшырылды. «Будьте же счастливы» (Наталья Топал) – иң яхшы документаль, «Айрат значит удивительный» (Галиябану Бәхтиярова) – иң яхшы кыска метражлы, «В лес за осиной» (Елена Ермолина) балалар өчен иң яхшы фильмнар буларак бәяләнде. Җиңүчеләр арасында «Җиде утрау арасында» документаль фильмы белән Алмаз Нургалиев та бар. Кинофестивальдә тәкъдим ителгән фильмнардан «Исәнмесез» (режиссёр Илдар Ягъфәров, сценарий авторы Мансур Гыйләҗев) – ТР Президенты, «Берүзе» (режиссёр Булат Минкин) – Казан шәһәре мэры, «Страх» (Болгария режиссёры Ивайло Христов) Матбугат призларына лаек булдылар.

КЫРЫМГА СӘФӘР

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Шамил Садыйков җитәкчелегендәге республиканың әйдәп баручы матбугат чаралары баш мөхәррирләре делегациясе Кырымда булып кайтты. Сәфәр вакытында «ТАТМЕДИА» АҖ белән Кырым Республикасы Эчке сәясәт, мәгълүмат һәм элемтә министрлыгы арасында үзара хезмәттәшлек турында меморандум имзаланды. Татарстаннан килгән кунаклар Исмәгыйль Гаспринский исемендәге һәм Симферопольдәге кырымтатар китапханәләрендә (аларга китаплар бүләк иттеләр), уку йортларында, истәлекле урыннарда, музейларда булдылар, матбугат хезмәткәрләре белән очраштылар.

ОЧРАШУ

К.Тинчурин театрында драматурглар Ркаил Зәйдулла һәм Мансур Гыйләҗев белән очрашу булды. Кунаклар пьесаларының язылу тарихы, тарихи шәхесләрнең театр сәхнәсендә гәүдәләнеше турында сөйләделәр. К.Тинчурин исемендәге X Халыкара заман милли драматургиясе фестивале кысаларында уздырылган әлеге чараны театр белгече Нияз Игъламов алып барды.

ИБРАҺИМ САЛАХОВНЫ ИСКӘ АЛУ

Казакъстанның Күкчәтау шәһәрендә язучы, ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган

мәдәният хезмәткәре Ибраһим Салаховны искә алдылар. Чарада өлкә һәм шәһәр җәмәгатьчелеге, Казакъстан халыклары ассамблеясе, ветераннар советы вәкилләре, әдипнең иҗатын яратучылар, туганнары, якыннары катнашты. Искә алу кичәсенең ахырында Ибраһим Низам улы рухына дога багышланды.

КИТАП ТӘКЪДИМ ИТҮ

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында башкорт язучысы Айгиз Баймөхәммәтовның «Нахак» китабы тәкъдим ителде. Бу авторның татар телендә нәшер ителгән өченче китабы. Ул «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте ярдәме белән «Казан утлары» журналы китапханәсе» сериясендә басылып чыкты. Әлеге чарада «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Шамил Садыйков (ул А.Баймөхәммәтовка китапның беренче нөсхәсен бүләк итте), Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин, Татарстанның халык шагыйре, дәүләт эшлеклесе Разил Вәлиев, язучылар Газинур Морат, Хәбир Ибраһим, Рәкит Аллабирде, Нәҗибә Сафина, Казандагы Халыклар дуслыгы йортының Татарстан башкортлары җәмгыяте җитәкчесе Тимур Кустабаев, Мөслимнән татар китапларын сатучы эшмәкәр Рамилә Дәүләтова һ.б. чыгыш ясады. Кичәне язучы, «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире Рафис Корбан алып барды.

ӘДӘБИ КОНКУРС

Татарстан Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе тәкъдиме белән игълан ителгән әдәби конкурска 1459 эш килде. Бәйге нигезләмәсе шартларында күрсәтелгәнчә, 1 сентябрьдә романнан башка жанрларда язылган әсәрләрне кабул итү туктатылды. Конкурсны оештыруда җаваплы «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллинның сүзләренә караганда, романнарны (бүгенге көнгә бу жанрда 5 әсәр кабул ителгән) 1 декабрьгә кадәр җибәрергә мөмкин. Бәйгегә утызлап поэма, сиксәнләп хикәя, кырык повесть килгән. Иң күбе – шигырьләр. Конкурс ябык. Жюри әгъзалары тәхәллүс куелган әсәрләрне генә укыячак. Киләчәктә җиңүче әсәрләрне журналларда бастырып чыгару һәм китап итеп нәшер итү күздә тотыла.

ЕНИКИ ӘСӘРЛӘРЕ ТӨРЕК ТЕЛЕНДӘ

Төркиядә татар әдәбияты классигы Әмирхан Еникинең хикәяләре төрек телендә басылып чыкты. «Бер генә сәгатькә» дип аталган китапка язучының сугыш чорына караган хикәяләре тупланган. Аны Бартын университеты галиме Альп Әрән Демиркая тәрҗемә иткән.

«ӨЧ АРШЫН ҖИР» АМЕРИКАДА НӘШЕР ИТЕЛДЕ

Татарстан Язучылар берлеге тәрҗемә үзәгенең эшчәнлеге кысаларында Аяз Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» повесте Айшәнур һәм Кадыйр Чәкичләр тәрҗемәсендә АКШның «Амазон» нәшриятында дөнья күрде.

ӘДӘБИ САБАНТУЙНЫҢ ҖИҢҮЧЕСЕ

Арчада узган Әдәби сабантуйда Әлмәт шәһәреннән Сиринә Мифтахова беренче урынны алды. Җиңүчене Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла игълан итте.

ТУЙМАЗЫДА ОЧРАШУ

Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат итүче Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары, шагыйрь Мансур Сафин белән филология фәннәре докторы, профессор Әнвәр Шәрипов Башкортстанның Туймазы шәһәрендә каһарман-шагыйрь Хәйретдин Мөҗәй исемендәге «Илһам» әдәби-иҗат берләшмәсе утырышында катнаштылар һәм чыгыш ясадылар. Алар Татарстандагы әдәби тормыш турында сөйләделәр, иҗат планнары белән уртаклаштылар.

2021 елның 23 сентябрендә 92 нче яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, А.Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты **Мәрзия Низам кызы Фәйзуллина** вафат булды.

Мәрхүмәнең җәсәде Яңа Бистәдәге татар зиратында җирләнде.

2021 елның 24 сентябрендә 79 нчы яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Казакъстанда яшәп иҗат иткән шагыйрь **Равил Якуп улы Гозәиров** вафат булды.

Сәхифәне **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

В ЭТОМ НОМЕРЕ:

«Проза и поэзия»: роман Р.РАХМАН «Татарка», рассказ В.НУРИЕВА «Мияу из Казани»; стихи Б.ИБРАГИМА, Г.МУХАМЕТШИНА, Р.ЗАМАЛА.
«Новые имена»: повесть И.БИЛАЛОВА «Гора Мадины».
«К 100-летию журнала «Казан утлары»: статья Р.ХАРИСА.
«Казан утлары» – в моей судьбе»: статья Ф.САФИНА.
«Литературный конкурс «Ах, милей родной народ!»: рассказ С.САУБАНОВОЙ «Кнут отца».
«Юбилеи»: статья В.ИМАМОВА, посвящённая 75-летию М.Галеева; фотоархив М.ГАЛЕЕВА; статья Г.ГАЙНУЛЛИНОЙ, посвящённая 65-летию Н.Гиматдиновой.
«К юбилею»: фотоархив.
«Бриллианты эпохи»: письма Р.Сибата читает Г.САФИУЛЛИНА.
«Литература родственных народов»: стихи А. ГОШАЛЫ в переводе Р.САЛАХА.
«Бесценные голоса»: статья к 95-летию С.Сулеймановой и 75 -летию М.Аглямова Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.
«Перепись населения - 2021»: статья И.ЗАГИДУЛЛИНА.
«Страница юмора»: подготовила З.ГИЛЬМУТДИНОВА
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Александровский пассаж. Вид из Чёрного озера (г.Казань); фото И.АБРАМОВОЙ.

IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: novel by R.RAKHMAN «Tatar», story V.NURIEV «Miyau from Kazan»; poems by B.IBRAHIM, G MUKHAMETSHIN, R.ZAMAL.
«New Names»: story by I.Bilalov «The Mountain of Madina».
«To the 100th anniversary of the magazine «Kazan Utlary»: an article by R.HARIS.
«Kazan Utlary» is in my life»: article by F.SAFIN.
«Literary contest» Ah, dear native people!»: story by S.SAUBANOVA «Father's whip».
«Jubilees»: article by V.IMAMOV dedicated to the 75th anniversary of M.Galiev; photo archive of M.GALIEV; article by G.GAINULLINA dedicated to the 65th anniversary of N.Gimatdinova.
«Meeting the anniversary»: photo archive.
«Diamonds of the era»: G. SAFIULLINA reads letters.
«Literature of related peoples»: poems by A.Goshala translated by R.SALAH.
«Priceless voices»: article dedicated to the 95th anniversary of S. Suleymanova and the 75th anniversary of M.Aglyamov. The column is led by N.AKMAL.
«Population Census-2021»: article by I.ZAGIDULLIN.
«Page of humor»: prepared by Z.GILMUTDINOVA.
From the photo archive of the magazine.
Diary of social and cultural life.
On our covers: Alexander Passage. View from the Black Lake (Kazan); photo by I.ABRAMOVA.

Тышлыктагы сурәтләр

Тышлыкның беренче битендә: Казандагы Александр пассажы.
Черек күлдән күренеш. *И.Абрамова фотосы.*